# казан утлары

2

ФЕВРАЛЬ-1972

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**2**

ФЕВРАЛЬ
1972

## Бу санда:

РОМАН, ПОВЕСТЬ, ХИКӘЯ, ШИГЫРЬ

**М. ӘМИР. Балыкчы ялганнары.** Повесть . . . . 3
**Р. ГАТАУЛЛИН. Утызынчы яз.** Шигырьләр . . . 62
**М. МӘҺДИЕВ. Фронтовиклар.** Роман. . . . . 68
**Г. РӘХИМ. Гомер чылтәре.** Шигырьләр . . . . . 107
**Ә. ГАДЕЛ. Ил иминлеге.** Шигырьләр . . . . . . 109
**М. ЗАРИПОВ. Пани Сирена.** Хикәя . . . . . . . 110
**Р. ЗАКИРОВ. Ышаныч.** Шигырьләр . . . . . . . 120
**Б. СӨЛӘЙМАНОВ. Ак каурыйлар.** Шигырьләр . 123

ӘДӘБИ МИРАС

**Л. ИХСАНОВА. Җырланмый калган җыр** . . . . 124
**Ш. МӨДӘРРИС. Без — синеке, Партия, без — синең белән.** Публицистика. **Полк намусы.** Трагедиядән өзек. **Блокноттан.** Шигырьләр. **Фронт юлларында. Тагын Берлинда.** Сугышчан хатирәләр. **Язучының хатлары** . . . . . . . . 125

КамАЗдан ОЧЕРКЛАР

**Р. ВӘЛИЕВ. Каурыйлар чыныкканда** . . . . . . . 148

ПУБЛИЦИСТИКА

**М. МӘХМҮТОВ. Еракдагы якын Чили** . . . . . . 156

СССР ТӨЗЕЛҮГӘ 50 ЕЛ

**И. ИВАНОВ. Рухи туганнар** . . . . . . . . . . 163

МӘДӘНИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**Ф. ГАЗИЗУЛЛИН. Г. Фәезхановның социаль-экономик карашлары** . . . . . . . . . . . . . 170

КИТАП КҮЗӘТҮ

**М. ӘМИР. Яңа аваз** . . . . . . . . . . . . . . 176
**Җ. САФИУЛЛИН. Уңышлы эзләнү** . . . . . . . 180

ЯҢА КИТАПЛАР

**М. СИРАҖИ. Эшчән куллар** . . . . . . . . . . 183
**Х. САРЬЯН. Дала иртәсе** . . . . . . . . . . . 183

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**М. ӘПСӘЛӘМОВ. Ленин гвардиясе солдаты** . . 185

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары** . . . . . . . 188

КПССның
ТАТАРСТАН
өлкә
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

Хатлгр өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*
Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар. Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.

**Баш редактор: Гариф Ахунов.**

**Редколлегия: Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рафыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

---

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева.*

---

Производствога бирелде 15/XI-1971 ел. Басарга кул куелды 11/I-1972 ел. ПФ 04003. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 86946 экз. Заказ И-839. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1972 ел.

Мирсәй Әмир

# БАЛЫКЧЫ ЯЛГАННАРЫ

ШАЯН ПОВЕСТЬ[1]

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

### Әйбәт күршеләр



Әйе, иртәгә балыкка чыгасы бар. Чыкканда да шаярып кына түгел, бик чынлап. Балык тотмый кайтырга һич ярамый иртәгә. Кунаклар киләсе. Эссе җәй көннәрендә Казан базарыннан биш бәягә алып, дачага ит ташыйсы килми, әлбәттә, бәрәңгесен күтәреп килгәч тә житәр. Димәк, төп ышаныч тотыласы балыкта. Минем генә түгел, Тажиның да хәле шундый. Тик ул моны үзе башкачарак аңлата. Оныкдигән була. Янәсе, ул Казаннан ит күтәреп килергә дә авырсынмас иде, тик менә оныгы балык дип үлеп бара, имеш. Оныкдигәне песи хәтле бер малай шунда. Балык ярату мәсьәләсендә песидән дә уздыра, ди. Әле ул малайның әнисе дә бар. Анысы да кыздырган корбан балыгы өчен җанын бирергә әзер, ди. Җәйге ял вакытларында Идел һавасы сулап, Идел балыгы ашап, ашап бетерә алмаганын тозлап алып китәр өчен әллә кайдан — Мәскәү аръягыннан этисе дачасына кайта.

Дача димәктән... Тажиның да, минем дә дача дигәнебез, мәгълүм булганча, соңгы елларда барлык шәһәр тирәләрен басып киткән гади яшелчә-җимеш бакчасыннан гыйбарәт.

Бу мәсьәләдә без аеруча бәхетле булып чыктык: күп замандашларыбызга караганда алданрак урынның әйбәтен эләктереп калдык. Поезддан төшкәч, ерак та түгел, төннәрен паровоз тавышларына куркып уянырлык дәрәҗәдә үк якын да түгел. Аннан да әһәмиятлерәге — нәкъ Идел култыгында. Көймәләребез капка төбендә генә тора. Шулар өстенә тагын күршеләребез менә дигән. Берсе әнә шул Тажи дус... Ләкин ул минем иң якын күршем түгел әле. Аның белән ике арада, ягъни бер

[1] Дәвамы. Башы 1 санда.

ягы белән миңа, икенче ягы белән Тажига терәлеп торган күршебез Мәхмүт бар.

«Әчем пошса, чыгам тышка, карыйм сайраган кошка»... Ә менә минем өчен Мәхмүт күрше булганда сайраган кошың бер якта торсын. Әчең пошса, Мәхмүт янына гына бар. Бер минут эчендә бөтен кайгыхәсрәтеңне оныттырыр. Шундый оптимист кеше!

— Нихәл, бүген ничек йокладың? — дип сора син аңардан, начар йоклаган булса да, сер бирмәс. Кайберәүләр кебек «төненә жиде уянам» дип зарланмас, «шәп! — дияр.— Бер ятуда жидешәр тапкыр йоклыйм!» дип жавап бирер. Бервакыт шулай, бакчаларыбызга нигез салган елны ук инде, безгә кайдандыр, Арча ягыннан бугай, яшь алма үсентеләре алып кайтып бирделәр. Утыртып чыктык. Икенче көнне иртән торып килсәк, Мәхмүтнең алмагачларын берсен дә калдырмый йолкып алып киткәннәр. Без аның кайгысын бүлешергә уйлыйбыз. Ул шат:

— Ярый әле, тамыры ныгымас борын, кечкенә чакларында алганнар,— ди.— Алма бирә башлагач урласалар, кызганыч булыр иде. Аның кайгырмавын күреп, безнең дә күңелләр күтәрелеп китте.

Бер язны Идел бик каты ташып, бакчаларыбыз су эчендә калды. Өйләребезнең янына да бара алмадык. Бер заман ташулар кайтып, юллар ачыла төшкәч, килсәк, ни күрик: котырган ташкын Мәхмүтнең бөтенләй өен үк жимереп төшергән. Күршебезнең зур кайгысын уртаклашырга дип янына барсак, Мәхмүтебез шырык-шырык көлә. Шомлана калдым. Тажи белән бер-беребезгә карашып алдык: нишләгән бу мескен? Бу нинди көлү?.. Тукта әле, Мәхмүт, дибез, ничек син болай...

Күрәм, күршебезнең шатлыгы эченә сыймый:

— Шәп булды бит бу! — ди.— Рәхмәт Иделгә! Өемне күчереп салырга иренеп йөри идем, болай булгач, булды. Керештем бу эшкә! — ди. Малае да кайткан чак иде, бер атна эчендә өен коймадан ераккарак күчереп, элеккесенә караганда әйбәтрәк тә итеп салды да куйды. Хәзер инде безнең дә өйләребезне аныкы турысына күчерәсебез килеп йөри дә бит, ләкин нишләптер Идел безгә ярдәм итәргә ашыкмый әле.

Мәхмүттәге оптимистлык бетәсе түгел. Әле менә быел гына (гафу итегез, тагын бер мисал китермичә чыдар хәл юк), әйе, быел гына, хәтта шушы арада гына, искиткеч матур бер көнне иртүк торып тышка чыксак, бөтен бакчабызга ямь биреп, тирә-якка хуш ис бөркеп утырган нәфис чалма чәчәкләребезне жыеп киткәннәр. Чәчәк кырындагы түтәл өстендә ялангач тәпи эзе генә торып калган. Димәк, бала-чага эше. Бик каты кәеф кырылды моңа безнең кызларның да, әниләренең дә, үземнең дә, хәтта малайның да! Яндырып каргыйбыз чәчәк каракларын: киртә аша чыккан чакларында кул-аякларына шырпы кадалгыры, чәчәкләрне исңәгән вакытта борыннарын корт чаккыры...

Шул вакыт күршегә күзем төште. Жиләк түтәлләренә су сибеп йөри. Трусиктан гына. Тукта! Аның чәчәкләре нишләгән? Әллә кайдан күренеп торалар иде бит, безнекеннән күбрәк тә иде. Берсе дә юк. Аклары да, алсулары да. Димәк?.. Хәер, бәлки, алар үзләре жыеп алгандыр?

— Күрше, нихәл?!

— Хәерле иртә,— ди Мәхмүт, бер дә кәефе кырылганга охшамый.

— Безнең пионнарны жыеп чыкканнар бит, әй!

Рәхәтләнеп көлә Мәхмүт.

— Безнекен дә! — ди.

— Аның нәрсәсенә шатланасың, тиле?

— Шатланмыйча! Бик күңелле фал ич бу.

Минем телсез калуымны күреп, ни өчен күңелле икәнен аңлатып бирергә кереште:

— Верандада менә дигән чалбар белән пиджагым эленеп тора. Сараемның ишеге бикләнмәгән, ә анда мотор. Базда май кирәкме, балмы, тамагың ни тели, өсте такта белән генә капланган...

— Шуннан?
— Берсенә дә тимәгәннәр.
— Димәк?
— Димәк, халык культуралашкан. Әйбергә тими, ризыкка тими, өс бөтен, тамак тук. Чәчкә кирәк аңа! Нәфислек! Эстетик культура үскән! Без, каләм әһелләре, гомеребез буена шул турыда хыялланабыз түгелме соң? Куанычлы күренеш түгелмени бу?

Менә сиңа оптимист логикасы! Нәрсә әйтәсең? Чынлап җавап бирергә керешсәң, үзеңнең көлкегә калуың бар. Бәлки, аның шаяруыдыр. Белмәссең, оптимист белән юморист икесе бер шайтан. Шулай да хәлләсен таптым. Адаш исемен ярдәмгә чакырдым:
— Беләсеңме, мин әйтәм, Мөхәммәтша булса, сиңа ничек дип җавап бирер иде?
— Чамалыйм,— ди Мәхмүт.— Ул әйтер иде, базарда чалма чәчәкнең берсен бер сумга саталар,— дияр иде.— Ә сезнеке кебекләрен тәңкә ярымга да тартып алырга торалар,— дияр иде...

Аннан арыгысын үзем ялгап алып киттем.
— Менә шул шул! Димәк, сатар өчен урлаганнар. Кимендә йөз сум табыш итте бүген карак. Төкерә ул синең эстетикаңа...

Тыңлап та тормый мине Мәхмүт, үзенекен сукалый.
— Ә мин синең ул Мөхәммәтшаңа болай дип җавап бирер идем, ди:— Хәләл көче белән тапкан бер сумын бер бөртек чәчәккә бирергә әзер торучылар йөзләп, меңләп булмаса, нишләр иде карак синең пионнарың белән? Халыкта чәчәккә мәхәббәт зур икән диган сүзме бу?
— Шулай да, Мәхмүт, балалар арасында караклык итүчеләр булу шәп түгел.
— Анысына инде, туганкаем, үзебез гаепле.
— Ягъни?
— Әйе, синең белән мин гаепле һәм Сергей Михалков...

Ул арада янибызга Тажи килеп житте. «Исәнме-саумы» юк, әлбәттә. «Хәерле иртә» юк.
— Егетләр,— ди бу житди генә.— Минем пионнарны урлаганнар.

Бу юлы инде Мәхмүткә кушылып мин дә көлеп җибәрдем...

Һии... Мәхмүт турында мондый мисалларны искә төшерә башласа-а-а-ң. Хатыны пар килгән тагы үзенә. Ул аларның бер-берсе өчен өзелеп торулары! Пар сандугач кебек сайрашып яшиләр дип шундыйлар турында әйтә торганнардыр инде. Хәтта бервакыт бу гаилә турында берәр лирик повесть яки сәхнә әсәре язасым килеп тә йөргән иде. Тәнкыйтьчеләрдән курыктым: ышанмаслар, дип уйладым. Тормышта мондый идеаль гаилә булмый, диярләр, чынбарлыкны ялтыратып күрсәткән дип гаепләрләр... Мөхәммәтша турында әйткән дә юк инде. Шул ук Тажи күзеңне ачырмас. Әле монда язган кадәресе өчен дә әләкмәсен дип, әйбәт күршемнең берәр кимчелекле ягына да тукталасым килә. Бар аның да житешсез ягы, бар.

Кимчелеге шул — балык тоту эшенә бармак аша карый. Я кармагы тиешенчә көйләнмәгән була аның, я җебе чуала. Я җим капчыгының рәте булмый. Ә балык дигәнең үзенә күрә түгел, бик көйсез мәхлук: чиртми генә. Тажига чиртә. Миңа да. Мәхмүткә юк. Су төбендә йөзгән балыкка дәшеп, ялынып карый.— Миңа күп кирәкми бит,— ди...— Әнисе белән кызыма бирәү, песи белән үземә бирәү булса, житә,— ди.— Болай барып чыкмагач, кызыктырып карый.
— Менә бит нинди матур, симез чуалчанны, үз авызымнан өзеп, кармакка каптырам...

Юк. Чиртми балык. Мәхмүт аларны алдарга тотына. Бала чагыннан белгән ырымнарын ходка җибәрә: төкереп салдым, сикереп кап, көймә эчендә ялтырап ят. Тфү, тфү! Минем кармагым түгел, Әйшә-Патима

кармагы... Юк, иске ырымнарны хәзерге балыклар аңламый дип, безнең исемнәрне әйтеп карый: минем кармагым түгел, Таҗи кармагы... Минем кармагым түгел... Аптырагач, даннары дөньяга җәелгән замандашларыбызны искә төшерә. Тфү, тфү! Минем кармагым түгел, Эрнест Хемингуэй кармагы... Тфү, тфү! Минем кармагым түгел, Михаил Шолохов кармагы... Ниһаять, сабыры бетә. Эләкмәгән балыкларга ачуланып:

— Ярар, яхшылыкның кадерен белмәсәгез, үзегезгә үпкәләрсез,— ди дә кармакларын җыярга керешә. Үзе шат.— Бик яхшы булды әле, балык чистарту бәласеннән котылдым. Моннан соң, йокы калдырып, килеп йөрисе дә юк.

Ләкин ул болай ансат кына котыла алмый. Шундый йолабыз бар: бәхетле кармак иясе балыксыз күршесе исеменә атап салырга тиеш. Ягъни чираттагы балык аңарга. Беләбез, моның өчен Мәхмүттән рәхмәт ишетү юк. Биргән балыкны алмый ялындыра, алса, яманлап теңкәгә тия. Кечкенә дип, я чирле балыктыр бу дип, ачуыбызны китерә. Барыбер ай-ваена карамыйбыз, хатыны белән кызына да, песие белән үзенә дә җитәрлек балык тотып бирәбез.

Дөрес, аңа да эләккән чаклар булмый түгел. Тик андый вакытларда Мәхмүт ничектер гаепле кеше шикелле сүзсезләнеп кала. Соңгы вакытларда балыкка карата тагы да суына төште.

Таҗи белән без җәйнең ямьле көннәрендә төнге икедән торып балыкка китәбез. Күңелле күршебезне дә кампаниягә аласыбыз килә. Ә ул безне кичтән үк кисәтеп куя: «Зинһар, уятып йөри күрмәгез, йокысызлык белән җәфалана торган гадәтем юк»,— ди. Гарьләндерергә тырышып карыйбыз.

— Аучы азарты юк синдә, йоклаган йөрәк,— дибез.— Балык тотуның тәмен белмисең,— дибез.

— Ул мәсьәләдә башта энә минем малай белән ярышып карагыз,— ди.— Аңардан уздыра алсагыз, атасына бәйләнерсез.

Ә малае!.. Алла сакласын! Ул өйдә булганда безгә почет юк. Таҗи да, мин дә аның мокыт шәкертләре булабыз да калабыз. Дөрес, әтисе кебек сүзчән түгел. Әмма ләкин Сабанеевны яттан белә. Идел өстенә чыгып, балыксыз кайткан чагы юк. Ул барда без дә балыкка аптырамыйбыз. Мәхмүтнең үз гаиләсе турында әйткән дә юк. Азат кайткан айда үзләре, песиләре генә түгел, алмагачларына кадәр балыкка ылкыналар [1].

Безгә дә өлеш чыга. Хәтта үзебез балыкка бармаган көннәрдә дә иртән торуыбызга, дүрт-биш тере балык салынган җәтмә соскычын күтәреп, Мәхмүт килеп җитә. Без алмаска итәбез, уңайсызланабыз. Күршебез ялына башлый:

— Зинһар, кире кайтармагыз, кая куеп бетерик, Азат тагын сигез кило тотып кайткан бит,— ди.— Иренсәгез, үзем чистартып бирәм,— дия башлый.

Кайвакыт чынлап ук чистартканны күтәреп килә, оятсыз. Акчага дисә, бер хәл иде. Бушка бит! Ничек алмыйсың?

Алгач ярап куя тагын. Ләкин андый көннәрдә безнең өчен балыкка баруның кызыгы калмый. Мәсәлән, миңа балыкны ашаудан бигрәк аны тотуы кыйбат. Дөрес, Азат белән бер көймәдә чыгу бик рәхәт. Тик шунысы бар: мин үзем балыкка бару өчен әйбәтрәк көнне яратам. Ә Азат! Җил дип тормый, давыл дип тормый. Яңгыр да юк аның өчен, салкын да... Төн дә юк, көн дә, яз да юк, көз дә...

---

[1] Алмагач балык ашамый дисезме? Ашамас! Мәхмүтләрнең алмагачлары гына түгел, чия, карлыган куаклары, җиләк, яшелчә түтәлләренә кадәр барысы да балык эчәкләре, балык тәңкәләре белән ашланган. Ә балык юган су кая китә дип беләсез? Шуңа котырып үсә аның бакчасы.

Шулай булгач, нигә күп булмасын аларның балыклары? Кайбер көннәрдә аларны балык һөҗүменнән Таҗи белән мин генә дә коткара алмыйбыз. Андый көннәрдә минем сул як күршеләрем ярдәмгә килә. Андрюшиннар. Күршеләрем дим. Чөнки алар шактый зур гаилә. Рәсми яктан бакчаның хуҗасы итеп Толяны йөртәбез. Безнең коллега, искиткеч әйбәт кеше. Әйтик, ямьле якшәмбе көннәрендә безгә кунак килгән чаклар була. Я верандада, я имән күләгәсендә кәефләнеп, ашап-эчеп утырабыз. Ә Толя әллә кайда, үз бакчасында бөтенләй бүтән эш белән мәшгуль, карлыган корткычлары белән көрәшеп йөри. Шул чакта кычкыр син аңа: «Анатолий, эшлә бер яхшылык, янибызга килеп, безнең белән бер генә рюмка күтәреп кит әле!» диген, килә, күтәрә, закускасыннан да баш тартмый. Мактап та куя әле, житмәсә. Шундый тәкәллефсез, шундый үз кешеләрчә әңгәмәгә дә кушылып китә. Хәтта кайвакыт күрше хакына карлыган корткычларын да онытып, мәҗлеснең азагына кадәр утырып кала. Тик Толя үзе күбесенчә өйдә булмый. Командировкаларда йөри, төрле очрашуларда. Фронтташ дуслары күп, әле көнбатыш чикләренә оча, әле Себер төзелешләренә олага, әле көньяк курортларына китеп югала [1]. Ял айлары туры килгәндә Людасы белән бергә китәләр. Анысы да бик әйбәт кеше. Тик ул да, шәһәрдә эшләү сәбәпле, ире белән китмәгән чакларында да бакчага ял көннәрендә генә килә ала. Шул арадада без аның әйбәтлеген күреп калырга өлгерәбез. Күзе бар кешегә күрмәү мөмкин түгел Люданың әйбәтлеген. Өстенә соңгы модада тегелгән мини лифчиге белән мини трусигын гына киеп ала да, алтын сары ялларын туздырып, зифа буйларымны төрле хәлендә күрегез дигәндәй, әле алмагачларына үрелеп, әле җир җиләге өзәргә бөгелеп, Таҗи белән Мәхмүт ише олырак яшьтәге ирләрнең иң матур хисләрен уятып йөри (үзем турында әйтмим: тыйнаклык саклыйм).

Болары төп хуҗа исәпләнсәләр дә, әйткәнемчә, бакчада һәрвакыт була алмыйлар. Малайлары бар. Анысы да мәктәптә укулар бетмичә күзгә күренми. Каникул вакытында да әти-әниләренә ияреп тегендәмонда китәргә бик ярата. (Әйбәт малай. Хөр күңелле, кечкенә булуына карамастан, җавапка бик тапкыр дип мактарга телем кычытып торса да, ашыкмыйм әле: башы яшь, үскәч кем булыр бит?) Ә менә Анатолийның әтисе белән әнисе бар — болары инде тамыр җәйгән гөлләр кебек. Май башларында ук күчеп киләләр дә көзгә кадәр шунда. Кыраулы төннәр дә куып җибәрә алмый аларны бакчадан, атналарга сузылган салкын яңгырлар да, өй түбәләрен куптарып ата торган давыллар да.

Без үзебез андый көннәрдә шәһәргә кайтып яңа фильм карауны яки гастрольгә килгән спектакльләргә баруны артыграк күрәбез. Шуңа күрә бу фидакарь күршеләребез белән гел диярлек кояшлы көннәрдә генә очрашабыз. Үзләре дә безне һәрвакыт кояш кебек ачык чырай белән каршы алалар. Берсеннән-берсе әйбәт кешеләр. Петр Петрович, инде җиденче унны тутырса да, һаман көлеп кенә тора. Кайчан карама син аның түгәрәк йөзенә, нәрсә дип кенә сүз кушма — беренче җавабы елмаю булыр. Тагы ни кирәк? Артыгын сүз белән әйтеп торуның кирәге дә калмый. Һәм әйтми дә ул аны. Ә менә аның карчыгы! Вера Ивановна! Аның яхшылыкларын сөйләп кенә бетерә торган түгел. Ул инде, сиңа елмаеп кына калмый, ул сине мактап рәхәтләндерә. Әллә кайдан ерактан күреп исәнләшә ул синең белән. Якты чыраен тоеп, ягымлы авазын ишетеп, ихтыярсыз аңа таба тартыласың. Ул да синең каршыңа килә.

— Ой, кузем тимәсен, бигрәк матурланып, яшәреп киткәнсез,— дип башлап җибәрә. Исәнлек-саулыгың турында белешкәч, хатыныңның

[1] Һәм бик акыллы эшли. Чөнки, өйдә торса, аның үзен кунак баса. Өеңә килгән кунакны сыйлауга караганда, үзең кунакка барып сыйлануга ни җитә?

хәлен сорашуга кучә, аны мактый, берәмләп-берәмләп балалар турында сорый — аларны мактый, аннары безгә килеп йөри торган чыбык очы агай-энеләребезне, дус-ишләребезне исенә төшерә, аларны мактый. Телгә алыр кешеләр беткәч, бакчабыздагы җиләк-җимеш агачларына мәдхия укырга керешә. Чәчәк түтәлләребезгә сокланып туя алмый. Әле чәчәк атарга өлгермәгән гөлләрнең сабакларын, яфракларын мактый. Хәтта безнең бакчада үскән чүп үләннәр дә гүзәл булып күренә аңа.— Яшеллек күп сезнең бакчада,— дип мактый ул аларны.— Агач төпләре сөрелеп, тирес белән каплап куелган бакчаның ни яме бар аның! — ди.— Боларга, ичмасам, караган саен күзең рәхәтләнә. Дөресен әйтим, бу сүзләре аеруча күңелемә хуш килә. Ни өчен дисәң, чүп үләннәре — минем авырткан җирем. Үземнең, бәлки, артык исем дә китмәс иде. Бакча идарәсе кешеләре яки агроном-мазар күрсә, бер дә яратмыйлар. Нихәл итәсең, участок сайлаган вакытта үзем өйдә юк идем шул. Хатын шундый чүп үләнле җир сайлаган.

Ул арада Вера Ивановна безнең өйдән кемнеңдер юынырга чыгып барганын күрә дә, күзе юынгычка төшә.

— Әмма уңган да кеше инде үзегез,— ди миңа.— Умывальнигыгызны тагы нинди матур итеп, яңартып куйгансыз, карап туя торган түгел...

Мактарлык та шул. Ул юынгыч моннан алты ел элек үк тишелеп ага башлаган иде. Шуннан бирле яз саен мин аның тишекләрен универсаль замаска белән сылап, эченнән дә, тышыннан да марля ябыштырып, көймәдән калган буяу белән яңартып куям. Бер елны яшелгә буйыйм, бер елны зәңгәргә. Акка буяганым да бар, сарыга да. Ә быел ак кургаш суригы таптым. Әллә кайдан балкып, җете кызыллыгы белән чыннан да күзнең явын алып тора.

— Ә аның баганасы! Баганасы! — дип дәвам итә Вера Ивановна.— Юк, багана гына түгел бу, чын сәнгать әсәре! Бары сезнең генә кулдан килә торган эш бу. Аны иҗат итәргә сезнең талантыгызның гына көче җитә...

Әйе, анысы да игътибар итмәслек түгел. Урынсыз үскән яшь имәнне тамырында килеш шундый хәлгә китердем бит. Кирәк кадәр ботакларын калдырып, ябалдашын кисеп төшердем дә кабыгын суеп алдым. Болан мөгезе кебек тармакланып утыра. Кәүсәсенә умывальник асылган. Сабын, щетка кебек әсбаплар өчен шүрлеге дә үзеннән үсеп чыккан. Сөлге эләргә генә түгел, майкага да, эшләпәгә дә, сәгатькә дә, транзисторга да — һәркайсына бер тармак. Күзлек эләргә дә урын бар. Полиэтилен капчык яки кефир шешәсе элеп киптерергә бик әйбәт. Теләсәң, садогыңны, җим капчыкларыңны, трусик-плавки кебекләреңне дә шунда элеп киптер...

Вера Ивановнаның ул баганаңы беренче мактавы түгел инде. Шулай да мактаган саен җанга рәхәт. Күңелгә мондый уйлар килә: эх, әгәр дә бу Вера Ивановна әдәби тәнкыйтьче булса! дим. Шундый тәнкыйтьчеләр булмау аркасында күпме әсәрләребезнең һәр гади кеше күзенә күренеп бетми торган нихәтле яхшы яклары ачылмый кала?..

Юк. Вера Ивановна берәүне дә юри мактамый. Ялагайлануы да түгел. Ялагайланырга сәбәбе дә юк. Бу аның кеше яратуы. Кешегә карата булган мәхәббәт тойгыларының күңеленә сыймыйча ташып тышка чыгуы. Шундый кеше турында ничек телең барып начар сүз әйтмәк кирәк?..

Әнә шундый әйбәт кешеләр алар Андрюшиннар. Бар да бер төсле түгел, һәркайсы үзенчә әйбәт. Тик бөтенесе өчен уртак бер сыйфатлары бар: һәммәсе балык ярата. Шулпалап пешерелгән балыкмы ул, табада кыздырылганмы яки кояшта какланганмы, төтен белән ысланганмы — алар өчен бары да яхшы. Тозлаган балык алар өчен һәрвакыт деликатес. Мәсәлән, мин үзем дә әйбәт какланган балыкны бик яратам. Мәгәр

күңелем булганчы бер ашасам, яңадан берничә ай буе күрмәсәм дә исем китми. Мәхмүт та шундый. (Яшьрәк чакта хәтта икебезгә бер балык башы белән исерешә торган идек.) Ә Андрюшиннар — олысы булсын, кечесе булсын — тозлы балыкны көненә биш тапкыр ашасалар да туймыйлар, ягъни бизә белмиләр дигәнем. Хәтта килә торган кунаклары да бу мәсьәләдә үзләре кебек.

Шуңа күрә алар балыктан бервакытта да баш тартмыйлар. Тик акча тәкъдим итеп кенә юмарт күршемнең теңкәсенә тияләр. Мәхмүт акча алырга риза булмыйча, тарткалаша-тарткалаша да, аптырагач, ярар алайса, соңыннан бирерсез дип, китергән күчтәнәчен калдырып китә. Ләкин Андрюшиннар өчен бу очраклы бер эпизод кына. Алар үзләре дә тоталар. Тик алар турында «балыкка баралар» дип әйтү дөрес булмас иде. Алар балыкка бармый, балык аларга килә. Ягъни суга төрле тәмле-томлы (мәсәлән, күгәргән ипи, әчегән ботка, исләнгән ит шикелле) ризык калдыклары ыргытып, балыкны үз капка төпләренә иләштерәләр. Бабай таң тишегеннән торып кармакларын ала да калитка баганасына бәйләп куелган көймәсенә чыгып утыра. Без Иделнең үзәненә юл тотып, култыктан чыгып киткән вакытта ул үзенең күптән модадан чыккан озын-озын кармак чыбыкларын тезеп салган була. Сәламләвебезгә каршы әлеге мөлаем елмаюы белән генә җавап биреп, көймәсендә кала. Алты-җиде сәгатьтән без әйләнеп кайтабыз. Бабай һаман көймәсендә елмаеп утыра. Безнең садокларда алтышар, җидешәр кило балык. Ә аныкында бер кило чамасы. Кай көннәрдә без бөтенләй балыксыз кайтабыз, аның садогында һаман бер килосы бар. Ләкин бабай тоткан балык Андрюшиннар гаиләсенә чәп итәргә дә җитми. Җәй буена гына түгел, кышка да җитәрлек итеп тозлау өчен аларга балыкны күбрәк көмеш кармакка тотарга туры килә. Көмеш кармакка дигәндә җаның теләгән балыкны күпме сорасаң шул хәтле китереп бирергә кулыннан килүче уңган кемсәләрнең Идел буенда бервакытта да беткәне юк. Тик аларны да таба белергә кирәк. Тапкач югалтмыйча тота белү дә зур эш. Андрюшиннар ул яктан бәхетле булып чыктылар. Дачник өчен кадерле кешеләр алар тирәсеннән бер дә өзелми. Сөтен дә күтәреп киләләр, эремчеген дә, катыгын да. Ул тавык турында әйтерлек кенә дә түгел: итен дә китерәләр, күкәен дә, кәкәен дә (бакчачылар арасында соңгысы күкәенә караганда кыйбатрак йөри). Ләкин сүз ул турыда түгел бит әле, балык турында. Балык китерүчеләр дә күп. Тик аларның күбесе соңга калалар. Шулай да Вера Ивановна аларны илтифатсыз кире борып җибәрергә ашыкмый. Иң элек үзләрен мактый, аннары балыкларын. «Ах, кызганыч, бүген алып өлгергән идек шул!» — дип куя. Тегеләр тәмле сүзгә бик үк эреп китмичә, күңелсезләнеп, кире борылалар. Үз алларына мыгырданулары, ачы тиргәнүләре ишетелеп кала: «Шул, сволочь, акула эше!»

Кеше җанлы Вера Ивановнаның нечкә күңеле үзенә яхшы ният белән килгән кешеләрнең болай рәнҗеп китүләрен күтәрә алмый.

— Туктагыз әле, сөеклеләрем! — дип кычкыра.— Килегез әле.— Ирина Галиевна кирәк дигән иде, барыгыз әле шуңарга. Аның күршесе дә бар.

Ул кичеккән балыкчыларны калиткасы аша кертеп, икенче рәттәге бакчачылар ягына озата һәм үзенең сатучыларга да, алучыларга да яхшылык эшләвен тоюдан җаны тынычланып, күңеле рәхәтләнеп кала. Тегеләрнең гөнаһысы өчен кемнәндер гафу үтенгәндәй, үзалдына әкрен генә сөйләнә:

— Бигрәк тәрбиясез кыланалар, мескеннәр. Нишләп акула булсын инде ул Жорочка. Җитмәсә, сволочь, диләр. Алла сакласын, ничек телләре әйләнә шундый уңган, шундый тыйнак кеше турында?..

# Жор

Мин дә беләм ул уңган кешене. Гомумән, безнең тирәдә аны белмәгән кеше табылыр микән? Төрле кеше төрлечә атый. Вера Ивановна өчен ул — Жорочка. Бабай үзе Георгий Мухтарович дип зурлый. Мәхмүт белән без Жор дип кенә йөртәбез.

Һәвәскәр балыкчыларны мин үзем өч категориягә бүләм: беренчесе — балыкны ашаудан бигрәк, тотарга яратучылар; икенчесе — тотудан бигрәк, ашарга яратучылар; өченчесе — тотудан да, ашаудан бигрәк, аны сатарга яратучылар.

Жор өченче категориягә керә. Минемчә, ул аларның чынлап та иң уңганы һәм талантлысы.

Язын, әйтик, Идел өсте боздан ачылып та бетми, чабак уылдыгын чәчәргә дә өлгермәгән, ата балыкларның кабыргалары агач игәве кебек кытыршы чак. Һәвәскәр балыкчылар әле көймәләрен буярга да керешмәгән. Ә Жор инде Андрюшиннар бакчасы янында... Өстендәге сырмасы малаеныкын кигән сыман тыгыз булып, тартылып тора. Аякларында киң куныч кайтарылып төшкән аучы итеге, кулында олы кәрҗин. Әйтерсең аның эчендә шыплап тутырылган чи балык түгел, ә очып торган пенопласт шакмаклары — Жор аны сынар кулы белән шундый җиңел уйната. Икенче кулында баш бармак чаклы гына бизмәне. Кыш буе шәһәрдә ятып, яңа тоткан балыкка зар булган бакчачылар аны бик тиз сырып алалар.

Тирес чуманы хәтле кәрҗингә сыеша алмый сикерешкән утыз-кырык кило балык өч-дүрт минут эчендә Жорның җаен авызы кебек пыртманитына сыя да бетә. Өстәвенә, әле бушап калган кәрҗинен рәхмәт белән тутырып җибәрәләр.

Балыкның иң шәпләрен беренче булып эләктергән Петр Петрович, Жор өчен алдан ук әзерләп куйган мөлаем елмаюын кире җыеп алырга да онытып, тере чабактан вобла ясарга керешә. Карап торуга бик гади эш: тозга әвәләгән балыкларны бер савытка тутырып таш белән бастырасы да бер-ике көннән киптерергә элеп куясы. Ләкин син аны үзең эшләп кара да Петрович ясаганны ашап кара! Аның чабактан ясаган вобласы чын воблалан, ягъни шәплеге белән даны чыккан Әстерхан воблаларыннан тәмле була. Ул аның төсе! Алтынсу сары булып, майланып торулары! Кояшка тотып карасаң, үтә күренеп, авызыңнан сулар китерә!.. Ул исләре дисәң... Хәер, китте. Хәзер инде сүз бу турыда түгел, Жор турында.

Әйе, шундый өлгер кеше инде ул Жор. Аның исемен дә без юкка гына Жор дип үзгәртмәдек. Жор — ул кармакчылар телендә балыкның иң шәп чирткән вакыты дигән мәгънәне аңлата. Аеруча чуртанга карата. Әйтик, җәй азыкларында спиннинг тотып Идел өстенә чыксаң, җәпле кармагың янына ялтыравык урынына муштугыңны яки трубкаңны бәйләп сал, чуртан барыбер каба. Кыскасы: чуртан чуртанны йота торган чак. Ә безнең Георгий Мухтарович өчен елның һәр ае, һәр атнасы гына түгел, һәр көне жор.

Шулай да безнең бакча тирәсенә көн саен килми ул. Киресенчә, теләсә кем Идел өстенә чыга алмаслык җилле-давыллы яки яңгырлы көннәрне күренә. Шимбә, якшәмбе иртәләрендә исә, һава хәлләре сиксән яшьлек бабайларның дәртен уятырлык дәрәҗәдә әйбәт, аяз булса да, кояштан алда килеп җитә. Мондый көннәрдә инде аның кәрҗине чабак белән түгел, импорт итеге кигән кызлар аягы кебек нәфис сынлы чөгә балыклары белән тулган була. Күз тиюдән сакларга теләгәндәй, Жор аларның өстенә үлән каплап йөртә. Һәм аны теләсә кем алдында ачмый да. Аның янында телең ни әйткәнне колагың ишетми торган булса, җәй буена чөгә төсе күрмисең. Бервакыт үзем шундый хәлгә

төштем. Үзем дә балыкчы булгач, башкаларның тәҗрибәсе турында сораша торган гадәтем бар. Беркатлылык күрсәтеп, Жордан да сорадым. Үзем бер балык та тота алмый кайткан көн иде. Аның кәрҗине эре-эре корбан балыклары, судаклар белән тулы булуын күреп, тәкать тота алмадым:

— Ничек тотасыз сез? — дидем.— Кайсы урында? Нинди ысул белән?

Көлеп кенә куйды Жор.

Анысы шулай нәтиҗәсез генә үтеп киткән иде. Икенче бер вакыт бер кәрҗин чөгә күтәреп килгәч, тагын телемне тыеп кала алмадым.

— Бу бит тотарга тыелган балык, ул кадәр кыйбат сатмасагыз да ярар иде,— дип ычкындырдым.

Әйтерсең бөтенләй ишетмәде; җавап та бирмәде, елмаймады да. Һәм шуннан соң аның чөгә күтәреп килгән чагын күрмәдем. Тотмый түгел, тота, бүтәннәргә китерә, ә мин күрмим. Мәскәү кунаклары килгән чакта заказ биреп карадым, юк, бетте минем өчен чөгә балыгы. Ике ел ураза тоттырды. Усаллыгымны күрмәгәч, менә быел, аллага шөкер, яңадан ачылып тора әле. Бик кирәк булганда өмет бар диган сүз.

Ләкин мине Жорның балыгыннан да бигрәк, көймәләре, көймәләреннән дә бигрәк моторлары сокландыра. Әйе, «ләр»е дим. Аның көймәсе дә бер генә түгел, моторы да. Чөнки ул аның иң тиз йөри торганын ярата. Берсеннән-берсе тиз йөри торган, яңадан-яңа моторлар чыга тора. «Москва» моторын да башлап мин аңарда күрдем. Көймә моторының шуңардан да шәп йөри торганы булмас, дип уйлаган идем. Күп тә үтмәде, Жор «Вихрь»га утырды. Бусы инде бөтенләй җен кебек... Моторына карап көймәсен дә алыштыра бара. Аның кулына кергән моторлар гаҗәп күндәм булалар тагын. Кабызгыч бавын шаярган шикелле итеп ярты гына тарта: моторы шундук гөрләп эшли башлый. Ярты минут эчендә күздән дә югала. Хәзер аның өстендә зәңгәрдән уңып ак төскә кергән тыгыз майка да карадан сорыга әйләнгән шорт кына [1]. Көндез дә шулай, төнлә дә, аязда да, яңгырда да. Берәр текә борылышта кадалып төшсә дә, аңа берни булмый диган сүз. Күрәнгә әйләнгән ак аю кебек чумар да китәр, пылт итеп калкып та чыгар...

Жор турында шушылай күп сөйләп торуымның сере шунда: иртәгә тагын аңа йомышым төшүе бар. Чөнки, бая әйткәнемчә, иртәгә миңа балыксыз кайтырга ярамый.

### ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

## Иртәгә балыкка чыгасы көннең киче

Шуннан да ыгы-зыгылырак кич була микән кеше тормышында? Балык боткасы үзе генә дә ни тора. Гадәттәге боткаларга карага̀нда төп аермасы шунда: аны үзең пешерәсең. Табып аласың хатыныңның ташландык бер кастрюлен. Аны чистартып торуның кирәге юк. Кисмәктән генә чумырып су саласың. Ярманың ниндие туры килә. Тары ярмасымы, солыныкымы — бары да бата. Алар янына тагын былтыргы капчык төпләрен селкеп, ачыган геркулес, тычкан ярмасы белән аралашкан борчак, күксегән дөге, укмашкан манный, гомумән, искереп ашарга яраксыз хәлгә килгән арпа, карабодай, макарон, вермишель

[1] Үзебезчә әйтсәк, кесәле трусик, яки балаксыз чалбар диярге мөмкин.

калдыкларын да кушып җибәрсәң, тагын да яхшырак. Шунысы рәхәт: берсен дә юып тормыйсың. Ләкин алар гына җитми. Биргән җимең балыкның телен йоттырырлык булсын дисәң, тәм-томга, төрле хуш исләргә бай булган сыйларның берсен дә кызганма. Әнис маең бармы, канфора, канәфер майларымы, ванилин яки валерианка — барын да сал, хәзинәңдә булмаса, тап! Ярар инде дип, кул селтәмә, аптекага йөгер, күршеләреңнән сора. Бирергә саранлансалар, сорамый ал. Болар мин уйлап чыгарган чаралар түгел, меңнәрчә балыкчылар тарафыннан күп еллар буенча сыналган тәҗрибә җимешләре. Үзем генә белгән серләрем дә бар. Барын да әйтеп бетерсәм, кармакташларым мине һәвәскәр балыкчы димәсләр, ачык авыз дип әрләрләр иде. Барын да әйтә алмыйм, шулай да яшь балыкчыларга киңәш төсендә кайбер тәҗрибәләремне уртаклашасым килә. Мәсәлән, балык сезоны бик кызган айларда валерианка табу кыенлашып киткән чаклар була. Андый вакытта мин үземә врачлар язып биргән йөрәк даруларын — валокардин, карвалол, Зеленин тамчыларын ходка җибәрәм.

— Йөрәгең авыртса нишлисең? — дисезме.— Балык тоту белән дәвалыйм. Нәкъ врачлар кушканча. Лирик планда гына тоту, ягъни тал күләгәсендә тыныч кына кармак салып, нәфис чәчәкләр яки матур хатыннар турында гына уйлап утыру килешмәсә, Амосов кушканча эш итәм: җилгә каршы каерып-каерып ишкәк ишәргә тотынам! Эсселәп китсәм, майканы да салып тормастан, гөрс суга! Идел уртасына. Киерелеп-киерелеп, агымга каршы колач сала башлыйм. Аннары кире борылып, шактый ерак агып киткән көймәне куып җитәм дә сикереп өстенә менәм. Тагын ишкәк, якорь! Спиннинг! Кайткан вакытта да моторны кабызмыйм, өч-дүрт километр араны «ракета» белән ярыша-ярыша, ишеп кайтам. Кайтып җиткәч бензин багы да бушамаган моторны җилкәгә алам да җан-фәрманга йөгереп яр башына менеп китәм. Кая анда валокардин яки карвалол турында уйлап тору! Йөрәк, мескен, авыртырга маташуы белән исәпләшмәгәнне күргәч, эчтән тына...

Тукта, ботка пешерә идек бит әле. Шула-а-ай. Хәзинәдә булган барлык ярма затын һәм тәм-томнарны кастрюльгә тутыргач, капкачын пар чыкмаслык итеп, ягъни чит-читләренә эластик оек куныччлары кыстырып ябып, өстеннән өч кирпеч белән бастырып куясың да утка утыртасың. Газың булмаса, электр плитәсенә утыртырга мөмкин. Техникадан артта калган кешеләргә гади керосинка, хәтта примус та ярый. Утырттыңмы? Ярый. Кастрюлең кайный торсын, үзең кармакларыңны, көймәңне, бауларыңны, якорьларыңны барла. Моторыңны көйләп куй, суалчан, чебен корты, ботка чиләге, җим капчыгы, батыргыч, сачок, садок кебекләреңне кара.

Шундый, берсеннән-берсе әһәмиятле эшләр белән мәш килеп йөргәндә, хатыныңның сиңа дөнья җимерелгәндәй куркынып:

— Боткаң көя! — дип кычкырганы ишетелер. Борчылма, көйгән ботканы балык тагын да ярата төшә. Хәзерлек эшеңне дәвам иттер. Өстеңә-башыңа нәрсә аласың? Мөмкин кадәр искерәк киемнәреңне әзерләп куй. Сугыш заманыннан калган плащ-палатканы онытма. Белмәссең, яңгыр-фәлән явып китүе бар. Көмеш кармак турында да уйла: өйдәге чалбарың кесәсендә калмасын. Ашарыңа нәрсә кирәк буласы, эчәреңә? Транзисторыңны нишләтәсең?..

Бик нык хәзерләнәм дип, кичтән артык озак юанырга ярамый. Кастрюлеңне плитәдән ал да капкачын ачмаган көе генә ныгытып төреп куй. Нәрсәгә төрү — һәркемнең үз мөмкинлекләреннән чыгып билгеләнә. Әйтик, махровый халат яхшы. Аның өстеннән сырган бишмәт белән төрсәң, бигрәк тә шәп.

Инде тизрәк яту ягын кара. Иртән өчкә торасың бар. Әйе, иртәгә балыкка чыгасы көннең киче шуның белән бетте диярgә мөмкин. Ләкин киче генә. Шуннан соң аның төне башлана.

# Иртәгә балыкка чыгасы кичнең төне

Менә шунда күрәсең инде балык тотуның файдасын! Бигрәк тә симерүдән курка торган кеше булсаң... Шундый бай эчтәлекле төн ул иртәгә балыкка чыгасы кичнең төне! Тормышның никадәр катлаулы нәрсә икәнен аеруча ачык тоясың ул төнне.

Ятар алдыннан чишенеп тормыйсың. Хәтта, киресенчә, иртән торгач артык вакыт әрәм итмәс өчен, иске күлмәк, бөрмәле чалбар, тишек оек кебекләрен киеп үк куйсаң да ярый. Аска ак җәймә җәеп, өскә юрган ябып торасы да булмый. Шәһәрдәге квартирадан дачага күчерелгән иске диванга сузылып ятасың да күзеңне йомасың...

Ниятем күзне йому белән йоклап китәргә иде дә бит, син теләгәнчә барып чыкса, чын тормыш буламыни ул?

Мин күземне йомган минутларда йокыны куркытырлык берни дә юк иде әле. Малай да, кызлар да шәһәрдә. Әниләре дә әнә, әллә миңа йокларга комачауламас өчен, әллә үзенә шулай рәхәт булганга, тавышсыз гына ята. Еракта гы тимер юл буеннан поезд узганы ишетелә. Кайдандыр, әллә урман ягыннан, әллә су өстеннән йомшак кына булып музыка моңы килә. Зарарсыз. Оета торган гына тавышлар. Эрисе дә китәсе... Ләкин юк, килми генә бит йокы. Әллә нинди кирәкмәгән уйлар килә күңелгә, ә йокы юк. Я инде, әйтик, 1947 нче елда ук Моркваш турысында балык тотканда кармагымнан ычкынган кызылканат килә күз алдыма. Ул вакытта Идел хәзерге кебек диңгезгә әйләнмәгән иде әле, үзәненнән чыгып дөньяга җәелмичә, акыллы гына агып ята, балыкны да, махсус күперчек ясап, сөзәк яр буеннан гына тота идек. Кармак сапларыбыз хәзерге шикелле теш казыгычы хәтле генә түгел, колга буе иде. Балык чирткәнен калкавычка карап белә торган идек...

Орчык хәтле итеп, нарат кабыгыннан юнып ясалган калкавычым, койрыгын һавага күтәргән хәлдә, тыныч кына агып, кормушка җебе яныннан узып барган җиреннән кинәт батты китте. Андый вакытта берни уйлап, акыл белән киңәшеп торып булмый, нишләргә кирәген кул үзе белә. Бамбук чыбыгым сынар чиккә житеп сыгылганын күрәм дә, кулым белән генә түгел, җаным-тәнем белән җеп очында талпынган балыкның авырлыгын тоям. Ул шундый гаҗәеп, илаһи бер тойгы, аның рәхәтлеген берни белән чагыштырып булмый. Аны аңлатырга бернинди телнең, бернинди сүзнең көче җитми. Ул изге тойгының ләззәтен бары үзең татып кына белергә мөмкин. Аны тату бәхетенә ирешү өчен, әлбәттә, балыкчы булырга кирәк. Һәвәскәр балыкчы!

Шундый тойгы рәхәтеннән шашар чиккә җиткән хәлдә, күперчек буйлап балыкны су читенә таба өстерим. Атлап бараммы, йөгерепме, очыпмы — анысын белерлек хәлдә түгелмен. Пөрәк хисләрем артык ашәрүдән балага әйләнеп киткәнмендерме, ни булгандыр, белмим, су саеккан җиргә килеп җиткәч, нәкъ малай чактагыча, балыкны яр буена атмакчы булып, су өстенә күтәрдем. Балыгым эшнең кая барганын сизеп алды бугай, үзенең көмеш кабыргасын ялтыратып, кура җиләге кебек җете кызыл канатларын җемелдәтеп, ким куйганда ярты метр озынлыктагы сыгылмалы зифа буен күрсәтеп, урталай бөгелде дә шундый көч белән кире эчкә таба тартылды, ике катлап бөтерелгән хәрби ашея җеп (ул елларда бездә хәзерге капрон кыллар юк иде әле) шартлап өзелде һәм шундук кызылканат артыннан калкавычым да су төбенә китеп юк булды...

Моннан чирек гасыр элек баштан кичкән шул хәл бүгенге кебек

булып күз алдыма килә. Күз алдыма килә генә түгел, күңелемдә шул вакыттагы тойгыларым кабатлана.

— Их! — дип куям, әрнеп,— хәзер булса! Аны алай, юләр малайларча, өскә күтәрмәскә, өстерәп кенә яр читенә чыгарырга кирәк булган.

Ләкин тәҗрибә дигән нәрсә гомер буена җыела икән ул кешедә һәм гомер буена җитми икән... Йокы һаман килми. Тәҗрибә җитмәү аркасында ычкындырган тагын бер балык күз алдыма килә. Анысы да бик күптән, әле Идел тугаендагы күлләр бергә кушылмаган елларда булган хәл. Олы күл буенда Мәхмүт белән икәүләп спиннинг атып йөрибез. Минем әле ул четерекле коралны яңа үзләштереп килгән чак. Балык эләктерүдән дә бигрәк, йөз метрлы кылны чуалтмыйча, кармакны ерак ыргыта белүемә куанып бетә алмыйм.

Үз осталыгыма үзем сокланудан дәртем эчемә сыймагандай, бөтен көчемә киерелеп атып җибәрдем бервакыт, ялтыравыклы кармагым Олы күлнең нәкъ уртасына барып төште. Ашыкмый гына саный-саный, батыргычымның күл төбенә барып җиткәнен көтәм... Бер... ике... өч... Егермегә кадәр санадым. Батыргыч һаман төпкә төшеп җитә алмый әле. Егерме бер... егерме ике... ниһаять, җеп әз генә бушагандай итүгә, чыгырны әйләндерә башлавым булды, кармагым... нәрсәгәдер бик каты эләгеп, шып тукталып калды. Төпсәгә эләкте, ахрысы, хәерсез, дим. Тартыргамы, бушатыргамы? Тартсам, тагын да ныграк эләктерермен дә кармагым өзелеп калыр дип куркам. Шулай икеләнеп торганда, төпсә дигәнем салмак кына дулкынланып куйды. Мин моны кулларым, беләкләрем белән генә түгел, бөтен тәнем белән тойдым. Таныш тойгы! Тик моңар кадәр татып күрергә туры килгәннәренә караганда берничә тапкыр көчлерәк. Үземне-үзем белешмәстән тотындым бар көчемә тырышып чыгырны әйләндерергә. Ләкин чыгырым мин теләгән якка түгел, беләк көчемне каерып, кирегә әйләнә. Мин тартам, балык тарта. Шундый көч белән тарта, чуртан гына түгелдер бу, дип уйлыйм, аттыр... И тартышабыз, и тартышабыз, балык әз генә дә якын килми, тик мандолина кылы кебек тартылган кармак кылым өскә күтәрелә генә бара. Аптырагач, Мәхмүткә кычкырдым. Ләкин нинди ярдәм көтәм аңардан, үзем дә белмим. Мәхмүт тә белми. Аптырагач, арт яктан килеп билемнән кочаклады да мине тартырга тотынды. Әкияттәге кебек шалкан тартабызмыни! Ә балык ярга таба килми. Һаман өскә күтәрелә. Ниһаять, су өстенә килеп чыкты бу. Тик без аның тәртә буе чуртан икәнен генә күреп өлгердек. Кире су төбенә кадалып, яңа көч белән тартылды да... кармагым җиңеләйде калды... Хәлем бетүдән дә бигрәк ушым йомшарып, җиргә утырдым. Мәхмүт тә егылып китте. Тик шунда гына тәҗрибәле балыкчылардан ишеткән акыллы киңәшләр исемә төшә башлады. Тартышырга кирәкми иде бит миңа, әкренләп-әкренләп җепне бушатырга, чуртанның карышуы йомшый төшкәч кенә үземә таба китерергә, янадан тартыша башласа, тагын бераз җибәрергә, шулай итеп аны тәмам арытканчы, хәлдән тайдырганчы йөртергә кирәк иде. Кеше тәҗрибәсе кешенеке шул ул, үзеңнеке түгел, нәкъ кирәк вакытта ярдәмгә килеп өлгерми.

Сикереп тордым да тотындым яңадан шашып-шашып атарга. Баягысыннан да шәбрәк җибәрәм. Әллә тагын җитмеш-сиксән метрга төшерә торганмындыр кармакны. Юк, чуртан яңадан килми. Тәмам хәлдән тайдым. Аяктан егылыр чиккә җиттем, ләкин туктый алмыйм, һаман атам...

— Җитәр,— диде шунда Мәхмүт.— Ял ит әзрәк.

Әйе шул.

— Их, мин әйтәм, Мәхмүт дус! Ычкындырдык бит. Аркылы агачка асып, икебез ике башыннан җилкәбезгә күтәреп кайтып, бөтен Займище халкын шаккатырган булыр идек бит! Ә?!

— Кайгырма ычкынган балык өчен,— ди оптимист дустым,— шатланырга кирәк.

— Шатланырга?

— Әйе. Чөнки ычкынган балык онытылмый ул...

Ә бит дөрес! Зур-зур балыкларны тотып алып кайткан чакларым да күп булды. Ләкин бары да онытылган. Ә менә ычкынганнары!.. Гомер буена онытылмыйлар, үзәкләрне өзеп искә төшәләр дә: «Их, хәзерге тәҗрибәм булса!..» — дип куясың.

Ләкин хәзер дә «ычкындырмам» дип өзеп әйтү кыен. Тәҗрибә дигән нәрсәне гомер буена җыясың, ә ул һаман җитми, дип юкка гына әйтмим. Чөнки һәр ычкынган балык үзенчә ычкына. Менә тагы, әле өченче ел гына ычкынган ун килолы чуртан күз алдыма килде. Бусы инде зур Иделдә. Аның да уртасында. Карасик дип аталган алтын-сары ялтыравык тагылган өч җәпле зур кармакны көймәдән ерак та ыргытмадым. Әмма тирәнлек җитәрлек иде. Капты бит! Тәҗрибә бар, шундук аңлап алдым: гадәттәге кило ярым яки өч килолы гына түгел, сирәк очрый торган чоңгыл чуртаны. Биш ат көче белән тарта диярсең. Тәҗрибә бар, бик каты карыша башласа, җибәрәм. Җибәрәм дигәч тә, «авызлыкны» бөтенләй бушатмыйм. Ун-унбиш метр киткәч, кирелеге йомшара башлый, тагын көймәгә таба китерәм, тагын җибәрәм. Әлеге үзе балыкчы булган кешегә генә аңлашыла торган илаһи тойгы тоташтан ун-унбиш минут чамасы дәвам итә! Андый кадерле минутларны гомереңдә бер тапкыр тату өчен генә дә яшәргә ярый бу дөньяда.

Ниһаять, чуртаным тәмам арыды. Нукта кидерелгән карт алаша шикелле, бернинди карышусыз көймә янына килеп ятты. Каен бүрәнә кебек, рәхмәт төшкере, ярты көймә буе бар. Пләмәннигем сачок белән күтәреп алырга үрелде. Сачокка сыймый, күсәк, баш ягыннан алыйм дисә, койрык ягы баса, койрык ягыннан эләктерсә — баш ягы. Уртасыннан алып, сачокның кыршау өстенә аркылы салып карый. Тик тигезлек саклый алмый, иләмсез зур җанлы бүрәнә шуа да төшә, шуа да төшә.

Аруы җиткән икән үзенең дә, җеп өзәр хәле дә калмаган, күрәсең. Сачок белән кабыргасын шулкадәр кытыклауга да исе китми. Пләмәннигем сачогын куеп, чуртанны кулы белән тотып алмакчы иде, рөхсәт итмәдем. Ачы тәҗрибәм бар, ыргып китеп, саңагы белән яраласа, җәрәхәте ел буена сузылуы мөмкин. Үзем дә аптырашта. Һаман шулай тик ятмас бит инде ул, бер заман аңа хәл керер. Нишләргә? Мондый вакытта аныияк астыннан гына эләктереп алу өчен махсус ыргак шәп булыр иде лә бит, гөнаһ шомлыгына каршы, алмаганмын. Бар андый ыргагым. Өч ел үземнән калдырмадым. Бер тапкыр да кирәге чыкмагач, артык әйбер дип, йөртми башлаган идем. Хәзер кайда ятадыр, белмим дә. Сачокны да нигә тирәнрәк итеп ясамаска инде... Нишләргә? Әллә, ышанычлырак булсын өчен, мотор ачкычы белән башына сугып, ушын алыргамы? Ачык бер карарга килергә өлгермәдем, пләмәннигемнең сабыры бетте, ахры, гади алабуганы алган шикелле, җебеннән тотып чуртанны көймәгә күтәрә башлады... Кисәтергә дә өлгермәдем, чуртан һавага чыгарганны яратмыйча, капыл гына башын читкә каерды. Җеп өзәр хәле калмаган дип ялгышканмын икән, гади җепне генә түгел, 07 миллиметрлы кылны өзеп, алтын-сары карасигымны да үзе белән алып, ашыкмыйча гына, су төбенә батты да китте...

«Миндә балта бар иде!» — дигән тавышка башымны күтәреп карасам, әйләнә-тирәбездә алты-җиделәп көймә. Көймә саен өч-дүрт кеше. Тамаша күрергә җыелганнар икән. Тотындылар узган эшкә салават укырга: тегеләй итәргә кирәк иде, болай итәргә. Кайсы минем нинди блеснага тотуым белән кызыксына, кайсы үз башыннан узган тарихны исенә төшерә... Инде үземнең дә зиһен эшли башлады. Их, мин әйтәм, юләр. Үз-үземне тиргим. Көймәмдә менә дигән бау бар бит. Элмәк

ясап, хәрәкәтсез яткан чуртанны шуның белән буып кына күтәреп аласы булган...

Шуннан соң мәнә өченче ел инде сачогымны бозау сыярлык итеп зурайттым, ыргагымны да янымнан калдырганым юк, көймәдә һәрвакыт запас бау да була. Ә теге ун килолы балык юк. Дөрес, мин аны кешегә сөйләгәндә бераз киметеп, сигез кило чамасы дип кенә сөйләдем. Чөнки ышанмаган булалар. Ә бу хәлне үзләре күреп торган шаһитлар ышана, хәтта алар: «Унга гына бетәме соң, кимендә унике килолы чуртан иде ул»,— дип тә җибәрәләр. Беләм, балыкчыдан көләргә яратучылар, бу юлларны укыгач, елмаячак. Янәсе, балыкчы шундый кеше инде ул, һәрвакыт аның ычкынган балыгы зур була. Юкка җәберлисез балыкчыны. Ычкынган балык зур булмый, киресенчә, зур балык ычкына! Моны аңларга кирәк. Ләкин ул синә никадәр җан рәхәтлеге биреп, дөньяда яшәүнең тәмен татытып, бөтен кан тамырларыңны дулкынландырып, миллион нервларыңны хәрәкәткә китереп, күңелеңдә гомер буена сагынып сөйләрлек матур истәлекләр калдырып ычкына. Тик бер нәрсә гарьләндерә мине яки гаҗәпләндерә: берәүнең яшәү юлында шундый онытылмаслык эз калдырган вакыйга ни өчен беркайда да ул кешенең анкетасына теркәлми? Һич югында, биографиясенә язылмый? Һәркем диярлек үзенең гомер юлында бик күп һәм вакыты белән бик зур вакыйгалар кичерә. Ләкин шулар бары да хәтердә калмый бит. Хәтта язып куелган вакыйгалар да онытыла. Ә менә бөтенләй әһәмиятсезгә саналып, көндәлеккә язарга да кирәк табылмаган вакыйгалар әнәсеннән җебенә кадәр гомер буена хәтердә сакланалар. Әйтик, әнә шул ычкынган балык? Ни өчен саклый аны хәтер? Бер дә юкка гына түгелдер. Димәк, хәтернең үз серләре бар. Хәзергә без белмәгән серләр. Нигә социологларыбыз шул турыда фикер йөртми икән?..

Уф! Менә бит нинди уйлар килә күңелгә. Ә миңа йокларга кирәк. Тагын әз генә йокламый ятсам, аннары...

Каһәр генә суксын! Курыкканым алдыма килде: Каршы утраудагы динамик, километрларга җәелгән көчле тавыш белән бөтен Идел буен яңгыратып, джаз уйнарга тотынды. Ул утрауда, юләр әйтмешли, кырыклап предприятие һәм учреждениеләрнең ял базалары урнашкан. Көн дә кич шулай дөнья яңгыратып күңел ачалар. Ә ял көненә каршы төннәрдә аеруча... Ким дигәндә төнге унбергә кадәр дәвам итә. Моңарчы, ичмасам, күзгә йокы кермәсә дә, күңелгә матур-матур уйлар килә иде. Ә бу музыка астында...

Музыка?!

Бар иде безнең дә яшь чаклар. Хәтта малай чаклар. Совет власте бар, ә «плюс электрофикация» дигәне әле юк заманнар. Дөньяда радио дигән нәрсә барлыгы турында да яңа ишетә башлаган еллар.

Комклубка радио сөючеләр түгәрәгенә барабыз. Репродуктор яки громкоговоритель дигән нәрсә бөтенләй юк иде микән, бердәнбер наушникны колакка куеп карар өчен, бер көтү малай чират тора идек. Ул наушниктан да чинаган, гыжлаган, сызгырган тавышлар гына ишетелә. Шунысы кызык: ул заманда коточкыч чинау, сызгыру авазлары да хәзерге шикелле нервага тими, киресенчә, ниндидер серле яңалык булып кына тоела иде. Шулар арасында кеше авазлары яңгырап китсә, шатланабыз. Ә инде ара-тирә берәр аңлашылган сүз дә килеп чыкса, тыңлаучының бөтенләй йөзе яктырып китә, шатлыгын эченә генә яшереп кала алмый, чират көтүче төркем белән дә уртаклаша:

— «Ленин» дип әйтә! Әнә... әнә... «революция», ди. Музыка!.. Җырлый!..

«А куда ты, паренек, а куда ты...»

Валлаһи! Шул кадәр ачык ишетелә...

Бәхетле колакка тыңлап бетәргә бирмибез. Җитте, хәзер минем

чират... Тагы гыжылдау, тагы сызгыру тавышлары!.. Әллә теге малай, ачык ишетелә дип, юри әйткән инде? Чү! Музыка!.. Мәскәүдә уйналган музыканы Стәрлетамак клубында торып, яртышар минут кына булса да һәркайсыбыз үз колагы белән ишетеп чыккач, шәһәр бакчасына жыелып утырабыз да тойгыларыбызны бүлешергә тотынабыз. Әбүгалисина тылсымнарыннан узган бу хәлнең чынлыгына ышанасы килми.

— Бу нәрсә? — ди арабызда өлкәнрәк булган комсомол иптәшебез.— Бу әле радиомыни? Менә социализм төзелгәч күрерсез әле! Ул вакытта радио бөтен урамнарда булачак. Бөтен бакчаларда! Хәтта һәркемнең өендә. Бөтен жирдә көне буе музыка уйнап торачак. Музыка тыңлый-тыңлый эшлисең, музыка тыңлый-тыңлый ашыйсың. Музыка тыңлый-тыңлый эреп йокыга китәсең. Йокыдан уятканда да, кабыргаңа төртеп, я әрләп түгел, моңлы музыка тавышы белән генә уятачаклар...

Йоклый алмый борсаланып яткан жиремнән ихтыярсыз көлеп жибәрдем.

— Менә, ул көн килде. Музыка тыңлый-тыңлый эреп йокыга кит инде! Гажәп бит! Теге елларда, шул чор теле белән әйтсәк, мәдәнилекнең югары баскычы булып күз алдына килгән музыка, аның һәрбер жирдә өзлексез яңгырап торуы хәзер миңа, бүгенге заман теле белән әйтсәк, культурасызлык булып тоела. Чынлап та, музыкадан гарык булдык бит без хәзер. Тәүлекнең теләсә кайсы сәгатендә приемнигыңны тоташтыр, музыка яңгырый. Хәтта үзеңнекен тоташтырма да, колагың гына тыгылган булмасын. Үз өеңдәме син, поездамы, пароходтамы, урмандамы, Идел өстендәме, айдамы — кайдан булса да музыка тавышы ишетелми калмас. Һәм күп вакытта ул миңа рәхәт бирәсе урында күңелне генә борчый. «Әллә мин үзем шундый, музыкадан тәм таба белми торган кеше микән?» дип, беркөнне композитор дустым белән сөйләшеп карадым.

— Сөйләмә,— диде дустым, кулын селкеп.— Мин үзем кая керергә белмим ул музыкаль башбаштаклыктан. Мәжбүри генә булмаса, кеше язган музыканы тыңламыйм да. Үзем генә язам...

Дөньяны каплаган джаз көчәя генә бара. Беләм, хәзер инде мин барыбер ул туктамыйча йокыга китә алмыйм. Борчылмавым хәерләрәк, тыныч кына тыңлап тик ятыйм... Бер... ике... өч... Юк! Шулай да хулиганлык бу! Берәү күңел ачканга икенче берәү газапланып ятсын, имеш!.. Әллә бу минем эгоистлыгыммы? Минем урында Мәхмүт күршем булса ни дияр иде икән? Беләм. Ул әйтер иде миңа: син үзеңне әнә шул джаз моңы астында парлашып-парлашып биюче яшьләр урынына куеп кара, дияр иде.

Әйтерсең Мәхмүт миңа чынлап та шулай дип әйтте һәм мин тынычланып киткәндәй булдым. Музыка да ничектер аңлаешлырак, күңелгә ятышлырак булып яңгырый кебек, күңелемә матур уйлар килә башлады. Әйе шул. Соң син үзең комсомолга язылганнан бирле шушы көннәрне күрү өчен көрәшмәдеңмени? Комсомолга керүең дә шуның өчен түгел идемени? Күпләргә, эшләп яшәүче барлык кешеләребезгә дә иркенле, бәхетле тормыш килсен дип тырышмадыңмыни? Шуның өчен дип ачлыкларга, ялангачлыкларга, жил-яңгырларга, кар-бураннарга, сугыш газапларына түзмәдеңмени? Бүген сиңа йокы бирмичә, дөнья яңгыратып күңел ачучылар — син күздә тоткан күпләр түгелмени? Халык дигәнең шулар түгелмени?.. Әллә тормышның, кешеләребезнең кайчандыр син хыял иткәнгә караганда алгарак китүләре нормадан чыгу булып күренә микән сиңа? Бездә бит хәзер төп проблема ничек булса да тамак туйдыру мөмкинлекләрен табу түгел, ә ничек итеп тәмлерәк һәм шифалырак азыклар табу мәсьәләсен фәнни нигездә хәл кылу. Өс бөтәйтү чараларын табу түгел проблема, ә ничек итеп бүгенгә хас зәвыкта киенә белү. Укый-яза белмәүчелекне бетерү проблемасы да

күптән юк бездә, көн тәртибендә кешеләребезне заман таләп иткән күләмдә фән белән, техника белән коралландыру мәсьәләсе...

Бик катлаулы мәсьәләләр бит болар.

Культуралы ял дигәне үзе!..

Традицияләр мәсьәләсе!..

Вакытсыз килеп кергән шундый уйларга батып ята торгач, шашкын музыка авазларын да ишетми башлаганмын, күрәсең. Шулай ук аның тукталганын да сизмәгәнмен. Йокыга куерып барган җиремнән колак төбемдә генә чиертелгән гитара тавышына уянып киттем...

— Уф! Шул гына җитмәгән иде.

Бу Тажи да инде... карап торсаң, җитмәгән җире, эшләмәгән эше, өлгермәгән төше юк. Ә шул бер тишек көймәсенә баш була алмый. Ни ватып яндыра белмәде шуны, ни берәрсенә сылый алмый. Хәер, кемгә хаҗәте булсын ул ярык тагаракның! Өченче җәй инде менә, койма буена каплап салынган килеш ята. Җитмәсә, нәкъ безнең тәрәзә каршында.

Койрыгыннан да, борыныннан да чишмә төсле бәреп су керә башлагач, Тажи аны ямап вакыт әрәм иткәнче, арзан гына хакка булса да сатып, яңа көймә алырга дигән карарга килгән иде. Ул белгән акылны бүтәннәр дә белде, күрәсең. Биш тәңкә бирүче дә булмады. Шулай да бер карт өч сум тәкъдим иткән иде. Аны да чылбыры өчен генә бирәм дигәч, Тажиның башына уй төште. «Туктале,— диде ул.— Яңа көймә алгач, үземә кирәк булуы бар,— диде.— Мондый ышанычлы чылбырны ун тәңкәгә дә табып булмый бит хәзер. Күп кешеләр менә дигән яңа көймәләрен эт чылбыры белән бәйләп йөриләр. Яшьрәк жулик теше белән дә өзә алырлык...»

Һәм ул көймәсенең чылбырын алып куйды да, «бушка бирәм, теләгән кеше килеп алсын!» дигән белдерү язып, аны яшь бакчачылар участогына илтеп элде. Килеп-килеп караучылар булды булуын. Ләкин хәзерге яшьләр арасында, эш сөймәү ягыннан хөрәсән ялкауларын уздырырлык егетләребез булса да, элекке заман мокытлары юк шул: бушка килгән бу көймәне төзәтү мәшәкате яңа көймә сатып алудан кыйммәткәрәк төшәсен бик тиз чамалап өлгерәләр. Берсенең Тажи белән ничек сатулашуын үзем күреп, ишетеп тордым. Күптән түгел Тажиның үзендә үк укып йөргән, хәзер инде нәшрият тирәсендә эшкә урнашып, быел гына бакча участогы алган яшь кадр иде ул. Тажи аны бик ачык йөз белән каршы алды. Көймәсен карарга килгәнлеген белгәч, тагын да ачыла төште һәм аны кыстап-кыстап чәй эчәргә алып керде. Кунак янына мине дә чакырды. Үзе ясап, үзе үк «Таживин» дип исем кушкан карлыган аракысын чыгарды, закускага үзе каклаган балыкны куйды, шул көнне генә тотып кыздырылган корбан белән дә сыйлады. Көймә карарга килүче, яшь булса да, бик культуралы кеше икән. Бер сыйдан да баш тартмады, ашады, һәркайсын мактады. Аеруча «Тажи-вин»ны ошатты. Эчеп туя торган гына түгел бу! — дип кат-кат салдырып эчте. Аннары без бергәләп көймәне карарга чыктык. Тажи да, мин дә ярык тагаракның яшь чактагы хезмәтләрен искә төшереп, аны мактадык. Аның әле хәзер дә, әзрәк төзәткәләп, кайбер такталарын алыштырып, тишек-тошыкларын ямаштырып җибәрсәң, менә дигән көймә булып китәрлек рәте барлыгын әйттек. Яшь бакчачы көймәне төрле ягыннан әйләнеп, белгечләрчә игътибар белән карап чыкты.

Ниһаять, әйтте:

— Рәхмәт инде, Тажи абый, мондый затны бүләк итүең өчен,— диде.— Бушка алу җайсыз булса да, үзең тәкъдим иткәч, бик рәхмәт,— дигән булды.— Тик мин аны хәзер үк алып китә алмам әле.

— Ярар,— диде Тажи,— җаеңны кара. Көчләп бирергә теләмим.

— Әгәр мин килеп алганчы икенче берәр кешегә ошап куйса, бирегез, мине көтмәгез. Үпкәләсәм дә сезгә түгел, үземә үпкәләрмен.

Тагы ничә кеше килеп Тажиның чәен эчеп, «Таживин»ын мактап киткәндер, белмим. Көймә һаман урынында. Тагын шунысын әйтә алам: көймә тик яткан саен ныграк туза икән. Алып китүчеләр булмаса да, ул көймә үләксәсен ошатучылар табылды. Таң алдыннан кәсепкә чыгучы чәчкә караклары шул көймәгә басып койма аркылы уза. Бусы бер. Икенчедән, гыйшык тоткан яшь егетләр белән яшь кызлар бик яраттылар үзен. Бию мәйданнарында музыка басылгач, бакча өйләрендәге картлар йокыга талгач, бер-берсен култыклаган хәлдә, су буйлап килеп сарып йөриләр-йөриләр дә, төн урталары житкәндә, әлеге көймә өстенә утырып үбешәләр. Бер генә пар булганда зарарсыз. Ләкин күбесенчә бер пар янына икенче пар килеп кушыла, алар янына өченчесе, дүртенчесе... Монда инде коллектив мәхәббәт башлана. Арадан берсе кызык сүз әйтсә, калганнары көтүләре белән бергә кушылып көләләр. Аннары икенчесе әйтә. Яшь чакта кеше кызык сүз сөйләргә бик оста була бит. Чөнки көлүчеләре бер дә ялындырмый. Бөтенләй кызыксыз сүз әйтсәң дә кызыкка алалар, юктан-бардан сыннары катып көләләр. Көлешеп кенә калмыйлар, күмәкләп жырларга тотыналар. Гитара яңгыраталар. Аның өстенә һәр парда диярлек транзистор. Бөтен дөньяның төнге музыкасы синең тәрәзә төбеңә жыела дигән сүз.

Менә шунда йоклап кара инде син.

Гитара ярты көйдә бүленеп калды. Матур гына итеп кыз бала көлгән тавыш ишетелде. Көймә төбе төбердәп алды. Әле генә шундый ягымлы итеп көлгән кыз бала ачы тавыш белән чарылдап кычкырып жибәрде. Егете мәнсезрәк нәрсә, күрәсең. Әллә кызның изүенә бака салды, әллә берәр жирен бик каты авырттырып тотып алды... Әнә, әнә тагы кычкыра:

— Ой, ой!.. Ну, пусти!

Өзгәләнә мескен бала. Егете дигәнем, әллә берәр хулиган һөҗүм итәме? Әнә тагын!

— Ой, мама-а-а!

Шундый әрнеп кычкырды кыз, сикереп торып утырганымны сизми дә калдым. Ярдәм кулы сузмый ничек чыдап ятарга кирәк! Ләкин ишеккә дә барып житә алмадым, кызның көмеш тәңкә кебек чылтырап көлеп жибәргәне ишетелде. Кире урыныма яттым. Кызы үзе мәнсез икән. Аның урынында булсам, шулай тилереп кычкырыр идемме, дөнья жыеп! Артык яшь нәрсә, күрәсең, юләр. Әнә хәзер күгәрчен кебек гөрләшәләр. Әллә киттеләр инде? Әйе, тавышлары ерагая бара. Китегез, кит, алдыгыздан артыгыз яхшы... Бәлки, әз генә булса да черем итә алырмын... Итәрсең черем, әзерләгән! Тавышлары инде тәмам басылды дигәндә, яңадан көчәя башлады. Кире борылдылар, ахры. Үзләре генә түгел, әллә дүртәү, әллә алтау. Берсен-берсе тыңлап та тормый сөйләнә-сөйләнә, тагын әлеге каһәр суккан көймә янына килеп туктадылар. Ялгыш кына гитара яңгырап куйды. «Шатлан, мин дә монда!» дип мыскыл иткәндәй, транзистор инглиз телендә берничә сүз әйтеп алды. Тотындылар такылдарга, көлешергә, нерваларың гына чыдасын!.. Тагын оптимист күршем биргән рецептны искә төшердем: «Син үзеңне алар урынына куеп кара!» Нерва өянәгенә каршы гаҗәп шифалы рецепт. Шундук тынычланып каласың. Хәтта рәхәт булып китә. Бар иде бит минем дә шундый чакларым. Яшь чакларым, юләр чакларым!..

Яшьлеге үтсә дә, юләрлеге калган, күрәсең. Югыйсә, шушы хәлгә тыныч кына чыдап ятар идеммени? Акыллы картларча, таяк тотып чыгып, өсләренә жикерә-жикерә, бу дөньяда ничек яшәргә өйрәтмәс идеммени мин аларны, юләрлегем булмаса?

Йокламыйм да, ачуым да килми. Их, үземнең дә шулар яшендә чагым булса! Өстәвенә, хәзерге тәҗрибәм... Беләм, таушалган фикер, һәр карт юләрнең башына килә торган арзанлы хыял. Иясез этне куган-

дай, башымнан көчләп куып чыгарам бу хыялны. Йөрмә монда, алар яшендә минем балаларым бар!..

Үз балаларым искә төшкәч, күңелемә бүтән төрле зар-моңнар килә башлый. Әнә кеше балалары ничек күңел ачып, саф һавада ял итеп йөри. Ә безнекеләр шәһәрдә. Кино кирәк аларга, театр, китапханә. Шушындый әйбәт җәйге кичтә... Яшь чакта яшь була белү дә ярый шул... Ә бәлки, минекеләр хаклыдыр? Кеше кәефе белән исәпләшмичә, төн уртасында ихахайлап, радио акыртып йөрүне тәрбиялелек билгесе дип буламы?

Шундый уйларга бирелеп, Тажи көймәсе янындагы шау-шуны тагы ишетми башлаган идем, ахрысы. Су буена чыга торган бәләкәй капка ачылгандай булды да, бер тапкыр да йокламаган килеш, икенче тапкыр уянып киттем. Әйе, кемнәрдер кереп килә. Ә бит капка йозаклы иде? Төн уртасы? Торып тәрәзәгә барырга өлгермәдем, ишекне кага башладылар. Сак кына, әдәп белән генә. Тажи микән? Торыр вакыт та җитте микәнни?

— Кем ул?

— Ач, әти, бу без.

Үземнең малай. Кызлар да шунда.

Әниләре уянмасын дип, пышылдап кына әрлим үзләрен.

— Нәрсә сез, башыгызга ис тидеме әллә? Бу вакытта? Нинди поезд белән килдегез?

— Кичтән үк килгән идек,— дип пышылдый улым.— Базада булдык. Мә, шуны өстәлгә куй әле.

— Нәрсә ул?

— Спидола.

— Син йөрдеңмени анда транзистор акыртып?

— Тс! Әни уянмасын.

Әрләвемне дәвам итәргә өлгермәдем, балаларым караңгылык эченә кереп юкка да чыктылар. Малай алъяк бүлмәдәге караватка сузылды, кызларның чардакта кыштырдаганнары ишетелде. Карманып, мин дә үз урыныма барып яттым. Ике минут үттеме, юкмы, малай, пыф-пыф итеп, иреннәреннән куык өрә башлады. Кызлар да һавага сеңгән төтен кебек юк булып, тынып калдылар.

Тыш якта да тынычлыкны бозардай тавышлар басылды. Төн буена яныма килергә куркып йөргән йокы да килде, ахрысы, әледән-әле авызым ачыла, күзем йомыла башлады. Ниһаять, татлы йокыга чумдым инде дигәндә өй артында гына мәче мырауларга тотынды. Шунда ук ана икенчесе кушылды. Ялындырып кына килгән назлы йокым тагын ялт юкка чыкты. Чөнки беләм: парлашып мәче мыраулый башласа, аны тиз генә туктар димә. Ул арта гына барачак. Торган саен дәһшәтлерәк, ямьсезрәк төс алачак. Беләм: Мәхмүт биргән рецепт та бу очракта файда китерә алмый. Юк инде, үземне ата мәче урынына куеп карар хәлем юк. Артык түзәрлегем калмады, нервaларым котыруга чыдый алмыйча, сикереп тордым. Йөгереп ишек алдына чыктым. Веранда түбәсендә күптән файдаланылмыйча ята торган өч метрлы бамбук чыбыгым бар иде, тиз генә шуны үрелеп алдым да, өй артына посып, шыпырт кына мәче мыраулаган урынга юнәлдем. Ай яктысында күрәм: берсе өй буендагы роза куагы төбендә утыра, икенчесе коймa буенда. Өй буенда утырганына чамалап, бамбук чыбыгымны җан-фәрманга селтәдем. Бик шәп төшәсе иде мәчегә, ләкин чыбыгым нәрсәгәдер тартылып, юнәлешен үзгәртте дә роза куагына туры килде. Кыштырдаган тавышка мәчеләр икесе дә атылып юкка чыктылар. Нәрсә комачаулады дип, чыбыгымны карасам, ни күрим: аның кармагы алынмаган җебе дә булган икән, кармагы чалбар төбенә эләгеп тартылган. Бу хәлне күргәч, әллә ачуым куык шикелле шартлап юкка чыкты, әллә хәлне аңлап, акылым эшне үз кулына алды — кинәт кенә тынычлан-

дым да калдым. Алдыма чалбар төбенә эләккән кармакны иплəп кенә ычкындыру проблемасы килеп басты. Әле дә тәнгә эләкмәгән дип куанам.

Менә шундый төн ул иртәгә балыкка чыгасы кичнең төне! Көтелмәгән куанычлар китерә ул сиңа, нерваларыңны чыныктыра. Буеңа карагандa үлчәвең авыррак булса, аны киметүгә ярдәм итә. Гомер юлында башыңнан үткән матур-матур хатирәләрне исеңә төшерә, кайвакыт күңел хәзинәңә яңа истәлекләр дә өстәп җибәрә...

Пәке ярдәме белән кармакны ычкындырдым, балак очлары кыршылган бөрмәле чалбарыма кечкенә булса да бер тишек ясап, аны балыкка кию өчен тагын да лаеклырак сыйфатка кертәкәч, яңадан урыныма килеп яттым. Бу вакытта сәгать икенче яртыны узган иде инде. Ә миңа өчтән дә калмый торырга кирәк. Тажи иртәрәк уятмаса тагы. Димәк, ни булса да, юк дигәндә бер сәгать йокларга мөмкинлек бар әле.



## ДҮРТЕНЧЕ БҮЛЕК

# Бик якынлашты кирәкле төш хәзер...

Тәки үземнекен иттем: йоклаганмын бит. Шулай да кеше килеп уятканны көтмәдем, нәкъ балыкчыга хас булганча, интуиция белән уяндым. Сикереп торып тышка чыксам, Тажи килә. Авыз ачып эндәшеп тә тормады, мине күрү белән кире борылды. «Уятырга килүем иде, сөйләшеп торырга вакыт юк, син дә тизрәк бул!» дип әйтүен ашыгыч хәрәкәтләреннән генә аңладым.

Миңа хәзер тиз генә моторны чыгарып көймәгә беркетергә дә кормушканы карарга кирәк. Тукта, малай да килде бит әле. Барасы килмәс килүен, шулай да... Карап торам, шундый тәмле итеп, чын күңелдән бирелеп йоклый, уятырга җәл. Төн буе гулять иткән бит ул мескен... Безгә аның әллә ни кирәге дә юк югын. Шулай да ул барса, мотор мәшәкатеннән котылам инде үзем. Әйтеп карыйм әле.

— Әй, төнге кунак, балыкка барасыңмы?

— Ә? — Күзләрен ачты, башта, берни аңламагандай, карап торды. Аннары төшенеп алды, ахры, авырсынмыйча гына торды, — әйдә, — диде. — Мин сиңа моторны чыгарып куям. Үзем бара алмыйм бүген, шәһәргә кайтасым бар.

Миңа шунысы гына кирәк тә.

Мин кат-кат төрелгән кастрюль эчендә кайнар килеш торган ботканы алып, җим капчыгы һәм башка кирәк-яракларны рәтләп, бәләкәй капкадан чыкканда, мотор урнаштырылган, аркан яки ишкәк кебекләре дә көймәгә ташып куелган иде инде. Сыра мичкәсе хәтле биштәрен аркасына асып, бер кулына спиннингы белән сачогын, икенчесенә чиләген тотып, Тажи да килеп җитте.

— Ярый, улым, рәхмәт. Барасың килмәсә, көчләмим.

Малай безгә хәерле юл теләп кулын болгады да ашыга-ашыга өйгә, йокларга кереп китте. Без тизрәк юлга чыгу ягын карадык. Юл уңаенда Мөхәммәтшаны алып китәсебез бар. Сөйләшкәнчә, төянеп, яр буена чыгып тормаса, кереп уятып йөрисебез юк... Чыкмыймы соң! Белә бит ул балыкчы сүзен. Әнә яр башыннан кул болгап тора. Авыз ерылган. Димәк, кәефе яхшы. Мөгаен, ир-атка да, хатын-кызга да үзара гына сөйләргә ярый торган берәр кызык яңалыгы бардыр.

Көймәне тырылдатып, борыны белән ком өстенә үк мендереп утырткач кына моторны сүндердем.

— Бигрәк озак йоклыйсыз, хәшәп! — дип каршы алды.— Көтә-көтә саргаеп беттем...

— Әйдә утыр тизрәк, теленә салынма. Башта көймәне этеп җибәр.

Бишләре белән чиләгеп көймәгә бирде. Җиңел генә этеп җибәрмәкче иде дә, көймә шактый нык утырган булып чыкты. Мышнап төште.

— Син, адаш, мине мыскыл итү өчен юри шушылай тау башына китереп мендердең инде моны.

— Зарланма, күрсәт көчеңне.

— Башка вакыт булса эһ тә димәс идем.

— Әле ни булган?

— Карманный туалетны онытмадыгызмы?

— Курыкма. Урынында.

— Төне буе авырып чыктым, хәшәп. Балыкка барасы булмаса, валлаһи, тормый идем.

— Ни булды?

— Тарихы зур. Бәхетегездән балык эләкмәсә, тегендә баргач сөйләрмен. Һуп!

Бар көченә омтылып, көймәне кузгатып җибәрде, үзе җиңел генә сикереп, борынга менеп тезләнде. Тажи бер-ике тапкыр кирегә ишүгә көймәбез ярга яны белән әйләнде. Суынып өлгермәгән мотор бер тартуда гөрли дә башлады.

Эх, бу җилсез иртәдәге Идел өстенең гүзәллекләре! Еракларга җәелгән сыгылмалы көзге. Күз алдында әледән-әле алмашынып торган яшел утраулар ике катланып, серле булып күренә. Уңда да, сулда да, артта да, алда да, өметләрне канатландырып, көмеш балыклар сикерешә. Йөрәкләрне җилкендереп, зур-зур чуртаннар уйнаганы күренеп кала. Ике утрау арасындагы тар бугазларны узганда су өстен мәгънәле дулкынландырып чабак өерләре кайнаша. Күңелләр ашкына. Кирәк урынга очып кына барып җитеп, тизрәк кармакларны төшерәсе килә. Бер минут та көттермичә саллы-саллы корбан балыклары эләгеп чыгасына күңелдә шик калмый. Берәрләп кенә дә түгел, икешәрләп! Кайбер салуда хәтта өч кармагыңның өчесенә берьюлы эләгеп чыкса да гаҗәпмени?

Хәзерге көймә моторларының бер кимчелеге бар: каты гөрлиләр. Сөйләшергә комачаулыйлар. Көймәдәшләрең белән матур тойгыларны бүлешеп булмый. Ләкин аның шул ук кимчелеге безгә файда да китерә. Сөйләшергә мөмкин булмау аркасында, кирәк урынга барып җиткәнче байтак кына хәзерлек эшләре башкарыла. Мин мотор тотып барам, Тажи белән Мөхәммәтша якорь бауларын сүтеп, аларны барган уңайга тукталмыйча гына ыргытырга җайлап куялар. Биш-ун минут кадерле вакытка экономия ясала.

Менә без зур-зур култыкларны, тар гына бугазларны, Идел белән кушылып чиксезгә әйләнгән күлләрне узып, зур елганың үзәненә килеп кердек. Каршыбыздан гына узган теплоход дулкынында чайкала-чайкала ашыгабыз. Бераз гына хәтәр дә, рәхәт тә. Хәтәр юллардан исәнсау үтү үзе күңелле бит әле ул. Менә кызыл маяк турысына җитеп киләбез.

Тукай әйтмешли, «бик якынлашты кирәкле төш хәзер».

Ничек итеп җан-фәрман барган көймәне егетләрчә авызлыклап кире боруым, Тажи белән адашның яшь матрослардан да болайрак житез һәм төгәл хәрәкәтләр белән якорьларны төпкә ташлап, көймәне агымга аркылы туктатып куюлары турында мактанып тормыйм. Бер минут вакытны әрәм итмичә, җим капчыкларыбызны төпкә төшереп җибәрдек. Җепләребезне чуалтмый-нитми генә кармакларыбызны да салдык. Тиздән эләгергә тиешле балыкларны сосып алу, сосып алгач, салып

кую өчен кирәк буласы сачок-садокларыбызны кул астына чыгардык. Тәҗрибә бар, беләбез. Балык дигән көйсез мәхлукның кармакларны салу белән чиртә башлаган чагы бик сирәк була торган хәл. Беренче унбиш минутны бик тыныч утырасың. Хәтта ярты сәгать көтү дә бик табигый тоела. Шуннан артыкка китсә, күңел дигәнең борчылырга чамалый башлый. Ләкин аңа сер бирмисең. Зарар юк, кайвакыт ике сәгать көттереп тә чиртә ул балык.



## Мөхәммәтша корсагыннан үткән хәлләр

— Ярар,— диде Тажи,— жим капчыгы тирәсенә балыклар җыела торсын, ә син, Мөхәммәтша дус, вәгъдә иткән тарихыңны сөйли тор.

Мин дә куәтләп куйдым.

— Әйе шул, чиртү башланса, тыңлап утырырга вакыт булмас.

Мөхәммәтша ялындырып тормады.

— Совхоз кибетенә җибәрде мине хатын,— дип башлап та китте.— Моннан өч көн элек. Чәй-шикәр алып кайтырга. Туры килсә, күкәй-фәлән дә алырсың, диде. Киләм. Көн эссе. Эчәсе килә бит. Күрәм — кое. Чыгырга уралган чылбыры да бар, чылбырга тагылган зур чиләге дә. Төшереп җибәрдем, тартып чыгардым. Мөлдерәмә тулы чиләкне бура читендәге тактага утыртып куйдым да эчтем бер рәхәтләнеп. Шундый чиста, тәмле салкын су. Эчеп туя торган түгел. Әзрәк хәл алдым да, тагы эчтем. Янымa бер хатын килеп чыкты. Юан гына. Тотты да мин эчкәннән калган суны үз чиләгенә сала башлады.

— Тукта, мин әйтәм, түтинкә, аннан бит мин эчтем, яхшы түгел. Түк анысын. Авырсынсаң, үзем икенчене чыгарып бирәм.

— Зарар юк,— ди теге тыныч кына.— Бакчага сибәргә генә алам.

— Алайса ярый, әллә эчәргә аласызмы дип торам.

— Бу коедан берәү дә эчми хәзер,— ди.

Шикләнә калдым.

— Ник?

— Аннан мәче үләксәсе чыкты,— диде дә китеп тә барды.

— Тфү! — дип куйды Тажи.— Каян килә синең башыңа җыен шундый әшәкелек?

— Алайса, сөйләмим, бетте.

— Я, башлагач сөйләп бетер инде. Шуннан?

— Шуннан шул: минем күңел әллә нишләп китте инде. Эч авырта башлагандай булды. Башка бәрде. Кая хәзер миндә чәй-шикәр кайгысы! Кәрҗин белән күкәй күтәргән бер хатын очрады. Аңа да тукталып торган юк. Йөгер мин кире өйгә! Кайтып кердем күзләрем аларып. Хатын аптырый калды.

— Нәрсә булды? — ди.— Ник төсең качкан?

— Эш харап, мин әйтәм. Шулай, шулай. Сөйләп бирдем хәлне. Хатын да житдиләнеп китте. Әмма үзен кулга алды. Беләсез, врач кеше.

— Курыкма,— ди бу миңа, тыныч кына.— Хәзер мин сиңа бер дару бирәм,— ди.— Ачкычын үзендә генә йөртә торган бикле шкафны ачты да, салды бирде миңа бер стакан чамасы спирт.— Эчеп җибәр шуны,— ди. Эчтем. Спирт настоящий! — Хәзер тыныч кына ятып тор,— ди. Яттым. Минде бит башка. Күңел күтәрелде, мәче онытылды. Ятып чыдар хәл юк. Тордым. Тел ачылып китте. Әллә нинди экәмәтләр кылә телгә. Хатын ачуланырга итеп карый, эчемә ябышып котын алам тегенең. Тагы йомшара. Даруын мактыйм. Бик килешергә итә, мин әйтәм, тагын бераз гына булса... Әллә чынлап курыкты, әллә болай күңеле

йомшак чакка туры килде, тәки тагын ярты стакан чамасы салып бирде бит. Беләсез инде минем хатынның ул мәсьәләдә рәхимсез икәнлеген.

— Туктале,— диде Таҗи.— Син бит безгә бүгенге авыруың турында сөйләмәкче идең.

— Сабыр ит, хәшәп! Тарихы зур дидем ич мин.

Кыскасы, ул көн шундый күңелле, матур үтте. Хатын да, мин дә бер-беребездән бик канәгать булдык.

Ә менә кичә тагын, юләрләнеп, шул матур эпизодны кабатлыйсым килде бит. Бу юлы совхозга түгел, теге якка барган идем, Обсерватория кибетенә. Кирәк нәрсәләр алынган. Арткы урамнардан кайтып киләм. Күрәм: кое, нәкъ теге кое төсле. Янына да бармадым, карап кына уздым. Килде бит башка юләр уй. Башны авыруга салып кайтып кердем. Алып кайткан әйберләремне идәнгә үк ташладым да караватка барып аудым.

— Ни булды? — ди хатын, янга килгән. Күрәм, борчыла.

— Әйтергә дә куркам,— дигән булам.— Барыбер ышанмассың. Ышансаң, гафу итмәссең бу юләрлегемне.

Чынлап ук куркына калды хатын да.

— Аптыратмасана, әйт. Бер бүген генәмени синең юләрлекләрең, ди.

— Тагы су эчтем,— мин әйтәм.

— Нинди су?

— Коедан. Ә аннан бүген иртән генә эт үләксәсе чыккан булган икән.

— Ай-һай...

— Әйттем бит, ышанмассың! — дидем дә үпкәләп йөзтүбән әйләндем. Укшыгандай итенә башладым.

Хатын җитдиләнде.

— Бу инде мәче генә түгел, җитдирәк чара күрергә кирәк,— диде дә, әлеге, ачкычын үз янында йөртә торган, шкафын ачты. Нәрсәдер алды. Кухня якка чыгып керде. Мин ятам йөзтүбән, янәсе, аның нишләгәнен ишетмим дә, күрмим дә.

— Тор әле,— ди бу миңа бер заман. Сыңар кулы белән иңбашымнан тотып, башны күтәрергә булыша. Тордым, стакан суза. Кызгылт сыекча белән тулы.— Эчеп җибәр шуны! — Сынатмадым. Эчтем. Иод тәме дә килә шунда, тагы ниндидер дару. Тагын нәрсәдер салып китерде. Карыйм, чиста. Эчтем. Спирт түгел. Мә монысын да! — Әллә марганцовка суза, әллә бүтән дару. Эчтән генә үземне тирги-тирги анысын да эчтем... Хәзер ике бармагыңны тамагыңа тык та укшы, ди. Башыңны и, менә монда. Карыйм, идәндә тас. Коса-коса җаным калмады. Ярты төнгә кадәр азапландым. Хатын бик канәгать булып янымда йөри. Мин эчемне бушаткан саен, әйбәт, әйбәт, тагын! — дип куя. Мин тик яткан араларда ачуланмыйча гына битәрли.— Бәләкәй бала түгел бит инде син, җаныкаем,— ди.— Укымаган кара мужик та түгелсең, теләсә кайда, теләсә нинди коедан кайнамаган су эчеп йөрергә...

Менә шул, әле дә тамак төпләрем авыртып тора. Балыкка барасы булмаса, валлаһи, бүген көне буе авырып ята идем...

## Балык чиртмичә әләгәме?

Ышанып бетмәдек, әлбәттә. Шулай да көлештек. Таҗи ниндидер тәнкыйть сүзе дә әйтмәкче иде. Тик: «Синең бу хикәяң, Мөхәммәтша туган, бик үк...» дияргә генә өлгерде. Бер кармагына чиртә башлаганны күреп, бүленеп калды. Күзләре акаеп китте. Көймәне дер селкетеп, кармагын чыгара башлады. Дустыбызның гадәтен белмәсәк, кимендә ике килолы корбанны каптырды бу дип уйлар идек һәм кулыбызга сачок тотып, ярдәмгә әзерләнер идек. Ә без кымшанмадык та. Шулай

да кызыксыну тойгысы уянды. Бар игътибарыбыз анарда. Әй тарта теге җепне, әй чыгара, әй сава, әй кабалана!.. Ун метрдан артык бит. Беренче балык, почин дигән сүз! Барыбызны да кызыксындыра. Нәрсә килеп чыга хәзер?! Ниһаять, килеп чыкты. Чәнчә бармак хәтле шыртлака. Көлешкән булдык. Таҗины мондый уңышы белән мыскыл итәргә маташкан булдык. Ә дөресен әйткәндә, барыбыз да күнелсезләндек. Чөнки беләбез, тәҗрибә шуны күрсәтә: шыртлака бар җирдә күбесенчә юньле балык эләкми торган була.

— Әйе, яхшы фал түгел! — диде Таҗи үзе дә.

Шуны раслагандай, мина да чия яфрагы хәтле генә корбан баласы килеп эләкте. Тагын көлешкән булдык.

— Нигә,— мин әйтәм,— гадәттә һәр хайванның баласы, кечкенәсе матур күренә. Ә балыкның — зурысы?

— Син шунысын әйт,— диде Таҗи.— Ни өчен кармакка күбрәк вак балык эләгүчән? Хәтта тирән урында да?

Бусына Мөхәммәтша җавап тапты:

— Чөнки балыклар да кешеләр кебек,— диде.— Берәр тәмлерәк ризык күрсәләр, балам ашасын дип, өзелеп торалар. И шуның белән сөекле балаларының башына җитәләр.

Юк-барны сөйләшеп утыра торгач, тиешенчә чиртү вакыты да җитте. Узып та бара. Ә балык юк, чиртми дә. Андый вакытта эч поша башлый. Утырабыз боегып, һәркайсыбызның иреннәре кыймылдый. Нигә кыймылдый? Анысы турында...

Чү! Таҗи дустыбыз түзмәде.

— Нигә бу кадәр боектыгыз әле, егетләр? — диде.— Күңелсез бит болай. Боеккач-боеккач, күңеллерәк итеп боегырга кирәк. Пан директор әйтмешли, веселее надо грустить, веселее!

Мөхәммәтшага җитә калды.

— Беләсезме? — диде.— Пан директор дигәннән, «Унөч урындык» кабачогын без карамый калмыйбыз. Һәркайсыбызның бер яраткан персонажы бар. Мин үзем Терезага гашыйк. Шул чыкканны гына көтеп утырам. Ә хатынга сиздермәс өчен, мина пан Гималайский ошый, дигән булдым. Хатын да хәйләкәр. Экранда Тереза килеп чыкса, мина йомыш таба: чәйнекне карап кер әле, кайнамый микән? — ди. Ык-мык итә башласам, тынычландырган була.— Курыкма, пан Гималайский күренсә, мин сина кычкырырмын,— ди, явыз...

Бездән дә бигрәк Мөхәммәтша үзе рәхәтләнеп көлде. Тагы тынып калдык. Балык һаман чиртми. Чиртмичә дә эләкми.

— Балык чиртмичә дә эләгәмени?

Шулай дип соравы мөмкин кайберәүләрнең (әйтик, балык тотуның күп серләрен белмәгән кешеләрнең).— Әйе,— дибез без андыйларга.— Чиртмичә дә эләгә. Хәтта, мин әйтер идем, без тоткан җирдә гомумән күбрәк чиртмичә эләгә. Бигрәк тә корбан. Шундый ялкау балык ул. Суалчанны яки кортны кармагы-ние белән авызына каба да, китәргә ашыкмыйча, бер урында суырып тик ята. Суырып беткәч, кармагын төкереп ташлап, китеп бара. Шуннан соң инде юләр балыкчы (балыкчының безнең кебек акыллысы да була, әлбәттә), җимсез кармагына балык чирткәнне көтеп, сәгатьләр буенча боегып утырырга мөмкин. Мондый хәлгә калмас өчен, нишләргә кирәк? Чирткәнне көтмичә, җебенне әледән-әле тартып карарга кирәк. Нинди ешлыкта тарту — анысы балыкның ничек эләгүенә карап билгеләнә. Мин үзем, мәсәлән, чиртү бер дә юк вакытта, кармагым төпкә барып җиткәнне сизгәннән соң, авыз эченнән генә утыз өчкә кадәр саныйм да кармак сабын капыл гына күтәреп куям. Ялкау корбанның суалчанны гамьсез генә суырып яткан чагы булса, шалт! Эләкте дигән сүз. Тиз генә чыгарып балыкны ычкындырып аласың да, җимен рәтләп, кармакны тагын төпкә төшереп җибәрәсең. Хәзер инде егерме бергә кадәр санау да җитә (чөнки балык

өере белән йөрергә ярата). Егерме бергә дә эләктердең, ди. Аннан арыгысын уналтыга кадәр генә сана. Әһә! Уналтыга да эләкте. Инде унөчкә төш... Җидегә, өчкә кадәр барып җитәргә мөмкин. Эләкми башласа кире утыз өчкә таба юл тот. Утыз өчкә дә эләкми башласа, илле сигезгә кадәр сана, ул да ярдәм итмәсә, туксан тугызга... Ә инде туксан тугызга кадәр туксан тугыз кат санаганның соңында да эләкмәсә, тәсбих тарткан әбиләр шикелле, юкка иреңеңне кыймылдатып утырма, ул урыннан күчеп кит.

Без дә шулай иттек.

Сәгатьтән артык санап утырып та, юньле балык урынына тагын бер өтек шыртлака килеп эләккәч, тәмам сабырым төкәнде:

— Әйдәгез,— мин әйттем,— күчәбез. Уңышсыз урын булып чыкты бу.

Иптәшләрем күптән шул теләктә икән, тик көймә хуҗасы мин булганга, әйтергә кыймый утырганнар. Шатланып риза булдылар. Дәррәү кузгалып, җим капчыкларыбызны да, якорьларны да күтәреп алдык. Ике йөз метр чамасы түбәнгәрәк төшеп һәм маяктан да эчкәрәк кереп, яңа урынга утырдык. Бу мәшәкатьле эшкә, әлбәттә, унбиш, егерме минутлап кадерле вакытыбыз китте. Анысы бер хәл иде. Яңа урыныбыз искесенә караганда уңышсызрак кына түгел, көтелмәгән дәрәҗәдә бәлале булып чыкты. Мин әле кармагымны рәтләп, су төбенә төшерергә дә өлгермәгән идем. Таҗи күңелгә шом салырлык тынычлык белән:

— Капты! — дип куйды.

— Кормушкаңа эләккәндер,— диде Мөхәммәтша.

— Ай, кормушкага гына булса!

Аларга игътибар итмичә, тизрәк үз кармакларымны салырга ашыктым. Ул арада адаш аңарга гына хас образлы телдә үзалдына тиргәнергә тотынды. Ике-өч секунд эчендә аның авызыннан чыгып өлгергән катлаулы җөмләдән кәгазьгә язарлык ике генә сүз ишеттем:

— Чукынды мөртәт.

Димәк, кармаклары төпкә эләккән. Инде алар өчен тагы яңа урынга күчәргә кирәк булыр микәнни? Ышанасым килми. Дөресрәге, исәпләшәсем килми мондый хәл белән. Тегеләргә бөтенләй игътибар итмәскә тырышып, үз кармагымны киереп тоткан хәлдә, санарга керештем: бер... ике... өч... утыз өч! «Һап!»

Үзем дә сизмәстән, әле генә Мөхәммәтшадан ишетелгән сүзне әйтеп җибәрдем.

Моңарчы үзләрен гаепле хис итеп, тавыш-тынсыз гына җепләрен тарткалап, кармакларын ычкындырырга азапланган Таҗи белән Мөхәммәтша, минем дә кармак төпкә эләккәнне белгәч, иркенрәк тын алгандай булдылар.

— Димәк,— диде Мөхәммәтша күтәренке тавыш белән,— бу урында дию парие кадәр коряга ята.

— Өзелде! — диде Таҗи, шул ук тынычлыгы белән,— дүрт кармагым да китте.

— Минеке дә.

Дию парие минем дә бер кармакны алып калды.

— Яхшы чакта ычкыныйк бу урыннан. Таҗи, күтәр якорьны!

— Тукта, башта җим капчыгын алыйм.

Аның җим капчыгы да эләккән булып чыкты. Һәм шактый нык. Миллиметр калынлыктагы капрон кылга тагылган капчык — ычкынмый да, өзелеп тә чыкмый. Әй тарта тегене Таҗи, әй тарта. Дөнья кадәр вакыт узып китте, һаман тарта. Әллә ниләр кыландырып, әле уңга, әле сулга кыегайтып тарта торгач, Таҗи кинәт тынып, сагаеп калды.

— Егетләр,— диде, серле пышылдап.— Коряга түгел бу, балык. Зур балык йоткан кормушканы. Шул бирми!

— Ак аю түгел микән? — диде Мөхәммәтша.

— Шаярма. Балык дырылдатканны тоймаска, мине син кем дип беләсең? Ышанасың килсә, мә үзең тотып кара әле.

Ләкин ул Мөхәммәтшага тоттырырга өлгермәде, кормушкасы күтәрелә башлады.

— Ычкынды.

— Шулай диген. Балык, имеш!

— Валлаһи әгәр, балык иде...

Җим капчыгы шактый бушаган булып чыкты. Ләкин нәрсә аны шулай озак җибәрмичә торган,— бу сорауга җавап бирерлек бернинди дә билге юк иде.

— Ярар. Балыкчының чираттагы саташуы булгандыр. Чыгар тизрәк якорьны, болай да күп вакыт әрәм иттек.

Гөнаһ шомлыгына каршы, Таҗи ягындагы якорь да нәрсәгәдер эләккән иде.

— Нәрсә, әллә якорьны да җәен йоткан? — диде адаш, мыскыллы көлеп.

Әмма шаяра торган мәсьәлә түгел иде бу. Кармак яки җим капчыгының җебен өзеп котылып була. Ә якорь эләксә!.. Баштан үтмәгән хәл түгел, тәҗрибә бар: кайвакыт икешәр сәгать азапланасың. Якорь шикелле кадерле нәрсәне капроннан ишкән арканы белән су төбендә калдырып китәсе килми. Болай гына көч җитмәсә, моторны кабызып тарттырып карарга кирәк булыр.

Бәхеткә каршы, эш аңа барып җитмәде. Таҗиның артык көчәнеп тартудан тәмам сүнә башлаган соры күзләрендә өмет уты кабынып китте.

— Килә! — диде ул, шартлар чиккә җитеп.— Валлаһи, нәрсәдер килә.

Мөхәммәтша да җанланып китте.

— Дию пәрие үземе?—диде.—Чыгар әле, кирәген бирик, кабахәтнең.

— Телең белән түгел, кулың белән булыш!

Икәүләп тарта башладылар.

— Раз, два... взяли! Еще-е-взяли!

Ниһаять, күренде. Җәтмә! Ике башы су төбендә калган озын җәтмә.

— Эче тулы балык! — дип кычкырды Таҗи.— Стерлядь!

Бу хәлне күргәч, Мөхәммәтша, утка пешкән шикелле, кулларын баудан тартып алып, көймәнең уртасына ук килеп утырды.

— Җибәр ычкындырып,— диде ул.— Бәласеннән башаяк.

Ләкин Таҗи җибәрергә ашыкмады. Көч-хәл белән тынын ала-ала, якорьга эләккән җәтмәне үзенә таба тартуда дәвам итте.

— Юк инде,— ди иде ул, аһылдый-аһылдый.— Җибәрми торсын! Браконьер эше бу. Башта минем кармакларымны кайтарып бирсен. Азапланган өчен балыклары да хәләл.— Таҗи хәзер җәтмәне көймәгә китереп җиткереп, кулы белән тоткан иде инде. Көймә читендә генә җәтмә җебенә уралган беләк буе чөгә тыпырчынганы күренде.— Әһә! Менә кем дырылдаткан минем кормушканы. Үз гомеремдә мондый зифа буйлы чөгә эләктергәнем юк иде! Кил әле монда, гүзәлем...

Мөхәммәтша җитдиләнеп, хәтта кырысланып китте.

— Ташла, Таҗи, юк белән пычранма.

— Юк инде, браконьерга карата либераллык күрсәтү...

— Нинди браконьер, синең белән минем кебек балыкчылар салган җәтмә...

— Наусы балыкчы булса, буёгы булыр иде. Без дә аның өстенә салып, кармакларыбызны өздермәс идек.

— Браконьерга бәйләнү тагын да начаррак. Әллә син аны белмәс дисеңме? Мөгаен, шушы минутта да берәр җирдән карап, бинокль белән күзәтеп торадыр.

Тажи җәтмә җебенә уралган чөгә балыгын ычкындырып алалмый азаплана, үзе көчәнә-көчәнә һаман сөйләнә иде.

— Карап торса торыр. Бу балыкны ычкындырыр хәлем юк. Җаным фида. Унбиш тәүлек мәҗбүри хезмәт белән җәзаласыннар...

Ниһаять, ул, мең азап белән булса да, чөгәне аралап алып, көймәгә салды. Ләкин җәтмәне һаман ычкындырмады.

— Нишлисең инде тагы? — диде Мөхәммәтша, борчылып.

Тажи җәтмәне тартуын белде.

— Монда барыбызга да җитәрлек хәзинә!

Һәм чынлап та җәтмәгә уралган чөгә, корбан балыклары шактый күп күренә иде.

Мин үзем бу хәлгә аптырый калдым. Мөхәммәтша да хаклы кебек, Тажи да. Чынлап та, шушы хәлдә ул җәтмәне кире су төбенә ташлап китсәң, җинаятьчегә юл кую була. Шул ук вакытта бу балык бит безнеке дә түгел. Бармы безнең моңа мораль хакыбыз?..

## Нишләвегез бу?

Бу четерекле сорауга җавапны тормыш үзе бирде. Бөтен игътибарыбыз бәхәсле җәтмәгә юнәлгән булгангадыр инде, күрми дә калганбыз, яныбызда еермә шикелле шаулап, зур гына көймә килеп туктады. Моторы да «Вихрь» икән шул. Таза-таза гына ике кеше утырган.

Тажи дустыбыз, әллә үҗәтләнеп, әллә каушавыннан нишләгәнен онытып, җәтмәне һаман ычкындырмый тотып тора иде.

«Вихрь»ле көймәнең уртасында утырган мыеклы кеше шактый кырыс тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Нишләвегез бу?

Тажи да алай бик коелып төшмәде, тегенең үзе шикелле тупас кына җавап бирде.

— Нишләгәнне күрмисезмени?

— Браконьерлык белән шөгыльләнәсез?

— Киресенчә, браконьерларга каршы көрәшәбез.

— Кем җәтмәсе?

— Бәлки сез беләсездер?

— Документыгыз?

— Ә сезнеке?

— Рәхим итегез.

Ярым хәрби, ярым милиция формасында киенгән мыеклы кеше кызыл тышлы таныклыгын ачып күрсәтте. Балык сакчылары икән. Эчкә җылы кереп китте. Мин аларны җәтмә хуҗалары дип, ягъни явыз ниятле браконьерлар дип белгән идем. Дөресен әйткәндә, андый кешеләр белән иге-чиге күренмәгән Идел өстендә пычакка пычак килү бик күңелле эш булмаячагын уйлап, эчтән генә шүрләп тора идем. Бик рәхәтләнеп, хәлнең ничек булганын сөйләп бирдек.

Ләкин балык сакчылары ансат кына ышанырга теләмәделәр. Штраф турында сүз чыкты. Җәтмәдә өзелеп калган кармакларыбыз аларны ышандыру өчен кире кага алмаслык көчле дәлил булыр дип уйлаган идек. Аңа да исләре китмәде. Янәсе, браконьер халкы әллә нинди хәйләләр уйлап чыгарырга оста була. Ышан син аларга! Әнә анда, Камада, хәтта вертолет белән тота башлаганнар балыкны браконьерлар,— дип куйды мотор янында утырганы. Мин аны, әлбәттә, чынга алмадым. Көләсе дә килмәде. Җитмәсә, яныбызда бернинди документ та юк. Бары Мөхәммәтшаның гына җәйге сезонга алган тимер юл билеты бар икән. Бакчачылар икәнлегебезне әйттек. Аның өстенә, сөйләшүләребездән чамалап, зарарлы кешеләр түгел икәнебезне аңладылар, ахрысы, бераз ипләнә төштеләр. Хәтта мыеклысы нидер сизенгән-

дәй, татарчалатып (моңарчы сөйләшү рус телендә бара иде) сорап та куйды.

— Әлләме сез газета тирәсеннән?

Моңарчы эндәшми утырган Мөхәммәтша, нәрсәдәндер илһамланган-дай, кинәт җанланып китте.

— Кешене таный беләсең икән, агай-эне,— диде.— Газетчы гына түгел, атаклы язучы утыра синең каршыңда. Драматург! Менә бу! — Ул кулы белән минем теземә сугып куйды.— Мирхәйдәр Фәйзи абзаң булыр бу! Бармы «Галиябану» дигән спектакльне караганың? Шуны язган кеше булыр бу!

Мыек, сәерсенеп, күзләрен миңа төбәде. Мин уңайсызлануымнан нишләргә белмим, битем, колакларым ут кебек янганын гына тоям.

— Галиябану? Сылуым иркәм? — дип куйды мыек.

Кире каксам, эшне тагын да боза төшәрмен дип куркам, расларга да намусым җитми. Аптырагач, Мөхәммәтшага ачуланган булам.

— Арттырасың ла. Нигә кирәге бар аның монда?

— Ә сез нигә тартынасыз? — диде мыек.— Гордиться итәргә кирәк.

— Ә монысын кем дип беләсез? — диде Мөхәммәтша, Таҗины күрсәтеп.— Каюм Насыйри турында ишеткәнегез бармы?

— Каян хәтерләп бетәсең барын да.

— Аны белмәгән кеше юк; галим, атаклы тәнкыйтьче!

— Тәнкыйтьче, ә үзе балык орлый.

— Нинди урлау булсын...

— Бурныкын карак орлый.

Көймә хуҗасы буларак, җаваплылыкны үз өстемә алырга туры килде.

— Шулаен шулай килеп чыга инде дә,— дидем.— Әмма хәрам юл белән булса да эләккән балыкны күрә торып җинаятьчеләргә калдырып киткәнче, бик үк килешмәсә дә, үзебезгә алу дөресрәк түгелмени?

— Ә сез, иптәш Галиябану, белмисезме, стерлядьны тотарга закон кушмый?

— Беләм. Рас тотылган икән инде...

— Алар бит үлмәгән!

— Безнең урында үзегез булсагыз, нишләр идегез икән?

— Менә без болай эшләр идек,— диде мыек, житез генә урыныннан торып, җәтмәне Таҗи кулыннан алды. Шундук иптәше ярдәмгә килде. Гаҗәп бер ансатлык белән җәтмәне чыгара-чыгара әчкә таба йөзделәр. Җәтмәгә уралган эре-эре чөгә балыкларын азапланмыйча гына ычкындырып, суга җибәрә башладылар.

Минем өчен гаҗәп зур бер ачыш булып күренде бу хәл! Җәтмәгә эләккән балыкларны, житмәсә шундый сирәк очрый торган гына түгел, безнең кебек хәләл кәсеп белән көн күрүче кешеләрнең төшенә дә керми торган эре, матур, тере чөгәләрне кире суга җибәрү! Башыма да киләсе түгел иде. Таҗига исә бу хәл бөтенләй акылга сыймый торган эш булып күренде бугай, түзә алмады, кычкырып җибәрде:

— Нишлисез сез? Җүләрлек бит бу! Ичмасам, бер-икесен калдырыр идегез. Шул бәлале җәтмә аркасында бөтенләй балыксыз кайтабыз бит.

Мөхәммәтша авызын ерү өстенә, кып-кызыл теш казналарын да күрсәтеп, нидер әйтә-әйтә рәхәтләнеп көлә, тик: «Кай... Ка... Каюмның йөрәге ярылмасын!.. Вали-вали... валидол каптырыгыз!» дигәнен генә аңлап була иде.

Адашның йөгәнсез шуклыгы белән Каюмга әйләнгән Таҗи чынлап та бу хәлне бик авыр кичерде.

— Ничек итеп кулың барырга кирәк? Хет үзегезгә алыгыз, юләрләр, әзрәген генә булса да,— дип һаман сөйләнә иде.— Гомер эчендә бер генә туры килә торган хәл бит бу...

Әллә аның шулай үзгәләнүе, әллә «Мирхәйдәр Фәйзи», «Каюм Насыйри» кебек серле исемнәр тәэсир итте, Идел сакчыларының миһербаннары килде бит. Җәтмәнең бер як яртысын җыеп алып, икенче башына күчкәч, мыеклы начальник бөтенләй «дубрыйланып» китте.

— Болары тыелган парода түгел, мәгез,— дип, таба кебек җәелгән биш-алты корбанны безнең көймәгә ыргытты. Бу юмартлыгының мәгънәсен иптәше дә аңласын өчен, русчалатып, үзалдына әйтеп куйды.— Наши известные писатели! — Аның белән генә дә чикләнмәде.

— А эти почти дохлые. Все равно погибнут,— дип, тыпырдап торган биш чөгәне өстәде.— Әйдә, рәхәтен күр. Каюм агай, омсынып калма.

Бушап калган җәтмәне җыеп үз көймәләренә алгач та китәргә ашыкмадылар әле. Күренеп тора, өлкән сакчының безгә нидер әйтәсе килә иде.

Таҗи үзе дә белмичә аның бу теләгенә юл ачты. Бөтенләй эреп төште ул. Сүзгә саран нәрсә,— көтелмәгәнчә телдәрләнеп китте.

— Агай-эне икәнсең, әйтсәм әйтим инде,— диде ул,— башка вакыт булса, мондый юл белән килгән балыкны бәлки аласым да килмәс иде. Ә бүген миңа балыксыз кайтырга ярамый. Үзем тота алмасам, акчага сатып алырга, акчага таба алмасам, урларга әзер идем. Кунакларым бар, хәлне аңлавыгыз өчен рәхмәт сезгә.

— Төрле вакыт була адәм баласының тормышында,— диде теге агай-эне.— Үзем дә сезгә тап булгач, уйлап торам әле. Оят булып китте берсәк. Рәнҗеп калмагыз безгә. Вот сез,— диде ул карашын миңа төбәп,— Галиябануны язган кем дидегез әле... Мирхәйдәр абзый? Ялганчы буласым килми, китабыгызны күргәнем юк. Җырыннан гына ишетеп беләм. Ә үзегез... сез инде мине кичерегез, мин сезне күптән вафат кешедер дип уйлый идем. Хотя уйлаганым да юк. Просто дөньяда бар дип тә белмәс идем. Юньләп укып та булмады, үзебезнең мөселман телендә вовсе. Максим Горькийны беләм. Шолоховны да, Василий Теркинны да укыштырган бар. Ә үзебезнең мөселманнан зур кешеләрне... Әнә Муса Җәлилне беләм. Аны да русчадан укыштырып. Ә бүтәннәре. Менә сез,— ул инде Таҗига борылды.— Насыйри агай дидегез? Ачулансагыз ачуланырсыз, ишеткәнем дә юк сезнең турыда. Бик яшьли вербоваться итеп киттем Себер ягына. Эшләмәгән эш калмады. Нижне-Камскида милиционер булып йөрдем. Яңа калада вытрезвиловка ачылгач, беренче исерекне айныткан кеше мин...

Бу беркатлы кешенең безгә шулай ачылып китүе җанны эретеп җибәрде. Аның белән ныклабрак танышырга, исем-фамилиясен, адресын белергә ниятләп авызымны гына ачкан идем, көймә түренә утырган егет моторын кабызып җибәрде. Мыеклы сакчы үзе дә тагы нидер әйтергә теләгән иде кебек, ләкин әйтә алмады. Хәрәкәткә килгән мотор, сөйләшергә бирми бер урында тырылдап әз генә торды да алга таба алып китте. Күптәнге танышыбыз күк тоела башлаган мыеклы дустыбыз безгә кулын гына болгап өлгерде. Рәхмәт әйтеп кычкыруыбызны да ишетмәгәндер...

— Менә тип! — диде Мөхәммәтша. Ул хәзер өр-яңадан сыны катып көләргә тотынган иде.

Ләкин минем көләсем килмәде.

— Шулай да әйбәт эшләмәдең син, адаш!

— Нәрсәсе начар? Рәҗе безнең кармакка мондый балыклар эләгәсе бар иде. Икешәр килолы корбан бит болар, хәшәп! Ә стерлядьлары! Стерлядьның мин тере килеш нинди икәнен күргәнем дә юк иде.

— Шулай да үзең тотканга җитми. Ләкин эш анда түгел. Шундый әйбәт, саф күңелле кешене мыскыл итүең ямьсез килеп чыкты.

Мөхәммәтшаның тагы сыны катты.

— Менә суфи! — ди мина.— Тапкырлыгым өчен рәхмәт әйтергә тиеш сез мина. Андыйларны шулай кызык итмәсән...

Әйлән артына, Мөхәммәтша,— диде Тажи кырт кына.— Әле һаман көймә эчендә сикергәләп яткан балыкларны ул тавыш-тынсыз гына өчкә бүлеп куйган иде инде.— Кычкыр, бу кемгә?

— Ал үзенә.

— Бусы?

— Мина.

— Калганы көймә хужасына.

Көтелмәгән мажара белән иртәнге сәгатьләр узып китте. Мотор тавышы астында сөйләшмичә генә кайтып барабыз. Күнелдә бер ямьсез төер бар. Шулай да юкка артык борчыласым килми. Бүген өчен ин әһәмиятлесе — балыксыз кайтмыйм. Шунысын уйлыйм: өйдәгеләр дә, киләсе кунакларым да бу балыкларны үзем тотканга ышанмаячак. Сатып алдым диярга туры килер микән?.. Ә нигә дөресен әйтмәскә? Бу бит үзен тотканнан да кызык...

Нәкъ шул минутта Мөхәммәтша төшәсе яр буена килеп життек.

— Тик, агай-эне, карагыз,— диде Мөхәммәтша.— Бу жәтмә вакыйгасы турында беркемгә бер сүз әйтмәскә! Андый хәбәр тиз таралучан. Хужаларына барып ишетелсә, хәшәп!..

Саубуллашу сүзе шул булды. Ләкин... ай-һай, мондый кызыклы серне агай-эне, дус-иштән яшереп тотарга көчем житәр микән?

## Утсыз төтен булмый

...Үз турыбызга килеп житкәндә карт Андрюшин, кармак чыбыкларын тезеп салган хәлдә, көймәсендә елмаеп утыра иде. Безне күрүгә чиләген күтәреп урыныннан кузгалды. Сак хәрәкәтләр белән ашыкмыйча гына көймәсеннән чыгып, безгә каршы килде. Димәк, ярыйсы гына эләктергән. Чынлап та анын чиләгендә матур-матур гына алабугалар кайнаша иде.

— О-о-о! — диешкән булдык без, картнын күнелен күтәрү өчен.— Петр Петрович вакытны әрәм итми!

Чынлап та күнеле булганын шуннан белдек: елмаюы тагын да арта һәм мөлаемлана төште. Безнен садоклардагы зур-зур корбаннар белән эре-эре чөгәләрне күргәч, кинәт елмаюы бетеп китте.— Бу инде анын чын-чынлап гажәпләнүе иде. Хәтта теле ачылды.

— Да-а-а! — диде.— Бүген бөтен балыкчылар зарлана, чиртми торган көн,— диләр. Беләсезме, хәтта Георгий Мухтарович үзе балыксыз кайткан бүген.

— Булмас ла?

— Әнә, Толяга зарланып утыра.

Бабай үз калиткаларына таба борылуга, каршысына Анатолий белән Жор үзләре килеп чыкты. Бабай безнен балыкларга соклануын эчендә генә яшереп кала алмады:

— Әнә безнен күршеләр бүген сездән уздырган, Георгий Мухтарович! Карагыз әле.

Янибызга Жордан алда Анатолий килеп житте һәм рәхәтләнеп, гажәпләнүенен бөтен шартын китереп, шакатты. Жорнын өлгергән помидор кебек йөзен күргәч, Тукайнын «оялгандыр дия күрмә, жибәргәндер дисән әүла» дигән куплеты искә төште. Әлбәттә, жибәргән. Ләкин үз-үзен тотышыннан, теленнән белерлек түгел. Безнен балыкларны күргәч тә анын исе китмәде. Тик күзләрендә бик әзгә генә ниндидер сорау билгесе чалынып киткәндәй булды.

— Кемнән? — диде ул гамьсез бер тынычлык белән.

Ихтыярсыз күңелемә «мөгаен, шушының җәтмәсен арчыганбыз» дигән уй кагылып узгандай булды. Мактану тойгылары онытылды. Үзем дә сизмәстән:

— Утраудагы балыкчылардан,— дип җавап бирдем.

— Күренеп тора,— диде дә Жор үзенең «Вихрь»лы алюмин көймәсенә юнәлде. Бабай да яңадан кармаклары янына керел бара иде инде. Анатолий гына безнең яннан аерыла алмады. Ул һаман шат иде.

— Чынлап та үзегез тоткансыз дип торам,— диде ул, көлеп.— Әмма мондый балыкларны көмеш кармакка эләктерү дә сирәк очрый торган бәхет.

Ул арада Жор, моторын үкертеп, кузгалып китте, күздән дә югалды.

— Нәрсә, Жор чынлап та балыксыз кайтканмыни? — диде Таҗи.

Анатолий кулын селкеп, көлеп куйды.

— Аңа ышану да кыен. Икенче берәү кыйммәтрәк түләгәндер дә безгә китереп җиткерә алмагандыр. Ул бит гомумән сүзсез кеше. Бигрәк тә ялган сөйләр дип, башыма да килмәс иде. Ә беләсезме: нәрсә сөйләде ул миңа? Беркем дә белми торган урынга җәтмә салган булган икән, иртүк караңгылы-яктылыдан карарга чыккан, барып өлгермәгән, имештер, һавадан бер вертолет килеп төшкән дә, ал тәгәрмәче белән монын җәтмәсен эләктереп, кире һавага күтәрелгән. Яр буендагы урман өстенә китеп, күздән югалган. Җәтмәгә эләккән балыкларым җепкә тезгән мәрҗән шикелле, ялтырашып, асылынып барганын гына күреп калдым,— ди.— Анатолий үзе үк кычкырып көлеп тә җибәрде.— Ялганлавының да рәте юк. Вертолет! Нинди юләр ышансын?! — Ул тагын кычкырып көлде. Мин дә, Таҗи да көлмәдек. Вертолет белән балык тотучы браконьерлар турында теге рыбнадзор кешесе дә нәрсәдер әйтте бугай бит? Мин аңа игътибар да итмәгән идем. Чынга да алмадым шикелле. Инде килеп монда ишетәм.

— Карале, мин әйттем, Таҗи дус. Вертолет белән балык тотучылар турында без дә кайдадыр ишеткән идек түгелме соң?

— Ишеттек,— диде Таҗи, исе китмичә генә.

— Әллә чынлап шундый хәл бар микән?

— Утсыз төтен булмый.

— Барыбер ышанмыйм,— диде Анатолий, кулын селкеп.— Балыкчы ялганы. Аның да аламасы.

— Нигә гаҗәпләнергә? Айга очудан да катлаулырак эш түгел яки Венерага.

— Ә сезнең вертолетта очканыгыз бармы?

— Әби булып әбиләр оча хәзер вертолетта, корсаклы хатыннар.

— Анысы шулай,— диде Анатолий, бераз йомшарып.— Минем күп очканым бар. Пассажир өчен берни түгел. Ә менә су өстендәге әйберне эләктереп кара син? Бердән, вертолеттан торып су өстенең ераклыгын дөрес чамалау читен. Су алдый! Әйтик, син су өстеннән 50 метр биеклектә. Ә ул сиңа 5 метр хәтле генә булып күренә. Икенчедән, суга якынайган саен винттан бәргән җил белән су өстендә өермә уйный. Менә шунда төшеп, ал тәгәрмәчеңне, су эченә батып торган җәтмә астыннан үткәреп, эләктереп кара син! Ас булырга кирәк моның өчен, виртуоз булырга!

Таҗи, авызын күтәреп, тавышсыз гына көлеп куйды.

— Безнең татар халкында шундый бер мәкаль бар,— диде.— Этлеккә тәһарәт кирәкми, ди.

— Начар мәкаль түгел,— диде Анатолий.— Шулай да андый эшне башкара алган очучы булса, мин аны дәүләт премиясенә тәкъдим итәр идем.

**БИШЕНЧЕ БҮЛЕК**

## Чакырылмаган кунак

Көткән кунакларым килмәде. Ял көнем күңелсез узмакчы иде, бирешмәдем. Моңа караганда күңелсезрәк хәлләрне дә күрмәгән кеше түгел без. Бер уйлаганда, килмәүләре яхшырак та. Килсәләр, хәзер миңа алар белән ничек итеп күңел ачуыбыз турында язарга кирәк булыр иде. Дус-ишләр белән мәҗлес корып, кызык сүзләр сөйләшеп, кәефләнеп утыру күңелле, ләкин ул турыда язу күңелсез. Язган тәкъдирдә дә укучыдан рәхмәт ишетүең икеле. Чөнки аны уку тагын да күңелсезрәк. Игътибар иткәнегез бармы икән? Тормышта бәйрәм дигән нәрсә үзе бик күңелле, ә бәйрәм турында язганны уку бик үк күңелле түгел. Әгәр миннән: теге яки бу газетаның я журналның иң күңелсез саны, синеңчә, кайсы? — дип сорасалар, бәйрәм саны дип җавап бирер идем. Парадокс, әйеме? Шулай булуы табигый микән, әллә журналистларыбыз гаепләме? Бу турыда Фәнил белән гәпләшәсе булыр әле. Ә хәзергә...

Иң элек бик әйбәтләп, төне буе уяу ятканның хакын чыгарырлык итеп йоклап алдым. Аннары су коенып, анадан яңа туган кебек сафланып, җиңеләеп чыгуыма, теге мажаралы балыклар, мәкальдә әйтелгән насыйп аш шикелле, тешне сындырып авызыңа керердәй булып, өстәлгә менгәннәр иде. Көткән кунаклар килмәсә дә, ул балыкларның ашалмый калу куркынычы юклыгын, укучы, шаять, үзе чамалый торгандыр. Бик әйбәт күршеләрем барлыгы турында әйткән идем. Дөрес, Мәхмүтне Таҗи миңа бирмәде ул көнне, үз кунаклары янына алды. Сатулашып тормадым. Үз гаиләм дә кечкенә түгел, аллага шөкер. Аның янына тагын сул як күршеләрем исән булсын, Андрюшиннар!.. Ләкин аларны да чакырырга өлгермәдем, өй турыбызга тырылдап моторлы көймә килеп тукталды. Артык игътибар да итмәгән идем, азмыни хәзер безнең ярга кагылып үтүче моторлы көймәләр? Калитка ачылган тавышка борылып карасам... башында беретын күрүгә үк тынып алдым: Латыйп карт. Өстендә өч кесәле күлмәге, спортчылар чалбары кигән. Нечкә аяклары арасыннан куян үтәрлек булып тормаса, фигурасына карап, яшь егет дияргә булыр иде үзен. Кулында җәтмә-садогы. Садок эчендә бөгәрләнеп яткан зур чуртан! Үзе кыюсыз гына елмая.

— Мөмкинме?

Чакырылган дусларыма дип әзерләнгән барлык кунакчыллык хисләрем шушы картка насыйп булган икән. Авызым үзеннән-үзе җәелеп китте.

— Әйдүк, Латыйп агай, рәхим итегез,— дип, аяк өсте бастым.— Бик мактап йөрисез икән. Рәхмәт.

Поездда «Склероз» герое белән очрашуым һәм аның онытылып калган болоньесы турында кичә үк әниләренә дә сөйләп өлгергән идем. «Латыйп агай» дигәнне ишеткәч, ул да кунакның кем икәнен чамалап алды. Икәүләп якты йөз күрсәтәбез.

Карт иркен сулап җибәрде. Шулай да кунак буларак тыйнаклык күрсәтү вазифасын үтәми кала алмады, ахрысы:

— Мин мактармын да бит,— дигән булды,— сезнең нинди вакытыгыздыр? Ашыгызга таракан булмыйм дип куркам. Чакырылмаган кунак — татардан яман диләр. Аның өстенә, ул кунак үзе үк татар да булса...

— Иске сүз. Чакырып килгән кунакның аты олы, чакырылмый килгәннең хакы олы, дигәнне дә онытмагыз. Килмәсәгез, болоньегызны тотып, үзем эзләп барачак идем. Узыгыз түрдән...

Кыскасы, чакырылмаган кунагыбыз бик хаклы рәвештә өстәлебезнең түреннән урын алды. Күчтәнәчкә китергән чуртаның үз алдында ук

Андрюшиннарга озаттым. Үпкәләмәде. Бире килешли Мөхәммәтша янына тукталган икән, нинди балыклар тотып кайтуыбыз турында артыгы белән ишеткән булып чыкты. Кемгә килүен дә белеп килгән: кичә үк әйткәннәр.

— Склероз турында сөйләшә башлагач, үзем дә сизенгәндәй булган идем дә,— ышанырга кыюлыгым җитмәде. Ә инде белгәч, плащымны алуыгыз турында да ишеткәч, аны онытып калдыруыма шатланып бетә алмадым. Чынлап та оныттыммы икән мин аны? — дим үз-үземә.— Әллә, карт хәйләкәр, юри оныткан булдыммы икән?

— Әле шулай юри оныту ихтималы да бармыни?

Көлә картлач.

— Хәтер ягы рәтләнде бит минем хәзер,— ди.— Шулай да, истәоста чакта сиңа күрсәтеп калыйм әле,— дип, кулмәк кесәсеннән блесналы кармак китереп чыгарды. Фигуралы көзге кебек ялтырап, уйнаклап торган ак никельле блесна!

— Күргәнең бармы мондыйны?

Карыйм, мин белгән блесналарның берсенә дә охшамый. Бераз гына «Байкал»ны хәтерләтә кебек, ләкин ул түгел.

— Күргәнем юктыр, ахрысы?

— Чуртанны шуңа эләктердем.

— Кайдан таптыгыз мондый ялтыравыкны?

— Чуртан да, судак та, бу блесналы күрсәләр, тәкатьсез булалар. Опты балыгы да шулай, алабуга да...

— Ничек дип атала үзе?

— «Габделлатыйп» дип исем куштым мин аңа.

— Үзегез ясадыгыз?

— Тарихы кызык инде аның.

— Кызык булса, сөйләгез әле.

— Тыңларга иренмәсәгез...

— Нинди ирену, кеше сөйләгәнне тыңларга дисәң, мине куш. Гаиләм дә үземә охшаган.

## Чистай сәгате
## һәм Тула самовары

— Бик әйбәт,— диде Латыйп.— Алайса, иң элек мин сезгә менә моны күрсәтим әле.

Ул үзенең кул сәгатен ычкындырып алды. Алтын сәгать. Аны ике катлы кин каешыннан салдырып, ас ягын күрсәтте. Күгәрми торган корыч капкачка мондый сүзләр язылган иде:

«Латыйп кордашка. 60 яшең белән котлап, дусларың».

Берәм-берәм барыбыз да карап чыктык. «Әйбәт бүләк, әйбәт бүләк!» диештек.

— Үзебезнең Чистай,— диде карт. Ашыкмыйча гына сәгатен кире беләгенә бәйләп, сүзендә дәвам итте.— Бервакыт шулай чуртанга бик бай урынга туры килдем. Чуртан да күп, тамыр-томыр да җитәрлек. Спиннингны аткан саен каба: я чуртан, я коряга. Күбрәк коряга. Бер чуртан тоттым, икене ычкындырдым. Биш блеснамны өздердем. Бетте минем блесна. Ә китәсе килми. Нишләргә? Тоттым да шушы сәгатьне ходка җибәрдем. Бер колагыннан кылга бәйләдем, икенче колагына карабинчик кидереп, өч җәпле кармак тактым. Авырлыгы җитәрлек, батыргыч та кирәкми. Шулай да, ерак ыргытырга, артык төпкә җибәрергә куркам. Бик кадерле бүләк бит, корягага өздереп калдырасы килми. Көймә турысына гына төшереп, уйнатып торам. Кадерен белгән балыкка, тирәнлек җитәрлек, дүрт-биш метр чамасы бар. Бер күтәрәм,

бер төшерәм. Бер заман — шалт Мөхәммәтҗан! Башта, коряга түгелме дип, тәннәрем чымырдап китте. Юк, түгел. Беләгем буйлап йөрәгемә рәхәт дулкын йөгерә, шундый салмак дулкын. Үзегез беләсез инде, балык тотмаган кеше түгел... Бөтен шартын җиренә җиткереп, китереп чыгардым. Судак! Кило алты йөз килде. Карыйм сәгатемне — йөри җан кисәгем. «Тузан да, су да үткәрми, бәрелү-сугылуга да исе китми» дип, юкка гына язмаганнар икән. Тагы салдым. Бер күтәрәм, бер төшерәм. Бер заман тагы — шалт Мөхәммәтҗан! Бу юлы чуртан. Анысы кило бер йөз килде. Ә сәгать йөри, рәхмәт төшкере. Тагы саласы килә бит. Шулай да үземне җиндем,— житәр, мин әйттем, өлкән брат әйтмешли, пора совесть знать.— Кайткач, акыл бар диген инде миндә, хатынга мактанам бит, юләр! Тотынды кыздырырга! — Тәмам барып җиткәнсең икән инде, ди, юләрлекнең чигенә, ди. Карт башың белән шундый көфер эш кылып йөрергә ничек оялмыйсың? ди. Үзенә хөрмәт күрсәткән дусларыңның, иптәшләреңнең истәлеген мыскыл итү бит бу! ди. Бик усал бит минем карчык. Моннан соң серемне сөйләмәм дип, кырык тапкыр тәүбә иткәнем бар. Сөйләми түзәлмим тагы. Сөйләү дә ярап куя шул кайчак. Чынлап та, шунда өздереп калдырган булсам, мәңгелек үкенеч бит, ә?

— Әлбиттә, әлбиттә,— диештек.

— Балык дәрте дигән нәрсә тәмам акылны ала бит ул кайчак, ә?

— Әлбәттә, әлбәттә. Бик була торган хәл.— Бусын мин ялгыз гына әйттем.

— Шул. Алды да яшерде сәгатемне. Сорама да, бирмим дә, күрсәтмим дә, ди. Сәгатьсез калдым бер заман. Чынлап та кызык бит?

— Кызыгын кызык, Латыйп ага,— мин әйтәм.— Ләкин бу бит әле, минемчә, «Габделлатыйп» дигән блесnaның тарихы булмады.

— Сабыр ит. Бусы кереш сүз генә. Арасына чуртан оялаган шул тамырлыкны тапканнан бирле блесна мәсьәләсе тәмам проблемага әйләнде бит! Барган саен ким дигәндә биш-алты блесна өздерәм, берике чуртан алып кайтам. Кыйммәткә төшә, нишләргә?

Бервакыт күршем кулында карап торуга бик сәер сары блесна күрдем. Иске примустан кисеп ясаган икән. Кылт итеп башка бер уй килде бит. Бик җилле самавырыбыз бар иде... Сез инде мине гафу итегез, самавыр турында сүз чыкса, сабый чакларым исемә төшә.

— Самавыр!.. Элекке заманны әзме-күпме күргән кеше булсагыз да, самавырның нәрсә икәнен мин белгән хәтле белмисездер әле. Ә хәзерге яшьләр өчен ул, су кайнатудан бигрәк, өйгә ачы төтен чыгара, башка ис тидерә торган, кыскасы, адәм башына җәфа өчен генә уйлап чыгарылган бер мәгънәсез аппарат.

Авылдан мин үзем, фәкыйрь семьядан. Кечкенә чагым. Өебездә карап торган бердәнбер байлыгыбыз — самавыр иде. Иртәнчәк тә, төш вакытында да, кичен дә, кадерләрәк күрше-күләң кергән чакларда көннең теләсә кайсы сәгатендә, бөтен тишекләреннән пар чыгарачыгара, гөрләп, сары алтын шикелле нурлар чәчеп, бөтен өебезгә ямь биреп, табыныбызга килеп утыра торган иде. Беркөнне, дөбер-шатыр кубып, өебезгә озын-озын мыеклы ясак җыючылар килеп керделәр дә шаулап торган самавырыбызны күтәреп алдылар да киттеләр. Өйдә мәхшәр купты. Самавыр артыннан калмыйча, барыбыз да йөгерешеп урамга чыктык. Урамда да мәхшәр...

Беләм, мыек астыннан гына көлеп утырасыз инде сез. Бу карт безгә, бик зур яңалык итеп, патша заманындагы гаделсезлекләр турында сөйләп утыра, дисез. Юк, мәсьәләнең ул ягы турында кырык кат әйтелгәнне кабатлап утыруым түгел. Шунысы онытылмый: самавырны алып чыгып киткәч, миңа бөтенләй дөнья җимерелгән төсле тоелды. Әйтерсең безнең бөтен хуҗалыгыбызны, гаиләбезне шул самавыр гына бергә оештырып тотып торган! Әйтерсең бар яшәвебез шуңа бәйләнгән! Нишләрбез

хәзер? Самавырсыз ничек яшәрбез?.. Шул кадәр кайгыга төштем, шул кадәр кайгыга төштем, бөтенләй авыруга сабыштым, әллә тагы үләр чиккә җиттем. Кич белән, самавырны күтәреп, эти кайтып кермәсә, белмим, нишләгән булыр идем. Хәзер килеп аптырыйм: нинди көч булды икән ул самавырда?

Ярар, үстем бер заман. Күптән совет власте. Беренче бишьеллыклар чоры. Өйләнгәнмен. Фатир да бар. Шулай да семья семья түгел кебек. Самавыр юк! Шәһәрдә инде үзем. Мичкә утын ягабыз. Суны урамга чыгып, ярты кварталдан барып алабыз. Кичләрен керәчин лампасы. Аларына ис тә китми, самавыр юклыгы эчне пошыра. Тырыштыра торгач, таныш-белеш ярдәме белән, тиешеннән артыгын да түләп, табылды. Тула самавыры. Балкып торган ап-ак никель! Инде аңа куанышу! Хатын белән икәүләп... Хатыным тора-бара шактый усалга әйләнсә дә, бик уңган булып чыкты. Өреп кенә тотты инде самавырны. Бервакытта да суын түкмичә я көлен селекмичә калдырмас. Ташырга ирек бирмәс, сабыйлар өчен махсус чыгарылган «Мурзилка» атлы нәфис теш порошогы белән генә агартыр, тотылмаган ак мамык белән генә сөртер иде. Ялга чыккан чакларда квартирны бикләп китәргә туры килсә, шуңа кызыгып карак-мазар керер дип, самавырны кешесез өйдә калдырмыйбыз, фланел халатка гына төреп, аның өстеннән киндер капчык кидереп, иң ышанычлы танышларыбыз өенә илтеп куя торган идек. Шулай саклап тоту аркасында самавырыбыз алтмышынчы елларга килеп җиткәндә дә бүген генә магазиннан кайткан кебек өр-яңа булып, ялтырап тора иде әле.

Бер заман килеп безнең өйдә кирәге бетә башлады моның. Үзегез беләсез инде, электр керде өебезгә, газ... Шулай да без аны һаман да иң кадерле әйберебез итеп, бик озак саклады әле. Ниһаять, тыгызлый башлады бу безне. Үзегез беләсез, семья зурая, әйбер күбәя бара. Җитмәсә яшьләр, өебез музейга охшый, дип көләләр... Котылырга булдык без моңардан. Ерак Башкортстанда калган бер агай-эне кунакка килеп чыккан иде. Авыл җирендә файдасы тияр дип, шуңа бүләк иттем. Сизелерлек куаныч күрсәтмәде күрсәтүен, шулай да кире какмаган иде. Ишетелер-ишетелмәс кенә итеп булса да, рәхмәт тә әйткән иде әле. Киткән вакытта «онытып» калдырган, шайтан...

Ярар. Беләсез, алтмышынчы елларга кергәндә бездә өй туйлары күбәеп китте бит. Чакыралар. Берсенә шушы самавырны тотып бардык. Бер дә иске дип уйларлык түгел инде, ялтырап тора, рәхмәт әйтеп алып калдылар. Әй шатланабыз, котылдык дип, әй шатланабыз. Ел узып китте, ике ел. Онытып та беткән идек инде. Чираттагы яңа елга үзебезнең малайга квартира бирделәр. Өй туена чакырылган бер иптәше шушы самавырны күтәреп килгән булып чыкты. Малай икенче көнне үк үзебезгә китереп ташлады. Ничә өй туе күргәндер, анысын белмим, онытылган самавырыбыз, шулай итеп, яңадан үзебезгә әйләнеп кайтты. Күргәч, күземә яшьләр килде. Һаман өр-яңа мескен самавыр! Булмас, мин әйтәм, шушындый затлы әйбер бу кадәр кирәксез чыкмас! Дөнья булгач, бардыр берәр эзләүчесе! Комиссионныйга илтеп бирдем. Теләмичә генә алып калдылар. Бер ел торды. Өч тапкыр бәясен киметтек. Магазин кешеләре, әрләп дигәндәй, үземә кире биреп җибәрделәр. Балалар утильгә бирергә бик кызыксалар да, кайчандыр безнең өчен шундый кадерле булган нәрсәне ул кадәр мыскыл итәргә көчем җитмәгән иде... Әлеге кеше кулында примустан киселгән блесланы күргәч, искемоскы арасында аунап яткан шул самавыр исемә төште бит. Утильгә биреп әрәм итәр хәлем юк, мин әйттем. Үзем үк проектын биреп, совхоз тимерлегеннән штамп ясатып алдым да ходка җибәрдем. Шуның белән блесна проблемасы хәл кылынган, карчык тарафыннан кулга алынган сәгатем дә үземә кире кайткан иде. Хәзер инде менә бөтен самавырдан исән калган өч блесланың берсен сезгә бүләк итәм. Рәхим итегез...

Чын күңелдән рәхмәт әйтеп алдым.
— Мин моны бары кадерле истәлек итеп кенә саклаячакмын,— дидем.— Балык эләкмәгән чакларда иптәшләргә күрсәтеп, тарихын сөйләр өчен генә янымда йөртсәм йөртермен.
— Мин үзем дә берсен сакларга уйлыйм,— диде Латыйп ага.— Бик тыгызга килгән чакта гына онытып җибәрмәсәм...
— Онытмассыз. Хәтер шәбәйде, дисез.
— Шәбәйде дигәч тә, яшь чактагы кебек, ишеткән бер такмазаны да истә тота торган юләр хәтер юк инде ул. Акылга утырды хәтер, кирәген генә саклый. Анысына шөкер. Югыйсә, иң кирәген тота алмый башлаган иде бит. Дәвалandым...
Картның бу сүзләре үземне дә кызыксындыра калды. Төпченебрәк сорый башладым.
— Ишетүемә караганда, сез бит хәтер начарлануны авыруга да санамый йөргәнсез. Ничек алай дәваланасы иттегез? Ни белән дәвалandыгыз?!
Картым хәйләкәр елмаеп куйды.
— Беләм,— диде.— Сезнең миннән теге онытылып калган «иң кызыгын» сөйләтәсегез килә. Белмим шул, иң кызыгы бәлки чынлап та онытылгандыр. Әмма хәтердә калган кадәресе дә сезнең өчен кызыксыз булмас дип уйлыйм. Хәтта кешегә сөйләргә оят ул вакыйганы.
— Болай булгач, сөйлисез инде.

## Хәтер төзәтү тарихы

Картыбыз, тын алып та тормастан, икенче вакыйга турында сөйләргә керешә башлагач, эниләре, табынның хуҗасы буларак, кунакны хөрмәт итәргә кирәклеген искә төшерде.
— Туктагыз инде,— диде.— Кунакны гел сөйләтеп утыру ярамас, сүз арасында әзрәк капкалап алырга да ирек бирик. Ашагыз әле. Латыйп ага, ашагыз...
Тамагы тук иде, ахрысы, кунагыбызның ашауга бик исе китмәде. «Рәхмәт-рәхмәт» дип, аз-маз гына капкалады да тагын телен ходка җибәрде.
— Чынлап дәваланырга,— диде,— беләсезме мине кем мәҗбүр итте? Теге сез Кадермәт дип атаган ач яңаклы күршем дә түгел, доктор да түгел, кем дисез? Хатыным. Ничек итепме?..
Ул үзе куйган сорауга туры гына җавап бирергә ашыкмады. Гадәтенчә, кереш сүздән башлады. Аның кереш дигәнен беләбез инде, әйтергә теләгән төп вакыйгасы борчак хәтле булса, кереш сүзе ботаклы бәрәңге чаклы була.
Дөрес, мин үзем аның бөтен сүзләрен дә кызыксынып тыңладым. Тыңламый хәлем юк. Чөнки тыңлау — ул өлешчә минем профессиямә керә. Ә минем өстәл янында утырган яшьләр авызларын ачкаладылар. Торып йөреп тә килгәләделәр. Шуңар күрә тел тормозы шактый йомшарган бу картның бөтен сүзләрен язып барсам, укучыларым да авызларын ачкалarlar, торып йөриселәре дә килә башлар дип куркам. Кайбер җирләрен лутчы үз телем белән генә әйтеп бирим.
Ул үзенең бала чагыннан башлап биографиясен сөйләргә керешге. Революциягә кадәр татарча укырга-язарга өйрәнүе, революция елларында акларга каршы сугышта катнашуы, аннары ярлылар комитетында эшләве, милиционер, укытучы, сәүдә работнигы булып йөрүләре, ниндидер курсларда укулары, беренче баскыч партия мәктәбен тәмамлавы, авыл советында хезмәт итүе, хәтта берникадәр вакыт райком секретаре булып торуы турыларында да әйтте.

— Белем житкәннән түгелдер инде, белемлерәк кешеләр житмәгәннән булгандыр,— дип тә куйды.

Ватан сугышында өч тапкыр яраланса да, инвалидка әйләнмәгән. Аннан соң хуҗалык эшенә кучеп, төрле җаваплы урыннарда булган. Ниһаять, республика күләмендә персональ пенсия алырлык кадерле бабай булып житкән.

— Хикмәт менә шул минем персональ пенсионер булуда инде,— диде ул. Персональ булгач, үзегез беләсез, миңа курортка барырга бушлай путевка бирәләр. И һәр елны көзгә табарак мин Мәскәү янындагы бер санаторийга барам. Барган саен карчыгым миңа, юл уңаенда Мәскәүгә тукталып, тегене-моны алып кайтырга заказлар бирә. Хатынкызны беләсез, олыгайган саен купшылана бара. Матур комбинация кирәк аңа, челтәрле-чуклы төнге күлмәк, дисеңме, импортный туфли, йөзне яшәртә торган крем, мотлак фәлән номерлы гамма... Нәрсә генә сорамый.

— Бу нинди киемнән туймаган кеше булдың, яшь чагың түгел бит! — дип тә караганым бар. Авызны да ачтырмый.

— Хатының кием таптырганга шатлан,— ди.— Киенү-бизәнү дәртем бетсә, минем синең өчен ни кызыгым кала! — ди.

Анысы да дөрес. Шуннан соң һич карышмыйм. Нәрсә кушса, шуны — ярар, алып кайтырмын, дип кенә торам. Язып биргән заказлар исемлеген бик яхшылап, югалмаслык итеп, кесәмә салып куям. Ә кире әйләнеп кайтканда барысын да онытккан булам.

Картының хәтеренә тәмам ышанычы беткәч, бер елны карчыгы үзе ияреп барырга була. Курортка ук түгел, Мәскәүгә генә. Хатынның кушуы буенча, Латыйп, бергә ял иткән Мәскәү кешесе белән сөйләшеп, өч-дүрт көнгә фатир таба. Мәшәкать кими торсын дип, юл чемоданын саклау камерасына тапшырып куя. Аннары Казаннан балалары утыртып җибәргән карчыгын бик әйбәтләп каршы ала. Курорт дусында матур гына кунак булалар. Хәтта беренче кичне театрга барып «Идеальный муж» дигән спектакль дә карыйлар әле. Икенче көнне кайчан Казанга кайтасыларын ачыклыйлар да, купшыланырга яратучы хатын, квартир хуҗасының кызына ияреп, магазиннарга чыга, Латыйп кайтыр өчен поездга билет алырга китә. Курорт сезонының кызган чагы, билет кассаларында халыкның кайнап торган көннәре икән. Башка елларда билетны гел курорт кешесе аркылы гына алдырып өйрәнгән Латыйп, бу мәшәкатьле эш үз өстенә төшкәч, күптән онытылган юл газабының нәрсә икәнен яңадан күрә, тәмам җан тиргә бата. Бер кассага чират тора, ала алмый, икенчесенә — ала алмый. Казан вокзалына китә. Янапешә, нәтиҗә юк. Хафага төшә карт. Чиратсыз тыкшынучы нахаллар белән кычкырыша-кычкырыша нервалары кузгала. Атна буена кайта алмый ятарга туры килмәгәе, дип курка башлый. Ничек тә ычкынырга кирәк! Менә бер заман кайсыдыр кассадан кычкыралар. «Татарстан»га бер билет бар, имеш! Йомшак урынга! Поезд бер сәгатьтән китә. Тагы нәрсә кирәк? — ди карт үз-үзенә.— Чемоданны алып өлгерәм! Бүтәннәр эләктергәнче дип, ашыга-ашыга билетны ала да саклау камерасына йөгерә.

Ә бер сәгатьтән картыбыз, вокзал газапларыннан ватылган тәннәрен йомшак урында тирбәтә-тирбәтә, Казанга карчыгы янына кайтып бара. Ә карчыгы?..

— Бер йокы йоклап уянгач кына хәтергә килде,— ди Латыйп.— Анда да аермый ятам: өндә булган эшме соң бу? Хатын чынлап та Мәскәүдә калдымы? Әллә төш кенәме?..

Соңыннан миңа ничек әләгүе турында сөйләп торасы юк. Характеры нинди икәнлеге турында әйткән идем. Иң кызыгы дигәнем шул булды: бу вакыйгадан соң хатын мине бик чынлап дәваланырга мәҗбүр итте. Больницага үзе илтеп салды. Югыйсә, мин бит курортта да дәвалану

турында уйламый торган идем. Уколларын алырга онытам, ванналары хәтердән чыга, даруларын эчәргә искә төшми. Биргән ризыкларын калдырмый ашыйм, өстәлгә куелган эчемлекләрен эчәм. Хәтта кайвакыт өстәлгә куймаганнарын да эчәргә туры килә. Аның өстенә һавада йөрим, домино уйныйм, биллиард сугам. Кино-мазар карыйм, телевизор. Ә хәтер!.. Врачларның я сестраларның Марусясына Катя дип, Катясына Наташа дип дәшәм икән, исләре китми. Елмаялар гына. Яшь сестраның елмаюы — үзе дару безнең кебеккә. Ә монда инде, больницада! Онытырга ирек бирмиләр анда. Берсеннән-берсе мөлаем сестралар, кирәк вакытта урыныңда булмасаң, артыңнан эзләп табып, даруларны үз кулларыннан эчерәләр. Уколларын алмасаң, караватыңа килеп кадыйлар... Өстәвенә, хатын үзе көн саен килеп, тикшереп тора. И рәтләделәр бит!

Хәтерем яхшырганны шуннан беләм: әллә никадәр яңа сүзләр өйрәндем. Берсеннән-берсе әйтергә читен сүзләр. Әле кайчан гына, яшь чагымда тел әйләнмәслек гарәп сүзләреннән торган озын-озын азан догаларын, аш догаларын ничек ятлый алганмын икән дип аптырый идем. Хәтта бер китапта: «Бу доганы яттан белгән адәм оҗмахка беренче булып, нәүбәтсез керер, кыямәт көнендә ул кемсәнең йөзе айның үндүртенче кичәсе кебек балкып торыр», дигән сүзләрне укыгач, «Исме агзам» догасын ятладым бит, юләр! Дилбегә буе. Гел гарәп сүзләреннән генә тора. Күрәсең, миндә малай чагымда профессор булырга, академик булырга җитәрлек хәтер көче булгандыр, рационал файдалана белмәвем аркасында юк-барга әрәм-шәрәм итеп бетергәнмендер дип, үкенеп йөри идем. Бер дә гаҗәп түгел икән. Соңгы бер-ике ел эчендә ятлаган дару исемнәрен генә әйтеп күрсәтсәм дә шаккатарсыз. Мәсәлән, әйтик **кокарбаксилаза** дигән сүз үзе генә ни тора! Аның янына тагын интенсаин, диоспонин, кардиомин, липокаин, андаксин, триоксазин, нитроглицерин, липоцеребрин, папаверин, ундивид, гендивид, пангомат, мепробамат, галинур, гамза, бренди,— дип тезеп китсәм...

Бүлдерми түзә алмадым.

— Гафу итегез, Латыйп ага. Ул «гамза» дигәне, «бренди»[1] дигәне нинди авыруга каршы бирелә торган дару?

Үзе дә көлеп җибәрде. Шулай да аптырап калмады.

— Гаеп миндә,— диде,— хәер, барыбер соңгы елларда ятланган яңа сүзләр. Үземә кирәкле дарулар гына түгел, хатынга яки башка берәр таныш кордашка кирәк булганы да ятлана бит аның: инсулин, холензим, аллахол, халогол, атропин, ношпа, калготка, шиньон...

Бу юлы хатын бүлдерде:

— Гафу итегез, бу соңгылары...

— Ә, әйе, тагы бутадым. Бутарсың да, хәзер бит аның борын-борыннан таныш булган гади аспирины да фамилиясен алыштырды. **Ацетилсалициловая кислотага** әйләнде. Телеңне сындырырсың... Әле дару исемнәрен генә, аларның да беренче булып телгә килгәннәрен генә әйттем. Шуларга тагын да ашлама төрләрен, яшелчә, җиләк-җимеш сортларын — мең төрле чәчкә исемнәрен куш, һә-ә-й... Соңгы елларда мин өйрәнгән яңа сүзләрнең берсен дә калдырмый җыйсаң, биш мичкәгә сыймас иде. Хәтер эше бит бу! Хәтереңне рәтләмәсәң, ничек барын да истә тотарга кирәк...

Картның телен, үзебезнең колакны бераз ял иттерү ниятеннән, без аны тагын бер тапкыр ашарга-эчәргә кыстап карадык. Юк, исе китмәде. Яңа баштан гәп башлап җибәрде.

[1] Исерткеч эчемлек исемнәре.

## Нәрсә эчне пошыра?

— Ярар,— диде.— Юк-барны җитәрлек такылдадым. Әмма әйтәсе килгән сүзләремне әйтмәдем әле. Сезнең белән танышуыма куанып утырам. Киң күңелле, ачык йөзле кеше икәнсез. Анысына тагын бер кат куанам. Югыйсә, хәзер кайбер зуррак кешеләребез арасында безнең кебекләр каршында масаю билгеләре күренеп эчне пошыра. Сүз дә юк, яшь буын, хәзерге җитәкче работникларыбыз безнең белән чагыштырганда зур белемле кешеләр. Эшне фәнгә нигезләп алып бара беләләр. Алар хакында мин, безнең эшне әйбәт дәвам иттерәләр дип, чын күңелдән куанып йөрим. Ә алар арасында киресенчә уйлаучылар бар. Безнең буын кешеләрен зур эшләрне башлап җибәрүчеләр итеп түгел, кайчандыр эшне бозып йөргән наданнар дип кенә карыйлар.

Беркөнне шулай зур гына бер җитәкче работник янына кереп чыктым. Кабул итте, рәхмәт. Эчемне пошырган кайбер мәсьәләләр турында сөйләдем. Күңелемә ошамаган эшләрен тәнкыйтьләдем. Үземчә киңәшләр дә бирдем. Тыңлап утырды, киңәшләрегез өчен рәхмәт,— диде.— Әһәмиятле фикерләр әйттегез, алар турында уйларбыз,— диде. Күңелләрем күтәрелеп, канатланып чыгып киткән идем. Икенче көнне ишеттем: минем турыда сүз чыккач: «Ә-э,— дигән,— ул карт миңа да кереп чыкты, винтиклары бушаган аның», дигән.

Ярар, үзем турында әйтмим дә, ди. Кечкенә кеше. Хәтта бит легендар Чапай турында нинди генә анекдотлар сөйләмиләр хәзер? Ни әйтсәң дә Ленин үзе исән заманда яшәгән кешеләр бит әле без. Аның җитәкчелегендә башкарылган эшләрдә катнашкан кешеләр! Ә? Менә сезгә, каләм әһелләренә, бу турыда уйларга кирәк иде, дип тә әйтүем.

Карт минем җавапны көтеп тынып калды. Ни әйтим? Мин дә, теге «зур гына бер җитәкче работник» шикелле, аңа «рәхмәт, әһәмиятле фикерләр әйттегез. Алар турында уйларга кирәк булыр» диюдән артык сүз әйтә алмадым. Ләкин икенче урында сүз чыкса, мин бу карт турында винтиклары бушаган дип, кул селкеп кенә куймас идем. Минемчә, хакыйкать юк түгел аның сүзләрендә...

Аннары ул миңа, каләм әһеле буларак, тормыштагы кайбер кимчелекле якларыбыз турында газетага язып чыгарга киңәшләр бирә башлады. Шушы Идел өстендә үк үз күз алдыбызда булган башбаштаклыклар, уч төбе хәтле утрауларга да теләсә кемнең бернинди плансызнисез өй китереп салулары, балык тоту эшендәге тәртипсезлекләр турында әйтте. Һәвәскәр балыкчы исеме астында браконьерлык белән шөгыльләнүчеләр күп, диде. Сөйли торгач, хәтта үзен дә, мине дә өлешчә браконьер итеп чыгарды. Шәһәрдә исә аның эчен пошыра торган күренешләр тагын да күбрәк икән. Машина дип шашынучылар, үз рәхәтләре өчен башкалар белән исәпләшмичә, кеше тәрәзәсе төбенә гараж китереп салучы эгоистлар, берише яшьләрнең кирәгеннән артык эт белән мавыгулары, халык ял итә торган шәһәр бакчаларын этләр бәдрәфенә әйләндерүләре турында зарланды.

— Хуҗаларын әзрәк акылга өйрәтим дип, тавышыңны күтәрә төшсәң, сиңа карап этләре ырылдый башлый,— диде ул, шактый ачуланып.— Этеңне тый, дисәң, «Тешләми ул, өрә генә!» дип тынычландырырга телиләр. Өрә генә, имеш!.. Картның йөзе янып, кызарып китте. Ул, үзен-үзе тыя алмыйча, ярсып кычкырып җибәрде.

— Өрмәсеннәр миңа! Сукбай түгел мин. Кеше йортына килеп кергән килмешәк тә түгел! Кемнең хакы бар миңа өрергә?!

Ул үзенең тиешсез урында кызып китүен аңлап, уңайсызланды бугай, елмаеп, гафу үтенде.

— Гафу итегез, сезгә кычкыруым түгел. Шуны гына әйтәсем килә:

мондый башбаштаклыкларга карата бер закон булырга тиеш бит? Матбугат кешеләре, каләм әһелләре игътибар итсә...

Аның сүзләрендә хакыйкать юк түгел иде, әлбәттә. Ләкин мин аны ялган вәгъдә белән юмалап кына котылырга теләмәдем. Бу темалар буенча каләмгә тотынырга үземнең хәзергә вакытым да, ниятем дә юк икәнлеген ачыктан-ачык әйттем. Үзен Фәнил белән очраштырырга вәгъдә бирдем. Ул бик дәртле һәм житез яшь журналист,— дидем.— Әлбәттә, бу мәсьәләләр белән кызыксыныр һәм, һичшиксез, язарга да өлгерер...

Ниһаять, кунагыбыз бездән бик мәмнүн булып кайтырга кузгалды. Мин аны озата чыктым. Көймәсе янына килгәч, баягы сүзләренә өстәгәндәй, тагын әйтеп куйды:

— Менә бу моторны гына кара. Аның туксан тугыз детале бар. Һәркайсының исеме бар. Хәтер капчыгында шуларга да урын табылган бит.

— Әйбәт эшлиме соң?

— Әйбәт кенә дисең! — Картның яңадан балыкчылык хирeслeгe килеп китте, ахрысы. Тагын илһамланып сайрарга кереште.— Бервакыт,— диде,— әле хәтерне рәтләмәгән чак булгандыр инде, якоремне онытып калдырганмын. Кире кайтып йөрсәм, чиртү вакыты әрәм була. Якорь урынына тоттым да шушы моторны бәйләп салдым. Кайтканда ашыгасы юк, мин әйтәм, эшләмәсә ишкәк белән дә кайтып житәрмен. Нишләде дип беләсез? Ышансагыз ышаныгыз, ышанмасагыз көчләмим. Су төбеннән күтәреп алгач, кирәк жирләрен чүпрәк белән сөртеп корыттым, цилиндрны ачып биш-алты тапкыр өрдердем — и син күр дә мин күр! Тырылдатып кайтып та киттем. Шундый моторга ничек тел тидерәсең!

Рәхәтләнеп көләм.

— Әйбәт,— дидем.— Ялган булса да, әйбәт. Молодец, Латыйп ага!

Картым егетләрчә жиңел генә көймәсенә кереп китте. Юлым төшкәндә яки балыксыз кайтырга һич ярамый торган көннәрдә үз кармагыма эләкмәсә, аның янына сугылырга чакырды.— Минем садоктан запас өзелми,— диде.— Сау булыгыз! Рәхмәт!.. Менә хәзер мотор белән ничек эш итүемне карап тор инде!

Ул койрык ишкәге белән көймәсен артка алып, борынын кирәкле юнәлешкә каратып куйды да моторына борылды. Каеш бавы маховикка урап ук куелган икән — бер генә тартты,— тырылдап кабынып та китте. Үзенең дә бу кадәр уңыштан авызы колагына житте. Аның өчен мин дә чын күңелдән куандым.

Ул моторны иң әкрен йөрешкә куйган да, әледән-әле миңа борылып карап, сынар кулын селки-селки ераклаша бара иде. Кинәт артымда бик каты кычкырган тавыш ишетелде:

— Плащ!!!

Карасам, улым, картның болониен һавада болгый-болгый, калиткадан чыгып килә икән.

## АЛТЫНЧЫ БҮЛЕК

# Ә бит бар алар!

Ана сөте белән кермәгән тана сөте белән керми, диләр. Бу Фәнилне тәки балыкчы итеп булмады инде, ахрысы. Ни күрсә шуның белән кызыксынып бара үзе, очраган бер вакыйга белән булсын, күргән бер кеше белән булсын — мавыгырга гына тора. Әмма балык тотарга дисәң, юк. Түземе житми. Үч иткән шикелле, аның белән чыксаң, я балык эләкми торган көн туры килә, я берәр көтелмәгән вакыйга очрый. Теге

үлеп терелгән Ваня турында шуны белеп кайтты: суга батып үлү нияте, әлбәттә, егетнең уена да килмәгән. Машасын сынау өчен үзенчә шундый шаян хәйлә корып карамакчы булган. Янәсе, ул шулай хәбәрсез югалып йөргән арада хатыны нишләр? Ягъни, чынлап яратса — көтәр. Яратуы андый-мондый гына булса — китәр. Гомер буе тыныч йокы күрми азапланып яшәгәнче андый хатыннан котылганың яхшы, китә бирсен.

Ләкин аның бу шуклыгы бик кыйбатка төшә язган. Ярый әле, үзенең «мәете» боз астыннан чыгу турындагы хәбәр артык озакламый үзенә барып ишетелгән. Югыйсә, хатын дигәнең, мәхәббәте Идел тиранлеге булса да, үлгән ирен көтеп, ятларга карамый утырыр иде микән? Бигрәк тә Маша шикелле, теләсә нинди ир-атның күңелен җилкендерә торган чибәр хатын? Үзе ашыкмаса да, ашыктыручылар табыла аны. Бәхетенә каршы, Ваня вакытында кайтып өлгергән. Фәнил әйтә, аның алай чыгып китүе, әлбәттә, хатынын сынау өчен генә эшләнмәгән, ди. Төп сәбәбе — армия күреп, өстәвенә, механик һөнәре дә алып кайткан егетнең авылда каласы килмәгән. Шәһәр тирәсеннән яки берәр төзелештән урын чамалап йөргән. Тапкан да булса кирәк: хәзер Машасын да алып Чаллыга киткән, автомашиналар заводы төзелешенә барып урнашкан, ди.

Ә милиция органнары өчен яңа эш: теге мәетнең кем булганлыгын белергә кирәк бит. Баш сөяген казып алып, Герасимов ысулы белән рәсемен ясатырга җибәргәннәр. Фәнилне дә хәзер Ваняның язмышы түгел, әнә шул ясалачак рәсем кызыксындыра.

Фәнилне балык тоту белән мавыктырырга комачаулый торган тагын бер кыенлык бар: аны теләгән көнне (ягъни балык әләгәсе алдан ук күренеп торган көнне) алып чыгып булмый. Ул эштә була. Күп вакыт хәтта ял көннәрендә дә командировкада булып кала. Димәк, аны балыкка алып бару өчен мотлак ял көне булсын да аның өйдә чагы туры килсен. Шулар өстенә тагын әйбәт көн кирәк. Әйбәт көн дигәнең дә балыкчы күзлегеннән караганда әйбәт булуы шарт.

Югыйсә, болай да була: бер ял көнне чынлап та без теләгән шартларның өчесе дә бергә туры килгән иде кебек. Бердән, ял көне, икенчедән, Фәнилнең өйдә чагы, өченчедән, көне дә карап торуга искиткеч матур иде. Күк йөзендә бер болыт әсәре юк. Су өсте шундый тигез, җилнең хәтта кайсы яктан искәнен дә чамалау мөмкин түгел.

Бернинди тоткарсыз, нәкъ вакытында чыгып киттек. Өчәү без. Таҗи белән Фәнил дә мин. Моторыбыз җырлап кына бара. Балык тоту өчен кирәкле бөтен нәрсәләребез яныбызда. Килеп җиттек, алдан чамалап куйган урыныбыз да буш — безне көтеп тора. Көймәбезне нәкъ үзебез теләгән ноктага утырттык. Бөтен шартын китереп җим капчыкларыбызны төшердек. Кармакларыбызны салдык. Зур сабырлык белән, сабырлыгыбызга караганда да зуррак өмет белән ышанып, беренче балык эләккәнне көтәбез. Ләкин ник кенә бер балык кагылып карасын кармакларыбызга! Ярты сәгать үтте... Бер сәгать. Каптырып салган җимнәребез шул көе. Алыштырып карыйбыз, файдасы юк. Дөрес, минем үземнең артык исем китми, мондый хәлләрне күрмәгән түгел. Фәнилдән уңайсыз. Сизәм, Таҗиның да хәле шундый. Үзебезне Фәнил каршында гаепле санаган кебек утырабыз. Аны өметләндерергә теләп, юату сүзләре әйтәбез.

— Зарар юк,— дигән була Таҗи.— Балык ул кайвакыт өч сәгать утырганнан соң гына чиртә башлый.

— Дүрт сәгатьтән соң чиртә башлаган чаклары да була,— дип өстим мин.

Күптән эче поша башлаган Фәнил, аптырагач, көлеп җибәрә.

— Бәлки ул өч көннән соң чиртә башларга уйлыйдыр?

— Алай да була,— дип куя Таҗи, җитди генә.

Тагы тынып утырабыз.

— Их, киндер түбе булса! — дип көйде Тажи.— Я киндер мае!

— Булса да әллә ни үзгәреш кертә алмас иде бу хәлгә,— диде Фәнил.

Тажи җанланып китте. Киндернең тылсымлы көче барлыгын тырышып-тырышып исбат итәргә кереште.

— Киндер түбе булсамы? — диде.— Яки мае? Кормушкага бер генә уч кушып, я өч-дүрт тамчы гына маен тамызып җибәрсән, бер километр түбәндә йөзгән балык та аның тәмен тоеп, кормушка төбенә атыла. Хәтта йоклап яткан балык йокысыннан уянып китә аның исенә.

— Арттырасыздыр ла, Тажи абый?

Тажи үзенең бер көнне читтән килгән кунагы белән балыкка чыгуы турында сөйли башлады:

— Мин утырам көймәнең бер башында, кунагым — икенче башында. Мин бер балык та тотмадым, ә кунагым бер үзенә ундүрт кило тотты. Көлә миннән, мыскыл итә. Балыкчы булып йөргән буласың син дә, ди. Мин әйтәм, очраклы хәл булды бу, бер елны тартай симерә, бер елны бүдәнә. Икенче чыксак, бәлки син минем хәлдә калыр идең, дим. Әйдә иртәгә тагын чыгабыз, ди. Әйдә, мин әйтәм. Икенче көнне дә шул ук хәл: миңа берни юк, аңа эләгә. Урынны алыштырып карадык, аның урынына күчеп утыргач, миңа өч балык эләкте. Ләкин алар да, ялгыш, минем кармакларны аныкы дип белеп капканнар, күрәсең. Унбиш минут үтүгә — бөтен балыклар аңа күчте. Ә миңа — шишара. Шул өч балык белән калдым. Кунагым тагын уникe кило тотты.

Шуннан соң ул миндә бер атна торды. Атна буе күземне ачырмады, мыскыл итте. Теге өч балыгың да минем кормушкага килгән балык иде бит синең, ди.

Озаткан вакытта, самолетка утырыр алдыннан гына серен әйтте: киндер маенда икән хикмәт. Кечкенә флакон белән янында йөртә икән. Кормушкага өч кенә тамчы тамызасың, ди. Янымда киндер маем я түбе булмаса, мин балыкка чыкмыйм да, ди. Тиргәдем үзен.

— Шунда миннән өч тамчы маеңны кызгандыңмы? — дим.

Көлүен белә.

— Кызгануда түгел хикмәт, серемне ычкындырсам, мин балыкчы буламмыни? ди. Яшермим,— ди — тагы кызгану да булмады түгел, ди. Чөнки үземә дә биш-ун тамчы чамасы гына маем калган иде, ди. Соңгы чыгуда бөтенесен тамызып бетердем, ди. Тагы бер чыгарга чакырган булсам, үзе дә хур буласы икән.

Фәнил дәртләнеп, күтәрелеп китте.

— Соң аны табу шулай кыенмыни? — диде.— Алай тамчылап кына да кирәк булгач...

— Табарсың, бар! Ике ел эзлим инде мин аны.

— Бөтен Татарстанда юкмыни?

— Юк. Әүвәлге елларда Татарстанда бит киндер үстерүче районнар булган. Хәзер юк.

— Табам мин аны,— диде Фәнил.— Киндер бит ул балыкчыдан бигрәк хуҗалык өчен, илнең экономикасы өчен кирәкле культура. Нигә аны үстерү мәсьәләсен күтәрмәскә? Бүгеннән керешәм бу эш белән шөгыльләнергә!..

И керешер. Сизеп торам, Тажи, гадәтенчә, берне ун итеп арттырып сөйләде. Беләм. Бүгенге кебек балык эләкми торган көннәрдә киндер мае да берниндн могҗиза тудыра алмый. Фәнил өчен балыгы кыйбат түгел, киндер проблемасы хәзер аңа тема буларак кызык. Ул хәзер аны тикшермичә, аның төбенә төшмичә туктамаячак. Кайчандыр Татарстанда күренекле урын тоткан киндер үстерү мәсьәләсе чынлап та хаксызга игътибар үзәгеннән төшеп калган булса, бәлки аны кире үз урынына

кую да берәр нәтиҗәгә ирешер. Мәкалә язып чыгар, берәр район яки колхозны рухландырып җибәрә алыр. Ә балык тоту белән мавыгу ягы, ай-һай! Шушындый әйбәт көнне дә чиртмәве, балыкка гына түгел, безгә карата да аның күңелен суыта. Аның карашында без, әлбәттә, олы юләрләр. Юкка алданып, булмастайны өмет итеп, вакыт әрәм итеп утыручылар...

Ә мин алай уйламыйм. Беләм, Таҗи да алай уйламый. Балык чиртмәсә дә, бәхетле хис итәм мин үземне бу минутларда. Беләм, Таҗи да шулай.

Таулардан тауларга җәелгән киң Идел өстенең тынлыгына карап утыруы рәхәт миңа. Гаҗәп: Иделнең әйтеп бетергесез зур көчен һәм мәңге ачылып бетмәс серләргә ия булган елга икәнлеген мин аның тыныч вакытында ныграк тоям. Ачуланган чагында ул хәтәр. Ләкин нинди көчле җилләрдә дә, көймәләрне генә түгел, пароходларны әйләндереп төшерерлек давылларда да ул үзендә булган куәт запасының меңнән берен дә күрсәтә алмыйдыр кебек. Андый чакларда ул үзенең көчен түгел, бары явызлыгын яки тилелеген генә күрсәтә. Яратмыйм Иделнең андый чагын.

Хәер, Идел үзе явыз түгел. Котырынса, җилгә-давылга ачу итеп кенә котырына. Яратмыйм җилне-давылны! Яратмыйм өермәне, пәри туен! Шагыйрьләр яратсын!

Шагыйрьләр дигәннән... Бер шагыйрь дустым белән дә балыкка чыкканым бар минем. Үзе белән бергә көчле җилгә эләктек. Көймәбез үрле-кырлы сикерә. Якорьларны өстерәп, урыныннан күчә. Бортка бәрелгән дулкыннар яңгыр булып өстебезгә ява. Кая анда балык тоту кайгысы! Ничек итеп исән калу турында уйлыйбыз. Шунда да күңелемә килде бит бер шуклык.

— Куан инде,— мин әйтәм,— шагыйрь дустым! Теләгәнең булды.

— Сөйләмә, зинһар,— ди,— болай да күңелем уйный.

— Нигә? — мин әйтәм.— Давыл булсын бит сезгә, шагыйрьләргә, өермә булсын! Буран, ураган булсын! Шторм! Рәхәтен күр инде менә...

— Явыз! — ди миңа. Нәрсә әйтсен? Күрә, мин хаклы.

Шулай ул, тышта котырган гарасатка тәрәзәдән карап утыру гына күңелле. Әле дә кырда яки Идел өстендә түгелмен дип, шөкер итеп утырасың!

Тын Идел өстенә карап утырам. Ул нинди зур, нинди мәһабәт! Чиртмәсен балыгы! Табигатьнең шундый серле, тылсымлы көзгесе өстендә сизелер-сизелмәс кенә тирбәлеп утыру үзе генә дә «тәнгә сихәт, җанга зур файда» түгелмени?.. Уйланам: шулай да кая киткән ул балыклар? Әйтерсең алар ниндидер сихри көч белән бөтенләй юкка чыккан. Ә бит бар алар! Шушы Идел эченнән беркая да китмәгәннәр. Бар гына түгел, иксез-чиксез күп. Бар кечкенәләре, бар адәм күтәрә алмаслык зурлары. Әгәр аларның барлыгын белмәсәк, Иделдә бернинди балык юк дип ышансак, су төбенә кармак салып сәгатьләр буенча көтеп утырырга түземебез җитәр идемени?

Нигә бүген чиртми балык? Анысын да беләм: димәк, көн без күргәнчә үк әйбәт түгел. Димәк, һавалар үзгәрәчәк. Һәм инде ул үзгәрү процессы башланган. Тик без аны әлегә сизмибез. Ә һавадан еракта су төбендә йөзгән аңгыра балыклар сизә. Ничек сизәләр? Ни өчен мондый чакларда аларда тамак кайгысы булмый? — анысын инде ихтиологлар белсен! Минем һәвәскәр балыкчы гына булып каласым килә. Алданып утыра белү дә кирәк миңа. Әйе, һәвәскәр балыкчының иң гүзәл үзенчәлеге — гөнаһсыз нарасый шикелле алданып утыра белүендә.

Ә Фәнилгә ул кирәкми. Башы яшь. Һәм ул алданып утырмый да, без утырганга гына утыра. Әле генә түгел, балыкның иң шәп чирткән чагында әйт син моңа: «Әйдә кайтыйк» диген, сүзсез риза була. Аның үз кармагы бар. Тормыш Иделенә салып куйган ул аны. Кая барса —

шунда чиртә аңа. Теге вакытта Ваня вакыйгасен электергән иде, бүген киндер маен хәтер сандыгына салып куйды. Белэм, бу тема аңа әллә ни бирмәс. Ләкин барыбер республикабыз турында белемен тирәнәйтүгә ярдәм итәр. Журналистка ул да отыш. Шулай да, көннәр әйбәтләнгәч (бүгенге көнне инде бозылганга саныйк), тагын алып чыгарбыз әле без аны. Ничек тә үзенә менә дигән балык тоттырып карыйсы килә. Шунсыз аңа балык җене кагылмаячак.

## Бәйдән ычкынган Карабай

Әйтәм ич, аңгыра балык безгә караганда алданрак сизә, дип, һавалар чынлап та бозылып китте. Атна буе диярлек җилләп-яңгырлап торды.

Андый көннәрнең үз куанычы бар. Кыр эшенә бернинди кагылышы булмаган, ашлыкны пешкән күмәч яки майлы ботка рәвешендә генә күз алдына китерә белгән купшы ханымнар да, игеннәр уңа дип, яңгырга шөкер итеп йөргән булалар. Безнең ишеләргә шәһәргә кайтып, яңа фильмнар карарга, казага калган газета-журналларны укырга, тегенемоны язып куярга мөмкинлек туа. Культурадан туйган ял батырларына, өйдән чыкмый ашап-эчеп, шикәрле-баллы гайбәт чәйнәп, борычлы-тозлы анекдотлар сөйләшеп утыру өчен яхшы булып кала. Бакчаларга су сибәсе юк, балыкка барасы юк. Рәхәт!

Шулай да күңел дигәнең һавалар әйбәтләнгәнне көтә. Озакка сузылган яңгырлардан соң килгән аяз көн — һәвәскәр балыкчының иң якты хыялы. Менә шундый көнне алып чыгасы бар Фәнилне Идел өстенә!..

Без яхшы көнне көтеп яткан арада, Мәхмүт күршемнең улы кайтып төште. Әлеге Азат — балыкчының зурысы. Хәтерегездәдер, Сабанеевны яттан белә дигән идем. Аның өстенә, үз тәҗрибәсе дә, китапка салсаң, өч томга сыймас.

Әтисе турында әйткән дә юк. Тажи белән без дә аны үз улыбыздан якын күреп каршы алдык.

Сөйләштек. Көннәр әйбәтләнү белән, бергәләп, Фәнилне дә үзебез белән алып, балыкка чыгарга сүз куештык.

— Ярар,— диде Азат,— көннәр әкренләп әйбәтләнә торсын. Ә мин хәзергә үзем генә чыгып, разведка ясап кайтыйм. Моторны да сыныйм.

— Мотор турында борчылма,— дидем.— Минеке яхшы эшли.

Азат мәгънәле генә көлеп куйды.

— Минем мотор яңа бит хәзер,— ди.

Яңаның да ни җиттесе түгел, самый шәбе икән. «Вихрь»! Үзем алган булсам, хәтта бүләк итеп биргән булсалар да, бу кадәр куанмас идем. Шундый авыр нәрсәне күтәреп йөрү кайгысы артыр иде. Ә күршенеке булгач...

— Их, мин әйтәм, типтерәбез икән! Җордан калышмыйбыз булай булгач!..

Азат Идел өстенә чыгып киткәндә төш авып та җитмәгән иде әле. Көн һаман җилләп, явымлап тора иде. Чыгып китте дә югалды егет. Кич булды, болыт артында кояш батканы да күренмәде, капыл көн караңгыланып китте. Азат юк. Кичке аш ашадык, төн җитте. Йокларга яттык. Юк. Төне буе дигәндәй йокы аралаш ишетелгән мотор тавышларына колак салып яттым. Юк, кайтканы сизелмәде.

Иртән иртүк торып тышка чыгу белән су буена күз салдым. Юк, күршемнең көймәсе күренми. Мәхмүт янына барып карадым, йоклый, уятмадым. Тажи өе ягына колак салдым. Тынлык. Чын-чынлап борчу төште эчемә. Ераграк китеп, моторына берәр хәл булды микән? дим. Аннан да начаррак хәлгә очрады микән дип тә куркам. Нилэр булмас дисең төнге Иделдә? Бигрәк тә мондый җилле-яңгырлы чакларда?

Өченче ел күк күкрәгәндә мотор кабызып азапланган берәүне Идел өстендә яшен сукты... Үземнең бер томанлы иртәдә баржа белән бәрелешеп, бата язып калуым исемә төшә. Икенче бер вакыт, ярдан бик еракка көймәм белән бер төпсә өстенә барып менеп, ике сәгать буена ычкына алмый азаплануым күз алдыма килә. Тагын Мәхмүт янына барам. Йоклый, гамендә дә юк. Бу юлы түзмәдем, уяттым. Торып утырды, йокысын ача алмый.

— Ни булды?

— Азат һаман юк бит,— мин әйтәм.— Берәр җиргә тукталасы түгел идеме? Әйтмәдеме?

— Берни әйтмәде.

— Нигә һаман юк соң? Ни булды икән?

Әтисенең исе дә китми:

— Ни булсын аңа? — ди.— Тагы бер кич кайтмый калса да гаҗәпләнмим,— ди.— Хәзер аның бәйдән ычкынган Карабай кебек чагы.

Әтисе шулай дип торгач, мин дә борчылмаска булдым.

«Ярый алайса, йокла» дип, борылып китим дигәндә, Таҗи участогында шыбырдаган тавыш ишетелде. Әйләнеп карасам, Таҗи үзе алмагачларына шлангтан су сиптереп йөри. Нишли ул? Саташкан дисәм?

Ихтыярсыз янына бардым.

— Нишләвең бу, Таҗи дус?

— Алмагачларга су сибәм ич.

— Соң,— мин әйткәм,— акылыңдамы син? Өч көн буе яңгыр ява бит.

— Яуса ни!

— Эш юктан эш булсын, дисеңме?

— Бик беләсең килсә, торбаларда хәзер басымның иң көчле чагы, ди.

— Көчле булмыйча! Бу көннәрдә берәү дә сиптерми шул.

— Ә мин сиптерәм. Күрәсеңме, ничек каты бәрә!

Чынлап та шлангтан атылган су алмагач яфракларын өзә яза иде.

Бәхәскә кермәдем. Җавабы Хуҗа Насретдинны хәтерләтсә дә, белми эшләмидер. Югыйсә, алмагачлары бу кадәр шәп булмас иде.

— Ярар,— дидем.— Җаны теләгән жылан ите ашаган, диләр. Сибәсең килгәч, сип әйдә. Тик минә монда Азат кайтмаган бит әле. Кичә чыгып киткән кеше!

— Кайтыр...

## Телепатия

Кайтты шул. Кич булгач кына, әллә бүген дә юк инде дип, тагы да катырак борчыла башлагач кына кайтты. Чынлап та, борчылырга һич кирәк булмаган икән. Рәхәтләнгән егет, нәкъ әтисе әйткәнчә, бәйдән ычкынган Карабай кебек кыланган. Җитмәгән җире калмаган. «Мотор ничек?» дип сорагач:

— Во! — дип, сул кулының баш бармагын гына тырпайтты һәм уң кулы белән аның өстенә тоз сипкән хәрәкәт ясап куйды. Кармакны төпкә салып тоту өчен дә, спиннинг атарга да бик шәп урыннар тапкан. Безне ышандыру өчен дигәндәй, симез-симез генә корбаннар һәм бер чуртан белән судак тотып кайткан.

— Берсекөнгә төштән соң көн әйбәтләнә,— диде Азат.

Таҗи да, мин дә аның бу сүзенә сабый балалар кебек ышандык.

— Берсекөнгә? Димәк, җомга көн?

— Әйе,— диде Азат.— Кичтән чыгып китәбез. Шимбәне дә утрауда кунабыз. Якшәмбе көн кич кайтабыз.

Без аның бу тәкъдименә ризамы, юкмы, анысын сорап та тормады. Без дә каршы сүз әйтергә кыймадык. Чөнки беләбез: әз генә ризасызлык белдерсәк, теге «мин бер үзем китәм» диярго тора.

— Фәнилне дә чакырабызмы? — диде Тажи.

— Рәхим итсен! Дүрт кеше — чак кына була...

Ләкин безгә өчәү генә чыгарга туры килде. Азат белән сөйләшкән көнне үк Тажи, «Фәнилгә әйтеп куям» дип, Казанга кайтып киткән иде. Фәниле килде, үзе юк. Болай булган икән: Алма-Атагамы, Фрунзегамы — кемнеңдер юбилеена капыл гына бездән бер вәкил җибәрергә кирәк булган. Андый вакытта Тажига гына мөрәҗәгать ит. Командировка дигәндә хәтта балык белән дә исәпләшеп тормый. Кунак итеп чакырган җиргә булса инде, бигрәк тә. Алма-Атага гына түгел, Марска диген, минут эчендә җыенып чыгып китәргә әзер...

Азат әйткән прогнозны радио расламады. Ләкин без Азатка ышандык. Һәм аның дөрескә килгәнлеген өченче көнне үз күзләребез белән күрдек. Менә без, көн кичкә авыша башлаган булса да, әле бөтен көченә янган җәй кояшы астында ялтырап яткан Идел өсте буйлап түбән таба очабыз. Әйе, очабыз. Үзең утырып йөргәндә бигрәк тә искиткеч икән бу мотор. Моңарчы мин аны кешедә күрә идем. Дулкыны белән минем көймәне читкә тибәреп, янымнан гына выжлашып үтеп киткән «Вихрь»ларга, сокланудан бигрәк, ачуым килеп кала иде.

— Йөриләр шунда, масаеп! — дип сукрана идем. — Ни пычагыма кирәк икән шул кадәр ашыгу?

Үзең башкаларны выжлатып узып китү бик күңелле икән ул!

Үзләренчә җан-фәрманга эшләп барган «Стрела», «Зиф» яки «Кама» кебек моторлар «Вихрь» тизлеге янында бөтенләй туктап торган шикелле артта калалар. Хәтта «Москва»! Көймәләр генә түгел, катерлар артта кала, баржалар, пароходлар. Яр буенда күкрәп утырган урманнар, дебаркадерлар, авыллар бер-бер артлы күз алдыннан уза. Сул як ярда километрларга сузылган яр буе хуҗалыклары белән Казан үзе торып калды. Алда Түбән Ослан, Матюшино, Шеланга, Каратун, Кама Тамагы... Юлга чыкканга кадәр барасы җиребез көймә өчен чамасыз ерак тоелган иде. Азат шикелле «бәйдән ычкынган» яшь кешенең тиле маршрутына риза булып китү минем өчен азган атның тайга иярүе булмас микән дип, бераз шикләнеп тә торган идем. Хәзер күрәм, мондый мотор белән Камага гына түгел, Агыйдел тамагына, хәтта Уфасына кадәр китсәң дә гаҗәп түгел икән. Рәхәтләнеп, үз алдыма үзем горурланып барам. Тик бер нәрсә күңелне борчыгандай итә: мондый мотордан соң минем «Зифым» артык әкрен тоелмас микән? Машинадан соң алаша җигелгән арбага утырып барган шикелле эч пошыргыч булып калмасмы?

Идел буеның серле төне, ничек кәефле итеп кичке аш ашавыбыз, шомлылыгы белән гүзәл яр буенда кунуыбыз турыларында язып тормыйм. Минем өчен иң куанычлысы — Фәнилнең шат чырае иде.

Барып чыга болай булса. Үз кулы белән салмак-салмак кына балыклар да эләктерсә (Мәхмүт малае белән булгач анысында шик юк), тәмам кеше була бу егет...

Азат безне караңгылы-яктылыдан уятып, ары алып китте. Көн акрын гына яктыра. Идел киңәйгәннән киңәя, яр буйлары ераклаша бара. Кайбер юнәлештә хәзер аның чите бөтенләй югалып, офык белән тоташып китә. Диңгез! Әйе, диңгез! Ләкин безгә, бу җирләрнең иксез-чиксез тугай-болыннары, үзләренә күрә зур-зур тарихлары булган кечкенә-кечкенә авыллар, калын-калын урманнар белән капланган чагын үз күзләре белән күргән кешеләргә, ничектер ул мәңге болай диңгез булып кала алмас кебек тоела. Бу елларда безгә шулай кирәк булды, фәнтехникабызның, экономикабызның бүгенге дәрәҗәсе өчен шулай файдалы дип таптык та үз кулларыбыз белән Иделне диңгез иттек. Ихти-

мал, шундый дәрәҗәгә күтәрелербез: энергия чыганакларын ул кадәр табигый байлыкларны — бәрәкәтле туфрак белән капланган алтыннан кадерле җир мәйданнарыбызны меңәр-меңәр гектарлап корбан итмичә генә кулга алу юлларын табарбыз да диңгезне яңадан Идел хәленә кайтарырбыз.

Менә бит нинди уйлар килә күңелгә. Нигә килә ул? «Күңелгә килгән алга килә» дигән мәкаль бар. Юкка әйтелмәгәндер. Дөньяда беренче булып яңа җәмгыять төзибез. Коммунистик төзелеш практикабызда да кайвакыт тыштан караганда искегә кайту булып күренгән хәлләр чынлыкта алга китү булмыймыни?

Фәнилгә карыйм. Ул да уйланып бара. Ләкин аның башында бүтән уйлар. Бу минутта ничектер мин аның күңелендәге уйларын күрәм шикелле. Белмим, алга төшеребрәк киелгән капрон эшләпәсе, Идел киңлекләре өстен ашыкмыйча гына айкап баручы мәгънәле соры күзләреме, бер караганда ачулы гаҗәпләнергә, бер караганда чәнчеп елмаерга әзер нәфис ирен читләреме миңа ярдәм итә: чынлап та мин аның уйларын тоям.

— Никадәр су байлыгы безнең Татарстанда! — дип уйлый ул. Идел белән Камадан җәелгән Куйбышев диңгезенең яртысыннан күбе безгә керә. Өч йөз мең гектар дигән сүз... Әйе, әйе, нәкъ шулай уйлый. Ул санны мин, әлбәттә, үзем дә белә идем. Ләкин оныткан идем инде. Менә хәзер Фәнилнең уйлары аша ул санның өч йөз мең икәнен күрдем.— Ул уйлавында дәвам итә:— Камага коя торган Вятка, Агыйдел, Зөя, Ык кебек сулар бу санга керми бит әле, ди. Шуларга тагын ул елгаларның тугайларына сибелгән күлләрне куш... 317000 гектар су көзгебез бар. Ә магазиннарыбызда кайчан да булса бер свежий балык сатканнарын күргәнең бармы? Инде очраклы рәвештә тере карп сатканны күргәнсең икән, меңенче кеше булып чиратка басарга көчең җитәме? Свежий балыкны бит бездә хәзер күбесенчә браконьердан сатып алган кеше генә күрә дә, бик яхшы дигәндә, менә безнең кебек үзе тоткан кеше ашый...

Тукта әле, Фәнил уйлыймы соң боларны, әллә мин үземме? Юк, Фәнил. Шул турыда бер фельетон язарга каләме кычыта бугай аның...

Бу вакытта Азат алдагы юлны бинокль белән күзәтеп бара иде. Нидер күреп, кулы белән безгә ишарәләде. Ул күрсәткән якка борылып карадык. Безгә каршы яктан — ләкин шактый сулданрак, безнеке шикелле «Вихрь» моторы куелган дюраль көймәдә ике кеше килә иде. Берсе миңа таныш сыман тоелды. Ләкин ара шактый ерак булу өстенә, ике «Вихрь» тизлеге бергә кушылганлыктан, ачыклап өлгерә алмадым. Көймә безнең турыдан узып китеп, күздән дә югалды.

— Жор! — дип кычкырды Азат.

— Жор? — Фәнил сәер гаҗәпләнеп, көлеп җибәрде. Ул тагын нидер әйтте, тик мотор гөрелтесе аны юньләп ишеттермәгән иде. Азатның аны аңламый каласы килмәде, ахрысы, кинәт кенә моторын әкрен ходка күчерде һәм «нәрсә дидегез?» дип сорады.

— Жорны әйтәм,— диде Фәнил көлеп.— Озак яшәр: нәкъ браконьерлар турында уйлап бара идем.

Миңа кызык булып китте: дөрес сизгәнмен бит егетнең нәрсә уйлавын! Тукта әле, ачыклый төшик.

— Ә беләсеңме, Фәнил, мин бит синең нәрсәләр уйлаганыңны күреп килэм.

— Нәрсә уйладым, я әйтегез?

Бәйнә-бәйнә әйтеп бирдем. Фәнил гаҗәпләнүдән, хэтта көймәдә икәнлеген онытып, сикереп торды.

— Булмас ла! Ничек инде ул?

— Утырыгыз.

Азат та кызыксына калды.

— Әллә дөрес?
— Цифрларына хәтле дөрес. Идел белән Кама акваториясенең безнең территориягә кергән квадратурасын мин төгәл белмим. Өч йөз меңнән күбрәкме, азракмы? Шуңа күрә мин аны түгәрәкләп, чынлап та өч йөз мең дип уйладым. Тере карплар турында да нәкъ мин уйлаганча. Бер генә хатагыз бар. «Меңенче кеше булып чиратка басарга көчең җитәме?» — дидегез. Ә мин «меңенче» дип түгел, «йөзенче» дип кенә уйлаган идем. Фельетон язарга ниятләвем дә дөрес.
Азат, әлбәттә, ышанырга теләмәде.
— Мине юри шаяртасыз. Сөйләшеп куйгансыз...— диде.
Фәнил аңа җавап биреп тә тормады.
— Телепатия бит бу! — диде.— Башка вакытта да шундый күрәзәлек иткән чакларыгыз буламы?
— Үзем белән якыннан таныш кешеләрнең уйларын белгән чакларым була.
— Ничек итеп? Берәр сере бармы?
— Кешенең уен белү өчен билгеле бер вакыйгага, яки шартка мөнәсәбәттә ул кешене күңелдән үз урыныңа куеп карарга һәм үзеңне шул кеше итеп тоярга кирәк.
— Һәм ул мөмкин эш дисезме?
— Нигә булмасын? Менә сез мине беләсез. Тырышып карагыз әле, әгәр сез мин булсагыз, шушы Идел диңгезенә карап, нәрсә уйлар идегез?
Фәнил дә, Азат та беразга тынып калдылар. Мотор тавышы тагы да әкренәя төште.
— Минме? — диде Фәнил,— әгәр мин сезнең урында булсам, бу җирләрнең элекке диңгезгә кадәр булган күренешләре күз алдыма килер иде.
Азат көлеп куйды:
— Мин уйлаганны әйттегез!
— Менә бит,— дидем мин җиңүче кыяфәтендә.— Почти дөрес әйттегез. Инде, әгәр мине яхшы белсәгез, уегызны дәвам иттерә аласыз.
Тагын беразга тынып калдылар.
— Пасую,— диде Азат.
Фәнил сул учын җәеп аңа «тсс» дигән ишарә ясады һәм үзенчә мин булып дәвам иткән уен телдән әйтә башлады:
— Их, кызганыч! Нинди матур болыннарны, нинди зур табигый байлыкларны әрәм иттеләр бит. Моның өчен киләчәк буын безгә рәхмәт әйтмәс...
Нәрсәгәдер абынгандай, миңа карап, тукталып калды. «Дөрес дәвам итәмме?» дип сорый иде аның күзләре.
— Димәк, Михаил абзыеңны җитәрлек белмисең икән әле,— дидем мин.
— Үзем дә шулай дип шикләнгән идем.
— Димәк, картлар яшьләрне аңлап җиткермиләр дигәнгә караганда, яшьләр картларны аңлап җиткермиләр дигән сүз дөресрәк?
— Сездә, әлбәттә, тәҗрибә зуррак,— диде Фәнил.
Азат, бик әһәмиятле эшен оныткандай, сискәнеп китте һәм берни әйтеп тормастан, моторны тагы ходка җибәрде.

## Күктән төшкән егет

Үзара сөйләшү яңадан кыенлашты. Хәзер инде мин артка карап утырган хәлдә, күңелемнән Азатның зирәклегенә сокланып барам. Юньләп читләре дә күренмәгән шушы дәрья өстендә ничек итеп үзенә кирәк юлны таба ул? Без бит инде күптән фарватердан чыктык. Маяклар

бөтенләй диярлек күренми дә. Ә бу су төбендә нинди-нинди генә урыннар юк! Төбенә житкесез күлләр дә бар анда, тирән-тирән чокырлар, сыртлары өскә чыга язган калкулыклар, бер көнне күренә, бер көнне югала торган утраулар, түбәләре су өстенә килеп терәлгән төпсәләр... Мондый тигезлектә бару өчен аларны үтә күрергә кирәк бит. Миңа калса, бернинди ориентир да юк кебек. Ә Азат аларны тапкан. Болай гына күренмәгәннәрен бинокле белән карап ала. Үз-үзенә бик ышанып бара ул. Саклык йөзеннән моторын әкренәйткән чаклары бик сирәк. Андый чакларда без үзара сөйләшеп алабыз.

Менә Азат бинокль аша еракларны күзәтеп барган жиреннән ничектер сагаеп калды. Моторның йөрешен әкренәйтте.

— Карагыз әле! — Ул кулы белән сул якка ымлады.— Ә-ә-әнә тегендә.

Еракта, чиксез булып жәелеп яткан су өстендә бер кеше басып тора иде. Ерак булгангадыр, ул кечкенә күренә. Чынлап та кешеме соң ул? Әллә берәр корыган агач кәүсәсеме?

— Ул безне чакыра,— диде Азат,— мәгез әле, үзегез карагыз.

Бинокль аша карыйм. Чынлап та кеше. Кәрәмәт иясе шикелле, су өстендә батмыйча, басып тора. Әйтерсең боз өстендә. Әйе, безгә кул изи. Ничек анда кергән ул? Ярдан ерак, янында көймәсе-мазары да юк. Башыннан аягына кадәр киемнән. Хәрбигә охшый кебек.

— Гажәп! Мә әле, син дә кара.— Бинокльне түземсезлек белән көтеп торган Фәнилгә бирдем.

— Чынлап та безне чакыра ич ул! — диде Фәнил.— Барырга кирәк.

Азат күзе белән генә миннән сорый:

— Нишлибез?

— Барып карыйк, кеше бәлки берәр кыен хәлдәдер?

Азатның юлны бүләсе килми иде, ахрысы.

— Белмим шул,— диде.— Анда бик сай урын булса кирәк.

— Бармыйча ярамый,— диде Фәнил.

— Көймә белән берәр төпсә өстенә менеп утырмабызмы? Моторны бәреп, винтны сындырсак?

Фәнил икеләнергә урын калдырмады:

— Мотор өчен куркыныч булса, ишеп барырбыз, әйдәгез.— Һәм ул ишкәккә тотына да башлады. Ләкин ишәргә кирәк булмады, Азат моторны әкрен генә ходка куйган килеш көймәне кәрәмәт иясенә таба борды.

Якыная килә без ул кешенең башында пилотка, өстендә комбинезон икәнен күрдек. Карасу-көрән чырайлы, яшь-яшь егет. Ике аягын бергә кушып, су өстеннән кул яссуы гына чыгып торган төпсәме, баганамы өстенә баскан килеш, кымшанмый да безне көтә иде. Унбиш-егерме метр чамасы ара калгач, Азат моторны сүндерде.

— Якынрак килегез! — дип кычкырды теге кеше.— Курыкмагыз. Монда тирән.

— Тирән булгач, нәрсәгә басып торасыз соң сез анда?

— Якынрак килегез, зинһар,— диде теге.— Менә бу яктан. Туп-туры миңа.

Ишкәк ярдәме белән тагын якыная төштек.

— Каян килдегез сез монда? Күктән төштегезме? Су астыннан калкып чыктыгызмы?

Егет жавап бирергә ашыкмады. Ташлап китәрләр дип курыккандай, тизрәк көймәне үз янына китерәсе килә иде аның.

— Бире, бире! — диде ул, куллары белән үзенә таба ымлап.— Татарлар икәнебезне аңлап алды, ахрысы, ул да татарчага күчте.— Бире, әз генә болайрак. Юк, анда винт. Һоп! — Ул ничектер түземсезләнеп көймәнең борынын ике кулы белән эләктереп алды, шундук сике-

реп тә минде, аякларын эчкә салындырып, көймәнең борынына утырды һәм кинәт хәлсезләнеп калгандай булды.

— Уф!

Без аның үзе турында ни дә булса әйтүен көтеп, дәшми тордык.

— Әйе,— диде ул, ниһаять, минем баягы соравыма җавап биреп.— Иң элек күктән төштем, аннары су астыннан калкып чыктым.

Фәнилнең күзләрендә кызыксыну уты дөрләп яна инде инде:

— Нәрсә, әллә самолеттан егылдыгызмы?

— Вертолет белән...

— Ничек? Нигә? Нинди вертолет?

— Әнә су астында.

— Авария?

— Ярый, бәхет бар икән. Тирәнрәк урынга туры килсә, күптән беткән идем. Винт әз генә күмелеп бетми калды. Ике сәгать смирно басып тордым су өстендә.

— Бер көймә дә күренмәдеме?

— Сезнеке кебек мотор белән бер көймә килеп чыккан иде, мине күргәч кире борылды да китте. Юньләп күрә дә алмадым. Ике кеше иде бугай.

— Җор! — дип куйды Азат.

Егет тынып калды. Уйга батты. Без дә аны ашыктырырга кыймый торабыз. Азат «нишлибез?» дигән сорау белән бер миңа, бер тегеңә карый.

— Әйтеп бир инде син, егет,— дидем мин.— Шулай да ничек килеп чыкты бу эш?

— Үзең генә идеңме? — диде Фәнил.

— Бәхеткә каршы...

Ул тагын сүзсез калды.

— Я инде!

— Их, агайлар! — диде егет, өзгәләнеп, елар чиккә җитеп.— Харап булдым бит мин! Җинаять эшләдем, бик зур җинаять! Коточкыч!..

Сорау-җавап тәртибендә без чибәр егетнең кем булуы һәм ничек итеп аның мондый авыр хәлгә төшүе тарихын бик тиз белеп алдык.

Әлеге вертолет белән балык тотучы браконьер дигәннәре шушы кеше булып чыкты.

Гражданский авиациядән Татэнерго карамагына бирелгән Илбай исемле бу егетнең төп эше Татарстан территориясендәге югары вольтлы электр чыбыкларын күзәтүче кешеләрне утыртып, кирәкле маршрутлар буенча йөртү икән. Кайвакытларда аңа заказчигын Чистайда яки башка берәр шәһәрдә калдырып, Казанга ялгыз кайтырга туры килә. Маршруты билгеле: ул үзенә күрсәтелгән юлдан читкә чыгарга да тиеш түгел, тиешеннән югары күтәрелергә яки түбәнрәк төшәргә дә хакы юк. Әйбәт кенә эшләп йөри егет. Бервакытны аның пассажиры, ягъни аның машинасында очкан инженер-электрик, эше беткәч, аңардан үзен туган авылына илтеп куюны сорый. Илбай белә: моның өчен маршруттан чыгарга, ягъни законны бозарга кирәк. Ләкин заказчик сорагач, каршы килми, тегене илтеп куя. Кагыйдәне бер бозгач, ялгызы гына Казанга кайтып барган чагында инде ул үзен иркенрәк тота. Җитмәсә, Илбай үзе балыкчы да икән, каһәр. Кызыксынып, яр буендагы кармакташларын карый-карый кайта. Су өстеннән караганда балыкчылар тарафыннан яшерен урыннарга салынган җәтмәләр дә бик ачык күренә икән. Шуларны күзәтә. Болай иркенләп йөрү ошап китә яшь кешегә. Башка көннәрдә дә, эшне бетереп, ялгыз кайтырга туры килгән чакларда үзен иркенрәк тота башлый. Яр буендагы балыкчыларны өстән карап үтү белән генә канәгатьләнми, яннарына төшеп, тегеләрнең уңышлары белән кызыксына, ухаларын авыз итә. Яшерен урыннарга салынган җәтмәләрне якыннанрак күзәтәсе килә. Ул бит белә: һәвәскәрләргә

балыкны җәтмә белән тотарга рөхсәт ителми. Димәк, бу җәтмәләр — браконьерлар эше. Ә балык сакчылары аларны күрми. Их, аларга, рыбнадзор кешеләренә, вертолет кирәк иде!..

Башыннан яшьлек юләрлеге дә чыгып бетмәгән Илбай шулай рәхәтләнеп, Такташ әйтмешли, «күктә гулять итеп» йөри. Беркөнне моның браконьерларны кызык итәсе килә. Балык типкән акчарлак шикелле, су өстенә төшеп, бер җәтмәне эләктереп карамакчы була. Таба. Ап-ак пенопласт калкавычлары белән аермачык күренеп торган җәтмә турысына килеп туктала. Әкрен генә төшеп, ал тәгәрмәчне бераз гына суга тыгып, җәтмәне эләктереп алырга итә. Җәтмә эләгә язып-эләгә язып, ычкына. «Болай булгач, була!» ди Илбай. Вертолеты белән яңадан күтәрелеп, яңадан төшә. Һәм бу юлы эләктерә. Җәтмә күтәрелә. Җәтмәгә эләккән балыклар да оча. Ләкин шунда авария була язып кала: вертолет алга очышын тизләтә башлагач, һавада асылган балыклы җәтмә артта калып, вертолетның астына ябыша һәм чак-чак кына арткы винтка уралмый кала. Пилот моны сизеп, тизлекне акрынайта. Ашыкмыйча гына бер утрауга барып төшә. Кеше йөрми торган аулак, кечкенә утрау. Балык күп калмаган булса да, Илбайга житә. Ул үзенең ярамаган эш эшләве турында уйламый. Браконьерны кызык иттем дип көлә. Читен, хәтта хәтәр эшне шундый осталык белән башкарып чыгуына горурлана әле. Болай булгач, миннән космонавт та чыгар! — дип хыяллана. Бу башсызлыкны ул тагын берничә кат кабатлый. Хәтта берсендә янында пассажиры да була. Мондый тиле башбаштаклык, ниһаять, үзенең логик азагына китерә. Егет соңгы очуында, суга тирәнрәк салынган җәтмәне эләктерергә азаплана торгач, карбюраторның һава алгычына су керә дә мотор сүнә. Илбай үзе кабинадан чак чыгып өлгерә — вертолет шундук су төбенә чума. Бәхетсезнең бәхетенә каршы, бу җирдә тирәнлек ике ярым-өч метрдан артмый икән...

Бу мажара белән мавыгып, байтак вакыт уздырдык. Фәнилне инде әйтәсе дә түгел, хәтта үзем балыкка китеп баруыбыз турында бөтенләй оныта язганмын. Азат искә төшерде.

— Безгә ашыгырга кирәк бит, җәмәгать,— диде.— Барып җитәргә дә байтак бар. Чиртү вакыты үтә.

Вертолетның язмышы турында иң күп борчылучы кеше Фәнил иде. Берәр билге калдырырга кирәк иде бит. Бу урынны яңадан табу ансат булмас.

— Мин бу урынны хәзер күз йомып та табам,— диде Илбай.— Басып тора-тора әллә ничә ориентир чамаладым.

— Шулай да су әз генә артса, бу винт түбәсе юкка чыга бит.

— Әнә бутылка! — диде Азат.

Кичке аш вакытында бушап бетмәгән яртыбыз бар иде.

— Хәсрәтең бераз басылыр дип, калганын бәхетсез егет авызына бушаттык та, шешә утырып йөзсен өчен, эченә бераз су салдык. Авызына бөке тыгып, универсаль замазка сылап куйдык. Муенына 3—4 метр чамасы озынлыкта капрон кыл бәйләп, очучыга тоттырдык. Ул аны тиз генә баткан машинасының нәрсәсенәдер бәйләп куйды.

— Булды,— диде.— Әйдәгез.

— Кая илтәбез соң сезне?

— Ә сез кая таба?

Безнең тиз генә ярга чыгарга уйламавыбызны белгәч, егет аптырый калды.

— Эш бик житди бит, агайлар,— диде.— Сез мине, һич югында, яр буена чыгарып куегыз инде, зинһар.

Аның йөзе сизелерлек кызарып китте. Тавышы, юешләнгән сыман, йомшара төште. Күрәбез: шешә төбендә бик аз калмаган булган, ахрысы. Шулай да ул аның хәсрәтен басканга охшамый иде. Күз күреме

жирдә булса да «Вихрь» өчен әллә ни ерак булмаган яр буена килеп житкәндә, ул бөтенләй йомшарган булып чыкты.

Төшәргә тәкъдим иткәч, елый ук башлады.

— Агайлар,— диде.— Зинһар, ялгызымны жибәрмәгез. Жинаятем бик зур, куркам, я качып китеп харап булырмын...

Безгә бу кызык тоелды. Аңа ничек дип жавап бирергә белмичә, көлешеп алдык. Бигрәк тиз башына киткән. Эчеп өйрәнгән нәрсә дә түгел, күрәсең, мескен.

— Әлфиякәем бар бит минем... Туебыз булганга ярты ел да юк. Балык талымлап йөри, әни нишләр, мескен?

— Баштарак уйларга кирәк иде, энекәш! — дидем мин.

Энекәшем йомшый гына төште.

— Асс булу турында хыяллана идем бит мин! Космонавт булу турында!..

Фәнилгә житә калды бит.

— Егетләр,— диде,— мәсьәлә чынлап та бик житди. Әйдәгез, пристань ерак түгел, илтеп куйыйк.— Ул хәзер күңеле белән безнең янда түгел иде инде. Фәнилдән башка гына балык тотарга туры киләчәк.

Шулай булып чыкты да. Пристаньга барып житкәндә, Фәнил Илбай белән бергә үзе дә төшеп калырга дигән карарга килеп өлгергән иде инде.



ЖИДЕНЧЕ БҮЛЕК

## Авыз белән түгел, күз белән кара!

Шуннан соң мин Фәнилне тагын тиз генә күрә алмадым. Азатның кайтуы безнең эшләрне бермә-бер жиңеләйтеп жибәрде: балыклы урын эзләү хәсрәте дә үзебезнең өстә түгел, көймә, мотор турында кайгыртасы да юк. Хәтта кайвакыт кормушка әзерләргә өлгермәсәң дә хур булмыйсың. Запаста Азатның күгәргән боткасы табыла. Тажи белән безгә, кармакларыбызны тотып, әзер көймәгә чыгып утырасы гына кала.

Дөрес, компаниябез аз сүзлерәк. Чөнки Мәхмүт күршебез малае кайтканнан бирле бөтенләй итекле песигә әйләнде. Сыланы гына балыкка саный. Алабуга булса, аның генерал чинындагысын гына кабул итә. Кайчак ялгышып чөгә эләгеп кайтса, аны принципиально ашамый: тотарга тыелган балык. (Бу мәсьәләдә минем дә, Тажиның да, хәтта, яшь булса да, Азатның да — аңыбыздан капитализм калдыгы чыгып бетмәгән. Чөгә тотуны аңлы рәвештә үзебезгә максат итеп куймыйбыз куюын, ә инде кайвакыт очраклы рәвештә кармагыбызга килеп эләгә икән, аны тотарга закон кушмый дип, кире жибәрергә көчебез житми, хәтта бер килолы булса да.) Мәхмүт дустыбыз үзе балыкка чыгу турында уйламый да хәзер. Без китәбез, ә ул рәхәтләнеп йоклый. Йокысы туйгач, алма төпләрен казып күңел ача, жиләк түтәлләренә су сибеп кәефләнә. Ара-тирә аучылык дәрте кузгалып киткән чакларда безнең белән чыккаласа да, гадәттәге Мәхмүт түгел. Янында малае булганда аның чәчәкле, чуклы теле тулысынча ачылмый. Ата янында бала үзенең кайбер тойгыларын күрсәтергә оялган кебек, бала янында ата да тартына.

Әйтик, шәһәр тирәсеннән еракта, кечкенә-кечкенә утрауларда яки Идел ярының аулак урыннарында бөтенләй киләчәк заман модасында киенгән яшь-яшь хатын-кызлар очрый. Кояшта кызыналар алар, су

коеналар яки сәламәтлек өчен файдалы төрле тән хәрәкәтләре ясыйлар. Табигатьнең бу гүзәл күренеше, әлбәттә, безнең барыбызның да игътибарын җәлеп итә. Мәхмүт дустыбыз исә, үзебез генә булганда, аларның без күреп бетермәгән матурлыкларын ача һәм алар турында үзләреннән дә матуррак итеп сүз белән әйтеп бирә белә. Ә менә янында малае булса,— юк. Гади күз белән генә түгел, бинокль аша караса да, я берәр пароход исемен күрә, я берәр утрау өстендә юктан бар булган яңа өйне. Ә ул өй тирәсендә боргаланып йөргән нәфис табигать күренеше турында ләм-мим...

Шуңа күрә Азат белән булганда, Мәхмүт безнең өчен чыкты ни, чыкмады ни. Хәтта чыкмавы яхшырак та. Чөнки садок тутырып балык алып кайткан кешеләрне мәгънәсен аңлап каршы ала белүче дә кирәк бит. Ә Мәхмүт аны гына белә инде.

Мөхәммәтша дустыбызны юксынмыйбыз (аңа шул кирәк: шушындый вакытта Идел буен ташлап, диңгез ярларына киткән бит, юләр.)

Дөресен генә әйткәндә, Азат янында аның әдәпсез әкиятләрен тыңлап утыру безнең өчен дә бик уңайлы булмас иде. Кордашыбызның улы үз улыбыз кебек.

Кыскасы, үз хәлебездән бик канәгать булып, Азат компаниясендә үзебезне, рус агай-эне әйтмешли, Гайса пәйгамбәр куенындагы кебек тоеп йөрибез. Балыксыз кайткан көнебез юк. Тагын ни кирәк? Кайвакыт кирәгеннән артыграк тотып кайтабыз икән, анда да кая куярга белми аптырыйсы түгел: Андрюшиннар исән, яхшы күрше буларак хәлебезне аңлыйлар. Теге вакыттагы шикелле уңайсызланып, тәкъдим ителгән балыктан баш тартып тормыйлар. Чөнки соңгы көннәрдә Җор күренми башлады. Көләч бабай әйтә:

— Иртәгә балык китерәм дип киткән иде,— ди,— менә ике атна була инде, ... күзгә-башка күренгәне юк...

Җорын шайтан алсын, җәй үтеп бара монда, җәй! Эх, бу җәйнең ямьле көннәре! Яшь гомер кебек, узып киткәнен сизми дә каласың! Балык тоту өянәгем басылыр көннәр җитеп килә. Күрше-күлән, дус-иш белән бер җыеласы иде бит.

Таҗи һаман Фәнилне юксына: «Тәки балык тотарга өйрәтеп булмады үзен,— ди.— Әрәм була бит егет,— ди.— Нәкъ менә хәзер, Азат монда чакта безнең янда булуы кирәк иде»,— ди.

— Азат белән дә алып чыгып карадык,— мин әйтәм.— Булмый күрәсең инде. Аның белән чыксаң, үч иткән шикелле, нинди дә булса бер «чыпыга» тап буласың.

— Чыпы дигәннән, теге вертолет белән балык тотучы нишләде икән?

— Ә теге боз астыннан чыккан мәет?

Шулар турында белү өчен генә булса да Фәнил белән очрашырга кирәк иде бит безгә.

— Таҗи,— мин әйтәм,— кайдан эзләргә беләсең. Тап әле син аны. Чакыр. Бәлки спиннинг ошап китәр үзенә. Каккрас җор башланган вакыт!..

— Тапмый калмыйм мин аны! — дип, Казанга кайтып киткән Таҗиебыз тагын үзе юкка чыкты. Бу юлы Мәскәүгә, табигать дуслары конференциясендә бездән өч делегат кирәк булган да, берсенә Таҗины тотып алганнар.

Азат ялының соңгы ун көнен Балтик буе илләренә сәяхәт итәргә планлаштырган булган икән, аның да китәр көннәре җитте. Иртәгә үзе белән быелгы сезонда соңгы тапкыр балыкка чыгарга хәзерләнәбез. Өченчегә Мәхмүтне дә алып барасыбыз килә. Ә ул теләми. Азатны тыңламагач, үзем үгетләп карадым, юк, аны бер әйткән сүзеннән кайтару бик кыен. Минем дә тиз генә чигенәсем килми. Нинди ход ясарга аны ризалату өчен? Азаттан яшергән булып, чалбар кесәсеннән генә

ачылмаган КВ бөкесе күрсәтеп карарга мы? Белмим шул, яшьлек чагы булса, бәлки тәэсир итәр иде. Ә хәзер? Өстәвенә — улы янында. Юк, барып чыкмас. Артык иркәләндең дип, оялтып карарга мы? Ай-һай, аны оялтулары! Картайдың дип гарьләндерергә мә әллә үзен? Юк, иң яхшысы — үпкәләп куркытам мин аны. Нигә? Ничәмә-ничә еллар буе дус булып йөреп, шушы гына үтенечемне дә тыңламагач, аңа үпкәләргә хакым юкмыни минем? Бар.

Ләкин эш аңа барып җитмәде. Көтмәгәндә генә Фәнил килеп чыкты, рәхмәт төшкере. Авызы ерылган, кулында яшел чехолы да салдырылмаган өр-яңа спиннинг. Икенче кулында ястык чаклы сары портфеле, портфеле эчендә катушкасы да, блесналары да бар.

Шундук эчкә җан керде. Тукта, мин әйтәм, болай булгач, Мәхмүткә ялыну, бәлки, кирәкмәс тә әле.

Һәм кирәкмәде дә. Фәнил чынлап та безнең белән балыкка барырга килгән булып чыкты.

Шушы арада аның туган көне узган икән. Бер иптәше бүләккә спиннинг тотып килгән.

— Мин анда, редакция сотрудниклары арасында, иң атаклы балыкчы исәпләнәм,— дип көлдерде ул безне.— Сезнең белән аралашуым аркасында шундый авторитет!

— Җүнлерәк балыкчыгыз да юкмыни соң? — ди Мәхмүт.

Көлә Фәнил.

— Бар иде берәү,— ди. Үзе як-ягына карана.— Мөхәммәтша абый юкмы монда, юк! Аңа сөйләрмен дигән идем. Аның репертуарына бик туры килә торган хәл.

Болай дигәч, безгә җитә калды. Мөхәммәтшаны да күптән тыңлаган юк. Газетадан укып, радиодан ишетеп, телевизордан күреп булмый торган вакыйгалар турында ишетәсе килә.

— Я, я, сөйлә, Мөхәммәтшага үзебез ирештерербез.

— Алайса, күргәндә үзегез әйтерсез. Берәү дигәнем,— штаттан тыш хәбәрчебез ул безнең. Ләкин редакциядә штаттагылардан да ешрак буладыр. Шул, кыш көне балыкка йөрергә бик ярата торган булган. Кармакларын алып, биштәрен күтәреп, җомга көн кичтән чыгып китә Васильевога, якшәмбе көн кич кенә өенә кайтып керә. Кайткан саен ике-өч кило менә дигән балык.

Бер көнне хатынына ишеттерәләр. Синең ирең бит анда бер матур апайга иялэшкән. Ул апай аны ике көн, ике төн буе бик шәпләп кунак итә, сиңа күчтәнәчкә сатып алган балыгын бирeп җибәрә. Ирең боз өстенә чыгып та керми, кармакларын чишеп тә карамый,— диләр.

Безгә кушылып Фәнил үзе дә көлә.

— Мөхәммәтша абый булса, әлбәттә, моны болай гына сөйләмәс иде,— дип куя һәм үзенчә дәвам итә.— Ярар,— ди хатыны. Ләкин иренә бернн сиздерми. Алдагы җомганы тегенең җыеп бәйләп куйган кармакларын шыпырт кына җеп очыннан кисеп алып кала.

Ике көннән кайта ире балык алып.

— Абау әйбәт балыклар,— ди хатыны.— Үзең тоттыңмы?

— Үзем булмыйча?

— Шушы кармаклар беләнме?

— Әлбәттә.

— Кармаксыз җепкә ничек эләгә соң ул балык?

Ир сагая кала. Ул уйлап өлгергәнче, хатын үзенең ишеткәннәрен дә, хәйләсен дә бәреп әйтеп сала.

Ир — ык-мык.

Һәм шуның белән балыкчылык карьерасы гомергә өзелгән штаттан тыш хәбәрченең.

— Җүнле хәбәрче дә түгелләр,— дип куйды Мәхмүт.

— Ихтимал. Сездә нинди яңалыклар?

— Сездән көтәбез.

— Мин ни, иптәшләрнең ышанычын акларга кирәк бит. Менә сезнең ярдәм белән бүләкне сынап карарга дип килдем.

Хуп күрүебезне без аңа башта ук әйтеп куйган идек инде. Нинди яңа хәбәрләр алып килүе турында сорадык.

— Нәрсә әйтим,— диде Фәнил.— Теге очучының эше судта. Чынлап та шактый җитди җинаять эшләгән булып чыкты. Өч ел чәпәрләр төсле күренә...

Баткан вертолетны махсус кранлы буксир белән күтәртеп чыгарганнар. Материаль зыян ун меңнән арта, ди. Өстәвенә, егетнең аңа кадәр дә тәртип бозулары күп булган. Яңадан очучылык эшенә кайтуы икеле, ди.

— Факты кызык,— диде Фәнил.— Шулай да аның турында ни дә булса язасым килми. Акларга ярамый. Матбугат аркылы каты хөкем итәргә дә кызганам мин ул егетне. Хулиганлыгы да безнең чорга хас рухта. Бу сиңа «зәңгәр төндә күрше карчыгының ак әтәчен кереп урлау» гына түгел инде. Менә шул. Күрербез. Ни белән бетәр.

— Тагы?

— Тагымы? Җор турында ишеткәнсездер инде?

— Нишләгән?

— Чынлап та ишетмәдегезме?

— Шуны гына беләбез: соңгы көннәрдә бу тирәдә күренми.

— Утыра,— диде Фәнил.

Ни өчен икәнен дә белгәч, күзләребез шар булды.

Баш сөяге буенча ясалган рәсемгә карап таныганнар: теге мәет бер дружинникныкы булып чыккан. Яңарак кына армиядән кайткан егет икән. Беркадәр вакыт балык байлыкларын саклау экспедициясендә эшләп йөргән. Аннары, туганнарын эзләп, Төркстан ягына китте дип уйлаганнар. Бактың исә, аны үтереп боз астына тыкканнар икән. Тикшерә торгач, очына чыкканнар — Җор эше, ди. Браконьерлыкта Җор ялгыз түгел икән. Бер предприятие каршында, аучылар коллективы исеме астында балыкчылар группасы эшләгән. Предприятие исеменә алынган моторлар, металл көймәләр, катерлар, балык тоту әсбаплары белән эш иткәннәр. Тере килеш сатып яки саттырып өлгермәгән балыкларны мичкәләрдә тозлаганнар. Яр буендагы хуҗалыкларында бишалты центнер балык табылган. Табылмаган яки сатылмаган кадәресен дә исәплап чыгарганнар. Кыскасы, яшерен балык заводы ачканнар. Теге егет боларның эзенә баскан. Аңардан котылырга кирәк булган. Бу эшне шулай шома башкарып чыгучы Җор икән.

— Прокурор белән сөйләштем,— диде Фәнил.— Моның өчен аңа вышка булачак, ди. Иң югары җәза!

Беравык ни әйтергә белми аптырашып тордык.

— Менә сиңа Җорочка!

— Димәк, янәшәбездә атып үтерелергә тиешле бандит йөри, ә без тып-тыныч күңел белән шуның балыгын алып калабыз! Җитмәсә, ике бәясен түләп! Җитмәсә, рәхмәт әйтеп!

— Бик шәп! — дип куйды оптимист дустым.

— Нәрсәсе шәп булсын инде?

— Бандитның тотылуы шәп. Икенчедән, безнең ише табигать сөючеләрне әйләнә-тирәбезгә авыз белән түгел, күз белән карарга өйрәтүе яхшы!

## Сәгатьле чуртан

Ниһаять, сезон үтеп барганда булса да, Фәнилгә дә фарт килде. Фәнил булгач, әлбәттә, «чыпысыз» гына булмады. Ләкин зарарсыз, хәтта, мин әйтер идем, күңелле «чыпы».

Иртә белән көн яктырып бетәр-бетмәстән без өчәүләп Иделгә чыгып киттек: Азат, Фәнил һәм мин.

Тажи белән минем һәрвакыт Фәнил турында кайгыртып сөйләшүебез Азатка да йогынты ясаган, күрәсең. Иделнең кай турысына бару яки нинди балыкка кармак салу турында гомердә сорамый торган кеше,— бу юлы иң элек Фәнилгә мөрәҗәгать итте:

— Нишлибез? Донкага тотабызмы, әллә спиннинг атабызмы?

— Минем, әлбәттә, бүләкне сынап карыйсы килә инде,— диде Фәнил.

Минем каршы түгеллегем Азатка билгеле иде инде.

— Булды,— диде.— Мин сезне чуртан оясына алып барам.

Ун минут үтмәгәндер, дүрт-биш километр араны үтеп, Иделнең Олыкүлгә аерылып кергән җирендәге ике утрау турысына килеп тә урнаштык. Каршы якта километрларга җәелгән су көзгесе, комлыяшелле утраулар аша, бөдрә урман белән капланган таулы ярлар арасында, тарихи чиркәүләре белән балкып Зөя күренә. Артыбызда сыгылмалы таллар арасына күмелгән балыкчылар таборы: фанер өйләр, аклы-яшелле палаткалар. Латыйп карт та шунда булырга тиеш. Нишләп ята икән? Балыкка киткәндер әле. Борыннарын ярга төрткән көймәләр сирәк күренә. Димәк, аларның күбесе балыкта. Ләкин алар, бу утрауда яшәүче балыкчылар, берсе дә безнең тирәдә юк. Яхшырак, балыклырак урын эзләп, еракка, Иделнең аръягына олакканнар. Шулай бит ул: балыклы урыннар, җиләкле аланнар, китапка язарлык әйбәт геройлар һәрвакыт син үзең яшәгән урыннан еракта булалар.

Әйтик, Казанда яшәүче балыкчылар, балык тотарга әйбәт урын эзләп, безнең дачалар янына килә. Ә без — үз дачаларыбыздан мөмкин кадәр еракка — Олыкүл тамагы тирәсенә китәбез. Ә мондагылар — шайтан белсен кая, тик үзләре яшәгән җиргә якын гына булмасын. Балык үзе дә ерактанрак килгән кешеләрне якын итәдер, ахрысы, тәҗрибә шуны күрсәтә. Мисал өчен әллә кая барасы түгел, менә шушында, якындагы балыкчылар санга сукмый ташлап киткән тамырлы урында, күпме балык тоттык бит!

Азат безне аеруча шаккатырды. Ул бүген бөтенләй коммунистик хезмәт ударнигына әверелде. Тырышты гына түгел, илһамланып, янып, ижат итеп эшләде. Туры мәгънәсендә ике станокка күчте. Әйе, әйе. Без, мәсәлән, атабыз да, кармагыбызның су төбенә төшеп җиткәнен көтеп утырабыз. Шул кадәр озак төшә, ул төпкә барып җиткәнче ашыкмыйча гына егерме бишкә-утызга кадәр саныйбыз. Кызурак тотсаң, алтмышка, җитмешкә кадәр санарга да була. Салган саен бит ул! Ә без аны мең тапкырдан да ким салмый торганбыздыр... Менә шуннан исәпләп кара инде. Салган саен ярты гына минут әрәм булса да, мең тапкыр салганда, күпмегә җыела?

Ә Азат берьюлы ике спиннинг белән эш итә. Берсе төшеп җиткәнче икенчесен чыгара тора. И бер минуты да әрәмгә үтми — бусы бер.

Икенчедән, без кармагыбыз төпсәгә эләксә, аны ычкындыра алмый азапланабыз. Өзеп калдырабыз. Кайчак кармагыбызга коряга яки бик зур балык эләккәнне белмичә, капылт тартып җибәрсәк, шарт итеп спиннингыбыз сынып чыга. Шундый кыйммәт бәягә «Динамо»дан сатып алынган купшы спиннинг! Азат аны сатып алмый, үзе ясый. Имәннән я өрәңгедән. Сындырып кара син имән казыкны! Бусы ике.

Өченчедән, ыргытырга җайлы дип, без кылның 0,6, күпкә китсә 0,7 миллиметр калынлыктагысын йөртәбез... Тазарак тамырга эләксә, өзми булдыра алмыйсың. Азатның кылы бер миллиметрлы. Аны инде шайтан да өзә алмый. Төпсәгә эләгә икән, анда да өзелеп түгел, кармагы төзәеп ычкына. (Азат өч җәпле кармакның шундыен махсус сайлап ала.)

Нәтиҗәдә менә без әле бер балык тотарга да, хәтта кармагыбызны тамырга эләктерергә дә өлгермәдек, Азат инде ун тамырдан исән-сау котылды, садогына бер чуртан да салып куйды. Һәм шул беребезгә эләккән бер килолы бер чуртан өчебезнең дә дәртен ун өлеш арттырып җибәрде. Кармакларыбызны очынып-очынып атарга тотындык. Фәнил шул кадәр канатланды, хәтта, сак булырга кирәклекне дә онытып, бер ыргытуында кармагы белән Азатның кәпәчен эләктереп алып китте. Бу хәлгә иң элек барыбыз да бик нык шатланыштык. Ярый әле, кәпәче генә, колагы яки борыны эләксә, егетебез сугышка бармый ветеранга әйләнер иде,— дибез. Ә болай, башыннан кәпәче очкач, Азат матурланып кына калды. Ни өчен дисәң, кәпәч дигәнем кәпәч тә түгел, соңгы елларда пәйда булган шундый бер шыксыз баш киеме. Кепка дисәң, кепка түгел, ни эшләпә, ни берет. Үзенең махсус исеме бардырмы, белмим (сөекле укучыларым, тәнкыйтьче дусларым гафу итсен, исемен ачыклау өчен аны теккән фабрикага махсус иҗат командировкасына барып йөри алмадым), шунысын гына беләм: бизәк урынына зәңгәрле-кызыллы буяу белән төрле кала исемнәре язылган ак чүпрәктән бөргәннәр дә бер читенә яшел пленкадан козырек тегеп куйганнар. Бөрмәсе трусик бөрмәсе кебек резинкалы булганга, бер үк калыптан чыкканы өч яшьлек сабыйга да ярый, алтмыш яшьлек Таҗига да. Тик аерма шунда, сабыйлар башында ул табигый күренә, ә өлкән кешене юләр сыман кыяфәткә кертә. Аны кигән кеше яшькә никадәр олырак булса, шул кадәр дураграк булып күренә (әйе, юләррәк кенә түгел, дураграк).

Азат аны Фәнил кармагыннан пәке белән ычкындырып алып, яңадан башына кия башлагач, үзенә дә әйттек:

— Кимә шул клоун бүреген, син болай акыллырак күренәсең,— дидек.

Ул:

— Балыкчының акылы буламыни? — дип кенә җавап бирде дә яңадан тилемсә кыяфәткә керде.

Барыбыз да көлешүдән туктап, моннан соң саграк булу турында бер-беребезнең исенә төшерештек. Күп тә үтмәде, Фәнил тамырга эләктереп кармагын өздерде. Блесна запасы да аз икән, Азат аңа кармагын көймәдән ерак ыргытмаска киңәш бирде:

— Хәтта бөтенләй ыргытма, көймә турысына гына төшер дә, блесваңны төпкә җиткерер-җиткермәс уйнатып кына утыр,— диде.

Фәнилгә, әлбәттә, бу ошамады. Тагын мин аның башындагы уен күрдем. «Юат инде, юат! — дип үпкәли иде ул күңеленнән Азатка.— Бала-чаганы алдаган кебек алда!»

— Ә син борчылма, Фәнил,— дидем мин аңа.— Азат синә юри әйтми. Уйнат блеснаңны.

— Рәхмәт болай теләктәшлек күрсәтүегезгә,— дип җавап бирде ул һәм теләр-теләмәс кенә кармагын бер күтәреп, бер төшерүдә дәвам итте. Хәзер аның өчен барыбер иде инде. Күрәм: бүләк ителгән спиннинг белән кабына башлаган дәрте бөтенләй сүнеп бара егетнең.

Шунда кинәт әллә ни булды. Фәнил инде сүнеп беткән җиреннән кинәт дөрләп кабынып китте. Күзләре очкынланды. Утырган урыныннан сикереп торды.

— Капты! — дип кычкырып җибәрде.— Коточкыч!

Ул нишләргә белми, кылы әле унга, әле сулга тартыла иде. Азат белән мин үз кармакларыбызны ташлап, аңа ярдәмгә килдек.

— Каптырдыңмы?

— Әһә, бушат әзрәк, җибәрә төш... Хәзер инде китер.

Өчәүләшеп дигәндәй көймә янына китереп җиткердек, сачок белән сосып алдык. Әллә ни түгел икән. Булыр-булмас бер килолы чуртан. Ләкин Фәнил өчен моның әһәмияте әйтеп бетергесез иде. Азат та, мин дә үзебез тотканнан артык шатландык. Фәнил бөтенләй икенче кешегә

әйләнеп китте. Хәзер инде ул кармагын көймә янында шундый дәрт белән уйната — ераграк ыргыту турында уйлап та бирми. Азат тагы бер яшь чуртан белән бер карт алабуга тотты. Мин бер баларак сыла эләктердем. Берсенә дә исе китмәде, Фәнилебезнең үз кармагы кармак. Уйната гына. Аның өчен куанып, үзенә сиздерми генә күзәтеп утырам. Әйбәт. Күзләрендә балыкчы хиреслеге яна... Чү! Ни булды? Ул кинәт нәрсәдәндер шомланып, хәрәкәтсез калды. Чыраена ачыктан-ачык куркыну билгеләре чыкты.

— Тамыр! — диде ул, тирән көрсенеп. Шайтан алгыры! Бүтән блеснам да юк бит.

«Кайгырма, табарбыз!» дип әйтергә өлгермәдем, тегенең тормозга куелган катушкасы кинәт бик каты чырылдап китте. Фәнил бөтен көймәне дер селкетеп, сикереп торды һәм үзенекенә охшамаган тиле тавыш белән илереп кычкырып җибәрде:

— Акула!!

Без тагын үз кармакларыбызны онытып, тәҗрибәсез иптәшебезгә ярдәмгә ашыктык. Аның кармагына эләккән балык бу юлы чынлап та акула диярлек бар иде. Безнең консультация астында Фәнил аны бер җибәреп, бер якын китереп ун-унбиш минут чамасы уйнатканнан (яки балык теле белән әйтсәк, азапланганнан) соң, ниһаять, көймә янына китереп яткырды. Нәкъ моннан өч ел элек минем алтын-сары карасигымны өзеп ычкынган чуртан. Ярты көймә буйлыгы бар. Әһә! Ниһаять, өч ел буе бушка өстерәп йөрткән бозау сыешлы сачогымның да, тимер ыргагымның да кирәге чыкты. Өч ел буе форсат көтеп йөргән тәҗрибәне ходка җибәрер көн килде.

— Туктагыз, мин әйтәм, ашыкмагыз! Хәзер беркая да китми ул! Иң әйбәте аны менә шулай ыргак белән тамак астыннан... Һоп! Һи-һи! Һи-һи-һи!.. Кайберәүләр, мөгаен, ычкындырды, дип уйлый торгандыр әле. Юк инде. Әнә ул, килбәтсез зур гәүдәсе белән, оялмыйча, көймә эчендә ята... Тукта?! Нигә анда ике блесна? Берсе авызында, берсе тамак астында? Әллә бу теге минем алтын-сары...

Балыкчы башына гына килүе мөмкин булган юләр уемны уйлап бетерергә өлгермәдем, Фәнил балалар шикелле шатланып, кычкырып җибәрде:

— Карагыз әле, сәгатьле чуртан ич бу!

— Сәгать? — Кылт итеп Латыйп карт исемә төште.

Карасам... чынлап та шул: «Латыйп кордашка, алтмыш яшең белән котлап, дусларың». Ах, картлач! Тәки түземе җитмәгән икән. Хәер, анысына гаҗәпләнмим. Хәтта сәгатьле чуртанның нәкъ менә безгә килеп эләгүенә дә алай ук исем китми. Шунысына шаккаттым: сәгать келткелт йөри. Үз сәгатем белән чагыштырып карыйм — минутка минут. Календаре да бүгенге числоны күрсәтә. Әнә нинди бит ул безнең Чистай сәгате!

Көймәдәшләремә шундук бу сәгатьнең үзем белгән тарихын сөйләп бирдем. Фәнил белән таныштыру турында Латыйп картка сүз бирүемне дә әйттем.

Тагын ничә балык тотуыбыз турында язып тору инде үзем өчен дә кызык түгел. Гомумән, шушында нокта да куйган булыр идем. Фәнил турында тагын бер-ике сүз әйтәсем калды. Аның кәефе гомердә булмаганча шәп иде. Тизрәк Латыйп карт янына барырга җыена башлагач, ул үзенең капчыгыннан яшькелт-кара сыекча белән тулы бер шешә китереп чыгарды.

— Егетләр,— диде,— минем сезгә тагын бер сюрпризым бар бит әле. Юри әйтми тордым. Алданрак әйтсәм, спиннинг турында онытып, божра белән тотарга ашыктырырсыз дип курыктым. Менә ул: киндер мае!

Табам мин аны, дигән иде, тәки тапкан икән. Тик үзебездән түгел, каяндыр Кавказ ягыннан алып кайтканнар. Аңа хәтле Фәнил, әлбәттә, мәсьәләне ачыклаган. Татарстанда чынлап та элеккерәк елларда киндер үстерү белән шөгыльләнгәннәр икән. Тик авыл хуҗалыгы фәненең бүгенге җиңешләре югарылыгыннан караганда, безнең җирләр өчен аның хәзер экономик эффекты юк, ди.

Ярар. Без аны сынап карарбыз әле.

— Әйдәгез, балыкчылар утравына, Латыйп карт янына. Сәгатен күрсәтеп шатландырыйк. Хатыны террорлавыннан да тизрәк коткарыйк үзен...

## Рәхмәт сиңа, Идел!

Балыкчылар утравыннан без Азат белән икәү генә кайтып киттек. Латыйп карт чаклы Латыйп карт янында торып калмаса, Фәнил дигәнебез Фәнил дә булмас иде. Димәк, «акула», гади генә түгел, сәгатьле «акула» тотса да, невропотологлар таләп иткән дәрәҗәдәге балыкчы булып җитмәгән әле. Соңрак без моны тагын да ачыграк күрдек.

Икенче көнне Азат китте. Озакламый Таҗи да Мәскәү ягыннан әйләнеп кайтты. Фәнил киндер маенның көчен сынап карарга бик кызыгып йөри иде, ул да килде. Быелгы сезон өчен Идел белән саубуллашырга чыгабыз дигәч, Мәхмүт дустыбыз да безнең белән барырга ризалыгын бирде. Булгач-булгач, бергә булсын иде инде дип, Мөхәммәтша дустыбызны да эзләп караган идек тә, әле кайтмаган булып чыкты. Үзе түгел, хәзергә аның турындагы бер анекдот кына кайтып житте әле, диделәр. Кемдер Адашның үз авызыннан ишетеп кайткан. Имештер, Кара диңгез өстендә сәяхәт кылып йөргәндә, авариягә очрап, боларның катерлары бата башлый. Запас көймә яки коткару бoҗрасы кебекләр беренче чиратта балаларга һәм хатын-кызларга бирелә. Яшьрәк ирләр йөзеп, йөзә белмәгәннәре буш шешәләргә тотынып чыгалар. Ә безнең Мөхәммәтшаның яшерен кесәсендә ни өчендер балалар очыртып уйный торган резин шарлар булган икән, өреп, куыклар ясаган да шуларга ябышып котылган, ди. Дөресме-юкмы? Үзе кайткач сөйләр әле...

Чынлап та киндер маенның хикмәте булдымы, уңышлы урын сайлаганбызмы, әллә инде көне шундый туры килде — сирәк була торганча кырдык без ул көнне балыкны. Таҗи белән минем турыда әйткән дә юк. Хәтта Мәхмүт өч кило чамасы тотты. Ә Фәнил! Ә Фәнил!.. Сала. Чирткәнне дә көтми, уникегә кадәр саный да тарта. Балык! Үзенә-үзе хәйран ул бүген. Балык эләккән саен куанычына чыдый алмый — кычкырып көлеп җибәрә. Тагы сала. Тагы кычкырып көлеп җибәрә. Бер ун тапкыр шулай рәттән кычкырып көлеп җибәргәндер. Нәтиҗәдә бер үзенә ундүрт килодан артык балык тотты бу. Һәркайсы шундый матур, сөйкемле корбаннар. Ашаудан бигрәк, күреп туя торган түгелләр...

Идел белән саубуллашуыбыз шундый күңелле булды ул елны. Барыбыз да канәгать! Балык дәрте басылган. Йөрәкләрдә хәзер икенче төрле дәрт баш күтәрә. Эш дәрте, иҗат дәрте! Рәхмәт сиңа, Идел! Һаман да шулай тулып ак! Балыкларың азаймасын! Балыкчылар күбрәк тоткан саен, хәзинәң арта гына барсын! Якты тормышыбызга хезмәт итүче бик күп кара эшләребезне карусыз башкарып барган хәлеңдә, һаман шулай саф сулы көмеш елга булып балкуда дәвам ит! Ярларыңда үскән мәһабәт калалардан, яхшы-яхшы заводлардан чыккан начар сулар сине пычратмасын! Синең үзеңне дә, безне дә яман күзләрдән саклаучы урманнарыңнан, гөлләреңнән аерылма!..

Җитәр, ахрысы. Җылыйсым килеп киткәндәй булды. Хуш, Иделем! Бөтенләйгә түгел, киләсе җәйгә кадәр...

Менә без хәзер киләсе җәй алдында, барыбыз да исән. Балык дәртебез дә үлмәгән икән. Асфальтны тишеп чыккан үлән шикелле, барлык бүтән эшләр катлавын онытырып, өскә калкырга омтыла. Ләкин узган елгы шаярууларыбызның нәтиҗәсе буел бездән балык тоту әсбапларыбызны һәм аларны куллану чараларын үзгәртеп коруны сорый. Бары да шул Фәнил аркасында булса кирәк.

Балык тоту эше белән тиз генә мавыгып китә алмаган кебек, ул аны тиз генә оныта да алмады. Ул аны газета битләрендә дәвам иттерде. Редакция планы буенча көндәлек эшен үтәп бару өстенә, Идел һәм балык турындагы уйлануларын яза башлады. Аеруча хәтердә калганнары шулар: иң элек «Браконьер № 1» дигән фельетонын бастырды. Ул анда шакшы суларын Иделгә чыгарып, балыкларны агулаучы предприятиеләрнең ваемсыз җитәкчеләрен тәнкыйтьли. Алар һәлак иткән фауна янында иң явыз браконьер тоткан балык та — йөз яшәгән чуртан янында шыртлака чаклы гына булып кала дип исбат итә. Аннары хәзерге Идел шартларында балык үрчетү проблемалары буенча бер ихтиологтан алган интервьюсын урнаштырды. Тагы шунысына күңелем булды: Латыйп карт белән таныштыруым да бушка китмәгән икән. Кайсыдыр газетада: «Өрмәсеннәр миңа!» дигән бик кызыклы фельетоны чыкты. Ә аннары — ялкыны турыдан-туры үзебезгә юнәлтелгән усал хезмәтен: «Һәвәскәрлектән браконьерлыкка бер адым!» дигән фельетонын укыдык.

Тегеләре буенча нинди дә булса конкрет нәтиҗәгә ирешә алгандырмы — белмим. Әмма соңгысы буенча нәтиҗәсе без белми калырлык булмады. Балык каптырганда бөҗра белән эш итүне һәм кеше башына биш килодан артык балык тотуны тыйган махсус карар чыкты.

Биш килосына ризабыз. Бер кешегә бик җиткән. Аны да тота алмаган чаклар күп була. Ә менә бөҗра белән тоту — ул безнең иң яраткан ысулыбыз иде. Фәнилгә ачу килеп китте. Без җәй буе аңа яхшылык эшләргә тырыштык. Ә ул! Бер үзенә ундүрт кило балык тоткан, имеш, соңыннан айлар буена шул турыда уйланып, борчылып, үзен җинаятьче санап йөргән, имеш! Җәенә бер булды бит ул хәл, анысын онытаI Бик ачуым килгән иде. Бу турыда Мәхмүт дустым белән сөйләшкәч кенә тынычландым.

— Молодец, Фәнил! — диде.— Мин ничә ел буе уйланып, ничек әйтергә, кемгә барып әйтергә белми йөргәнне әйткән дә биргән. Әйтүе — бер яхшы. Әйткәнне шулай тиз ишетеп алулары — ике яхшы!

Уйлап, уйлап, уйлап тордым да килештем. Әйе шул. Браконьер кайгырсын! Безгә нигә борчылырга? Шатланырга кирәк. Иң әһәмиятлесе, Идел бар бит, Идел! Үзебезнең Идел! Яшәсен Идел!

Казан
1971

**Рәдиф Гатауллин**

# УТЫЗЫНЧЫ ЯЗ

## Китапка хитап

*Хатип Госманга*

Киштәсендә, хәтерендә илнең
кешелекнең күпме китабы! —
Пергаментлар,
кульязмалар сөйли —
гасырларның безгә хитабы.

Сөйлә, китап!
Болгар чорларыннан,
Тарихыңнан «аять»
сөйлә әйдә:
телгә килсен Йосыф ибне Якуб,
һәйкәл булып бассын Зөләйха.
Фани дөнья сүзен, сөю җырын
борынгылар ничек үз иткән,
«Мәхәббәтнамәләр» дә исән һаман,
алмаз кашлар — шигъри йөзектә.
Сөйлә, китап!
Сәйфи Сараилар,
«Гөлстан»нар ничек калганнар? —
Янган калалардан исән-имин
чордан-чорга күчеп барганнар?
Казан зират караучысы түгел,
бер атаклы улы халыкның,
Мөхәммәдьяр, безнең күңелгә яр,
син гасырлар аша калыктың.
Сөйлә, китап! Нинди хикмәтле җыр —
Мәүлә Колый, Утыз Имәни?
Нинди кыйссаларга
тап булганбыз
Акмуллалар телен өйрәнеп?
Сөйлә, китап, нинди гамьнәр кичеп,
төрле илләр үтеп,
шулай да

бирдең алмаз телебез ачкычларын,
бабамнарның газиз тавышларын
ишеттердең ничек
Тукайга?!
Асыл мираслары заманнарның,
гасырларның оран-хитабы
хәтерләрдә булсын!
Сөйлә әйдә,
син үлемсез халык китабы!
Сөйлә...

## Сүнмәс йолдызларың

(«Сүнгән йолдызлар»ны карагач)

*Ринат Таҗетдиновка*

Гасыр башы караңгысын ертып,
якты булып,
йолдыз булып туган театр —
Тукай теләкләрен истә тотып
бик күпләрне әле уятыр.
Киләчәктә дә
аны алмаз көзге,
заман, рух көзгесе санарлар:
һаман арта
халык күңеленнән
сәяхәткә чыккан «Сәйяр»лар.
Чатырының башы — мең йолдызлы
сәнгать күге белән ябылган;
бүген әнә «Сүнгән йолдызлар»ны
инде сүнмәс өчен кабызган.
Ә йолдызлар... һәр кич алар калка,
гүя Волжская, Камал, Карилар,
Тинчуриннар — биек тәрәзләрдән
үзе корган йортка карыйлар.

Еллар белән яктың арта бара...
Раушан көзгең тарта, театр!
Халык рухын исән саклаганда,
күп гасырлар шулай уятыр
йолдызларың синең, театр! —
Сүнмәс йолдызларың...

## Тукай урамында

Кышкы көндә, февраль буранында,
килдем тагын Тукай урамына.
Ишелеп кар ява юлларыма,
тик аяз көн монда уйларыма:
мәңге кояш — Тукай урамында! —
Шагыйрь урамында.

Ыгы-зыгы трамвай юлларында,
тормыш тавышы — завод җырларында,
басып торам шулар уртасында.
Кушыла уй җилгә, буранына...
Шатлык туа Тукай урамында.

Булдым илнең күп урыннарында,
Кавказ, Себерләрдә, Уралымда.
Күп илләрдә булдым — уйларымда.
Булдым мин бөекләр урамында...
Ләкин һаман кире кайттым монда,
кайттым һаман Тукай урамына.

Юлларымда
яңгыр була, җил-бураннар була,
һаман киләм,
йөрим һаман монда,
җырлар да күп монда, бакый моң да.
Шул урамнан күрим сине,
дөнья!
Булыйм мәңге Тукай урамында,—
халык урамында!

## Гөлләр елый, улым...

Еламагыз җаннарым, дип
юаттым гөлләремне.
Яшердем гөл йөрәгенә
моң тулы күзләремне.

Нәни улым,
күземә карап сөйлә:
— Тимим, димсең — гөлгә?!
Әбиең әйткән:— Чәчәкләрен өзсәң,
гөл ул елый, үлә...

Гөл елыймы, әтием? — дисең.— Чынмы?
Нәрсә әйтим сиңа...
Гөл елый шул, улым, бик нык елый,
өзмә аны, тимә,
Елатма! Гөл елый. Җирдә җанлы-җансыз
бөтен нәрсә елый.
Таш җанлылар гына үлән-чәчәк
тоймый, диеп уйлый.
(Таш үзе дә елый!)

Болытларның салкын яше тама,
таулар иңри, түзми.
Елгаларның күңеле тулып таша,
бөгелеп, таллар үкси.
Кеше елый бик еш! Дөнья булгач
нинди чагың булмый...
Кайгы-шатлык, гарьлек-гамьнән елый...
(Ир — эченнән елый.)

Елый белү, улым, яхшы нәрсә!
Яшь юшкынны юа.
Ярасына, нәфрәтенә дәва
таба шулай дөнья.
Шулай, улым! Яшькә тула калса,
бер көн ике күзең,
ела... Ләкин елак дип атама
бу дөньяның үзен.

Кеше булсаң, яшьләреңне сөртеп,
юатучы була.
Юанырсың... Тик бел бәләкәйдән:
елатучы булма!
Елатучы булма! Бик сак кагыл
үләннәргә, гөлгә.

Гөл елый ул. Җирдә бөтен нәрсә
елый,
көлә белә.
...Хәтта үлә белә!

●

Кай илләргә икән барыр юлы —
кошлар очып үтте күкләрдән.
Мең кошларның саубуллашу моңын
озатучы күңел күтәргән.

Кай илләргә икән барыр юлы
туган илдән киткән кошларның?
Кош юлында күңел каурыйлары
китеп, кайталмаган дусларның.

Кай илләргә илтә икән юллар
туган җирдән, туган оядан?..
Кош оясы кебек тын калсам да,
көзге хисләремнән оялмам.

Кай илләргә илтә икән юллар,
кай диңгезләр күренер күкләрдән?..
Мең кошларның саубуллашу моңын
сагыш итеп җанда күтәрәм.

## Кавказ әсире

Мин Кавказда булдым,
данлы таулар,
һәм халыклар монда — данлылар.
Таудай горур Кешеләр иле монда,
таулар — Кеше кебек җанлылар.

Киек менгән тауның башларына,
биек менгән күккә бөркетләр!

Җәйран кебек җитез, чая кызлар,
һәм бөркеттәй монда егетләр.

Мин Кавказда булдым. Бөтенләйгә
гашыйк итте бугай тау иле.
...Биеклекне тойган күңел, хәзер
тауларга тиң сүзләр тап инде!

Мин Иделгә кайттым... Җиремдә дә
сагынам таулар илен, яшермим:
Үзәннәрдә — таулар җырын җырлыйм,
мин иректә Кавказ әсире!

## Соңламаска иде

Соңламаска, эх, соңламаска иде,
Үзгәртәсе иде бу җанны...
Бер абынмас җирдә ничә кабат
абынды ул ялгыш, буталды:
Имеш, алга барды...

Соң булганчы өлгерәсе иде
иелеп олы җаннар алдына,
чын күңелдән гафу үтенергә
соңламаска иде! —
бәхиллеген алып калырга...

Үзгәртәсе иде, үзгәртәсе...
Тумыштан ук «усал» бу җанны
укытасы иде,
                        онытасы
үкенүгә лаек булганны.
Өлгерәсе иде, соң булганчы,
тәүбә итеп Вөҗдан тавында,
аттай
тышаулыйсы иде горурлыкны,
кәгъбәләргә җәяү барырга,
ялан аяк һәм ялан баш кына...
Атлар идем шушы адымны...
Үткәнгә алып кайтып булса иде
һаман ашыккан шул җанымны,
борып булса иде...

Соңламаска, эх, соңламаска иде...

## Җилгә киткән сүзләр

Апрель җиле гастрольгә китте,
    Әлмәт ягына,
    поезд артыннан...
Артистларның бер бай поклонникыдай
тагылып йөрер бугай,
                        тартынмас,

һаман чәчләреңә кагылыр, үбәр,
җил — гүя әрсез Казан малае.
...Атна була Казанда җил юкка,
әллә нинди әле май ае...
Озатканда шул зур күзләреңдә
сагындырыр утлар күрмәсәм,
сагынырга хакым булмас иде...
Хәзер менә,
(ходай беләǃ)
җилдән көнләшәм.—
Ул бу җырны минем алып китте,
укып йөрер, калмый артыңнан.
Авторы итеп тә әле танытыр үзен,
мактанудан ул да тартынмас.

...Казан җиле гастрольгә китте.

●

Күр, ап-аклар агачларым күптән,
шау чәчәктә бакчам.
Матурлыгын күреп-аңларсызмы,
капкаларын ачсам?
Күр: әкияттән күчкән төсле гөлләр,
чәчәк таҗын ачкан...
Бал кортлары гөжли,
күбәләкләр...
Нурда уйный бакчам.
Күр, чишмәләр күпме —
вак-вак таштан
челтерәп,
көлеп аккан.
Җыр-авазлар белән тулы һәрчак,
шаулап тора бакчам.

Утызынчы язны каршыладык,
(шау чәчәктә бакчамǃ)
Көзгә ерак әле... Җәй, Кояшка
капкаларым ачам...

1971

## Мөхәммәт Мәһдиев

# ФРОНТОВИКЛАР

РОМАН[1]

### VI



Һич тә адәм уйламаганда Акбалыкка өлкән лейтенант погоннары таккан Гата кайтып төште. Гата, гомумән, көтелмәгән хәлләр, сюрпризлар кешесе. Кайтты, мәктәпкә килде, Һиндстандагы брахманнар турында тыныч кына сөйләп яткан Рушадны класс ишеген ачып чакырып алды да бөтен класс күз алдында кочаклады, аркасына «доң-доң» итеп бәргәләде, кулын чигәсенә куеп класска да мөрәҗәгать итте:

— Исәннәрмесез, бөркетләр!

Дәрес шуның белән өзелде, чәлпәрәмә килде. Гата класс ишеген япмаган көе үк көмеш портсигарын чыгарып яхшы папирос алды, хикмәтле зажигалка белән ялт итеп кабызды һәм кесәсеннән дүрткә бөкләнгән кәгазь чыгарды. Шау-гөр итте...

— Менә күр: абыеңны шушы мәктәпкә физик итеп билгеләделәр. Яшибез, картлач! Теге приказга мин дә эләктем. Билгеле, үзем теләмәсәм кайтмый идем. Кайтасы килде. Җитте. Без сынатмадык. Верховныйның үз приказы белән генә дә унике благодарностем бар...

Тавышка унынчы класс ишеге ачылды. Нәркис икән. Рушад бераз гына уңайсызланды. Ләкин Гата югалып калмады.

— У-һу-у! — дип гөрләде ул, папиросын яшереп.— Честь имею! — Гата үкчәсен үкчәгә бәреп смирно басты, кулын чигәсенә күтәрде.— Гутен таг! Бонжур, мадемуазель! Гвардия өлкән лейтенанты Гата Сәләхиев!

Нәркис ә дип тә, җә дип тә әйтә алмады, кызарды да ишекне ябып куйды.

Звонок булуга, Гата директор кабинетына юл тотты...

Гата шәп кайткан...

— Минем,— диде ул Рушадка,— кесәдә кырык сигез мең сум акча бар. Аттестатка җыелган. Болай булгач яшибез. Минем дәресләр алдагы чәршәмбедән. Шуңарчы ял көнгә Казанга элдертәбез. Киенәбез. Шиком. Икебезгә дә костюм, демисезонный пальто. Анда Сорочига кердем мин кайтышлый, җылан мөгезе белән күгәрчен сөте дә табарга

[1] Дәвамы. Башы 1 санда.

була.— Аннары тавышын түбәнәйтеп шыпырт кына өстәп куйды: — Минем кырык сигез мең генә түгел, «Вальтер» да бар. Чемодан төбендә кайтты инде — трофей. Тапшырырга кушканнар иде, малай җаным, ничек итеп үз кулың белән тапшырмак кирәк. Чемодан төбендә ятачак инде ул — мин олы юлга чыгып кеше үтерүче түгел. Истәлек просто. Но — корал саклаган өчен ике ел. Ә, шайтан алсын! Мине кем утырта ала! Берлингача барып житкән гвардия өлкән лейтенанты Гата Сәләхиев мин! Освенцим янында партия билеты алдым. Мин селкетәм дөньяны хәзер. Потомушто мин анын иң кабахәт этләренә каршы көрәшеп утны-суны кичкән! Мать якасына...

...Гата авырлык белән үсте. Утыз алтынчы елда ук шыр ятим калды. Әтисе үпкә авыруыннан, әнисе кеше белмәгән ниндидер эчке авырудан дөнья куйдылар. Идарә Гатаны карарга кеше билгеләде, утыз сигездә беренче тапкыр ФЗОга набор булды — Гатаны шунда җибәреп карадылар,— буй, авырлык житмәде. Комиссиянең бөтен бәйләнгән әйберсе авырлык икәнен белгәч, Гата хәйләгә керешге, икенче тапкыр барганда үзеннән тазарак күрше авыл малаен кертте — теге малай тотылды. Гата өченче тапкыр барды. Комиссиягә керергә чирек сәгать кала колхоз билгеләгән тәрбияче хатыннан алып килгән унсигез пәрәмәчне ашап, ярты чиләк кое суы эчте — авырлыгы нормадан артты. Гата теләгенә иреште. Ләкин Тукай урамындагы сигезенче ФЗОның идәнендә беренче төн кунганда Гата Тәтеш малайлары белән яман сугышып, милиция тикшерүенә эләкте һәм икенче көнне иртән конторадан документларын үз кулы белән урлап авылга качты. Әбисе йортына килмешәк бала булып барып керде, кеше өчен көтү чиратына йөрде. Тамак тук була иде, өс-башка да өлеш чыккалады. Теләп түгел, ачу белән укыды. Педучилищега эләкте. Җәен ялланып Акбалыкка көтүче ярдәмчесе булып килде. Сәнгатькә, бигрәк тә җырга мәхәббәте зур иде, беренче акча кулына килеп керү белән сигез телле тальян сатып алды. Кара мунчаларда төннәр утырып гармунга өйрәнде. Кара мунчада тизрәк өйрәнелә дигәннәр иде. Кемдер, иске чабата яндырып, шуның көлен ашасаң, гармунга тиз өйрәнәсең, дип Гатаны ышандырды — Гата анысын да эшләде... Яшьтән моңлы булды. Тау битендә көтү көткәндә Акбалык халкына Гатаның ягымлы, үзәккә үтәрлек моңлы тавышы ишетелеп тора иде.

Нинди дә булса берәр гаделсезлеккә очрап күңеле рәнҗегән көнне Гата әллә ниткән озын моңлы көйгә җырлап, тыңлаган кешенең бәгырен телгәли иде.

Кыйгак-кыйгак каз кычкыра
бер бәбкәсе юк өчен.
Ятлар безне бик кагалар
үз әнкәбез юк өчен.

Кызганыч, бик кызганыч була иде Гата бу җырны җырлаганда! Акбалыкта ул каһәр-җәбер күрмәде. Ләкин ятимлекне танырлык булды. Кышлык акча, кием-салым туплагач, педучилищеда уку артык авыр булмады, ятим егет дип училищеда да ярдәмнән ташламадылар. Гата шул уңайдан университетка эләкте — аннан яшүсмер көе сугышка китте. Алгы сызыкка барып керүгә Гатаны разведка отрядына билгеләделәр, шунда аның бөтен характеры, табигате ачылды. Штабта аны тиз таныдылар: разведка өчен Гатадай тәвәккәл, йөрәкле кешеләр кирәк иде. Краков операциясе алдыннан Гата дошман ягына кыю рәвештә үтеп керде, армия штабы өчен искиткеч кыйммәтле мәгълүмат — фашистларның штаб офицерын документлары белән алып кайтты. «Вальтер» шуныкы иде. Майор фон Краузе белән Гата, безнең якка чыккач, штабка барганда иркенләп сөйләште. Тегесе бераз русча, Гата бераз немецча бутадылар. Гатаның крестьяннан чыкканын, әти-әнисез үскән

бер авыл малае икәнен белгәч, фон Краузе күзлеген салып Гатага карады.

— Минем әтием,— диде ул,— университет профессоры, философия буенча бүгенге көндә Германиядә зур белгеч — Отто Краузе, Ницшеның тәгълиматын алга таба үстерүче. Үзенең сөекле улы Виллинең — фәннәр магистры Вильгельм Краузеның кем тарафыннан «гефанген» булуын (әсирлеккә төшүен) ишетсә, әлбәттә, атылып үләчәк...

Гата бу батырлыгы өчен Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнде. Кырык бишенче елның җәендә ул Мәскәүдәге Җиңү парадына катнашты. Фашист байракларын түбәнгә мәтәлдереп, Мавзолей янына китереп салучылар арасында Гатаның кыю разведчикларыннан бер солдат бар иде. Гата Мәскәүдә фырт йөрде. Калку түшенә Өченче Дәрәҗә Дан ордены таккан бер украин кызы белән танышты, утны-суны кичкән бу кыз белән Зур театрга барды — «Аккош күле» балетын иң алдагы рәтләрнең берсенә утырып карады. Гата аның кулын үзенең учына алып дөньясын онытып утырды. Сәхнәдә — гүзәллек, янда — гүзәллек, дөньяда — иминлек, күңелдә — көрлек... Шулай да ул вакыт-вакыт үзенең кырыс бала чагын хәтерләп алгалады. Чайковский музыкасы белән Гатаның балалык вакыты арасынданиндидер бәйләнеш бар иде сыман. Ул күңеле белән бала чагына әйләнеп кайтты.

...Авылга Казаннан концерт килгән көн иде. Балалар ул көнне дәресләрен хәзерләмәделәр, төштән соң караңгыга кадәр клуб янында уйнадылар. Малайларның бик күбесе инде билет алырга акча юнәлткәннәр иде. Акчасы булмаган кешеләрне исемлек белән колхоз хисапчысы кертә дә, ахырдан хезмәт көненнән тотып калалар икән дигән хәбәр дә йөри.

Гата кичен аннан-моннан капкалады да клуб янына ашыкты. Ул ничек булса да клубка керә алачагына ышана иде.

Кечкенә, житез малайга зур кешеләр белән әүмәкләнеп кереп китү, чыннан да, авыр булмады. Гата кешеләр тыгызланып утырган бер эскәмиянең астына сузылып кереп ятты. Аны күрүче булмады, тик утырган кешеләрнең аяклары гына каһәрләде. Кемнендер олтанлы итегеннән бик нык ат тизәге исе килә иде, бу олтан аның борын төбенә генә туры килде. Тизрәк утны гына сүндерсеннәр иде дә, башлансын иде. Ниһаять, ут сүнде. «Тавыш!» дип кычкырдылар. Ниндидер бер хатын-кыз: «Акча түләп сине карарга килмәгән ич монда, урыныңа утыр, чукынчык!» дип, кемнедер орышты. Озак та үтмәде, сәхнәдә искиткеч тавыш яңгырады. Гаҗәп матур тавышлы бер хатын-кыз клуб тәрәзәләрен зыңгылдатты:

Егет күңеле җилкенә,
Яхшы ат күргәч!
Бар нужасы онытыла,
Янда сөйгәне йөргәч.
Их, шаян син, кызыкай, кызыкай!
Кемгә насыйп булырсың, кызыкай?
Кемнәр сөяр, кемнәр кочар
Син гүзәлне, сылукай?

Их, җырлаучының үзен дә күрсәң иде. Гата эскәмия астыннан башын чыгармакчы булган иде, шул вакыт ат тизәге исе килгән җылы, парлы итек олтаны, авыр кыймылдап, аның авызын томалады. Шулай да бу хәленнән ул чиксез риза иде. Бераздан сәхнәгә бер ир кеше чыгып, гармунга җырлады.

Каховка, Каховка, иркәм син винтовка,
Кайнар ядрәдәй очып бар.
Иркутск, Варшава, Орел һәм Каховка —
Безнең үтелгән зур юллар.

Шул вакыт берәү рәтләр арасыннан кысыла-кысыла билет тикшерә башлады. Гата идәнгә сенде. Теге, җылы, парлы, олтанлы итек тагын аның борынына терәлде. Тагын берничә табан кысты аны. Кемнәрдер үкчәләре белән аңа төртеп карадылар. Берсе үзенең иләмсез зур табаны белән аны артка таба этте һәм нәкъ шул вакытта аның аякларына билет тикшерүче сөртенде. Кемдер тәмәке исе килеп торган каты кулы белән аның бугазыннан учлап тотты, торгызды һәм кеше башлары, нафталин исе аңкыган шәлләр, кершән-пудралы битләр арасыннан аны кулдан-кулга тапшырдылар. Берәү: «Җулик, билетсыз кергәнсең» дип, муен тамырына сугып калды. Шыңгырдап ишек ачылды һәм ишектән ап-ак булып бөркелеп җылы пар чыкты. Гата баскычка аягын да тидермичә каядыр очты. «Зың» итеп ябылган бозлы ишектән:

Тыныч кешеләр без, ләкин бронепоезд
Тотабыз запас юлларда, —

дигән сүзләр ишетелеп калды. Ул клуб караучының идән югач баскычтан су түгә торган урынына — чәрдәкле бозлар өстенә барып төште. Тез башлары, терсәкләр, аяк кинәт җылынып киттеләр. Байтак вакыт ул тора алмыйча ятты. Башында әллә нинди уйлар кайнады. «Их, кешеләр! Минем җыр тыңлавымнан сезгә ни зыян килер иде соң!»

Озак ятылган, ахрысы. Күзен ачкач, ул иң беренче булып күк йөзендәге Иләк йолдызны таныды. Клуб ишеге ачылган, аннан убырылып пар бөркелә, шау-гөр килеп, кысылышып кешеләр чыга иде. Шул вакыт Гата маңгай өстендә генә тәмәке уты күрде. Аңа берәү үзенең җылы, зур кулын бирде. Күрше Нурәхмәт агай икән.

— Тор, энекәш, тор, әйдә өйгә кайтыйк,— диде ул, Гатаны күтәреп.— Менә ничек өшеп беткәнсең.— Гата шул вакыт аның куәтле беләген тойды. Ир кешенең кулын тоту аңа бик рәхәт булды. Ул инде үзен көчлерәк итеп сизде. Шулай кайтканда тешен кысып күз яшьләре аркылы ант итте. Гомере булса ул беренче мөмкинлек чыгу белән дөньядагы иң зур концерт залының иң беренче рәтендә утырачак. Менә бүген Гата шул теләгенә ирešте.

Украин кызы үзенең туган авылына — Винница өлкәсенә кайтып китте. Анда аны сөйгән егете — фронттан яраланып кайткан Богданы көтә икән. Гата үзен кая куярга белмәде. Шул вакыт аның башында бер хәтәр уй туды: фронтта вакытта ул Волжск шәһәрендәге бер укытучы кыз белән «читтән торып» хат алышкан иде. Болай булгач булды! Үз машинасы белән акча эшләп йөрүче берәүне табу читен булмады. Машина өчен коточкыч күп акча түләп, кочагы-кочагы белән бүләкләр төяп, һич тә көтмәгәндә ул Волжскига кайтып төште. Теге кызның квартир тәрәзәсе каршында тузанга баткан ят машина — Мәскәү машинасы туктады. Кыз үзе мәктәптә икән. Хуҗа хатыны кызны җәһәт кенә чакырып килде. Гади генә киенгән, бизәнмәгән кыз өенә кайтканда ут йотып кайтты. Куркып кына бүлмәсенә керде — тәрәзәләр төбенә хәтле ачылган, ишекле-түрле марш атлап йөргән папирос капкан бер офицерны күрде.

— Честь имею! — Гата үкчәсен үкчәгә бәрде — кызның йөрәге табанына төшкәндәй булды. — Гвардия өлкән лейтенанты, Җиңү парадына катнашучы разведчик Гата Сәләхиев... Рөхсәт итегез сезгә менә бу бүләкләрне тапшырырга һәм шунда ук рәхим итеп өстәл хәзерләсәгез лә. Менә консервалар, менә шешә, колбаса, менә икмәк...

Кыз телсез калды. Хәер, Гата мондый зур тизлек белән теге украинканы да бөтенләй чуалтып бетергән иде шул...

Волжск кызына, уйларга дип, Гата өч сәгать вакыт бирде.

— Клава! — диде Гата, оялчан кызның кулларыннан алып.— Җаныкаем! Минем өч сәгать вакытым бар. Мин җавап көтәм. Минем белән Мәскәүгә китәбезме? Анда мин барысын да хәл итәм. Безнең генерал

әле шунда. Ләкин берсекөнгә без Германиягә очабыз. Без әлегә анда бергә китә алмыйбыз — ләкин мин сине Мәскәүнең иң яхшы отеленә урнаштырып калдырам. Унбиш көн дигәндә Берлиннан сиңа вызов килеп җитәчәк. Безнең анда бергә үткәрәчәк ике көнебез бар...

Кыз каушады, елады.

Ул арада өч сәгать вакыт үтеп тә китте.

Каты күңелле машина хуҗасы булмә ишеген шакыды. Машинасын кабызды. Ә Клава, берни дә әйтә алмыйча, Гатаның күкрәгенә юеш битен терәп елады да елады.

— Мин... мин... моңа әзер түгел. Мин... куркам, — диде. Бу — баш тарту иде.

Гата, авыр хисләр эчендә башы чатнап, Мәскәүгә кайтып җиткәнче шоферга ләм-мим сүз әйтмәде.

Генерал биргән срокка шулай да өлгерде...

Аннан соң күп җилләр исте, Германия туфрагы өстенә тыныч күктән күп яңгырлар яуды. Ләкин тыныч тормышта Гатаның йөрәге үзенә урын тапмады. Аның йөрәгенә давыл, өермә кирәк иде. Шпрее елгасы буенда йөргәндә, ул кырыс таш урамнарга күктән иңеп адашкан бер фәрештә — кече лейтенант формасы кигән Эльзаны очратты.

— Менә мин шушы фәрештәне бәхетле итәргә тиеш, — дип ул үз-үзенә карар кылды. Үз бәхете турында, ничектер, уйламады. Эльза шәһәр комендатурасында тәрҗемәче булып эшли иде. Ленинград кызы икән. Гата аның янына килеп русча эндәште. Аннан «без дә төшеп калганнардан түгел» дигән сыман бер-ике фразаны немецча да сипте. Эльзаның эти-әнисе Ленинград блокадасында һәлак булганнар, кыз ялгыз калган. Әнисе Россия немецларының кызы булган икән.

— Зәңгәр күзле татар буламыни? — дип сорады Эльза гаҗәпләнеп өлкән лейтенанттан.

— Минем күзләрдә сезнең караш чагылганда шулай ул, — дип шаяртты яшь офицер. — Менә үзебезнең якка алып кайтыйм әле мин сине... Безнең урман өстендәге аяз күкне күрсәтим әле мин сиңа...

Гатаның шашкан йөрәге шул Эльзаны эзләп кенә тынгысызланган икән. Шул көннән соң Гата үзенең чын мәгънәсендә гашыйк булганын аңлады. Яшәү аңа чамасыз ләззәтле, шатлыклы булып тоелды. Гыйшык... Нигәдер бу сүздән Гата бераз гына уңайсызланып кала һәм ояла иде. Юк, гыйшык түгел, дөньяда гыйшык юк, ә бары тик Эльза гына бар. Аның сары ефәк чәчле, нәфис ак беләкле, төпсез карашлы, матур акцентлы Эльзасы гына бар. Дөньяда башка берни дә юк... Татлы, газаплы, шатлыклы көннәр башланды.

Менә тормыш тагын да көтелмәгән ягын күрсәтте... Кайту мәсьәләсен Гата тиз хәл итте. Эльза да һич тә икеләнмичә бу план белән килеште. Гата кайта, эшенә урнаша, квартир таба, Эльзага хәбәр бирә. Аннан Эльза юлга чыга...

Ә хәзергә күңелсез. Акбалык урамын кар баскан. Урам уртасынарак чыгарып салынган бер ярым катлы агач кибет. Кибет тирәсендә саламлы чаналарга җигелгән атлар рәшәткә башын кимерәләр. Кая барырга? Рушад эшкә чумган, көн-төн китаплар белән. Алда бер атна вакыт бар. Ә Эльза кайткач нинди күңелле булыр. Аңа Акбалыкның чишмәсен күрсәтергә кирәк булыр. Матур түгәрәк җилкәләренә көянтә сала белерме икән, җанашым? Әле ике айсыз да күрешә алмабыз. Аннан барысы рәтләнер...

Гата урам уртасыннан бара. Әй, сез, Акбалык кешеләре, күрегез! Бу егетне сез танмйсызмы? Ул яшь чагында сезнең авылда көтү көтте. Сез аны кыерсытмадыгызмы? Ана карата гадел булдыгызмы? Бу егет сезне бик яхшы хәтерли. Юк, яхшылыктан башка берни дә күрмәде кебек ул сездә. Бәлки, сез аптырыйсыздыр, ничек бу малай шул дәрәҗәгә иреште икән дип? Ул егетне тарихи вакыйгалар үстерде, аптырамагыз.

Вилли фон Краузе әнә бу егетне аңлый алмады. Ничек инде ул, әтисез-әнисез үскән бер авыл малае — татар малае, үзенең солдатлары белән Краузеның штабына үтеп керде һәм аны кош тоткандай кулга төшерде?

...Кичке якта мәктәптән кайтышлый Рушад кибеткә сугылды. Кибет эченнән баскычка таба чират сузылып чыккан иде. Бөтенесе дә ирләр. Бу ни хикмәт бу? Нинди товар кайткан? Авыл халкы кибет тирәсендә һәрвакытта да укытучыга юл бирә, укытучыны чират торгызмый. Рушад олы гына агайлар үзенә юл биргәненә уңайсызланып эчкә узды. Кибет эчендә җылы, анда шыгрым тулы кызмача ирләр иде. Кибетче кызның шәлләре сыпырылып муенына төшкән — анда эш бик каты икән. Рушад нәрсә икәнен аңламыйча бераз гына читтән карап торды. Монда бөтен эшнең үзәгендә Гата икән. Аракыны мичкәдән зур табакка аударганнар да табакка алюминий чүмеч тыкканнар. Гатаның кулында стакан. Кибетче чүмеч белән чумырып алып, шул стаканга сала да Гатага биреп тора. Ә тегесе чираттагы агайларга. Гата үзе дә кызарган, теле телгә йокмый.

— Хәзер кем чираты? Фәрхетдин, синме? Тот!

— Давай, давай! Гата Сәләхиев дигән разведчикның үз кулыннан эчкәнем бар диярсең...

— Хәзер кем? Ну, Фәрхетдин, сиңа булды, янадан чиратка басма, суырдым-алдым булыр. Ауффидерзеен! Аревуар! Марш!

— Следующий кем? О-һо! Гыйлемҗан! Хәтерлисеңме бер вакыт миңа көтүгә чыктың син? Мин ул көнне старший көтүче идем? Тот! Әйдә, бетканче! Гата абыегыз бөтен Акбалык халкын сыйлый ала! Рәхмәт сезгә, егетләр, абзыйлар! Мине сез үстердегез. Әйдә, сәламәтлеккә... А вотгъ санта![1] Фюр ирен гезундхайт![2]

— Тәкыйулла! Мать честная! Синең белән берне үзем дә күтәрәм. Фронтовиклар өчен! Фр-он-то-вик-лар! Аңладыңмы бу сүзнең мәгънәсен? Син бу авылда иң зур кеше. Потомушто мин сине Берлин урамында очраттым. Анда хәтле бару өчен ниләр кирәк? Моны без үзе-без ге-нә беләбез. Их эрһобе майн глас...[3] Шер ами![4] Мең яшә, дускай!

Гатаны туктату мөмкин булмаячак иде, шуңа күрә Рушад шаярып кына чиратка баскан булды. Гата аны күреп шау-гөр килде.

— Иң якын дустым минем! Кил әле — бер кочаклыйм үзеңне. Ләкин мин сиңа салып бирмим. Син — укытучы. Син бу абзыйларның балаларын укытасың. Синең белән без бүген минем квартирда утырабыз. Анда минем Мәскәүнең үзеннән алып кайткан шешәләсе бар. Ә сиңа мондый җирдә ярамый. Син пакь кеше. Син керләнмә монда. Бүген разведчик Сәләхиев яшьлеген исенә төшерә. Бу — бүген генә...

Ул көнне кичен авыл урамында җырлап йөрүчеләр булды. Планнар төзеп бетергәндә генә Рушад янына Гата килеп керде.

— Киттек безгә минем квартираны карарга, живо! — диде ул. Рушад шаярып алды:

— Иртәгә кибетне ничәдә ачасың?

— Ә нәрсә? — диде Гата. — Иртәгә дә ачтырырга могу. Бу — минем нәзерем, көлмә, дустым. Ә хәзер киен һәм живо!

Гата алты почмаклы бер йортның эчкәреге ягына урнашкан иде. Порт эченнән вак-төяк әйбер чыгарылган, моржа агартылган, идәннәр юылган, мичкә җылы итеп ягылган. Портның түр почмагындагы стенага балалы болан рәсеме чигелгән палас эленгән, шундагы караватөстенә затлы әйберләр ябылган иде.

[1] А вотгъ сантá — сезнең исәнлеккә (*французча*).
[2] Фюр ирен гезундхайт — сезнең сәламәтлек өчен (*немецча*).
[3] Их эрһобе майн глас — мин үземнең бокалымны күтәрәм... (*немецча*).
[4] Шер ами — кадерле дус (*французча*).

— Бу — минем сөекле хатыным Эльзаны көтә, — дип күрсәтте Гата бизәлгән караватны. — Шул күгәрченем кайтканчы Гата абыең идәндә шинель җәеп йоклаячак. Ә хәзер чишен, утыр... Әй, апа! Безгә ике тарелка аш, бер банка консерва, ике стакан бир! — Бу — минем күптәнге дустым һәм дөньяның иң юньле егетләреннән берсе... Яратам фронтовикларны! Егетнең иң шәбе — фронтовик егет. Менә шулай, рәхмәт, апа. Без инде бүген сиңа йокы бирмибез — ишегеңне ныграк ябып чык. Бүген төн безнеке...

## VII

Урман эчендәге кечкенә станциягә Рушад кичке караңгы төшкәч кенә килеп җитте. Авыл, аның иркен басулары, урман тынлыгы артта калды. Авылдан нибары сигез чакрым ераклыктагы бу станциядә бөтенләй икенче тормыш. Монда зур дөньяның тормыш җепләре сузылган. Кар астыннан сузылган рельсларны зәңгәр ут ялый. Ул зәңгәр утлар тәбәнәк тимер баганаларга утыртылганнар. Кызыл ут — юл ябык, яшел ут — ачык. Ә зәңгәр ут нәрсә икән? Бу утлар күңелгә сагыш, шом алып киләләр. Әнә еркатан ук бөтен тимер юлны ут көлтәсе белән сөзеп поезд килә. Пассажир поезды. Син әле монда җиргә аягың белән басып торасың — син шушы як кешесе. Җирдән аягыңны алдыңмы — син инде пассажир. Син кем кадерлесе анда? Синең эчеңдә кайнаган хисләрдә кемнең ни эше бар? Поезд кычкырта-кычкырта Казанга ыргылды. Рушад тамбурда гына басып барды. Менә поезд урманны чыкты. Әгәр көн яктысы булса иде — Рушадның әнисе торган авыл моннан күренер иде. Бичара! Кешедән сатып алган каралты-курасыз йортта ничә елдан бирле инде гомер кичерә. Ялгызлыкта. Һаман дәфтәр тикшерә. Бердәнбер малае белән дә бергә яшәргә насыйп булмады...

Тамбур гөж килә. Вагон ишеге ачык, анда халык тулган. Һәркем үзенекен сөйли. Тәмәке тарталар...

Кулларына сыра шешәләре тотып вагоннан-вагонга таза спортсменнар узып киттеләр. Барысы да көр күңелле, дөнья ваклыкларында эшләре юк. Әйтик, аларга синең Закировыңның дәрестә тәртип бозуы нигә кирәк? Өрлекләре черегән фермаңда аларның ни эше бар? Синең карт, йончыган әнием аларга нигә кирәк?

Рушадларның авылы турысында тычкан утыдай бер ут күренеп калды. Әнисенең тәрәзәсеннән түгелме? Дәфтәр тикшерәме икән?

Поезд үкерә-үкерә чапты.

Яшел утлар рельслар өстенә сузылганнар.

Яшел утлар кызылга әйләнеп калалар. Станция тирәсендә җирдә зәңгәр утлар. Алары нигә? Алары нәрсә? Алары — Рушадның алдагы көне. Билгесез. Хәзергә билгесез...

Үз авыллары турысыннан узгач, Рушад вагонга керде. Шүрлекләрдә тыгызлап өелгән капчык, кәрзиннәр, аяк асларында — капчык, сумкалар. Монда да җанлы әңгәмә бара. Җирән сакаллы удмурт карты трубка пыскыта, шакмаклы калын шәл бәйләгән татар карчыгы аяк арасындагы кәрзиннең тоткасына ябышып утыра, ярым караңгыда берәү китап укып азаплана. Бөтен вагон мыр-мыр сөйләшә. Сугыш турында түгел, үлем турында түгел, ә тормыш, яшәү җае турында. Моны тыңлау үзенә бер төрле рәхәтлек бирә. Халык... Менә аның эчке дөньясы. Менә тыңла, өйрән. Син шушы халыкны яклап яшьли сугышка киттең. Халык ул абстракт төшенчә түгел, ул — менә. Рушад бер кырыйга кысылып утырды, йокымсырады. Мыр-мыр сөйләшәләр. Акрын гына, җайга гына.

Олы гына яшьтәге бер хатын ип белән сөйли:

— Шуннан аргысы соң, ниттем... кайттым да ашарына-эчәренә куйдым, атнага җитәрлек. Киләсе атнага тагын кайтам, боерган булса. Өем якын минем, чуен юл кырыенда гына. Мичен дә ягып томаладым.

— И алла, үзең дә инде шулай мәшәкатьләнергә. Тот та күршеләреңә бир.

— Бирдем, биреп карадым. Тормый, чыга да китә, ди. Чолан баскычына килеп тәүлекләр буе кычкырып, тырмашып йөри, ди, мескен. Алты ел бергә тордык шул, алты ел. Казанга күчкәнче.

— Соң ник аны үзең белән алмадың?

— Тегендә ярамый. Оныкларым кечкенә. Йоны бик коела, әйтеп торам бит — алты ел бергә яшәдек. Киявем бик чисдыклы кеше, сумашетший дум бульнисендә хирур булып эшли. Кызым да бик пөхтәлекне ярата — өйгә мәче кертү кая. Кызымның да эше бик әйбәт — эттилиние мутта эшли...

— Һи-и-и, шул тиклем җирдән атна саен мәче дип кайтып йөрмәсәң. Бәр дә үтер!

— Каргышы зур, ярамый. Борынгылар әйткәннәр, эт белән мәчене зыян китерсә генә үтер, дигәннәр, иеме? Ә моның чирек тиенлек тә зыяны булмады. Алты ел юрганым өстендә йоклады. Иптәш булып.

— Менә мин этнең башын капка баганасына бәрдем дә дөмектердем. Каргыш дип инде. Менә миңа пычак та булмады...

— Туктале, син яшь кеше бит, ашыкма.

— Анысы инде картайгач үлмичә булмас.

Күзен ачып сүзгә Рушад катнашты. Теге кәрзин тотып утырган хатын сөйли икән.

— Син, апа, — диде Рушад, — ул мәчеңне Казанга алып бар да университетка кертеп бир. Анда биологический факультет бар, алар анда этләр, мәчеләр, бакалар җыялар.

Хатын риза булгандай итте. Ләкин бераздан:

— Һе, анда аны харап итәләр, яралар, — дип авыр сулады. — Ярар инде, язга хәтле шулай йөрим дә язын кайтам мин. Тагын бер-ике ай вакыт калды.

Шулар янында ук утырган ике ир кешегә бу тема әллә бар, әллә юк. Колхозның механизациягә бәйле кешеләре булса кирәк, сарыга каккан туннан, тире бияләйләрен вагонда да салмаганнар.

— Телефонограмма алгач карасам — вагон инде бер сутка элек килгән. Простой өчен — сәгате сигез йөз сум. Колхозга күпмегә төшә ул? Җир ашлыйм дип бит инде. Биш тиен куян, ун тиен зыян. МТСка чабарга туры килде. Механикның аягына егылдым. Шулай-шулай, дидем, мине харап итмә. Шуннан бер ярты алып (беренче иҗекләргә басым ясап сөйли башлады), аның белән бергә салып, трактористны көйләп, чак чыгып киттек.

Шәһәргә якынайгач вагонда соранып йөрүчеләр күренә башлады. Сугыш хикмәте. Сугыш кешеләрнең тормышын җимергән, чыгырыннан чыгарган. Әле дә булса рәтенә сала алмыйлар. Берәүләр мохтаҗлыктан, икенче берәүләр ялкаулыктан. Менә чибәр генә тез гәүдәле яшь кеше баян асып килеп керде. Ике күзе дә сукыр. Киемнәре чиста, пөхтә. Янында унике яшьләр чамасындагы курчак кебек бер кызый. Кружка тоткан. Бу кыз укыймы икән? Баянист Рушад янына килеп басты, Рушад аны үз урынына утыртты. Чибәр кеше аккорд бирде. Вагон халкы тынып калды. Чибәр кеше бәбәкләре каралып ябышкан күз төпләрен читкә юнәлтте дә гаҗәеп моңлы, билгесез бер көй уйнады. Ачы тавышлы кызы нииндидер дингезче турында җырлады.

...Кара дингезгә фашист көймәләре килеп кергәннәр. Яшь лейтенант үзенең сөекле хатыны, баласы белән саубуллашып, эсминец бортына күтәрелгән. Эсминец дингезгә юнәлгән. Яшь лейтенантның хатыны причалда елап калган. Эсминецның өстендә, шөпшәләр шикелле, фашист самолетлары уйнаган. Ниһаять, аларның берсе бомбасын нәкъ эсминецның өстенә туры китергән. Экипаж актык сулышына хәтле көрәшкән. Эсминец борынын күтәреп акрын гына аска чума башлаган. Шул вакыт

аңа тагын бер бомба эләккән. Хәзер яшь лейтенант су төбендә ята һәм сөекле кызына, хатынына дәшә. Кызым Ватан өчен җанын бирерлек булып үссен, ди. Синең этиең Ватан каршында бурычын намус белән үтәп, диңгез ләмен кочаклап ята, ди. Нәләт төшсен ул фашистларга, җир йөзендә аларның эзе калмасын. Минем ятим кызымның күз яшьләре фашистларның маңгайларына кайнар ядрә булып бәрелсен...

Паровоз төтеннәренә чумган Казан вокзалы күренде. Перронда кара тун өстеннән яссы каеш буган милиционерлар йөри иде. Тегендә дә, монда да күмер төягән арбаларны этеп йөртәләр, паровоз ачы-ачы кычкырта, кайнар бәрәңге боламыгы сатучылар йөгерешәләр.

Вокзал — шәһәрнең пульсы.

Рушад капчык аскан кешеләр ташкынына иярде дә тимер капкага таба китте. Капканың бу ягында поездга утырырга дип җыелган халык чиратка баскан һәм ике-өч милиционер, сыбызгыларын сызгырта-сызгырта, аларның сафларын рәтлиләр иде.

— Осаживай назад!

— Назад! — дигән кычкырулар, маневр паровозларының ачы сызгыртуына кушылып, вокзаллар өчен генә хас булган тавышлар гаммасын тәшкил итәләр иде...

## VIII

Сорочи базары элеккедән дә калын. Монда кешелек тарихы туктаган. Монда базарның үз тарихы гына бар. Монда танылган сәгатьчеләр, танылган гармунчылар, драп, бостон, габардин белгечләре, велосипед, фотоаппарат осталары бар. Алардан узып берни сата да, ала да алмыйсың. Монда дөнья гөж килә. Әйтерсең лә сугыш бөтенләй булмаган, әйтерсең лә бу базарда бер сумга бер папирос алган Рушад аннан соң инде Көнчыгыш Пруссия крепостьларында фашистларны кыйнамаган... Базар өчен боларның берсе дә юк.

Хром пальтодан гына җил-җил атлап Гата килеп чыкты. Рушад бераз алданрак килгән иде.

— Хәрби формадан барахолкада йөрергә ярамаганлыкны беләсеңдер, шәт? — диде ул Рушадка кулын биреп. — Безнең бүгенге план: икебезгә дә — демисезонный пальто, сиңа — костюм. Миңа бүтән бер әйбер дә кирәкми. Шушы көннәрдә минем контейнер белән багаж килергә тиеш.

Рушад уңайсызланды, дәшмәде. Ләкин Гата — сизгер егет.

— Беләм, беләм, акча ягын әйтәсең, — диде. — Мин бит сиңа әҗәткә бирәм, аңладыңмы? Ярдәм түгел — ә-җәт-кә! Кайчан байыйсың — шунда түлисең. Илленче елдамы? Риза. Алтмыштамы? Бик шәп.

Гата кокардалы фуражкасын арткарак шудырды, папиросын кабызды. Берәр эшне тәвәккәлләр алдыннан ул һәрвакыт шулай итә иде.

Аларның базарда яңа кошлар икәнен белеп яннарына елтыр күзле спекулянтлар җыела башлады. Берсе үтереп-үтереп зажигалка ташы алырга кыстады. Көйли-көйли яннарында бөтерелде.

Московские камешки
для зажигалочки...

Биек коймa белән әйләндерелгән бер почмакта отрез саталар иде. Кешенең эченә чорнаган материал, куенына салган материал, муенына шарф итеп чорнаган драп... Гата мәсьәләне кызу хәл итәргә уйлады. Базар обстановкасын ул тиз чамалап алды — ничә әйтсәң дә, разведчик — монда ялт та йолт китерсәң генә уңасың. Өч-дүрт минуттан ул инде спекулянтларның үз телендә сөйләшә башлады. Каракүл бүрек, каракүл якалы зәңгәр драп пальто, кызыл күн белән эшләнгән ак фетр итек кигән көмеш тешле кара егет, боларга нәрсә кирәген белгәч, бер читкә алып китте. Егетләр үз гомерләрендә беренче мәртәбә «чумара» сүзен шушы көмеш тешледән ишеттеләр. Бу бераз гаҗәбрәк иде. Су-

гышка кадәр авылларда чумарлы аш пешерү гадәте бар иде. Ипи салганда әче камырны алып калалар да шуны вак кына чикләвек кебек турап борчаклы ашка салалар. Шул була иде бик тәмле, әчкелтем борчак чумары. Ләкин көмеш тешле егет бу сүзгә бөтенләй икенче мәгънә биреп сөйли. Үзе Яңа бистәдән икән. Рушад теге вакытны хәтерләп елмаеп куйды: озак сатулашсаң, алла сакласын, бу егет тә нияк астыңа баш белән бирәм дип куркытыр... Ул арада нәкъ шундый киенгән икенче бер олы татар ике пальтоны күтәреп килеп тә житте. Шуннан китте чит телдә сатулашу. Ну, бу Гатаны! Барысын да аңлый бит!

— Багана ярымга бирәм, — диде көмеш тешле. — Мөгәрич сездән, пальто башына берәр «данар» өстәмичә булдыра алмассыз.

— Бәясе кыйммәтрәк, — диде Гата, пальтоларны әйләндергәләп, — ну, анысын сатулашырбыз. Әмма мөгәричен дә инде чамасыз сорыйсың. Ике пальтога бер «почмак» житмәгәнмени?

Бәхәскә олы татар да кушылды.

— Ну, шту сез, егетләр! Шушындый малны кулга төшергәч, мөгәричтән бер «пәнҗеки» жәлләп торырга! Нүжәли инде без ахырдан әнә тегендә фәртмагка кереп тахил шәрабыннан авыз итмибез? Ә аның йөз граммына, беләсезме, күпме «корт» кирәк? Йөз граммы — бер почмак та бер сикәш! Белдегезме?

Олы татар рәхәтләнеп көлде, дусларча Рушадның аркасыннан какты.

— Шулай бит, энекәш?

— Шулаен шулай, — диде Рушад, — тик мин әле берни дә аңламыйм. Фәртмаг дигәне нәрсә соң аның? Продмагны беләм, раймагны беләм, культмагны беләм, дигәндәй...

Олы татар тагын рәхәтләнеп көлде. Көлә-көлә горгылдап йөткерә башлады.

— Ай, энекәшләр, үтерәсез мине. Соң бит инде кандала исе килгәнне бу тирәдә бары тик минә шушында — Фәрт абыенда гына табып була. Ай, билләһи, яшьлек... Син дөньяда «дүкәшлек» эч, но инде ашаганда — бер «челне» кызганма. Шунда гына кеше булырсың... Я, ярый, кул сугабызмы?

— Хәзер акчаның бер кадере дә юк, — диде олы татар. — Минә сугышка хәтлем бер «йәк» белән туйганчы ашап чыгып була иде. Хәзер аңа ике фифруз бирәләр. Уйлап кара, зажигалка ташы — борчак кадәр бер таш — берсе бер «чарки». Мәскәүнеке булса — «шаш». Я, кая китә ул? Ул инде, кәнишне, биргән кешегә күп күбен. — Шулай ди-ди ул Гата кулыннан ике пачка акча алды.

Егетләр мөгәричкә барудан баш тарттылар.

Көмеш тешле егет, яшь кенә булса да, төче телле икән.

— Алла боерган булса, игелеген күреп кияргә насыйп булсын. Безгә дә игелекле акча булсын, — дип калды.

Ленин бакчасы янында Рушад белән Гата аерылыштылар. Базар дөньясыннан, аның томаныннан арынырга, матди дөньяга кайтырга иде. Сугыш белән өзелеп калган укуларны нишләтергә? Хәзергә бер генә юл күренә: читтән торып укырга. Хәер, Гата моны армиядән кайтышлый ук хәл иткән икән. Ул инде педагогия институтының дүртенче курсына документларын биреп кайткан, университет белән саубуллашкан. Анда Гата фәне буенча читтән торып уку бүлеге юк икән. Ә менә Рушадның әле университет архивында казынасы бар...

— Читтән торып уку — чын белем алу түгел, — диде Гата, базардан шәһәр үзәгенә барышлый. Киләчәктә бу тәртип бетерелер дип уйлыйм. Син уйлама, җәйге сессия вакытында сиңа бер генә профессор да лекция укып башын ватмаячак. Заочник — үги бала. Синең белән эш итәчәк кешеләр — җыен вак-төяк: аспирантлар, ассистент кисәкләре, читтән ялланган акча эшләүчеләр... Аларга Акбалык мәктәбенең тарих укытучысы Рушад Сулимов әйбәт укыды ни, төшеп калды ни. Мин

шулай да галимнәрнең чынысын күреп өч ел менә дигән лекцияләр тыңладым. Доцент Тумановның лекциясе үзе генә дә ни тора! Аскет бит, чын аскет. Керә дә тактага формуласын язып сөйли-сөйли дә бервакыт исенә төшеп сорап куя: «Бу кайсы курс? Кайсы группа? Ә мин сезгә дөрес кердемме?» — ди. Көлешәбез. Фәнен яратабыз. Ә үзе — чудак. Дүшәмбе көн иртән керә дә: «Егетләр, минем нигәдер баш авыртып тора, ихтимал, лекциянең рәте булмас», — ди. Һәм булмый да. Азаплана, тирли. Бу хәл берничә дүшәмбе шулай кабатланганнан соң, безнең староста, — мәрхүм, шәп егет иде, Праганы азат иткәндә һәлак булган, — бер дүшәмбедә иртән Туманов лекциясе алдыннан тактага язган да куйган: «Доцент Туманов, әгәр дә сезнең башыгыз дүшәмбедә авырта икән, аракыны шимбәдә эчәргә киңәш бирәбез». Күрде, укыды. Берсүзсез сөртте. Карлыккан тавыш белән азапланып лекция укыды. Бичара... Хәзер ике аяксыз, укытып йөри. Өрлек кадәр гәүдә. Артиллерист булган. Өч ат өстери торган расчетларны бер үзе сөйрәп йөрткән. Күкрәге тулы орден. Радиодан әллә ничә мәртәбә инде аның турында тапшыру булды. Менә мин кемнәрне калдырып китәм... Бездән кем чыксын...

Рушад каршы төште:

— Минемчә, хикмәт кешенең үзендә. Әгәр син үзең намуссыз студент икәнсең, сине шунда ник әллә кемнәр укытмый. Ә шулай да стационарда уку күнеллерәктер инде. Ярый, иптәш өлкән лейтенант, тарих безне гафу итәр: без сирәк очрый торган вакыйгаларның шаһите булдык. Без, гомумән, авыр юлга чыктык. Ләкин кемгәдер җиңел булсын өчен, дөресрәге — киләчәк буын өчен...

— О-һо, син нәкъ Хушият карт төсле сөйлисең. Дөрес итеп. Берәү дә бәйләнерлек түгел. Ә беләсеңме, ул картыгыз сезнең нинди кош? Бер көнне вокзалда минем артта гына аркасын куеп поезд көтеп утырды, гражданскийдан булгач, күрәсең, мине танымады. Үзенең бер замандашын очраткан да мер-мер сөйли. Теләсәм-теләмәсәм тыңлаучы булдым...

— Нәрсә, тарих укытучысының алтынчы класста дәрес уздыруы турындамы әллә?

— Юк, бөтенләй башка. Син мәсьәләне ваклатма. Алтынчы класста тәртип урнаштырып син үзеңне әллә шәһәр алган полководец кебек сизә башладыңмы? Мин аларга күрсәтермен әле. Мин аларны. Мәсьәлә монда бөтенләй башка. Беләсеңме, ничек сайрый? Казанда унынчы елларда фәлән-фәлән хәзрәтләр бар иде, фәлән мәчет фәлән хәзрәт кулында иде, ди. Диннең фәлсәфәсенә кереп китте, дин дөньясында зур-зур галимнәр бар дип санап чыкты. Ислам диненең, ди, файдалы яклары бик күп. Безнең яшьтәгеләрне, ди, дин кануннары бик күп файдалы эшләргә өйрәтеп калдырды, ди. Менә ничек сайрый!

— Нигә, ул әле узган атнада гына дингә каршы лекция сөйләде, — диде Рушад көлемсерәп. — Анда да начар сөйләмәде. Авызыннан төкрек чәчә-чәчә, динне сүкте.

Гата сүгенеп алды.

— Минем, — диде ул, — шундый әзлексез, ышанычсыз кешеләрне күрсәм, ләхетем кыса башлый. Сандомир янында безнең бер яшь лейтенант белән кызык хәл булды: һәр пятиминуткада бу чыгыш ясый, һәрвакыт авызында кызыл сүз. Без тегеләй итәрбез дә болай итәрбез, Ватан өчен җаныбызны бирербез, дип сүз тегермәне корып йөрәккә төште. Кыскасы, бөтен җирдә җанын бирергә әзер тора бу. Беләсезме, ничек булды? Лейтенант бит ямь-яшел көе, әле сугышның нәрсә икәнен белми, училищедан гына ашыгыч хәзерләнеп чыгарылган. Бер көнне без аның белән бергә каты гына переплетка эләктек. Танклар килә, колонна булып килә, немецларның артиллериясе безнең тылны дөмбәсли, самолетлары күтәрелеп безнең өстә шөпшәдәй йөри — җир селкенә. Ә безгә подкрепление килеп житә алмый — кыскасы, беттек. Шул вакытта теге лейтенант нишли диген? Траншеяның стенасына сөялеп утырган,

күзен чытырдатып йомган һәм чукына! Япь-яшь егет, ә ничек дөрес итеп чукына. Үзе пышылдый, нәрсәдер укый. Бичара, шул куркаклыгы аркасында харап булды. Анысы соңрак, һөҗүм вакытында. Менә шулай. Кеше бик каты үтә киселеп кызыл булып сөйләштеме — көт тә тор, монда бер шик була...

Ленин бакчасы янында Гата трамвайга утырырга булды.

— Мин педка киттем. Кичен кунарга безгә килсәң — гәпләшербез. Минем элеккеге дусны беләсең — Киров бакчасы янында яши. Хәер, син егет кеше, синең әллә нинди сукмаклар бардыр әле. Димәк, бүген күрешмәсәк — иртәгә ундагы поездга. Ауффидерзеен! — Ул егетләрчә генә честь биреп кырт борылды да трамвай баскычына сикерде.

Рушад университет каршысына Ленин бакчасы аркылы чыгарга булды. Такта баскычлардан күтәрелде. Менә шушы карт топольләр арасыннан барганда бер вакыт каршыда колонналар күренә башлый. Шулар күренгәч, һәрвакытта да икенче дөньяга килеп кергәндәй буласың. Колонналар артында фән, галимнәр, проблемалар. Монда бөтен кешелек дөньясы өчен әһәмияте булган мәсьәләләр генә хәл ителә. Бу — югары фикерләр, бөек идеаллар йорты. Монда күңелең саф булса гына аягыңны атла. Бу йорт — тарих. Лобачевский, Толстой, Ульянов... Акбалык малайларын якалап сугышып йөргән егет, син соң шулар йөргән сукмакка аяк басарга лаеклымы? Алар кем дә, син кем? Алар — бөек математик, акыл иясе. Россиянең мактанычы Николай Лобачевский. Гигант Лев Толстой. Япь-яшь көе самодержавиегә каршы ташланган Володя Ульянов... Ә син кем?

— Рушад!

Чылтырап ишетелгән мөлаем тавышка Рушад сискәнеп китте. Бакча эчендәге тар сукмактан аңа таба кисеп Нәркис чыгып килә иде. Килә, үзе елмая! Рушадның йөрәге урыныннан кузгалып куйды. Шушы Нәркискә гашыйк булмыйча түзәргә иде! Түзәргә иде... Ут белән уйнау бит ул. Гашыйк булырсың, ул сине санга сукмас, белемең буенча барыбер аның артыннан житә алмассың...

Рушад юри генә җыерылган булды. Шулай да очраклы рәвештә килеп чыккан бу очрашуга ул бик шатланды. Күрешкән вакытта хәтта Нәркиснең ике бәләгеннән тотып та алды.

Нәркис шәһәрдә бөтенләй икенче төрле киенә икән. Өстендә кыйммәтле тун. Аягында яхшы, эче җылытылган ботинкалар. Бизәнүе дә авылдагыга караганда артыграк. Керфекләрен буйый төшкән. Иреннәр дә ничектер буяулырак, нәфисрәк.

...Башта сүз ябышмады. Нәркис күргәзмә әсбаплар эзләп йөри икән. Магазиннарда әдәбият һәм тел белеменә кагылышлы берни дә юк, ди. Сугышка кадәрме, кайчандыр чыгарылган Дарвин белән Миклухо-Маклай рәсемennән башка мәктәп өчен берни дә юк икән. Менә шулардан башка укытып кара син...

Рушад үзенең документларын читтән торып уку бүлегенә күчерүләрен сорап гариза калдырды. Аның шинеле монда күп ярдәм итте. Сугыштан кайтучыларга университетта игътибар зур икән.

Нәркис аны вестибюльдә көтеп тора иде.

— Әйдәгез, бераз гына бакчада сөйләшеп йөрик,— диде ул Рушадка. Рушад кулындагы зур төргәкне күрсәтте.

— Комачауламыйммы?

Ленин бакчасында сукмакларга ком сибелгән, бер-ике урында балалар төркеме йөри, тәрбиячеләре янында кечкенә көрәкләр белән кар өеп уйныйлар. Рушадның беркайчан да шәһәр бакчасында мондый итеп йөргәне юк иде. Ул кыюланып кызның үзе турында нәрсә уйлаганын белергә омтылыш та ясап карады.

— Менә бит ничек әйбәт булды, ә? Сезнең белән йөрсәм, юл уңасы икән. Ун минутта эшне хәл итеп чыктым...

— Әгәр минем нинди изге җан икәнемне белсәләр, кешеләр гел минем тирәдә генә чуалырлар иде. Ләкин кайбер кешеләр аны аңлау дәрәҗәсендә үк түгелләр шул,— дип, Нәркис хәйләкәр елмайды.

Рушад үз бакчасына ыргыткан ташны алды.

— Әгәр минем характерым Гатаныкы кебек булса иде, беләсезме, мин нишләр идем?

— Мин әле ул калай этәчегез белән танышу бәхетенә ирешмәдем шул...

— Юк, алай начар әйтмәгез. Гата — мировой егет. Үзегез дә ышанырсыз.

— Егет?!

— Ә, гафу итегез. Гата өйләнеп кайткан. Хатыны рус, немец гибриды. Фәрештә ди. Гата шуның кайтканын көтеп саргая...

Сүзнең җеп очын Нәркис эзләп тапты.

— Шулай да, характерыгыз аныкы кебек булса нишләр идегез? Сез дә гибридка өйләнгән булыр идегезме?

— Юк, мин, тәвәккәлләп, Акбалык урта мәктәбенең рус теле укытучысы артыннан ухаживать итә башлар идем.

Нәркиснең алсу яңакларына кызыллык йөгерде. Рушад шатланып куйды: әһә, мин дә кызлар белән сөйләшә беләм икән! Кызның да әле ниндие! Якын килергә куркырсың — Кенигсберг крепосте! Нәркис үзен тиз кулга алды.

— Бераз гына соңгарак калгансыз шикелле,— диде ул көрсенеп.

Рушад та үзенең маркасын төшермәскә тырышты. Тиз генә чигенергә кирәк. Ләкин чигенү зур осталык сорый. Кайвакытта ул һөҗүмнән дә катлаулырак. Катлаулырак... Чигенеп, һөҗүм белән ала алмаган шәһәрләрне алып була. Ә бу очракта? Соболев ничек ди? Бер матрос — матрос. Ике... Ах, син үзең генә бит, Рушад, маташма, булдыра алмассың. Бу кызый бик үткен һәм шуның өстенә кешенең бөтен уйларын укый ала торган күренә.

Рушад затлы тун кигән бу кызыйны култыкламакчы ук булган иде. Ләкин өстә — кара шинель. Флоттан кайтканыңны белмәсләр, бу нинди проводник диярләр. Кызның танышлары очравы мөмкин. Нигә аны читен хәлгә калдырырга? Ләкин кыз үзе үк «соңга калу» турында әйтте. Алай булгач, нигә монда йөри? Үзе әйтте бит, әйдә бакчада йөрик дип.

Бакча уртасыннан шулай көйгә генә сөйләшеп баралар иде. Барысы да ярый, барысы да көйле иде... Кешегә күпме кирәк? Бәхет нәрсә? Үтәлүе мөмкин булган теләкләрнең үтәлүе. Менә Рушадның сугыштан исән-сау кайтырга теләге бар иде. Җиңү көнен күрәсе килгән иде. Тыныч күккә карап Казан урамнарыннан йөрисе килгән иде. Демобилизацияләнеп кайткач, авылда аякларын җылы моржага терәп ятканда эшлисе, энергиясен сарыф итәсе килгән иде. Шуларның барысына да ирешелде. Аннары? Аннары мәктәптә менә шушы кыз очрады. Ул Рушадтан бер-ике яшькә олыдыр. Бу кыз нигәдер Рушадның һәр адымында очрый, аңа комачау итәме-юкмы, ләкин борчый. Нигә алай? Рушад үз-үзеннән бер фикерне яшереп йөри: Нәркис янында аңа рәхәт, бик рәхәт була. Борчулы, мәшәкатьле рәхәт. Аның янында йөрү, бәлки бәхеттер? Әнә Нәркис үзе дә бәхет турында сөйләп бара. Бәхет, ди, бик чагыштырма төшенчә. Кем үзенә нинди максат куя, кем шуңа ничек ирешә. Бәхетсез генерал, бәхетсез академик булырга мөмкин. Әнә бакча алдындагы фанер ояда ботинка төзәтеп утыручы кеше бәхетле булырга мөмкин...

Тар сукмактан юлга чыгып баскан берәү боларга нәрсәдер дәшеп туктатты. Ширпы сорый икән. Нәркис алга таба атлый торды. Рушад төргәген кар өстенә куеп ширпы кабызды. Теге кеше нәрсәдер мыгырданып Рушадның кулын үзенең дәү учына алды, яңагын эчкә суыра-

суыра, тәмәке кабызды. Рушадның кинәт кенә йөрәге «жу» итеп китте. Яныл торган шырпы аның бармагын пешерде. Тәмәкегә ут сораган кеше — Рушадның энисе күчеп килгән Кече авыл егете Мөбарәк иде. Ул Рушадтан ике-өч яшькә зуррак иде, ләкин сугышка чыгып киткәнче малайлыгын ташламады, Рушад янына йөрде. Һәрвакыт ярдәмчел булды, бер телем ипие булса, шуны Рушад белән бүлмичә ашамады. Усаллыгы зур иде, авылда аны «Мөби» дип кенә йөртәләр иде. Мөби гомер буе «мөгез чыгарып» яшәде, тик кенә торганда бөтен кеше күз алдында кипкән сыер тизәге ашап күрсәтү кирәкме, стаканы белән керосин эчүме, лезвиене авызга кабып шытырдатып чәйнәүме — барысын да эшли ала иде. Бервакыт Мөби ындыр табагыннан амбарга ашлык ташыды. Рушадлар ипи карточкасына һәм биш сутый бакчага гына карап калган ел иде — Мөби эштән кайтышлый һәрвакыт аларның җил капкасы янына басып сызгыра иде. Кесәсендә һәр ходай бирмеш көнне — өч-дүрт кушуч борчак булыр... Мөби хыялланырга ярата иде. Бер вакыт ул үзенә канатлар ясап азапланды. Һәм үзләренең өй түбәсенең кыегыннан җиргә сикереп карады. Ике-өч атна урында ятты, аннары таякка таянып йөрде. Сугыштан ике аяксыз кайткан Мөбине шәһәрдә йортка кергән дип сөйләгәннәр иде. Имеш, подвалда торалар икән. Яшь тол хатын, үзем карыйм, минем эшләгән акчам, синең пенсияң яшәргә җитәр дигән. Мөбинең әнисе ул сугышта вакытта үлгән, хуҗалык таркалган иде — шуңа күрә ул бу тәкъдимгә риза булып шәһәрдә калган. Ләкин соңгы вакытта авыл халкы Мөби турында төрле хәбәр алып кайтты. Имеш, яшь хатын чая булып чыккан, кичләрен каядыр югалгалый икән. Ә бер көнне хатын өендә кунмаган... Семьяда тавыш чыккан. Чая хатын дулаган.

— Син аксак тәре белән яшь гомерем әрәм уза, син булмасаң, мине әллә кемнәр биш куллап алырга әзер торалар,— дигән. Мөби андый мәсьәләләрдә яшьтән үк саф күнелле иде — бу хәлдән югалып калган, хатынына ялынган, елаган. Ләкин файдасы тимәгән. Шуннан ул аракы белән дуслашкан. Инде очраган таныш-белештән берәр тәңкә сорарга да кыенсынмый икән.

Менә ул тәмәкесен кабызды. Күтәрелеп карамады. Кырынмаган яңаклар. Юылмаган күзләр, каралган куллар. Саргайган тырнаклар... Мөби! Дус кеше, синме бу? Син бик шәп егет идең бит! Мөбидән бик каты аңкып аракы исе килә... Култык таякларын җайлап кыстырды да эре-эре атлап бакча юлыннан китте. Дәшәргәме? Бер читтә Нәркис карап көтеп тора. Әле генә бик тәмле, тыныч әңгәмә иде. Әле генә янда күңелне кытыкларлык помада исе бөркеп торган принцесса бәхет турында сөйли иде. Әле генә бик рәхәт иде. Нигә бу дөньяда һәрвакыт шулай — ак янында кара, ут янында су... Әллә Рушад өчен генә шулаймы бу дөнья? Мөби инде ераклашты. Гафу ит, Мөбарәк! Мин сине барыбер эзләп табармын. Барыбер табармын, тик бүгенгесе өчен гафу ит! Минем янымдагы кошчык беркайчан да синең фаҗигаңне аңлый алмас. Шуңа күрә безнең мөнәсәбәтләргә аны катыштырмыйк. Безнең яшьлек үзебезгә генә калсын. Тик, зинһар, үпкәләмә...

Шуннан соң инде Нәркис белән сүз ябышмады.

Моны сизгер күңелле кыз тиз аңлады, трамвай юлына чыккач, үзенең затлы перчаткасын салып Рушадка кулын бирде. Матур, сагышлы итеп карады.

— Мин сезне үзебезгә чакыра алмыйм, сәбәпләрен хәзергә әйтергә ярамый,— диде. Чайкала-чайкала шалтырап килгән трамвайга җиңел генә кереп китте.

Рушад бакча кырыендагы тимер рәшәткәгә сөялеп озак итеп тәмәке тартты. Озын култык таякларына ябык гәүдәсен элгән яшьлек дусты саргылт йөзле Мөби аның күз алдыннан китмәде.

Рушад бакчадан чыгып трамвайга утырды. Вагон шактый иркен иде. Ул бер читтә әйберләрен кочаклап утырды. Күзләрен йомды. Бер көнгә нихәтле тәэсир... Иртән базардан башланды. Һәркөн шулай булса... «Тыныч тормыш» дип сөйлиләр иде фронтта вакытта. Кая ул тынычлык. Йөрәкнең һич тә әле тынычлап типкәне юк. «Тынычлык» сүзе, «тыныч тормыш» сүзенең мәгънәсе бөтенләй башкача икән. Ул — синең баш очыңда дошман самолеты очмый, сиңа бу минутта үлем куркынычы юк, сиңа эшләргә, хезмәт итәргә мөмкин дигән сүз икән. Ә инде йөрәк беркайчан да тигез типмәс. Нәркисне күр — йөрәгең кузгалсын. Уку мәсьәләсен хәл итеп йөр — дулкынлан. Яшьлек дустыңны очрат — шуңа эндәшә алма — дошман тылындамыни? Йөрәгең тагын дөп-дөп килсен... Юк, тыныч тормыш, күрәсең, картайгач кына булыр. Менә, мәсәлән, таякларын кочаклап ике карт утырган. Кырпу бүрек, озынча җыйнак пальто кигәннәр. Кәҗә сакалларын селкетмичә генә әдәп белән генә гәп сугалар. Аларга Нәркис тә, Мөбинең язмышы да кирәк түгел. Алар әйтерсең гомер буе ашыгып чапкан хутка туктап калганнар да дөньяның барлык борчуына, мәшәкатенә кул селеккәннәр...

— Муса пәйгамбәрнең бер сәхабәсенең баласы булмый икән, чистый интеккән бу. Шуннан соң Муса галәйһиссәлам әйткән моңа: синең, дигән, бер ир балаң булыр...

— Һи-и-и, кара син аны, ә? Алдан әйткән диген...

— Ие, алдан әйткән. Шуннан, ходаның хикмәте, атна-ун көн үтми, тегенең хатыны бер ир бала таба...

— Һи-и-и, кара син аны, ә? Атна-ун көндә диген, ә? Шуны алдан белгән диген, ә?

Суконныйда Рушад төшеп калды.

Кондуктор сүс бауны дырт итеп тартты, вагон түшәмендә кыңгырау чыңлады, шундый ук тавыш алдагы вагонда да ишетелде. Кызыл буяулары купкан, таушалган трамвай үзенең бар эчке дөньясы, төрле язмышлары белән селкенә-селкенә алга таба чапты...

Сугышта бергә булган дустының җылы өендә кайнар бәрәңге белән кыздырылган колбаса ашап, чәй эчеп, серләшеп ярты төн җитте. Йомшак урынга тиешүгә күзләр йомылды. Нервларга ял кирәк иде. Ярый ла теге сәхабәнең тормыш юлын алдан әйтеп баручысы булган... Ир бала табар, имеш... Менә Рушадның андый әйтеп торучысы юк шул. Алда нәрсә көткәнен ул белә алмый. Юк, ялгыз йөрергә ярамый аңа моннан соң. Гата белән булганда яшәве җиңелрәк. Гата булса бүген Нәркисне дә үпкәләтми, Мөби белән дә сөйләшә иде...

Иртәгесен вокзалда Гата белән тиз табыштылар. Хәер, Гатаны эзләп торасы юк, аның әйләнә-тирәсендә, гадәттә, һәрвакыт ыгы-зыгы, шау-шу була. Бүген дә шулай иде. Аны ниндидер бер компания озата килгән,— егетләр, ирләр, хатын-кыз... Гата гөрли.

— Бер елдан диплом алам. Заочныйга күчтем. А как же? Университетта укыган башым белән педның заочный бүлегенә барып кердем бит... Мин әйтәм зам деканга, сез инде горурланыгыз моның белән, дим. Мин хәзер — урта мәктәптә ведущий физик. А как же? Шаярмагыз сез минем белән...

Гатаның бик кызык гадәте бар. Сөйләгән вакытта ул бераз гына үзенә каршы килгәнне ярата. Шулай булганда ул кызып китә, аннан матур, үткен фикерләр чыга. Инде андый кеше очрамаса — барыбер кемгәдер каршы килгәндәй, нәрсәнедер раслагандай, тыңлаучыны бераз гына сүгеп сөйли. Бүген дә шулай иде.

— Менә Рушадтан сорагыз,— диде ул озатучыларга, Рушадны тәкъдим итеп.— Бер үземә бер өй. Чиста, җылы. Киленне генә көтәбез. Ә сез нәрсә уйлаган идегез? А как же? Тотам да авылда музыка мәктәбе ачтырам. Укытсын, бер тиенсезгә эшләсен, но чтобы бөтен Акбалык баласына музыка грамотасы бирсен. Менә күрерсез әле киленегезне —

ах итәрсез. Класс! Ә нәрсә? Шулай булмаганда мин аны үземә гомерлеккә сайлыйммыни? Шаярмагыз сез алай...

Поезд кычкыртып әңгәмәне өзде. Озатучылар — Гатаның туган-тумачасы икән. Алар яз чыгуга, килен кайтса, авылга туйга кайтабыз дип гөрләшеп калдылар.

Поезд Вахитовка таба кузгалды.

— Да, бу станциядә безнең полкка тагын берәү өстәлергә тиеш бит әле,— диде Рушад.

— Ә, теге асылкошны әйтәсеңме? Әй, нәрсәсендер аңлап бетермим шуның. Нәрсәсе беләндер жир кешесеннән аерыла ул. Әллә инде без үзебез артык мужик...

— Дөрес әйтәсең, күңеле бик саф булырга охшый аның. Без нәрсә? Без тәрбияче түгел инде. Шул, фронтовик булуыбыз гына бар. Килер бер вакыт, синең белән безгә мәктәптә педагог булып эшләү түгел, көтү чиратына да чыгарга рөхсәт итмәсләр. Әнә мин ничә генә атна укытам — ничә тапкыр малайлар белән якалаштым инде. Ә бу якалашмый, укыта.

Гата бирешмәде.

— Ә, белгән инде аны. Малайлар, билгеле инде, андый фәрештә күргәч риза. Тәртип бозмый ул. Укытучы — матур булсын. Өлкән класс малайлары бар да гашыйк була кыз укытучыга, белгән инде аны. Матур гына булсын...

Иске коймалары, жиргә сеңгән буяулы йортлары белән Яңа бистә күренде. Перронның буе белән халык тезелгән иде. Вагон тәрәзәсеннән текәлеп карап барган Рушадка халык арасыннан Нәркисне эзләп табу кыен булмады. Поезд тирәсендәге ыгы-зыгыга катнашмыйча гына ул үз турысына вагон ишеге туры киләсенә ышангандай басып тора иде. Хәер, поезд туктагач та ул бераз кыймылдамый торды. Янында озатучысы бар икән. Эһә, ир затыннан. Рушад колаклары кызып киткәнне сизде. Битен тәрәзә пыяласына ныграк терәде. Менә ничек икән! — Сезне үземә чакыра алмыйм... Сәбәбен әйтә алмыйм...— Аңлашылды. Ә аннан алда ничек диде? — Бераз гына соңга калгансыз түгелме икән? — Әйе, кызда гөнаһ юк! Аңлаган кешегә аңлашылырлык итеп әйткән. Шулай да нигә Рушад янында үзен тынычсыз тота соң ул?

Авыр тынлыкны Гата бозды.

— Әнә, яхшы товар жирдә ятмый ул,— диде Гата, папиросын чыгарып.— Чорта с два! Мондый кыз тик кенә йөриме соң! Нәрсәседер не так моның дип мин сиңа...

Ләкин Гата сүзен әйтеп бетерә алмады. Кинәт кенә алга ыргылып тәрәзә пыяласына битен терәде.

— Мать честная! — дип кычкырды ул. Аннары ашыгып кына як-ягына борылды да, якын-тирәдә ирләр генә икәнен күргәч, бер ачы сүз әйтеп ташлады. Төкергән сыман итте. Рушад та нииндидер көтелмәгән хәл чыгудан шикләнеп текәлебрәк карады. Нәркисне озата килгән кеше — Сорочи базарында Гата белән Рушадка пальто саткан көмеш тешле теге кара егет иде. Вагонга кеше утырып беткәнче алар сүзсез генә басып тордылар. Аннары көмеш тешле егет Нәркиснең ике битеннән тотып үзенә якын китерде.

Салкын гына, хиссез генә дежур үбешү...

Мәжбүри эш эшләгән кебек кенә кул бирешү...

Дежур елмаю, дежур кул болгау. Егетләр моны сизми калмадылар. Поезд кузгалды. Көмеш тешле егет, перрон, Яңа бистә артта калдылар. Шуның белән Рушадның Яңа бистә кызына карата булган, әле үзе дә танырга курыккан хисләренең әллә ниткән серле җепләре өзелде. Бер минутта барысы да көлгә әйләнде...

— Болай булгач яшибез, разведчик,— диде ул кычкырып. Ул үз тавышын үзе танымады.— Яшибез! Икенче бер вакыт базарда бу кы-

зыйнын үзе килеп чыгып сиңа үтүк белән самовар сатуына да мин ышанам. Сиңа кирәк булыр — семьялы кеше.

— Ә-ә-ә, төкерергә! — дип Гата тагын сүгенде.

Кемне сүкте ул? Нәрсәгә төкерергә? Самовар белән үтүккәме? Көмеш тешле егеткәме? Нәркискә түгелдер бит?

— Мә, ин яхшысы — кабыз! Ленинградныкы, Урицкий фабрикасы. Безнең илдә хәзергә моннан яхшы папирос юк әле. Безнең генерал Берлинга гел шуны китертә иде... «Беломорканал» яшәсен, иптәш старшина!

...Станциядә аларны чыбыркы тоткан Заһир каршы алды. Нәркис күрше вагонда кайткан икән, якты чырай белән егетләрне сәламләде. Заһир чана башындагы печән астыннан яхшы киез итекләр алды, зур кара толыпны шәһәр кызына кидерде. Кызый боларның барысын да тиешле дәрәҗәдә кабул итте һәм чанага кереп урнашты.

Акбалыкка кадәр сигез чакрым юл иде...

## X

Язга шулай да ерак әле...

Авыл тулы — урман чыгаручылар, ишек алды тулы — печәнле йөкләр. Кичләрен авыл клубында аяк басарлык урын булмый. Таза-таза егетләр, пичәт күк бизәнгән кызлар түгәрәк уены уйныйлар, бииләр. Клубта мәхәббәт кайный: җиде-сигез авылның яшьләре кыш буе диярлек Акбалыкта урман чыгаралар. Урман эшләре бетешкә, әллә ничә кыз кияүгә чыгып, урманчы егетләр белән китеп барырга тиеш, диләр. Сугыштан соңгы туклык, тынычлык, күңел көрлеге иң беренче чиратта гыйшык-мәхәббәт мәсьәләсен «тиешле югарылыкка күтәрде». Авыл халкының чып-чыш сөйләшүенә караганда, бер-ике кызның чыннан да, туйны ашыктырмый да хәлләре юк икән... Ә хәзергә әле кичләрен кар өстенә тәрәзәләрдән гөлт итеп ут яктысы төшә, ишек алды тулы ат чанасы, өйдә — камыт, йөгән, абзарларда — чит авыл атлары. Атлар дөбер-дөбер китереп аяк алыштыралар, борылалар, төнлә клубтан кайткан җигүчеләренә мокырданып кына кешнәп дәшәләр, керт-керт башак ашыйлар. Авыл урамнарында печән исе, камыт күне, ат исе. Клубтан, абзарлардан төнге салкын һавага пар чыга. Туклык, ныклык, иминлек бөтен авылның сулышында, йөрәк тибешендә сизелеп тора. Менә яз житәр, сырма кигән таза егетләр бушаган чаналарына төялеп үз авылларына кайтып китәрләр, кунак булып килә башларлар, аларны сагынып кызлар моңаерлар. Авылда кыш буе моның кадәр егет тоткач мәшәкатьсез генә булмас.

Гайнелвафа карчык үз гомерендә яшь-җилбәзәкнең мәшәкатен күрмәде түгел. Кызы Гөлчирә гаять чибәр булды, унбиш яшенә җиткәндә һәр ходай бирмеш кичне артыннан егетләр ияреп кайта башладылар — кызның башы әйләнде. Шулай да тегесен кире какты, монысын куды — арада укымышлысы да, дәрәҗәлесе дә булгалады — ә менә күрше авылдан килеп Акбалыкта тракторда эшләгән чибәр егет белән даны чыкты. Эш зурга китмәде, шулай да кыз бер җәйне кинәт кенә сулды, боекты, тартылды. Әнисе белән сөйләшкәндә онытылып ялгыш җавап биргән чаклары булды, самоварны сусыз куеп эретте, ашка икешәр тапкыр тоз салды. Яшь вакытында үтәдән-үтә чая булган Гайнелвафа карчык боларның сәбәбен бөтен кешедән дә тирәнрәк аңлый иде, кызын гаеп итмәде, тик тракторист егеткә генә эчтән рәнҗеде. Ә бервакыт кичен бакча киртәсенә сөялеп җырлап торган Гөлчирәнең кыяфәтен сыер абзарының тирес чыгара торган тәрәзәсеннән карап торды. Гөлчирә төпсез күз карашын гадәттән тыш сагыш белән кояш батышы ягына текәгән дә шыңшый иде.

Тракторист — майлы крич
Хур иттең башларымны...

Шул җәйдән соң Гөлчирә дөньяга чыкмады, үзенең горурлыгын эченә җыйды да... сүнде. Кыз баланың хәвефле шуклыгын Гайнелвафа карчык та шулай дәшмичә, сорашмыйча гына кызы белән бергә кичерде. Моны карт сиздеме, юкмы, сөйләшми торган кешенекен каян беләсең! Бөтен авылда «Мин кем!» дип йөргән Гөлчирә әнә шул шуклык аркасында гына үзеннән шактый олы кешегә — мәктәп директоры Сабир Ишмуратовичка эләкте. Сабирның үзе янында беренче хатынынннан алып калган малаена үги әни булды. Дөрес, Сабир тиз арада Гөлчирәне укырга урнаштырды, өч-дүрт ел эчендә Гөлчирә читтән торып педтехникумны тәмамлады да законлы рәвештә укытучы булды куйды. Ә сугыш вакытында җиде класс белемең булганда — син инде болай да башлангыч мәктәптә беренче булып йөри аласың. Гөлчирәнең энесе — Галиәхмәт картларның бердәнбер улы — Гайнислам әнә җиде класс белем белән Урта Азия, Казагыстан якларында йөрде. Апасының педтехникум бетергәнен ишеткәч, хәтта аларны җизнәсе белән көчеп килергә дә чакырып язган иде. «Апа, синең белем белән монда министр булырга мөмкин. Әрәм булып йөрмәгез, килегез, өрек җимеше белән куй ите генә ашап яшәсе»,— дип язды.

Инде еллар үзгәрде, балалар үзгәрде, дөньяга карашлар үзгәрде. Инде барысы да үз урынына утырып бара. Акрынлап Гөлчирәнең элеккеге мин-минлеге кайтты, ул яңадан үз кысасына керде. Сугыш алар семьясына зарар сала алмады — Сабир биш-алты ай эчендә ике бармагын укмаштырып оештырган көе кулын асып кайтып керде. Читтән торып институт тәмамлады. Йорт-җирне ныгытты. Дөрес, яшь хатынны сыер каратып җәфаламады. Яшел эмальле чәйнек тотып Тәлгать әбиләренә сөткә йөрде. Шулай итеп яшь хатынның тышкы кыяфәтенә зарар килмәде. Югыйсә, хайван асраган укытучыларның иртән дәрескә килгәндә рәвешләре бер дә класска керерлек булмый. Чәч араларында салам дисеңме, бит-кашта башак оны дисеңме. Юк, Гөлчирә андыйлардан югары булды. «Директор хатыны» дигән рольгә ул тиз керде, тиз ияләнде. Мәктәптә тыныч эшләргә теләсәң, җәберзолым күрәсең килмәсә, директор хатынының көеннән тор. Директор хатыны белән сүзгә килергә ходай язмасын! Директор ничек итсә итәр, синең вак-төяк гаебеңне табар, приказга эләгерсең, синең классыңнан зарланырлар, синең фәнеңнең укыту сыйфатын көн тәртибенә куеп педсоветта тыңларлар, авыл Советы утырышында тыңларлар, профсоюзда тыңларлар... Сине авылдан иң ерак фермага агитатор итеп куярлар, укытучыларның август киңәшмәләрендә докладка эләгерсең. Директор, гадәттә, һәрвакыт әйбәт кеше була. Сабыр, төпле, белемле кешене генә урта мәктәп директоры итеп билгелиләр. Ләкин... директорның хатыны була. Әйе, хатыны була... Ул хатын алдында бер иелмәсәң, икенче иелерсең.

...Фронттан әллә ниткән егетләр кайта башлады. Кара инде бу тарих укытучысын. Дәшми, уен-көлкегә катнашмый. Үзе һаман класста нәрсәдер эшләп йөри. Көн саен диярлек алтынчыда дәрестән соң ниндидер русча җыр өйрәтә. Инде Закировка кадәр «Прощайте, товарищи! С богом, ура!» дип коридорда кычкырып җырлап йөри. Тарих укытучысының әле бер тапкыр да йомыш-киңәш белән Гөлчирә апасы янына килгәне юк. Кара инде теге физика укытучысын! Кем әйтер инде аны теге елларда Акбалыкта көтү көткән малай дип? Андагы мин-минлек, андагы чуар йөрәклелек! Ничек инде ул Гөлчирә белән бер авыз сүз сөйләшмәгән көе фән укытып йөри? Аннан соң бу егетләр әллә нинди ярамаган ысуллар белән тәртип урнаштыру өчен көрәшеп йөриләр шикелле. Юк, барыбер Гөлчирә апагыз янына баш бөгеп киләсегез булыр... Быел, гомумән, ел мәшәкатьле килергә тора.

Кече малай Тәлгать тә шәп укытучыга әләкмәде. Итәгеи, чәчен җыештыра алмаган Миңҗамал. Малайны тәки кеше төсле укытырга

өйрәтмәде. Малай да җыйнаксыз, бар белгәне — оныту. Гөлчирә икенче классның күршесендә, бүлмә тактасы аркылы гына укыта. Малаеның һәр сулышын тоеп укыта. Дәрес башланса, кул күтәргән шул:

— Апа, минем бәптәл өйдә калган!

— Апа, минем урычка сабы (каләм сабы) өйдә калган!

Укыганда малай ашыгып укый. Сүзләрне әвәли, йота. Сакаулыгы да бар. Инспектор Хәмитов дәресенә кергәч, бер көнне үч иткәндәй Миңжамал шул баладан сөйләтте. Гөлчирә бүлмә тактасы аркылы ут йотып тыңлап торды. Ә теге малай гадәт буенча ашыкты, изде. Борынын тарта-тарта изде.

Гөлчирә ул көнне түзмәде, елатканчы Миңҗамалны сүкте.

— Малай болай да өйдә көн-төн сабагын укый, син генә харап итәсең,— диде.— Малайның,— диде,— бу арада кәефе юк, инспектор барында аңа каныкмасаң да була иде. Физкультура дәресендә малайга салкын тигән, төннәрен температурасы кырык алтыга җитә...

Гөлчирәнең һәр әйберне бераз гына чамасыннан арттырып сөйли торган гадәте бар иде, ләкин Миңҗамалның үз гомерендә градусник тотып караганы булмаганлыктан, берсүзсез ышанды. Кырык алты икән, кырык алты...

Соңгы атнада фронтовиклар мәктәпнең астын-өскә китерделәр. Гомердә булмаганны... Алтынчы класс тарих укытучысына тагын номер күрсәтте. Бөгәрсең алай гына, юньсезләрне...

...Тарих дәресе бишенче иде. Класс болай тыныч кына каршы алды. Ләкин класста балаларны күреп булмаслык тузан болыты иде. Ботаника дәресендә колхоз амбарына экскурсиягә барганнар да, шунда амбардан кесә тутырып кайсы борчак, кайсы киндер орлыгы, кайсы нәрсә алып кайтып, бер-береннән шуны талап сугышканнар. Тын алырлык хәл юк, бөтенесе кызарышканнар, борын тишекләре киңәйгән, чабыш атлары кебек әсәрешкәннәр... Монда ике уйларга ярамый иде. Рушад ишек алдына чыгып тезелергә команда бирде. Шатланышып, ура кычкырып ишек алдына ташландылар. Мәктәп ишегендә каршы очраган Гөлчирәне бәреп ега яздылар. Шау-шу артыннан чыгып барган Рушадны күргәч, Гөлчирә бик мәгънәле итеп карап калды. Бу караштан Рушад:

— Я, тагын нинди антипедагогик адым ясыйсың син, малай актыгы? — дигән сүзләрне аңлагандай булды.

Мәктәп ишек алдындагы тигез җиргә сафка тезелделәр. Рушад мәсьәләне бик коры тотты. Стройны урамга алып чыкты да үзе биек кар өстенә басып, балаларга маршрут күрсәтте.

— Әнә теге урамнан әйләнеп, ферма янына хәтле йөгерәсез, аннары арт урамнан йөгереп монда кайтасыз, мин карап торам,— диде.— Ә хәзер слушай мою команду! Б е г-о-о-м! — Шул арада бер-ике малай алга элдертте...

— Отставить!

Яңадан сафка тезелделәр.

— Бего-о-о-м марш!

Урамда аяк астыннан кар кисәкләре очты. Малайлар чыр-чу килеп шатланышып йөгерделәр. Менә сиңа «Уот Тайлер восстаниесе»! Рушад кичә төн уртасына кадәр шул теманы укып планнар төзеп утырды. Менә сиңа план... Балалар әйләнеп кайтканчы класска кереп, ул форточкаларны ачты, күзәтү өчен яңадан чыгып кар өстенә басты. Инде кайтырга чыгучылар да бар, тиз йөгерәләр, шайтаннар. Кура җиләгедәй пешеп, ике-өч малай килеп җитте. Бүрек асларыннан кайнар пар бәреп тора, керфекләре тирләгән. Бу — малайларга үзенә күрә бер кызык булган. Моннан соң гел шулай юри тузан болыты ясап куярлар болар. Бу эшне кызыклыктан җәзага әйләндерергә кирәк. Әйе, шулай кирәк...

— Яле, тагын бер тапкыр,— дип кычкырды Рушад. Малайлар аңышмый тордылар.

— Тагын бер круг ясыйсы. А ну марш!

Монысын ук көтмәгәннәр икән. Койрыкта килгәннәр, беренчеләрнең алга таба чабуларын күргәч, кар өстендә басып торган тарих укытучысы янынннан зур ризасызлык белән уздылар.

Икенче кругны килгәндә барысы да мышкылдаганнар иде. Кызларның башларыннан шәлләре шуып төшкән, алжыганнар, малайлар ачулы иде. Тик Әскәревнең генә йөзендә шатлык чагыла иде.

— Менә, — диде ул, Рушад янына килеп җиткәч, — бик азынсаң шулай була ул: әнә Закировны күрегез... җан бирә калды.

Рушадның иртәдән бирле кәефе начар иде. Иртән кәефең булмаса, көт тә тор — бер-бер хәл була. Аның йөрәге «җу» итеп китте. Болай ук кирәкмәс иде кыланырга... Әнә бит Хушият картлар, башкалар ләм-мим әйтмичә укытып йөриләр. Сиңа гына кирәкмени армия тәртибе? Утыздан артык бала утырган класста тузан чыкмый буламыни? Ләкин бит аларның сәламәтлеге турында сүз бара. Ә тик торганда кар өстеннән йөгертергә ярыймы? Тузан икән тузан, дәресенә зыян китермә. Башкалар кебек... Ләкин бит син коммунист кеше. Коммунист... Ә Хушият? Ул да коммунист бит! Нигә болай соң әле бу? Нигә тормышның бер генә очрагына да хәзерлексез әле син? Ләкин бирешмә, син — сугышта булган кеше.

Закировны култыклап сөйрәп кайттылар.

Укытучылар бүлмәсенә кертеп диванга салдылар. Кемдер медпунктка йөгерде. Малайның күзе ямьсезләнгән, пульсы начар иде. Директор борчылды, ләкин Рушадка берни дә әйтмәде. Дәресе булмаган ике-өч хатын йөгерешеп Закировны терелтү чарасына керештеләр.

Фельдшер кыз килгәч кенә укытучылар бүлмәсендә бераз тынычлык урнашты. Фельдшер сабыр гына кыяфәттә малайның пульсын санады, йөрәген тыңлады. Аннары тагы да тынычрак тавыш белән:

— Берни дә юк, сулышы гына капкан, — диде. — Ләкин бу малайны физкультура дәресеннән азат итү турында әйтелгән иде сезгә, — диде ул директорга. Директор аптырап Рушадка карады.

— Болар семьялары белән харап булган кешеләр, — диде фельдшер кыз.— Кырык өченче елның язында кар астыннан чыккан башак җыеп моның әнисе, ике апасы агуланып үлде. Монысы ике ай больницада ятып чыкты, йөрәге шуннан какшап калды. Шулай, саграк булыгыз, зинһар өчен...

Тарих дәресенең биш минут вакыты калган иде. Закиров торды, оялып кына бүреген алып киде дә өенә кайтып китте. Рушадка бу малай бик, бик кызганыч булып тоелды. Менә бит кеше язмышы, кеше фаҗигасе синең янында. Әйе, сугыш кырында гына түгел, тыныч тормышта да һәр сәгать, һәр минут, һәр адымда кеше язмышы хәл ителеп тора. Нәрсә, әллә мәктәпне ташлап качаргамы? Ләкин кая? Тормыш сине нинди эшкә хәзерләде? Син нәрсәгә сәләтле? Башкача — син кем?

Кичен мәктәптән кайтканда Рушад директор белән бергә кайтты. Директор бу хәлгә артык зур әһәмият бирмәде. Күрәсең, чыгырыннан чыккан класста тәртип урнаштырып йөргән яңа укытучыга ул теләктәшлек белдерә иде. Ләкин Сабир Ишмуратович борчулы. Белмәссең, аның бәлки башка борчулары, башка мәшәкатьләре бардыр.

Тыкрык кебек тар гына урамда кар эчендәге ярым җимерек абзар тирәсендә Закировның тавышы ишетелә иде. Димәк, малайга берни дә булмаган, әбисе аны түбә карын көрәргә менгезгән. Кояш батса да, әле караңгы төшмәгән, кешене ерактан танып булырлык иде. Хәер, башта Закиров игътибар күрсәтте. Абзар кыегына яшеренде дә шуннан җырлап җибәрде:

И ходаем, сабыр бир,
Кер юарга сабын бир.

Без үзебез сабырсыз,
Кер юабыз сабынсыз.

Бу — минa чуртым да булмады, мин әле исән һәм элеккечә явыз, дигән сүз иде. Директор моны ишеттеме, юкмы, әмма Рушад малайның бөтен сүзен аңлады, аның рәвешен, чыраен күз алдына китерде. Укытучылар тарафыннан тиешле игътибар булмагач, малай шактый кыюланды. Кичке тынлыкта моның кем авазы икәнен һәркем аерырлык иде.

Барып кердем Сабирга.
Башын тыккан сабынга.
Башын алгач сабыннан
Куркып киттем Сабирдан.

Директор, ахрысы, боларны ишетмәде...

Директорның бу арада әле үз хәле хәл. Беренчедән, РОНО мөдире Шәмсетдинов бөтен бригада белән тикшерергә киләбез дип хәбәр итте. Язгы сынауларга хәзерлекне тикшерү булуы мөмкин. Дөрес, Шәмсетдиновның шулай дип әйтә-әйтә кыш үткәзә торган гадәте дә бар. Райондагы бөтен мәктәпләргә шулай «алдагы атнада» дип хәбәр итеп куя да директорларның котын алып эшләтә. Алдан хәбәр бирү — эшләтүнең бер ысулы ул. Ләкин урта мәктәп булгач, бригада белән килеп житсәләр дә, берни дә әйтә алмассың шул... Икенчедән, соңгы бер-ике айда семьяда тынычлык бетте. Гөлчирә быел бик нык үзгәрде. Хатын-кыз бит бер үзгәрсә кинәт үзгәрә һәм бөтенләй үзгәрә ала икән. Юк кына сүзгә дә бәйләнә, капризлана башлады. Әллә яшь хикмәтеме? Врачлар әйтмешли, берәр төрле күчеш периодымы?

...Гөлчирә кадерле яшәде Сабир кулында. Сугыш вакытында авылның хәлле кешеләре арасында кунак-төшем бик еш уйналды. Гөлчирә андый мәҗлесләрнең түрендә булды. Парлап йөрү модада түгел, хәер, аның ире дә шул Гөлчирәдә генә бар иде. Гөлчирә килмичә мәҗлес башланмый иде Акбалыкта. Тавышы бер генә гармунга да туры килмәсә дә, Гөлчирә җырчы исәбеннән йөрде. Аңа ияреп уйный алмауны гармунчылар үзләренең «культурный» итеп уйный белмәүләреннән, кушылып тавышын җайлый алмаучылар шулай ук «Гөлчирәнеке кадәр үк талантлары юклыктан» дип уйлыйлар һәм ышаналар иде. Яши торгач аның «талантлы җырчы» икәнлегенә ире дә ышанды булса кирәк, парлы мәҗлесләрдә, кызып алгач:

— Гөлчирәне җырлатыйк!

— Әйдә, Гөлчирә, теге яңа көйне башлап җибәр! — дип утыра торган булды.

Гөлчирә бөтен җирдә, бөтен кешенең игътибар үзәгендә булырга тырышты. Шулай тиеш дип, шуңа лаек дип ышанды да. Авырса да матур итеп авырды ул.

— Температурам күтәрелгәч унҗиде яшьлек кызлар кебек булам мин. Бит урталарым алма кабыгы кебек кызарып китә минем, — дип сөйли белә Гөлчирә. Аңа, сөйләвенә караганда, бөтен кеше соклана да. Больницага барса — аңа анда врач гашыйк була.

Район магазины алдында бозга таеп егылган Гөлчирә бер вакыт. Шунда ишектән чыгып килүче хәрби комиссар белән райфо мөдире аны тартып торгызганнар һәм әйткәннәр:

— Син, Гөлчирә сеңелем, бик матур итеп, грандиозно итеп егылдың, — дигәннәр. (Хәер, укытучылар бүлмәсендә бишенчеме, алтынчымы сөйләгәндә Нәркис кырыс кына итеп аны «грациозно» дип төзәтте төзәтүен.)

Гөлчирә әнә шулай шәп яшәде.

Ләкин бу уку елында тынычлык китте. Борчулар сентябрь аеннан ук башланды. Мәктәпкә, иң беренче чиратта, Гөлчирәгә буйсынмас кешеләр килделәр. Югары белемле Бәлкыйс килде. Укыту бүлеге мөдире

итеп куйдылар. Гөлчирә ничек кенә тырышып карамасын, моны үз кулына ала алмады. Бәлкыйс — әдәпле, белемле. Кешегә каты бәрелмәс, гайбәт сатмас. Бөтен булган кимчелеге — дәрестән чыкканда чәчләре, битләре акбурга буялган була. Математикның шунсыз булмый инде, күрәсен. Дәресенә керсә, ахырдан сәгатьләр буе анализ ясап үзегенә үтмәс. Кайвакытта класстан чыкканда ук, бусагада ук эшен бетереп әйтеп куяр:

— Дәресең бик ошады, моннан соң үзем кереп тормыйм, өйрәнсеннәр өчен яшьләрне кертәм...

Ошамаса — кыскача гына анализ ясар, авызының бер кырыенда аз гына елмаю булыр. Бу кеше — туганда ук педагог булып туган. Ул синең күңелеңне рәнҗетмәс, вөҗданыңны каһәрләмәс. Көзге кичләрдә Сабирның озак-озак мәктәптә укыту бүлеге мөдире белән калуына Гөлчирәнең баштарак эче пошты. Йомыш табып кинәт-кинәт кенә мәктәпкә килгәләп тә карады. Укытучылар бүлмәсенең урамга караган тәрәзә турысында тышта да йөреп карады. Күз-колак булырга Мәсрүрәне дә яллап карады. Әмма Бәлкыйс белән директор арасында шикләнерлек берни дә сизелмәде.

Октябрь башында мәктәпкә Нәркис килеп төште. Юк, монысы Гөлчирәне бөтенләй чыгырдан чыгарды. Гөлчирә аны күргән көнне өйдә тавыш куптарды. Бер сәбәпсезгә Тәлгатьне кыйнап ташлады.

— Син дә нервамны чыгарма әле, — дип дулады. «Дә» кушымчасының бөтен тирәнлеген, мәгънәсен Сабир гына аңлады. Табак-савыт юганда ике-өч көн буе өйдә тәлинкә, чынаяк кырылды — Гөлчирәнең кулыннан савыт-саба шуып төшә иде. Чыдый алмады, бер көнне тәнәфестә башка берничә хатын алдында Нәркис турында сүз кузгатты:

— Моның, — диде, — аяклары бик озын, нәкъ торна төсле. Аннан соң гәүдәсенә карата башы да кечерәк түгелме? Бу шәһәр кызлары әллә нинди кыяфәтсез булалар...

Ләкин бу сүзләрне хуплаучы булмады. Нәркиснең аяклары да, башы да, килеш-килбәте дә сүз әйтерлек түгел, моны һәркем белә иде. Шуңа күрә Гөлчирә беренче көнне үк аны үзенең дошманы итеп күңеленә беркетеп куйды.

Сабир Ишмуратович боларның барысын да аңлый һәм аңлаган саен йортта мөнәсәбәтләр киеренкеләнә сыман иде.

Урам башында, капка белән тигез кар тавында балалар чана шуа. Директор йортының чолан баскычында ялан баш, җинсез күлмәкле Гөлчирә күренде.

— Тәлгать! Т ә л-га-а-а-ть! Кайт, улым, кайт! Сарык итеннән бик тәмле өчпочмак пешердем — ашарга ка-айт!

Капкадан кергәндә генә Сабирны авыл Советының телефон дежуры куып житте. Районнан алынган телефонограммада иртәгә РОНОга ике толып салып мәктәп атын җибәрергә кушканнар иде.

Димәк, Шәмсетдиновның сүзе чын икән.

Борчулы, бик борчулы бу мәктәп тормышы...

## XI

Иртән йокыннан торып эшкә килешеңә һич тә көтелмәгән хәл ишетәсең килсә — мәктәптә эшлә. Уннан артык классың, егермедән артык укытучың, каралты-курасы, тулай торагы, амбары, завхозы, бухгалтеры белән хуҗалыгың булса — көт тә тор, иртәгесен мәктәпкә килгәч бер-бер хәл ишетерсең. Я ул — төнлә булган. Я ул — иртән, дәрес башланганчы, я — беренче дәрестә. Ләкин күбрәге — иртән тәрбия минутында. Мәктәп тормышында кайчак бик мәгънәсез терминология очрый — мәсәлән, «тәрбия минуты». Янәсе, дәрес башланырга ярты сәгать кала класс җитәкчеләре балаларны «тәрбияләп» чыгалар. Яхшы булырга, чиста йөрер-

гә, күршедәге карчыкларга су китерергә өйрәтәләр, колхоз атларына шефлык итүнең файдасы турында, көл җыюның әһәмияте, Нюрнберг процессының барышы турында сөйлиләр. Менә шулар «тәрбия минуты» дип йөртелә. Әйтерсең расписание буенча каралган алты сәгатьтә укытучы тәрбияләми, әйтерсең чисталыкка өйрәтми.

Гата эшкә тотынды да, күп тә үтмәстән, шушы «тәрбия минутына» һөҗүм итте.

— Болар барысы да һәр минутта һәр дәрестә бирелергә тиешле гомуми тәрбия процессының аерым детальләре генә, — диде ул. «Детальләре» дип үк әйтте. — Иртән мәктәп балаларына егерме минут гимнастика — и никаких гвоздей...

Гатаның бу тәкъдименә Рушад, Хәкимҗан, Нәркис кушылдылар. Бәлкыйс директор белән сөйләшеп мәсьәләне уңай хәл итте. Хәл иттеләр... һәм беренче көнне үк «ЧП» чыкты...

Гата мәктәп буенча дежур икән.

Быргы кычкырттылар, бөтен мәктәп балаларын ишек алдына сафка тезделәр. Хәкимҗан зур канәгатьләнү белән калку урынга басты да гимнастика уенын башлап җибәрде. Хәкимҗан командаларны бик ярата. Һәр күнегүгә аның үзе генә белгән исеме — жаргоны бар.

Бүген шуларны бөтен мәктәп баласы белән эшләтү аеруча ләззәтле иде. Гата да китель җиңенә кызыл бәйләгән килеш мәктәп ишек алдыннан бер әйләнеп керде. Ул әле һаман погоннарын салмый иде, шуңа күрә иркен ишек алдында хәрби форма белән йөргәндә ул үзен патруль сыман хис итте. Яшьлек, дәһшәтле, шанлы яшьлек искә төште. Бар иде җиңүчеләр булып Варшава урамына килеп кергән чаклар. Бар иде кырык бишенче елның язында азат итүче булып немец шәһәрләреннән узган вакытлар. Ул чакта Гата бик яшь иде кебек. Ул чакта ничектер бер якта үлем, икенче якта ап-ак чәчәккә күмелгән чия, алма бакчалары, кояш, дәрт, ниндидер бөек идеалларга бирелгәнлек бар иде. Бүген... Бүген Гата — карт кеше. Күңеле карт. Эльзадан хәбәр юк. Алтынчы, җиденче классларга физика дәреслеге юк. Сигезенче класс программасы буенча тәҗрибә ясарлык бернәрсә юк. Физика шкафын тузан баскан, каерып ачып компасларны, магнит дугаларын урлап бетергәннәр. Гата кабул итәргә бер көн кала шкафны тагын бер тапкыр талаганнар. Линзаларны алганнар...

Гата классларны йөреп чыгарга булды. Коридорда Галәвиев очрады. Дежур икән, гимнастикага чыга алмаган, күзләре дымлы. Тәрәзәдән йотылып карап тора. Закиров очрады — Хәкимҗан стройга бастырмаган, справка буенча син гимнастикадан азат, дигән. Шулай ук чыгасы килеп йөри. Алтынчы классның бүлмәсе озынча. Парталар ике рәт... Гата монда инде ике-өч дәрес уздырды. Беренче көнне үк классны ут итеп куйды. Хәзер тәртип бозмыйлар. Чү! Арткы парта астында нәрсәдер кыймылдады. Гата ниндидер бер көтелмәгән хәлне сизенеп аяк очларына гына басып артка китте. Разведчик! Менә синең осталыгың нинди вак урында кулланыла!

Тәрәзәдән төшкән иртәнге кояш нурын фокуска җыеп линзадан ут алып утырган малай — Әскәрев иде...

Разведчик! Сабыр бул! Сабыр, сабыр...

Ләкин Гата сабыр була алмады... Ычкынды.

...Беренче дәрес бетеп, тәнәфес вакыты иде, директор укытучылар бүлмәсендә ачуына буылган бер хатын дулаганын ишетте. Ул моны тиз таныды: Әскәревнең анасы икән. Теле телгә йокмый.

— Ни хакы бар аның минем малаема тибәргә, ә? Элекке заман дип белдегезмени? Суккан өчен нәрсә хәзер, ә? Әйт-дывага чыкмаган өчен генә баланы шулай мыскыл итәргә кем кушкан аңа?

Директор аны тынычландырырга тырышып карады.

Хатын аның саен кызды.

— Зимнәчтүркә киеп, мидал тагып кайттым дигәч тә! Кем кушкан аңа баланың якасыннан тотып өстерәп чыгарырга, ә? Бер дә әллә кем буласы юк, мирнекен ашап үсте, хәерче тиле! Мөрәле Сәләхи малае бит ул, мир көтүен көткән хәерче бит ул!

Гата укытучылар бүлмәсенең тәрәзәсе янына килеп баскан, урамга текәлгән, берсүзсез тәмәке суыра иде. Янына шыпырт кына Рушад килде.

— Нихәл, педагог? — диде. Көлемсерәде.

«Педагог» сүзендәге басымны Гата, әлбәттә, аңлады.

— Ә, чуртым... — Гата сүгенү сүз әйтте, бүлмәдәге тавышка ата улны, ана кызны аңларлык түгел иде, ике егетнең сөйләшкәнен ишетүче булмады. — Бөтен дөньясына төкереп янадан китеп барырмын әле. Мин, ахрысы, тыныч тормышның бу ваклыкларына бөтенләй дә җайлаша алмам...

— Син өстенә бастың, дускай. Мин кичә генә уйлап кайттым. Мин дә яраксыз икәнмен бит монда. Бир син миңа үземнең торпедный аппаратымны, бир син миңа автомат, граната, күрсәт син миңа цельне — мин аның көлен күккә очырам. Ә монда, гафу итәсең, булдыра алмыйм...

Әскәревнең анасы дулады дулады да Сәләхи малаен судка бирергә вәгъдә итеп кайтып китте... «Мир көтүен көткән» өлкән лейтенант Гата Сәләхиевнең бу вакытта җилкәләре төшкән, погоннары да түбәнгә шуышкан сыман иде.

...РОНО кешеләрен урамда Хушият карт тотып калган. Заһир мәктәп ишек алдына буш чана белән кайтеп керде. Соңгы дәрескә звонок булды, директор борчылып коридор буйлап йөренде, Бәлкыйсны әллә ничә тапкыр дәресеннән бүлдереп чакыртты, техничкаларга тынгылык бирмәде. Коридор идәнен тәнәфес үткән саен себереп кенә тордылар.

Алтынчы дәрес — әҗәл. Укытучы бу дәрестә гүр газабын кичерә. Ашказаны авырта башлый, баш шаулый, күз аллары караңгылана, авыз тәмсезләнә... Дөньяда бер эш тә алтынчы дәрес кебек авыр түгелдер. Алтынчы дәрестән чыккач укытучыларның битенә генә кара: күзендә май беткән, күз төпләре каралган, иреннәр күгәргән. Юк бит мәктәбендә бер буфеты, юк бит озын тәнәфестә бер генә стакан кайнар чәй эчерүче. Я, шөкер, звонок булды, аяклар үзләреннән-үзләре класстан алып чыгып киттеләр, журналны куярга да өйгә кайтып ашап алырга кирәк. Укытучы халкы — әрсез халык, кичке сәгать дүртләрдә ул яңадан кеше була, мәктәпкә килеп дәфтәр тикшерә, уен-көлке сөйли, җырлый, биеп тә ала. Тик менә кайтып ашап кына алырга кирәк. Әйе, кирәк...

Ләкин Хушият картта ашап-эчеп килгән РОНО кешеләре (Шәмсетдиновның бите пәрәмәч булган!) бөтенләй башкача уйлыйлар иде.

Укытучылар берәм-берәм класстан чыгып, РОНО кешеләре белән шыпырт кына исәнләштеләр дә, китап-дәфтәрләрен урнаштырып, директордан күрсәтмә көткән сыман позада калдылар. Гата килеп кереп ишек яныннан гына баш какты. Рушадның да сәламләве шуннан узмады.

— Иптәшләр, утырыгыз, җыелыш башлана хәзер, — диде директор, чәчләрен сыпыргалап.

Хатын-кызлар йөзләрен чытып диванга таба юнәлделәр. Директор соңгы сүзләрен бигрәк тә Гата белән Рушадка карап әйткән иде — күңеле сизенгән икән.

Гата, берни дә булмагандай, чөйдәге шинеленә үрелде.

— Иртәнге җидедән бирле тәмәкедән башка бөртек ризык капканым юк, честь имею! — дип, үкчәсең үкчәгә бәрде дә кул сырты белән фуражкасының эмблемасын борын өстенә турылады.

Шәмсетдиновның кичә кызыл битенә елмаю чыкты, авызының түбән ягы аска таба төшеп китте.

— Ә? — диде ул елмаеп. — Ә? Мин ялгыш ишеттемме, әллә аңлап бетермәдемме?

Рушад та чөйдәге яңа пальтосына үрелде.

— Юк, сез дөрес ишеттегез, мин дә иртәдән бирле берни капмадым.

Директор телсез калды. Ул әле Шәмсетдиновка, әле кире егетләргә карады. Аңа кыен иде, егетләр моны аңладылар. Шәмсетдинов болай гына актарып утырган «Семья и школа» журналын шап итеп өстәлгә ыргытты. Эче катып көлде.

— Менә нинди шәп егетләр, билләһи, ә! Кемгә каршы киләсез сез, ә? Сез кем белән сөйләшкәнегезне беләсезме соң? Ах-ха-ха! Ну соң егетләр! — Ул кинәт кенә чыраен үзгәртте. — Сез бит бөтенләй тормыштан артта калгансыз. Мин бит — Шәмсетдинов булам, Шәм-сет-ди-нов...

Гата ишек янында баскан көе ялт итеп честь бирде.

— Гвардия өлкән лейтенанты Сәләхиев булам. Бер сәгатькә обедка — честь имею...

Шалт итеп ишекне япты да юк та булды.

Гата җене Рушадка да кагылды.

— Икенче статья старшинасы корабельный торпедист Сулимов булам. Бер сәгатькә боеприпас алырга китәм.

Ялт борылды да чыгып китте.

Шул минутта ул үзенең шинельдән булмаганына бик үкенде. Өстендәге пальтосы, кешедән салдырып кигән ятышсыз кием кебек, җилкәнә баскан сыман булды...

Егетләр бер сәгатьтән мәктәпкә килгәндә кунаклар авыл Советына киткәннәр иде инде. Директор Шәмсетдиновны квартирга үзенә алган, ә инспектор Хәмитовны «көнлеккә» салып чират төзегән иде. Хәкимҗанда беренче көн, аннан Хушиятләрдә, Рушадта... Бәлкыйс авыз кырые белән генә елмаеп чират кәгазен егетләргә күрсәтте. Егетләр югында булган хәлне шыпырт кына сөйләп алды. Директор бөтен гаепне үз өстенә алган. Мин, дигән, аларга кем киләсен алдан әйтмәдем, алар сезне таныл сөйләшмәделәр дип караган...

— Ә приказны кемнән алдылар? — дип бүлдергән Шәмсетдинов. — Һәр икесен үзем сиңа җибәрдем. Коллективны ныгытырга дип җибәрдем. Менә ничек бозылган синең коллектив, — дип Сабир Ишмуратовичны кыздырган.

Шулай да директор егетләрне бик мактаган. Җыелыш дигән нәрсә кичектерелгән.

Ашап кызарып килгән Гата кулына венский гармунны алды. Бер-ике аккорд бирде дә уйнап җибәрде. Гармун тавышына әсәреп Хәкимҗан килеп керде.

— Уһу, болай булгач музыкантлар күбәйде,— диде ул шатланып.

— Болай булгач ассамблея оештырырга була инде, — диде Гөлчирә дә сүзгә катышып.

Диванда китап укып утырган Нәркис чәчрәп күтәрелеп карады. Шулай да үзен кулга алды һәм җай белән генә төзәтте:

— Ансамбль булсын өчен сезнең кебек җырчылар кирәк шул тагын берничә, — дип беренче тапкыр Гөлчирәгә җөмлә әйтте.

Шуның белән бөтенесе хәл ителде...

Шул секундта Гөлчирә аны үзенең дошманнары исемлегеннән сызып ташлады.

Гата җыр башлады. Аңа Хәкимҗан, Рушад кушылдылар. Бераздан барысы да дәреслекләрен яптылар, күзләрен ниндидер бушлыкка терәп, үзләрен җырның сихри тәэсиренә тапшырдылар. Бу — рәхәт бер дөнья, күңелгә ятышлы, игелекле бер тормыш иде.

Эх, доро-о-ги,
Пыль да тума-а-а-н.
Холода, тревоги
Да степной бурья-а-а-н.

Жырга Нәркис тә кушылды. Хатын-кыз тавышы да өстәлгәч, бу, чынлап да, «ансамбль»гә охшап китте, жырлаучылар бер-берсенә карап елмаештылар, бүлмә эченә булып үткән дәһшәтле Ватан сугышының бөтен моңы, бөтен сагышы тулгандай итте...

Кра-а-й сосновый,
Солнце встает.
У крыльца ро-но-о-го
Мать сыночка ждет.

Жырның кушымтасын күтәребрәк алдылар.

И бескрайними путями,
Степями, полями,
Все глядят вслед на нами
Ро-о-дные гла-а-за-а-а...

Юк, укытучы булып эшләргә ярый бу дөньяда! Нәркисләр, Хәкимжаннар булганда, Бәлкыйс кебек укыту мөдире булганда нигә эшләмәскә! Килер бер көн, бу коллектив бунтарь Гатаны да, уйчан Рушадны да эченә алып эретер. Алтынчы класс та рәтләнер. Жиңү көненә аларның барысын да сәхнәгә чыгарга хәзерләргә кирәк. «Варяг» жырын өйрәтеп бетерергә кирәк. Укытучылык эше изге эш. Моны ташламаска кирәк...

Нәркиснең озын керфекләре «шулай» диган кебек Рушадка карап бер селкенеп алдылар.

Хушият карт килеп кергәч, ничектер, жыр үзеннән-үзе тынды. Ул кечкенә күзләрен желтерәтеп ишек төбендә чишенергәме-чишенмәскәме дигәндәй басып калды.

Нәркис тиз генә бер китап алды да ашыгып актарырга кереште. Кирәкле битен тапкач, китапны Рушад белән Гатага сузды да карандаш очы белән төртеп бер урынны күрсәтте. Хрестоматиядән Горькийның «На дне» дигән әсәре икән.

— На пустыре... там... Актер... удавился!
— Эх... испортил песню... Дур-рак!

Егетләр елмаештылар...

Билләһи, акыллы кешеләр белән яшәве күңелле бу дөньяда.

Иртәгесен бөтен мәшәкате белән РОНО «бригадасының» тикшерүе башланды. Миңжамал укытучылар өчен амбар артына аерым салынган урынга бер өзлексез йөгерде. Хушият татар теленнән кирәкле таблицасы урынына дәрескә анадонтаның эчке төзелешен күрсәткән таблица алып кереп хур булды. Хәкимжан да дәрескә керер алдыннан гомердә булмаганны каушап, автоматның пружинасын урнаштыра алмыйча жәфаланды, як-ягына каранып, хатын-кыз югын белгәч, саф татар теленда генә ачы итеп сүгенеп алды.

Хәмитов күбрәк Нәркис дәресенә йөрде.

«Бунт күтәргән» егетләрне Шәмсетдинов беренче көнне бөтенләй күрмәмешкә салышты.

Өченче көне Рушадның дәресенә Хәмитов кергәләде. Шул көнне график буенча ул аны кунарга да алып кайтырга тиеш иде.

Хәмитов — шома егет. Утызларда булыр. Бу егет сугышка катнаштымы икән?

Хәмитов — шәп егет, ыспай егет. Өстендә көмеш төсендәге костюм. Муенда — яшел саржа галстук. Түене — йодрык кадәр. Район үзәгендә галстук таккан кеше — нибары бишәү. Райфо мөдире, уполминзаг, парикмахер, Хәмитов һәм райздрав мөдире. Галстук хәтта Шәмсетдиновта да юк...

Квартирга кунак егет кайтасы булгач, Гайнелвафа карчык бозауны абзарга чыгарган, сап-сары итеп баскычларны, идәннәрне юган, вак бә-

леш пешергән иде. Карчыкка сөйләшергә кеше генә булсын. Ул якты чырай белән егетләрне каршы алды, әллә ниткән ак тастымалларын казып чыгарды, йөгереп йөрде. Алдан сөйләшенгән буенча, нәкъ чәй янына утырганда гына Гата килеп керде.

— Бүген, әби, кич безнеке, — диде Гата, кителен сыпыргалап. — Өч-дүрт сәгать вакыт каян килеп кая китмәгән...

Мал карап йөргән Галиәхмәт карт та өйгә кереп сәке буена урнашты. Сүзсез генә, иягең сыпыргалап тик утырды. Аның нәрсә уйлаганын шайтан үзе дә белмәс. Йөзендә һәрвакыт ярым елмаю, ярым мыскыллы бер караш булыр. Ни дигән сүз бу?

« — Их, сез, яшьләр, бу гомерне һаман шулай бер көенчә торыр, картаймабыз дип уйлыйсызмы? Ялгышасыз...»

« — Әллә Галиәхмәт бабагызның да сезнең кебек типсә тимер өзәрлек вакытлары юк идеме? Барысы да үтә, барысы да...»

Шулай уйлыймы ул?

Гата чалбар кесәсеннән шыпырт кына бер шешә алып өстәл астына таба яшерде. Моны картлар күрмәгәндә генә хәл итәргә кирәк иде.

— Син, старшина, стеклотара мәсьәләсен хәл ит инде. Мөмкин кадәр конспирацияне сакларга кирәк.

— Уңай моменты чыкмый калмас дип уйлыйм, иптәш өлкән лейтенант...

— Күптән сөйләшеп утырган юк, шайтан алгыры. Менә иптәш Хәмитовның килүе әйбәт булды бит әле. Югыйсә, көн саен биш сәгать дәрес, аннан соң тәҗрибә-фәлән ясарга приборлар әмәлләп ярты көн уза. — Гата сөйләнә-сөйләнә карт белән карчыктан күзен алмый уңайлы моментны көтә иде. Инде мичтән кайнар бәлеш тә килде — утыр да ашый башла.

Һәм җае чыкты.

Гайнелвафа карчык — сизгер кеше. Ялт-йолт өстенә киенде дә, келәттән он-фәләннәр аласы бар дигән булып, картны ияртеп чыгып та китте.

Шешә өстәлгә үк менде. Рушад чәй чокырларын Гата алдына тезде. Гатаның кәеф гадәттән тыш яхшы иде.

— Ике көнгә алты дәресемә керделәр. Что син? Укытып караган кешемени мин! И син нәрсә уйлыйсың? Ничава гына бит, белденме шуны. Кунаклар килгәч, директор абыең да гел кеше дәресендә йөри. Бир син миңа җитәрлек приборлар, бир син миңа электромашина, үлчәгеч приборлар, коры элементлар, пар машинасы, оптик пыялалар! Инженерлар хәзерләп чыгарам мин! Физфакка туп-туры юл ачам мин! Юк бит, коры тел белән Ом законын аңлатам бит... Кычкырып еларсың. Ну, ничего! Менә министерстводан багаж киләсе, имеш. Һәрхәлдә, быелгы унынчылардан бер сигез-ун бала физфакка керәчәк. Я, тоттык, егетләр!

Гата ялт итеп әйләндерде.

Бу процессны Рушад та җиңел башкара. Әнисе күрсә шаккатыр иде. Әтисе үз гомерендә сырадан көчле нәрсә эчмәде. Менә малай — булдыра. Әлбәттә, бик сирәк кенә, уңае белән генә...

Хәмитов чынаяк чокырына күз дә ташламады.

Егетләр аптырап калдылар. Гата турап куйган суганны чәнечке белән авызына озатып маташа иде, мөлдерәп торган, кеше кагылмаган чынаяк чокырын күреп, авыз ачкан килеш туктап калды. Аның күзләре әсәрде.

— Ә! — диде ул. — Ә? Бу ни дигән сүз?

— Бу — хуҗа буларак мин начар кыстыйм дигән сүз, — диде Рушад. — Әйдәгез, иптәш Хәмитов, хуҗалар кергәнче. Аннан ашап бер иркенләп сөйләшеп утырырбыз. Өч егет бергә килгәч, шәт, тема табылыр...

Һиһаять, Хәмитов та телгә килде.

— Ә мин, иптәшләр, мондый нәрсәне бөтенләй тотмыйм.

Гата чәнечке башындагы суган телемен кире куйды. Хәмитов сөйләшү дәртенә салкын су сипкәндәй итте. Беткән көе бетсен дигәндәй, Хәмитов куктә оча башлаган егетләрне салкын гына сүз белән җиргә утыртты.

— Безнең эш бик күп әле бүген. Минә тарихчы иптәшнең ике дәресенә анализ ясыйсы бар. Әйдәгез, тиз генә тамак ялгыйк та эшкә утырырбыз... Сезнең дә иртәгә тугызынчыларда физика бар бит. Беренчесенә үзем керәм...

Бу минутта иң кызганыч кеше — Гата иде. Ул урыныннан торды, ишекле-түрле йөренде, папирос чыгарды. Аның эче кайнады. Рушад берөзлексез калак белән чәен болгатты. Шикәре эресен өчен түгел, бары тик күңел бушлыгын, авыр тынлыкны тутырыр өчен. Хәмитов әледән-әле ак кулъяулыгын чыгарып авыз тирәләрен сөрткәли-сөрткәли ашады. Ыспай кызлармыни, каның катар. Син соң ике фронтовик арасында утырасың бит, ука башмак! Азрак сораш, һич югы, кайларда булдыгыз, дип сораш, егетләрнең күңеле булыр. Күтәреп эчеп җибәр, һич югы, кеше күңеле өчен бер-ике йот... «Тарихчы иптәш» дип сөйләмә, егет икәнсең, егет кешегә исеме белән дәш, «син» дип сөйләш! Шул булдымы эш, ачуым бер килмәгәе!

Гата йөренде дә йөренде...

Күз алдына әллә нинәр килде. Менә дөньяның әллә ниткән вокзаллары. Менә чемодан тотып ул вокзалларның берсенә Гата килеп керә. Хәрбиләр залына уза. Офицерлар арасына барып керә. Хром перчаткаларын сала, гадәт буенча, затлы портсигарын чыгара. Өч минуттан — Гата болар белән дус. Монда өч-дүрт сорау — ачкыч.

— Кайсы участокта булдың?

— Тугызынчы май көнне кайда идең?

— Ә каян башладың?

Менә шундый сораулар. Аннан конкретлаша төшә.

— Ә Днепрны чыкканда, беләсеңме, ничек булды? Соң бит без синең белән бер бригадада булганбыз...

— Ә Прагада! Прагада ничек! Тугызынчы май көнне андагы хикмәткә эләктеңме син?..

Бу халык белән поездда йөрүе никадәр рәхәт. Керәсең — исәнләшәсең. Кул бирдең — син инде таныш. Чемоданны ачасың — аттестатка ни бирелгән булса, шуны алып уртак өстәлгә саласың. Менә ипи, менә консерва, менә колбаса, шикәр. Бары да уртак. Өч минуттан — җан дуслар. Бар иде дөньяның шәп егетләре...

...Бу шома егет нишләп йөрде икән соң Гата Берлинга таба барганда? Институтта укып йөргәндер, өметсез! Монын үзенә күрә берәр авыруы бардыр. Кан басымыдыр, йөрәктер. Һич югы, бүсердер. Мондый кешедә шулай да була. Менә бит инде ярты сәгать өстәл янында — тәки җылы әңгәмә башлана алмады. Син юньле булсаң, ул анализларыңны калдырып торыр идең; син, кеше булсаң, менә хәзер уен-көлке сөйләр идең; син, егет булсаң, менә хәзер, һич югында, кызлар турында сөйләшер идек. Педучилищеда вакытта Каюм Насыйриның новеллаларын укыйлар иде. Иң авыр әйбер — нәрсә? имеш. Ташмы, тимерме? Юк, ташны да күтәреп караганнар, тимерне дә. Иң авыры — авыр мәҗлесле кеше икән.

Гата шинеленә үрелде.

Хәмитов, ак кулъяулыгы белән авыз кырыен сөрткәләп, урыныннан торды.

— Әйдәгез, эшкә утырырга вакыт,— диде.

Юлда кайтканда Гата берөзлексез сүгенде.

Күңелсез, бик күңелсез бу дөньяда! Нигә дип кайтылды соң? Мәскәүдә калырга була иде. Казанда калырга була иде. Кайда калсаң да гөрләшеп сөйләшергә, гәпләшергә компания булачак иде.

Кич җитеп килә, авылны тын гына караңгылык йотып маташа. Карт таллар башына каргалар кунаклаганнар; ахрысы, инде йокыга да киткәннәр. Ара-тирә берәрсе саташып кыйгылдап ала, кунаклаган ботагыннан ычкынып, пырылдый, башкаларны борчый. Шуннан тагын тынлык. Әле ут та алмаганнар.

Карт өянке башында каргалар арадан берсен каһәрлиләр. Мөгаен, саташып егылып киткәндер дә үз урынына утырмагандыр. Һәр җан иясенең, һәр тормышның үзенә күрә борчуы бар. Үз мәшәкате бар...

Шимбә көнне дәрестән соң педсовет башланды.

Бу — Гатаның үз гомерендә беренче мәртәбә педсоветка катнашуы иде.

Атна буе тикшерүләрнең гомуми тәэсире хакында РОНО мөдире Шәмсетдинов сөйләде. Ачы телле кеше икән. Сүзе төртмә, тәмсез. Суктырып, тәмсез итеп сөйли. «Яхшы» дигән сүз лексиконында бөтенләй юк. «Яхшы булды» дип әйтәсе урында «начар булмады» дип сөйли. «Фәлән кешенең дәресе дә миндә начар фикер калдырмады. Фәлән дәрес тә начар булмады. Класс җитәкчесе буларак фәлән иптәш начар эшләмәгән!» Телеңә төер чыккыры!

Шәмсетдинов укытучыларның политик белемнәрен дә тикшергән. Бу мәсьәләдә иң каты янганы Миңҗамал икән. Халык демократиясе илләренә ул Франциянe һәм Бенилюксны[1] кертеп харап булган. Әлбәттә, директорга, завучка һәм фронттан кайткан егетләргә андый сораулар бирелмәгән.

«Иң ахырдан «төрлеләрдә» сүз алырга вәгъдә итеп, Шәмсетдинов утырды. Дәү графиннан юка стаканга тутырып су салды да голт-голт итеп эчеп җибәрде.

Кыска гына тәнәфестән соң инспектор Хәмитов сөйләде. Кемнең кайсы дәрестә өтерне ничек куюын, укучыга нинди вакытта ничек каравын, парта кырыена кайсы укучының дәфтәрне ничек куйганын — барысын да сөйләде.

Дөньяда Хәмитов булудан алла үзе сакласын! Мондый ваклык белән ничек яшәмәк кирәк? Һәм ир кеше исемен күтәреп, чалбар киеп, ничек шулай вак була белергә кирәк! Хәмитов шактый зур ирония белән Гатаны чеметеп узды: ясаган тәҗрибәләре методик яктан дөрес оештырылмаган. Шуның өстенә, Гата бәрелү көче турында сөйләгәндә сугышта булган бер вакыйганы кыстырып алган. Катовице шәһәрен азат иткәндә, артподготовка вакытында. Артиллеристлар өчен бу гаҗәп бер очрак булган, бары тик разведка мәгълүматы гына ярдәм иткән: хикмәт снарядта түгел, ә танкларның бронясында икән.

Укучылар өчен бу — кызык та, әмма физика дәресе бар бит әле... Программа бар. Имтихан бар.

Сугышта булган очраклар аз түгелдер алар. Һәм, гомумән, сугыш турында сөйләп артык мавыкмыйсызмы, иптәшләр? Тарих дәресендә дә бу сизелде... (Тарих укыту турында — ярты сәгать!) Хәтта физкультура, хәрби эш дәресендә дә җае чыккан саен сугыш хәлләреннән бер мисал китерелә һәм башкалар, һәм башкалар...

Педсоветның икенче өлеше газаплы, ямьсез узды. Алтынчы класста тәртип урнаштыру өчен көрәштә антипедагогик алымнар куллану турында Шәмсетдиновка ата-аналардан жалоба килеп кергән. Монда ике мәсьәләгә аерым тукталынган. Беренчесе — укучыларның дәресен өзеп кар өстендә йөгертүләр, справкасы була торып та Закиров дигән бер укучыны үлем чигенә җиткерү; икенчесе — шул ук класста Әскәрев дигән малайның кыйналуы. Әскәрев якасыннан тотып өстерәп чыгарылган һәм класс ишеге янында, каршылык күрсәткәч, артына тез белән типкәннәр. Мәсьәлә хәзер тирәнгә киткән. Һәм бу хәл тарих укытучысы

[1] Бельгия, Нидерланд, Люксембург.

белән физика укытучысын мәктәптә калдыру-калдырмау яссылыгында (Шәмсетдинов «плоскость» дип сөйләде) тикшерелергә тиеш.

Укытучылар бүлмәсендә авыр тынлык урнашты. Беркем бер сүз дәшмәде. Директор борчылып түбән караган килеш утырды, өзлексез кулындагы карандашны әйләндерде. Нәркиснең күкрәге бер минде, бер төште: дулкынлана башласа, аның сулаганын бөтен кеше күреп тора ала...

Авыр, газаплы хәрәкәт белән урыныннан директор кузгалды. Күзләрен читкә — тәрәзә аша күренгән кар дәрьясына текәде. Их, чыгып китәргә иде шушы тәрәзәдән туп-туры, китәргә иде кар өстеннән урманга кадәр, керергә иде төлкеләр, тиеннәр арасына һәм берникди педсоветсыз, беркетмәсез, инспекторларсыз яшәргә иде. Кис идең урман, чап идең печән, төя дә озат идең авылга. Тик шушындый ямьсез җыелышлардан гына азат итсеннәр иде. Килер бер заман, тарих китапларыннан балалар гаҗәпкә калып укырлар: фиргавеннәр үзләре исән вакытта ук фәлән йөз мең кол хезмәтен кулланып фәлән миллион таштан үзләренә зур пирамидалар төзеткәннәр... Дарий үзенең гаскәрен Дарданелл аркылы уздырганда шторм аның понтон күперен җимерткәч, диңгезне камчыларга әмер биргән. Акбалык мәктәбендә бер вакыт егерме сигез укытучы биш сәгать буе җыелышта утырганнар. Ул вакытта мәгариф бүлегендә Шәмсетдинов дигән кеше эшләгән.

Сабир Ишмуратович тамагын кырды.

— Моңа бары тик мин генә гаепле, иптәшләр,— дип шактый ышанычсыз хәлдә башлап җибәрде ул.— Әйе, мин генә гаепле. Дөрес, бу класс безнең иң кыен коллектив, яңа укытучылар — мин күз алдында тотам, әлбәттә, иптәш Сулимов белән иптәш Сәләхиевне — бу коллективны рәткә салу өлкәсендә бик энергично эш башладылар. Бик энергично эш башладылар. Инде килеп, инде килеп, шушы эш процессында, шушы эш процессында (борчылган вакытта директор һәр чак шулай кабатлап сөйли) күңелсез картиналар чыккан икән, моңа как директор мин генә гаепле, мин генә гаепле. Иптәшләр, без бу мәсьәләне тирәнгә җибәрмик, үзара бетерик, мин как директор, как директор, сүз бирәм, безнең коллективта моннан соң андый эшләр булмаячак, булмаячак, и сез дә, иптәшләр,— мин, әлбәттә, иптәш Сулимов белән иптәш Сәләхиевне күздә тотам,— бу гаепләрегезне танып, иптәш Шәмсетдинов алдында сүз бирергә тиешлесез. Сүз бирергә тиешлесез...

Рушад урыныннан сикереп торды.

— Ни өчен алтынчы класс шул дәрәҗәгә җиткерелгән? Моңа сәбәп нәрсә?

Ул әйтеп бетерер-бетермәстә Гата чәчрәп чыкты.

— К черту! Төкерәм мин сезнең логикагызга! Мин эшлим икән — эшлим, шушы мәктәптә дисциплинаны как наять куям, әгәр алай аяк чалсагыз — гуд бай!

Ул кителенең тамак астындагы төймәсен эләктерә үк башлады, әйтерсең хәзер үк чыгып китәргә тели иде.

Ләкин Шәмсетдинов усал кеше икән. Киңчә кызыл шадра битенә тантаналы елмаю чыгарды, зур авызын иренеп кенә ачып, егетләрнең гайрәтен сүндерерлек бер-ике генә җөмлә әйтте:

— Беренчедән,— диде ул, елмайган килеш,— беренчедән: мин кайбер иптәшләрдән шыпыртрак кылануны сорар идем. Үзеңнең биографияңне һәм дә шулай була торып нинди җаваплы фән — партийный фән — укытуны ышанып тапшырганны онытмаска киңәш бирер идем мин кайбер шәп егетләргә. Икенчедән: мин кайбер җилкәсен куырып погон ялтыратып йөрүчеләрдән дә кайбер автобиографик моментларны онытмауларын сорар идем. Вчүжтәки, бу — урта мәктәп, ә төрмә түгел...

Беренчесе — Рушадның этисе теге якта калган дигән хәбәргә кагыла иде.

Соңгысы Гатаны үтерер өчен әйтелгән сүз иде.

...Гатаның беренче курсны тәмамлап кайткан елы иде. Җәен ул Акбалыкта көтү алды. Көтүче авырып киткән иде — Гата ул терелгәнче дип ялланды. Бер көнне кич капка төбендә яшүсмерләр белән тәмәке тартып гармунга җырлап утырганда болар янына Бибисара килеп бәйләнде.

— Хәзер үк таралыгыз, убыркы өстендә нинди ул гармун белән утыру,— диде.

Шунда Гата каршы чыкты. Бәхәс кызды. Гата ямьсез сүз әйтте. Бибисара җиңелде. Ләкин кояш чыкканда Гатаны алып та киттеләр. Тиз-тиз генә суд ясап утыртып та куйдылар. Гата шулай төрмәгә эләкте. Хулиган малайлар белән беренче көнне үк камерада сугышты. Икенче төнне камерадагы өч Казан малае Гатаның авызына чүпрәк тутырып, аяк-кулын нарга бәйләп куйдылар да маңгаена кыздырган кадак белән ике шадра ясадылар. Бу шадралар мәңгелек истәлек булып калды. Ул малайларны шуннан соң каядыр күчерделәр, ләкин Гатаны да ничектер азат иттеләр. Гатаның йөрәгенә кан урнашып калды. Ул үз гомерендә бер тапкыр елады. Һәм бары тик Гатача, көч һәм ачу белән, гарьлек һәм ярсу белән елады. Акбалыкка килеп, Бибисараның өенә кереп:

— Бер генә үтенечем бар: укыган җиремә хәбәр итмәгез, мине бөтенләй бетерәсез,— диде.

Үкереп-үкереп елады.

Бибисара хәбәр итмәде. Моңа нибары биш-алты елдыр әле. Ә хәзер... Шәмсетдинов шуны белә һәм запаста тота икән...

Мәсьәләгә үзенең беркатлылыгы белән Хәкимҗан кысылды. Кысылды... һәм «шып» утырды.

— Слышь, иптәш Шәмсетдинов,— дип тотынган иде ул.— Болай бит: шушы егетләр кайтып кына мәктәпне бераз рәткә салдылар бит...

Шәмсетдинов бу юлы елмаймады. Карлыккан ямьсез тавыш белән Хәкимҗанны кинәт бүлдерде:

— Димәк, военрук мунчала булган. Военрук үз урынында булган җирдә тәртиптән зарланучы юк...

Хәкимҗан телсез калды.

Кыска, ачык җөмләләр белән Бәлкыйс сөйләде. Фронтовик егетләр мәктәпкә килү белән мәктәптә эшнең җанланганлыгын, тәртипнең яхшырганын әйтте. Тәртип урнаштыру буенча көрәштә кайбер хаталар киткән икән, киләчәктә егетләр моны искә алырлар. Ләкин яңа укытучыларны бөтен укучылар ихтирам итәләр, алар иртәдән алып кичкә кадәр укучылар арасында.

Ишек янындагы терәксез урындыкта блокнотына нәрсәдер язгалап утырган Хушият карт торып басты. Тамагын кырды. Кереш сүз сөйләде. «Сәүит педагогикасы бездән, укытучылар әрмиясеннән, бик күп нәрсә таләп итә. Иптәш Кәлинин үзенең бер докладында укытучы турында болай дигән иде...

— Иптәшләр, минем әйтәсе килә, бәлки, мин ялгышамдыр, ялгышсам, иптәшләр төзәтерләр, ихтимал, дөресен әйтәмдер, минем әйтәсе килә, кайсыдыр ки, безнең яңа килгән иптәшләр мәктәптә электеннән килгән өлкәннәргә, чыныккан кадрларга карата бик үк дөрес булмаган политика алып баралар. Алыйк шул ук тарих укытучысын: бармы аның минем янга, и кәк класс җитәкчесе буларак, и кәк өлкән педагог буларак, бармы аның минем янга киңәш белән килгәне? Ә бит, иптәшләр, алтынчылар дер селкенеп торалар хәзер тарих дәресе керер алдыннан. Балалар бит өркеп беткәннәр. Балаларны чирләтеп бетерсәк, припадочный итеп бетерсәк нәрсә булыр? Ә бит, иптәшләр, «Учительская гәзитә»

болай дип яза: безнең илдә, ди, укытучы шундый югарылыкта торырга тиеш, ди, кайсыдыр ки, ди, бер генә капиталистик илдә тормаган, тормый и тормаячак та, ди бит, иптәшләр. Иптәш Шәмсетдинов монда бик дөрес әйтте, әзрәк үзеңнең биографияңә кагылышлы әйберләрне дә онытып бетерергә ярамас... Инде килсәк — иптәш Сәләхиевкә...

Гата җыерылып куйды.

Диванда битараф кыяфәт белән Миңҗамал, Гөлчирә һәм тагын берничә хатын-кыз утыралар иде. Менә рәхәт кешеләр... Гөлчирәнең мамык шәлен алларына җәеп салганнар да шуның сыйфатын тикшерәләр.

Хушият карт Гата турында сөйләгәнче, шулай ук, бер баш мәкаләнең укытучы турында әйткән җөмләсен китерде. Моны тыңлау газапка әйләнде. Рушадның күз аллары караңгыланды. Нәркис тә, башкалар да аның биографиясен белмиләр иде бугай. Карап карыйк, Нәркиснең мөнәсәбәте нишләр, үзгәрерме?

Хушият карт сөйли дә сөйли, әле Гатага килеп җитә алмый.

Рушад тәрәзәдән ишек алдына карады.

Киң, иркен ишек алдыннан мәктәп баскычына таба җил-җил атлап бер хатын килә иде. Кинәт Рушад сикереп торды. Теге хатын — Әскәревнең анасы иде. Гата харап булды! Бу хатынны, мөгаен, Хушият карт чакырткан. Педсовет барганда шуның өчен ул ишек янында утырган, шуңа күрә ике-өч тапкыр чыгып кергән. Хәзер дә ул юри вакытны суза, теге хатынның ыжгырып килеп кергәнен көтә. Үзең һәлак бул, иптәшеңне коткар! Устав шулай ди. Суворов шулай кушкан. Тукта, аю хезмәте булмасын! Бу хатын Рушадны да яратмый! Рушад берни белән дә исәпләшмичә линейка алып каршыда утырган Нәркискә төртте. «Тәрәзәгә кара» дигән ишарә ясады. Әскәревнең әнисе инде баскычтан менеп килә иде. Нәркис секунд эчендә мәсьәләне аңлады да торып чыгып та китте. Узышлый, диванда утырган Гөлчирәне дә эләктерде. Яшәсен акыллы хатын-кызлар! Мең яшә, Нәркис! Педсовет бик озакка сузылганлыктан, ике хатын-кызның торып чыгып китүе гадәти бер күренеш дип кабул ителде.

Хушият карт тегеләй борды, болай борды — мәсьәләгә якыная алмады. Ә бераздан хәйләкәр елмаеп ишектән Нәркис белән Гөлчирә килеп керделәр. Рушад аларга сораулы караш ташлады. Нәркис озын керфекләрен сирпеп түбән карады, елмайды. Димәк, мәсьәлә хәл ителде. Гөлчирә исә үзен бу компаниягә алуларына чамадан тыш шатланып, үзенең бу кешеләргә ярдәм күрсәтә алуына горурланып кып-кызыл булып утырды. Янындагы Миңҗамалга эндәшмәде дә...

Ишек алдыннан акрын гына атлап Әскәревнең әнисе чыгып бара иде...

Шәмсетдинов Гатаны бастырып куйды.

Гата башын түбән иде. Юк, бу дөньяда Гата бик кечкенә, бик әһәмиятсез җан иясе икән. Ә ул үзен көчле, куәт иясе дип йөргән иде. Кайчандыр Гата ирекле, хөр, пакь иде. Әйтик, бала чакта. Көз. Гата — уҗым басуы кырыенда. Маллар — камыл арасында. Ә Гата уҗым өстендә йөри. Бу — күңелгә рәхәтлек бирә. Вак кына яңгыр сибәли. Кырда баллы салам исе. Түбәндә, үзәндә, соры-зәңгәр пар эчендә авыл җәйрәп ята. Бер якта, офыкта — урман. Юкә урманы. Инде яфраклар коелган. Шулай да көн бик җылы. Юкә урманы күгәрчен тамагы төсендә. Бөтен җирдә сагышлы тынлык. Кайдадыр салам эскертләре артында симергән казлар кыйгылдашып ала. Авылга алар хәзер очып кына кайталар. Җир су эчә. Тын гына, мәһабәт кенә. Яздан калган ерганаклар кырыенда йомран, әрлән тишекләре. Алар да инде йокыдадыр. Вак яңгыр сулышны, йөрәкне иркәли, яшисе килә, бөтен тереклек дөньясына игелекле эш эшлисе килә. Авылдан мунча исе килә, вак яңгырга каршы күтәрелә алмыйча сыек аксыл төтен йорт түбәләренә

сырыша. Анда чөгендер пәрәмәче, таба ипие пешерәләр. Шушы җирдән аерылмаска, мәңге шушы таба ипие исе килгән авылның басу түрендә ахмак сыерлар, аңгыра сарыклар арасында камыл ерып йөрергә иде... Ләкин язмыш Гатаны эт итте. Тегеннән күтәреп алды — монда күтәреп салды. Аннан суырып алды — тегендә күчереп куйды. Ул япь-яшь көенчә менә шушылай суд алдында башын түбән иеп торды. Сугышка алынгач та Гатаны кыска сроклы командирлар курсына җибәрделәр. Гата анда да бер тапкыр янды. Посттан кайткач винтовкасын чистартмаган көе ятып йоклаган иде — эченә яңгыр төшкән икән — ике-өч сәгать эчендә көпшә «чәчәк аткан» булып чыкты. Тревога уйнадылар. Гата чак уянып пирамидадан винтовкасын алды да стройга чыгып басты. Курслар начальнигы полковник «на выбор» курсантларның аяк чисталыгын, винтовкаларын тикшерде. Күлмәкнең эчке якаларына кадәр тикшерде.

— На первый, второй, третий рассчитайсь!

Гата «өченче» дип кычкырды.

— Третьи номера, снять затворы!

Гата көпшә аркылы күккә карады һәм коелып төште. Көпшә эче кызыл тимгелле иде.

Полковникка мылтыгын биргәндә аның тамагы чатнады. Теле чак әйләнде.

— Боевая, незаряженая, номер сто девяносто ноль...

Калганын Гата төштә күргән кебек кенә хәтерли. Башын иде — анысын күз алдына китерә але дә. Озак дәшмичә торды.

— Бу нәрсә? — дип җикеренде аңа полковник.— Бу нәрсә, ә?

Гата дәшмәде.

Гаупвахтада ул өч тәүлек утырып чыкты.

Ләкин дөньяда бөтен күргән мәшәкате, җәфасы Гатага беткәнче файда китерделәр. Ул солдат тормышының, солдат язмышының кырыс гаделлеген яратты. Дөрес, анда да бер тапкыр ялгышты ул.

Бу хәл үз күзе белән күреп, үз кулы белән беренче фашист очучысын әсирлеккә алганда булды. Кара төтен бәреп җәһәннәмгә киткән миссершмидттан бер парашют аерылды. Гатаның ике егет белән заданиедән кайтышы иде. Таза гәүдәле, җылы киемле бу чибәр немецны парашют бауларыннан аралап алдылар. Немец мондый ук «хөрмәтне», әлбәттә, көтмәгән иде — каршылык күрсәтмәде. Коралсызландырып, аны штаб урнашкан авылга алып киттеләр. Әсиргә бланк тутырганда Гата үзе катнашты. Әсир карышты. Хезмәтенә кагылышлы сорауларга җавап бирмәде. Тәрҗемәче кыз тирләп чыкты, өйне тәмәке төтене басты. Шактый утыргач, әсир урыныннан торды да тәрҗемәче кыздан бер бит чиста кәгазь сорады. Кәгазьне алгач, бик нык йомарлап йомшартты һәм оятсыз рәвештә:

— Миңа туалетка барырга кирәк,— диде.

Фашизм турында ишеткән бар, ләкин мондый цинизмны Гата күз алдына китерә алмый иде. Өй алдына чыккач, Гата чыдамады, фашистның яңагына, киерелеп, берне кундырды. Әсир шырыйлап акырды. Гатаның бу «ЧП»сы командующийга кадәр барып житте, штрафнойга эләгүдән ул чак кына котылып калды. Ләкин фронтка эләгеп өч-дүрт ай үтүгә Гатаны кыю, тәвәккәл офицер буларак инде дивизия штабында беләләр һәм аеруча җаваплы заданиеләрне разведчик Сәләхиев группасына тапшыралар иде. Тормыштан бернинди иркәлек күрмәгән Гата, ниһаять, үзенең шашкын характерына туры килерлек мохит тапты. Бу — авыр заданиене үтәп чыгу шатлыгын тою, утны-суны кичкән тәҗрибәле карт разведчиклар белән эш итү, дөньяның бөтен ваклыкларыннан югары булу ләззәте иде. Бу — окоп хакыйкате дигән бөек, галибанә бер хис, изге хис иде.

...Теге яшь курсант вакытында, «чәчәк аткан» винтовкасын тотып

полковник каршында дәшмичә торганда, карт офицер аңа болай дигән иде:

— Минә нәрсә, туганкай: «гаепле, төзәлермен» дип әйтергә өйрәнергә кирәк. Шул сүз эченә барысы да сыя. Бу сүз минә нәрсә дигән сүз: мин сезгә караганда яшь, тәҗрибәсез — сез тәҗрибәле, өлкән; сезнең дәрәҗәгез зур, минеке кечкенә; мин сезнең ихтыярыгызга буйсынырга мәҗбүр, ә сез минем ихтыярым белән бу очракта исәпләшми аласыз; ниһаять, мине гафу итү-итмәү дә сезнең кулда...

...Гата башын югары күтәрде. Шәмсетдиновка туры карады. Солдат гадәтен эшкә җикте.

— Мин гаепле, төзәлермен...

Кешеләр җинел сулап куйдылар. Гата — кызганыч иде. Һай, бу тормышның адәм баласы өстенә җибәргән сынаулары! Гата кечкенә вакытта әнисе мичкә якканда мич алдында төрле фокуслар эшләргә ярата иде. Ала бер өлге пыяла — сала шуны күмер өстенә. Пыяла бөгелә-сыгыла эри. Аннан шуны кыскыч белән ала да баскычка алып чыгып кар өеменә тыга. Пыяла черт-черт килеп чәрдәкләнә. Аннан тагын эретә. Әйтерсең бу дөньяда Гата — пыяла кисәге, ә кемдер мич каршында утырып Гата белән уйный.

Педсовет соң гына бетте.

Заһир ат җигеп йөргән арада Шәмсетдинов директор кабинетына кереп юк булды, бераздан кызарып кына килеп чыкты.

Мәктәп ишек алдыннан ат чанасы чыгып барганын күргәч, барысы да иркенләп киттеләр. Төркем-төркем булып урамга таралыштылар. Өстән таулар төшкәндәй булды. Хәзер яшәргә мөмкин. Бу уку елында башкача килеп йөри алмыйлар инде алар.

Баксаң — яз башланган икән...

Яз бер көн эчендә, ихтимал, бер сәгать эчендә килә. Моны бөтен кеше дә аңлый алмый. Ләкин моны бөтен кеше дә сизә. Менә әле авыл кар дөньясына чумган, әле көн дә салкынча, ләкин житкән инде ул яз, житкән.

Яңа бистәнең үзәк урамыннан инде түбәнгә таба гөрләвекләр агадыр, шәһәр егетләре инде кепка кигәннәрдер, Яңа бистәнең ак фетрлы егетләре инде сыр-сыр итеп җыерып хром итекләр киеп куйганнардыр. Ул дөнья да әллә кайда, томан артында калды хәзер. Күңел бер үзгәрсә, бер чара юк икән. Узган төн Нәркис йокылы-уяулы саташып ятты. Юк, төш күреп түгел, әллә нинди томанлы хыялны чынбарлык белән бутады. Имеш, менә, мәсәлән, шулай булса: Нәркис шушы авылга кияүгә чыга ди. Ха-ха! Кызык! Нәркис авылга кияүгә чыккан! Бөтен Яңа бистә моңа ышанмас иде. Әйтик, кемгә чыккан? Рушадкамы? Ул бик астыртын егет. Аның нәрсә уйлаганын белмәссең. Гата? Дөрес булса, Германиядә каләше калган ди. Заһир? Ха-ха! Мәктәп завхозына кияүгә! Университет тәмамлап... Бу уйларны Нәркис башыннан куды.

— Акбалык булдымы авыл, Заһир булдымы егет,— диде дә йомшак юрганы астыннан нәфис, озын аякларын чыгарып иркәләнеп киерелде. Торыр вакыт җиткәнче шулай ятты. Ә менә кич белән күңеле әллә нәрсәгә ашкына башлады. Яз исе канны кузгатты, йөрәк тибешен ритмыннан чыгарды. Ләкин Нәркис моның сәбәбен белмәде.

Бу көн — елына бер генә була.

Хәер, елның бер көне дә икенче бер көненә охшамый. Моны акыл сизмәсә дә, йөрәк сизә. Ә Нәркиснең йөрәге бик сизгер аның. Каядыр күтәреләсе, очасы, океаннар, таулар аша үтеп бөтен планета өчен кирәкле изге бер эш эшлисе килә. Очарга, очарга да, Акбалык мәктәбе турысыннан узганда күктән бер кычкырырга иде.

Яз килә...

Ниләр, нинди шатлыклар, нинди кайгылар алып килә икән ул?

Шатлыклар гына булсын иде...

Язгы каникулга чыгарга бер-ике көн кала мәктәптә тыныч тормышны кузгатып-селкетеп алырлык тагын берничә хәл булды.

Көтмәгәндә генә Рушадка алтынчы класс белән җитәкчелек итүне тапшырдылар. Хушият карт, күрәсең, эшнең барып чыкмаячагын аңлаган. Ләкин директорның бу карарга килүенә бик җитди бер вакыйга сәбәп булды.

Ул көнне алтынчы класста пионер сборы үткәреләсе иде. Пионер вожатые Нәсимә, балаларны тезеп, быргы кычкырттырып, барабан суктырып ду китереп коридорда йөртте. Нәсимә — яшь, сылу кыз, аны Закиров та, Әскәрев тә тыңлый. Закиров — быргы кычкыртырга бик оста инде. Аннан да матур итеп кычкыртучы бөтен мәктәбендә юк. Шуңа күрә ул сборга берәр атна кала юньләләнеп китә, адым саен:

— Апа, сбор кайчан була? — дип сорап йөдәтә.

Бүген исә Закиров аеруча дәртләнеп йөргән иде. Сбор башланыр алдыннан Закиров әле тегесен, әле монысын алырга укытучылар бүлмәсенә кереп йөрде. Быргы да, барабан да, венский гармун да шунда иде. Закировка сборның башка өлешеннән бигрәк шушы ыгы-зыгысы ошый иде — шуңа күрә ул йөгерде дә йөгерде...

Сбор башланган гына иде...

Бөтен дөнья шахмат чемпионатына багышланган икән.

Алтынчыда җиде-сигез малай шахмат уйный беләләр, һәм унынчы класстагы мәктәп чемпионнары Решевский — Ботвинник партиясен уйнап күрсәтәселәр икән. Тып-тын сеанс бара иде. Кызарынып-бүртенеп Хушият карт килеп керде. Нәсимәне чакырып алды да кызу-кызу нәрсәдер сөйләште ләр. Нәсимә дә кызарды. Беравык тынсыз торды. Өлкән класс егетләре сөйли-сөйли шахмат уйнадылар...

Сбор беткәч, егетләр чыгып киттеләр. Нәсимә барысын да стройга тезде дә тотлыгып кына болай диде:

— Балалар, без сборга хәзерләнгән арада Хушият абыегызның пальто кесәсеннән утыз сум акчасы югалган. Кем алган, хәзер үк дөресен әйтегез...

Строй тетрәп китте. Барысы да бер-беренә караштылар.

— Укытучылар бүлмәсенә кем кереп йөрде?

Тынлык. Закиров түбән карады. Битенә ак таплар чыкты. Нәсимә моны күрде.

— Я, тиз булыгыз, кем керде?

Тынлык.

— Алайса, менә болай эшлибез: кем дә кем бүген дәрес беткәч укытучылар бүлмәсенә бөтенләй аяк басмады, ике адым алга...

Утыз бер бала алга атлады. Артта берүзе Закиров басып калды. Яшь кенә булуына карамастан, нинди оста психолог бу Нәсимә! Ничек ансат тотты бит каракны. Ул горурланып Хушияткә карап куйды.

Быргысыз, барабансыз гына сбор йомгакланды. Закировны укытучылар бүлмәсенә алып керделәр. Башта Нәсимә кызды:

— Ни битең белән пионер исеменә тап төшерәсең син, Закиров? Оят бит, оят! Әгәр Зоя Космодемьянская исән булса иде, сиңа нәрсә дип әйтер иде? Әгәр Александр Матросов синең шушы эшеңне белсә, нишләр иде? Ә Павлик Морозов?

Нәсимә гарьлегеннән елый ук башлады. Бу җинаятьтә ул да гаепле бит. Тәрбия эшенең начар куелуыннан бит бу хәл!

Закиров башын түбән игән иде, бер сүз дә дәшмәде. Хушият Нәсимәгә ярдәмгә килде:

— Соң син, Закиров,— диде ул,— үземнән юньләп сораган булсаң, мин бирмәс идеммени сиңа! Юньсезнең дә юньсезе икәнсең син. Үз табагына үзе... малай булып чыктың син. Мин бит, әдәм көлкесе, үз

өстемдәге жилеткага хәтле салып бирдем сиңа узган көз. Син шуның да кадерен белмәдең, шуның да. Я, әйт, кайда утыз сум?

Закировны тентеделәр. Чалбар кесәсеннән бер гайка белән винтовка гильзасы чыкты. Икенче кесәсе тишек иде. Телогрейка кесәсеннән тәмәке вагы чыкты. Моңа артык игътибар бирмәделәр. Закировның күлмәгеннән, чалбарыннан бер ис килә иде — сигез балалы семьяда үскән Нәсимә моны аңлады: димәк, Закиров төнлә юешләнә...

Закиров дәшмәде. Көн кичкә авышып килә иде, укытучылар бүлмәсенә дәфтәр тикшерергә, план төзергә җыела башладылар, Закировны шул көе кайтарып җибәрделәр.

— Әгәр үзең белеп иртән сәгать сигезгә китереп җиткермәсәң, каты режимлы мәктәпкә җибәртәбез сине,— дип Хушият карт янап калды.

Кайтырга җыенган Хушият карт толстовкасының күкрәк кесәсеннән күзлек савыты белән иартеп кызыл утызлыкны тартып чыгарды.

Нәсимә үкереп елап чыгып йөгерде.

Закиров иртәгесен дәрескә килмәде. Ул арада директор класс житәкчелеген Рушадка тапшырды. Рушад иң беренче көнне үк Закировның әбисе янына барды.

— Китте,— диде тешсез карчык,— китте...— Карчык моны шатланып әйтә идеме, әллә кайгырыпмы, Рушад аңлый алмады.— Поездга дип китте. Фызуга барам диде. Ун тәңкә акча бирдем, ярты ипи бирдем. Китте.

Рушад ишек янындагы чөйдә Закировның тузган, таушалган сумкасын күрде. Ярым ачык сумкадан «Урта гасырлар тарихы»ның кимерелгән почмагы чыгып тора иде — Рушадның күңеле тулды, бугазына авыр төен утырды. Карчык белән исәнләшергә дә онытып чыгып китте. Абзар түбәләре күрәлгән, анда юкагач таякта зырылдап бәләкәй җил тегермәне әйләнеп утыра иде...

Бу мәсьәлә артык шау-шу куптармады, шул көннәрдә генә мәктәпкә Мәгариф министрлыгыннан вәгъдә ителгән посылка килде. Дәү генә дүрт ящикта дыңгычлап тутырылган физика приборлары иде.

Гата ашаудан калды. Төнге сәгать берләрдә генә мәктәптән кайта торган булды. Хәтта Рушад белән дә сөйләшмәскә әйләнде. Физика шкафлары куелган класста унынчы класс укучылары белән көн итты, төн итты. Линзалар, амперметр, омметрлар, компаслар, магнит дугалары, Стефенсон паровозы макетлары, үткәргечләр, лампалар, коры элементлар... Гата хисләр ташкынына чыдый алмыйча укучылар барында тәмәке тартты, бер кичне папиросы беткәч акча биреп, хәтта бер егетне магазинга папироска йөгертте. Тик ул егет директорның унынчыдагы улы Ренат булып чыгып кына эш тирәнгә китә язды. Гөлчирә, ничектер, директорның сүзен тыңлады — тавыш чыгармады.

Берлиннан хат килгәч кенә Гата җиргә төште. Эльза май аенда кавышуны өмет итеп яши — Гатадан вызов килүен күптән хәбәр иткәннәр икән.

Гатаны бер яктан эш басты.

— Физика буенча ВУЗга керергә бер уңбиш кешене әзерлим,— дип котчыккыч эш башлады.

Икенче яктан сагыш басты.

Эльза, Эльза... Их, ул да монда булса. Сөйгәнең бит ул, хатының бит ул. Хатыныннан да кадерле кеме бар Гатаның бу дөньяда? Гатаның берние дә юк, йорты да, җире дә, ә менә хатыны бар. Ул — аныкы. Ир кешенең иң зур байлыгы нәрсә? Акчамы? Властьмы? Дәрәҗәме? Йорт-җирме? Юк, мең тапкыр юк! Иң зур байлык — инсафлы хатын. Эльза — дөньядагы иң зур байлык.

Язгы каникулны нинди акыллы адәм уйлап чыгарды икән? Моны нәкъ вакытында бирәләр. Укытучыларның нервлары инде тәмам актык чигенә җиткән көннәр була, инде бер-берсенең сүзенә дөрт итеп кабы-

нырга гына торган көннәр була — арылган, туелган. Укучылардан түгел — бер-береңнән туелган була. Ни хикмәттер, укытучы бервакытта да укучыдан туймый. Үзе сүгенгән була:

— Бер күрмәскә әллә ни бирер идем шуны,— дип берәр бәләкәй хулиганны каргый. Ә шул тәртипсез малай урамда очрап баш киемен салып исәнләшеп калса — укытучының күңелендә энә очы кадәр дә ачу калмый. Укытучы — дөньяның аерым категориядәге бер кешесе. Аның шатлыгы да, кайгысы да кешенеке төсле түгел. Бер малайның Хаммурапи патша законнарын белмичә икеле алганы өчен укытучы бер төн йокламаска мөмкин. Ул аны шул көнне дәрестән алып кала, арган көе, ач көе шул бала белән утыра, мәктәптән кайтышлый аның ата-анасы янына керә. Шул көнне укытучы үз эшен карый алмый, төне буе башы авырта. Бер-ике елдан карасаң — теге малай колхозның ат көтүендә йөри, менә дигән мактаулы колхозчы, җыелыш саен аны мактыйлар, бүләкләр бирәләр. Нигә ана синең Хаммурапиең, нигә ана синең Пифагорың! Әле алай гына да түгел, кырдан барганда сиңа әллә каян, атка атланган килеш сәлам биреп кала.

— Исәнмесе-е-е-з! — дип кычкыра.

Күңелендә ник бер бөртек кинә булсын! Шул вакытта укытучының да күңеленә әллә нинди ташкын белән шатлык хисләре бәреп керә, укытучы да бер рәхәтләнеп иркен сулыш ала...

Ә чирек буе укытып бер укытучы белән икенче бер укытучы арасында мөнәсәбәт тәмам киеренкеләнеп бетә. Алгебра укытучысы грамматика укытучысы җитәкли торган класста өлгерешне түбән биргән. Ә биология укытучысы чит тел укытучысы җитәкли торган класста чиреккә бер икеле чыгарырга җыена... Менә китә сүз, менә китә бәхәс. Әгәр укучылар моны белсәләр иде! Кемдер директор малаена дүртле генә чыгарып ята — директор хатыны коридорда, һәр почмакта инде чышын-пышын бу хәл турында сүз алып бара. Моны күргән теге «кемдер»нең дә ачуы килә, әллә нәрсәләр эшләп ташлыйсы килә — тик директор малаеның монда гаебе юк...

Әнә шул очсыз-кырыйсыз күңел җәрәхәтләре белән тәмам эштән чыккач кына, бер көнне Шәмсетдинов имзасы белән телефонограмма килеп төште. Иртәгәдән язгы каникул башлана!

Шәмсетдинов монда да үзенең кырыслыгына урын тапкан. «Кисәтеп әйтәм: каникул укучылар өчен генә, укытучылар һәр көнне мәктәпкә килергә тиешләр». Я инде, шунысын әйтмәсә нәрсә булган! Укытучы ул әйтмәсә дә килә инде мәктәпкә. Шунда килмичә Гата, Рушад кая килсеннәр? Бәлкыйсның мәктәптән тыш ни шатлыгы бар? Ә Нәркис нәрсә дип бәләкәй тәрәзәле иске йортта карт белән карчыкның көне буе чәй эчкәннәрен карап утырсын!

Каникулда мәктәп гөрләп торды.

Мәктәптә көне буе физиклар группасы эшләде. Хәкимҗан шахмат турниры ачып җибәрде.

Алтынчы класста Рушад сигнальщиклар группасы оештырды. Классның ике башына басалар да кечкенә кул флаглары белән дингез алфавиты буенча сөйләшәләр. Бу флагларны Нәркис тегеп бирде — Рушадка боларны тотып җилфердәтү аеруча рәхәт тоела иде. Алтынчы малайлары хәзер флот турында гына сөйләшәләр, Рушадның һәрбер сүзен йотлыгып тыңлыйлар иде. Инде компа́с, Гибра́лтар, Мурма́нск дип кенә сөйләшәләр, сөйләшкәндә мөмкин кадәр бу сүзләрне кыстырырлык җай эзлиләр. Алтынчы классның ишеге төбендә җиденче, сигезенче класс малайлары күренгәлиләр, кызыгып йөриләр.

Ул арада коридорга бер стенд чыгарып элделәр, андагы «Корабльләрне танып бел» дигән баш астында хикмәтле рәсемнәрне күргәч, бөтен мәктәп малайлары дөньяларын оныттылар. Крейсер, линкор, эсминец

була икән. Тральщик, охотник, монитор, сакчы катер, торпеда катеры була икән... Их, бөтен дөньясын онытып кит идең флотка, йөр идең шул корабларда диңгездә буразналар сызып! Ләкин флотка бик тәртипле, бик белемле кешеләрне генә алалар икән. Һич тә уч төбе, күкрәге киң булган өчен генә сайламыйлар икән. Флотта хезмәт итү — дөньядагы барлык башка төр эшләрдән иң абруйлы, иң дәрәҗәле эш икән...

Мәктәпнең икенче бер башында бөтен дөньяның барышы физика фәненә барып тәрәлгән иде — Гата үзе белгән бөек физикларның биографияләреннән әллә нәрсәләр сөйләп бетерде, уныньчы класслар көче белән физиклар турында ул да стенд эшләде.

Мәктәпнең икенче катында шахмат турниры барды — Хәкимҗанның сөйләве буенча дөньяда шахмат уйный белмәгән кеше иң кызганыч кешеләрнең берсе икән. Флор, Эйве, Бронштейн, Решевский, Ботвинник дип бервакыт ансат кына сөйләшә, бәхәсләшә башладылар.

Мәктәп гөр килә.

Нәсимә, Гөлчирә тугызынчы майга концерт хәзерләделәр. Нәркис рус телендә бер инсценировка оештырып йөрде.

Нәрсәгә кирәк Шәмсетдиновның кырыс сүзе?

...Яз бөтенесен үзгәртте дә бетерде.

Яз мәшәкать-борчулар алып килде. Ул алып килгән борчулар укытучыларның барысына да тегеләйме-болаймы кагылды. Көннәр йөгерделәр, гомер бәрәкәтсезләнде. Нәркис, директордан рөхсәт сорап, ике-өч көнгә Казанга китте. Ул киткәч, әллә ничек мәктәп бушап калгандай булды. Нәрсәдер җитми...

Гата физика кабинетыннан арынмады. Бер көнне Рушад ары сугылып, бире сугылып йөрде дә кичке якта өенә кайтырга чыкты.

— Йозагымның рәтенә төшә алмыйм, ачып кына бирсәнә,— дип, аны мәктәп баскычында Мәсрүрә каршы алды. Мәсрүрәнең тора торган йорты — мәктәп ишек алдында. Егерме биш яшьлек тол хатын менә ике ел инде кайнаталарын ташлап шушында, мәктәп квартирында яши. Шунда идән юарга су җылыталар, техничкалар шунда кереп ял итеп утыралар, иртән караңгыда ягарга килгәч, иң беренче шунда керәләр. Мәсрүрәнең бу йортта үз почмагы бар, чыбылдык артындагы бу почмакта аның бөтен тормышы, бөтен бәхете, бөтен бәхетсезлеге. Ул почмакта келт-келт итеп гади, герле сәгать йөри, ул сәгатьнең геренә өстәмә авырлык — иске кайчы асылган. Сәгать Мәсрүрәнең ялгыз тормышының күңелсез минутларын саный, гомер кимерешә. Сәгать өстендә зурайтылган бер рәсем бар, агач рам эченнән сабый баладай самими карашлы бер егетнең зур пилотка баскан йөзе күренә. Бусы — Мәсрүрәнең ике ай торып калган ире — кырык өченче елның җәендә хәбәрсез югалган солдатның сугыштан җибәргән бердәнбер рәсеме. Ул почмакта тимерле яшел сандык, аның өстендә күпертеп утырткан ястык. Зур-зур чәчәкле ястык.

Йозак тиз ачылды...

— Өемне дә карап чык инде,— дип, Мәсрүрә Рушадны өенә чакырды.

Батып бара торган кояшның саргылт нурлары як тәрәзәдән өйгә үтеп кергән дә мич алдындагы җиз самоварда, бакыр комганда чагылган. Өй эчендә әллә нинди үзәк өзгеч тынлык, саргылт-кызыл нур, әллә нинди ятимлек...

Мәсрүрә җәһәт-җәһәт кенә өстен чишенеп, кыска җиңле күлмәктән генә калды.

— Әйдә, утыр, иркенләп, өйдә көтеп торырга хатының юк. Чишенеп утырсаң да була. Безнең ише тол хатынның өенә керергә берәүләр курка — син әле йөрәкле икәнсең...

Рушад аңламамышка салышты.

— Ә нәрсәдән куркалар?

— Нәрсәдән булсын? Ирсез хатын кыңгыраулы була ул. Бигрәк тә ирле хатыннар шикләнәләр. Ирләрен тартып алырлар дип. Башларына япсыннар, башларына. Берсенең дә ире кирәк түгел, берсенең дә...

Мәсрүрә көзге янына килеп чәчләрен рәтләде, калын ике толымын сыпыргалап артка ташлады да үзе дың-дың басып чыбылдык артына керә-чыга йөрде.

— Менә кергән көе самовар борынын да карап чык инде, зинһар өчен.— Ул Рушадка ниндидер наз белән карады. Мондый караш бары тик яшь хатыннарда гына була ала. Кызларда булса — андый карашны чытлыклану дип атыйлар, яки бик тә гадиләштереп, мутланып карау диләр, ә бу — назлы караш...

Рушад хезмәт иткән эсминец минага эләккәндә аларның берничә иптәше диңгез төбенә китте. Рушад аларны хәтерли: яшь-яшь егетләр иде. Өйләнгән булсалар — менә шушындый хатыннар тол калды дигән сүз. Күпме ата, күпме ана баласыз калды дигән сүз. Ә сугышта андый корбаннар күпме! Менә син исән кайттың, тыныч кына эшкә урнаштың, менә син хәзер синең өчен үлеп калган берәүнең хатыны белән сөйләшеп утырасың. Әнә ул хатын назлы итеп сиңа карый, әнә ул башланган бер ярты аракы китереп куйды, ике стакан китерде, суган, тоз куйды, ипи турады. Бу хатынның синең белән бер сөйләшеп утырасы килә, эчен бушатасы килә — ә чыбылдык артындагы рамда аның чандыр йөзле, дәү пилоткалы ире ярыктан сиңа карый.

Мәсрүрә башлап үзе күтәреп авыз итте.

Башын түбән иде. Тагын авыз итте.

— Их, кеше хатыннары шикелле декрет отпускаларына чыгыен да акчасын алырга мәктәпкә бер килеп китиең...

Рушадка утырган саен авыр була башлады. Караңгы төште, чыбылдык ярыгыннан теге дәү пилоткалы егет инде күренми иде. Мәсрүрә ут кабызу турында уйлап та карамады.

— Я, миңа кайтыр вакыт җиткәндер,— дип әйтергә Рушад үзен-үзе мәҗбүр итте.— Рәхмәт сыйга-хөрмәткә. Төзәтәсе әйберләрең булганда тартынып торма, Гата — физик, мин корабльдә хезмәт иткән кеше. Безнең кулдан ни килми дисең син.

Мәсрүрә Рушадның пальтосын киертеште. Үзе төймәләште. Шул вакыт кинәт кенә башын Рушадның күкрәгенә куйды да пышылдап нәрсәдер әйтте. Егет каушап калды.

— Әллә бераз утырасыңмы? Нигә куып кына китмисең? Өеңдә кем көтә соң сине, юләр баш?..— дип, Мәсрүрә кайнар беләкләре белән Рушадның муенын, битен чорнады. Бер секундка Рушад югалып калды. Мәсрүрәнең чәчләреннән арзанлы одеколон исе килә иде, ул ис Рушадны исертеп җибәрде. Егет күзләрен чытырдатып йомды. Шул вакыт почмактан аңа теге пилоткалы солдат карагандай булды. Рушад тешләрен кысып Мәсрүрәне үзенең гәүдәсеннән аерды да ишеккә таба атлаганда гына үпмәкче булды. Әйдә, тол хатынның күңеле булсын!

— Юк, кирәк түгел,— диде Мәсрүрә, яшенә тыгылып,— минем күңелемне кузгатма. Кузгатма... каласы булмагач. Ярый, бар, хәерле юл. Кайчан керсәң дә сиңа ишегем ачык булыр,— дип, тагын әллә ниләр пышылдады.

*Дәвамы бар*

## Гәрәй Рәхим

### Гомер челтәре

Мин еллардан гомер дигән
Бер челтәр үреп барам.
Матур һәм ямьсез үрелгән
Төшләрен күреп барам.

Бер җире ефәктән үргән —
Елкылдап янып тора.
Бер җире ертык чыптадай,
Җанга шом салып тора.

Бер җирендә иң бәхетле
Көннәремнең рәсеме.
Бер җирендә шул бәхетнең
Кәфене һәм ясине.

Челтәремнең бер ягыннан
Шатлык кояшы калка.
Бер ягында кайгылардан
Авырайган ай бата.

Мин еллардан әнә шундый
Бер челтәр үреп барам.
Бу төше ямьсез димәгез —
Үзем дә күреп барам.
Тик матур җире дә бар, дип
Шатланып көлеп барам.

### Йола

Ерак юлдан кайтсаң әгәр бер көнне
Озак торып, күз күрмәгән җир иңләп –
Вокзалларга синең якын дусларың
Кочак тулы чәчәк тәяп килерләр.

Туең булса, балаң туса, өй котлап,
Төп йортыңа төшсә яшь-яшь киленнәр —
Нинди шатлык, синең якын дусларың
Кочак тулы чәчәк тәяп килерләр.

Көннән бер көн синең гомер очланыр.
(Мәңгелеккә бирелми ич гомерләр.)
Шуңа тагын синең өйгә дусларың
Кочак тулы чәчәк тәяп килерләр.

●

Бу дөньяның булды төрле чаклары —
Җиңел чак та, уртача да, ямьсез дә.
Тик уйлыйк без, яшәдек дип дөньяда
Матур гына, күркәм генә, төз генә.

Бик күпләрдән кала килә ич дөнья —
Бу канунны бозалмабыз без генә.
Калсын әле, калсын бездән бу дөнья
Матур гына, күркәм генә, төз генә.

Йортлар төзик, иген чәчик, юл салыйк,
Артсын байлык, артсын муллык йөз меңгә.
Яшәсеннәр киләчәктә кешеләр
Матур гына, күркәм генә, төз генә.

Шулай уйлап яшәгәннәр, яшәрләр,
Тотындык дип бик нык итеп төзегәнгә.
Чөнки шулай дисәң җирдә яшәлә
Матур гына, күркәм генә, төз генә.

●

Сиңа мине сөяр өчен
Бик күп нәрсәләр кирәк:
Җирдә яз булу кирәк,
Көн аяз булу кирәк,
Җанда наз булу кирәк,
Хәвеф аз булу кирәк.
Күңелләрдә таң саен
Сандугачлар сайрасын,
Гашыйклар чәчәкләрнең
Иң матурын сайласын.
Дөньяга шатлык тулсын,
Тойгылар самим булсын,
Кешеләр һәр мизгелдә
Олы изгелек кылсын.
Миңа сине сөяргә дә
Бик күп нәрсәләр кирәк:
Язгы аяз көннәрдә
Күктә яшен уйнасын,
Иң-иң тыныч төннәрдә
Җирдә давыл дуласын.
Җиһанның бар нәфрәте
Җыелсын да бер төшкә —
Ут-очкыннар чәчрәтеп
Суксын иң кара көчкә.
Иң хәтәр минутларда
Җанда көч ташып торсын,
Дөнья тын торганда да
Йөрәкләр шашып торсын.
Безгә бер-беребезне
Сөяргә күп шарт кирәк.
Җирдә тагын бер бөек
Мәхәббәт туа, димәк!

## Әхмәт Гадел

### Ил иминлеге

Малай чагым —
Төнге дала,
Якты учак,
Җил-атлар...
Егет чагым —
Яшел кием,
Ерак юллар,
Солдатлар...
Ә бүген мин
Бер ир-егет,
Йорт башымын һәм ата.
Җиңел түгел,
җилкәләрдә
Ил иминлеге ята.

●

Өч яшемнән сәяхәткә чыктым.
Карлы юллар,
серле күперләр...
Өч яшемдә беренче кат белдем,—
Сыкрап сына икән күңелләр...
Нарасыйдан юллар улы булдым.
Аерылуны белдем өч яшьтән.
Шул вакыттан бирле ерак еллар,
Ерак юллар белән серләшәм.

### Ачылу

Аерылып китсәм еракларга
Тыныч үткәралмыйм төнемне.
Имин микән минем Казан диеп,
Борчып торам һаман күңлемне.
Еракларга китсәм, еракларда
Йокы керми күзгә таң ата.
Күрмәгәнне ачык күрә башлыйм,
Яратканны ныграк яратам.
Йөрәккәем янар таудай яна,
Сагышымнан чабам вокзалга.
Моңсу булып атар кебек таңнар
Мин булмасам әгәр Казанда.

**Марсель Зарипов**

# ПАНИ СИРЕНА

хикәя

Сәриянең Польшага баруы һич көтелмәгәндә булды.

Сугыштан соң ул, беркая да чыкмыйча диярлек, Агыйдел буендагы бер район үзәгендә яшәде, шунда ук редакциядә җаваплы секретарь булып эшләде. Бар вакытын бетмәс-төкәнмәс өй мәшәкатьләренә, газетаны кайгыртуга бирде. Семья тормышыннан уңмады. Ире бик тә вакчыл, үтә чыккан көнче, кире беткән бер бәндә булып чыкты. Хатыны эш белән бер колхозга барып кайтса, атналар буе шуңа бәйләнеп бәгыренә үтә иде. Алар өч еллап тордылар да аерылыштылар. Сәрия улын бер ялгызы үстерде. Ул сабыр табигатьле, оялчан, тырыш малае белән горурлана иде. Туганнары, таныш-белешләре: бу тикле әнисенә охшар икән,— диләр иде аның малае турында. Чыннан да ул коеп куйган әнисе иде. Сәриянеке төсле кысыграк чем-кара күзле. Кашларына тикле йөнтәс калын тасма булып туптуры сузылып киткән. Ул быел урта мәктәпне тәмамлады һәм, конкурстан үтеп, Мәскәүдәге инженерлык-физика институтына керде. Сәрия беренче тапкыр өендә япа-ялгыз утырып калды.

Аңа тирә-як бушап калгандай тоелды, үз-үзенә урын таба алмый аптырап бетте ул. Менә шулай изаланып йөргәндә аның күзенә ниндидер журналда басылган халыкара викторина сораулары чалынды. Викторина «Сез Польша Халык Республикасын беләсезме?» дигән темага иде. Сәрия, үзе дә сизмәстән шуның белән мавыгып китте.

Сораулар шактый катлаулы иде. Ләкин Сәрия өчен Польша болай ишетеп кенә, газета-журналлардан укып кына белгән ил түгел. Сугыш вакытында ул Варшаваны азат итүдә катнашкан, ничәмә-ничә тапкыр Познаньга, Данцигка, Гданьскига очкан, «Көмеш тәре» орденына лаек булган иде.

Вакыты элеккечә үк кысан булса да, Сәрия берничә ял көнен, кичләрен викторинага багышлады, китаплар укып, сорауларга мөмкин кадәр тулырак, төплерәк җавап бирергә тырышты. Тырышканы бушка китмәде, конкурста җиңеп, ике атналык турист путевкасы отты.

Сәяхәт ул кадәрле кичерешләргә сәбәпче булыр дип Сәрия башына да китермәгән иде. Башта ул сугыш вакытында үзе булган җирләрне

яңадан күрәчәгенә шатланды, ләкин аның шатлыгына ниндидер уңайсызлану, үкенү хисе килеп кушылды: менә бит ничек килеп чыккан, ул ил турында, аның борынгы һәм бүгенге культурасы турында, экономикасы, шәһәрләре турында дөнья кадәр нәрсә белә, ә менә полкташлары, бер эскадрильяда сугышкан иптәшләре, аларның бүгенге язмышы турында берни дә әйтә алмый. Хат язарга дип, дусларының хәлләрен сораштырып торырга дип, үзе белән бер экипажда очкан Юзеф исемле үтә дә оялчан поляк егетенең адресын сорап алырга дип күпме җыенып йөрде, кулы җитмәде. «Бүген язам».— дип һаман кичектерә килде, ә иртәгесен яңа бер эше табыла торды. Шулай итеп — әйтергә генә ансат! — чирек гасыр үткән дә киткән. Кайда икән хәзер ул Юзеф? Бәлки әле дә булса оча торгандыр, бәлки пенсиягә чыккандыр, ә бәлки... Ни кадәр вакыт үткән бит...

Викторинаны поляк журналистлары үткәргән иде. Туристларны да алар каршы алып, алар отельгә урнаштырды. Кунакларны беренче көнне үк матбугат үзәгенә чакырдылар һәм аларның һәрберсе алдына: «Сезнең иң зур теләгегез нинди?» — дигән сорау куйдылар.

Бәлки бу сорау әдәп саклау, кунакларның күңелен күрү өчен генә бирелгән булгандыр. Әмма Сәрия эшнең мондый нечкәлекләренә кереп, алны-артны карап торырлык хәлдә түгел иде. Шуна күрә сорау бирелү белән ул: «Юзефны эзләп табу!» — дип әйтеп салды һәм шунда ук, гаебе бар кеше сыман, бу кешенең исеменнән, фамилиясеннән, үзе белән бер самолетта очкан булуыннан һәм хәзер аңа илледән өстен булырга тиешлегеннән тыш берни әйтә алмавын белдерде.

Чыннан да тагын нәрсә дип әйтә алсын соң ул? Юзефның куллары бик тә йомшак һәм көчле иде, дипме? Ул самолет кабинасына көч-хәл белән сыя иде, дипме? Юзеф миңа гел «прошу, пани» дип эндәшә иде, исемемне әйтә алмыйча гаҗиз була иде, шуңа күрә мине үзенчә «пани Сирена» дип йөртә башлады, дипме?.. Болар белән генә кешене эзләп табып була димени? Күпме ел үткән бит!

Бу сорау кунакчыл хуҗаларда бер мәлгә каушау тудырды, әмма алар моны сиздермәскә тырыштылар һәм бик ышанычлы итеп: бөтен илне айкап чыксак чыгарбыз, иллә мәгәр пилот Юзефны — исән булса — табып китерербез, дип вәгъдә иттеләр.

Сәрия ул арада Варшава белән танышa торырга риза булды. Туристлар бүген «Фаустны» тыңларга тиеш, иртәгә — опереттага барачаклар, аннары аларны Силезиягә, Поронинога, Закопанега алып барачаклар. Алар Варшавага кире әйләнеп кайтканчы бары да ачыкланган булыр.

Сәрия — үзе дә журналист кеше, өстәвенә, журналистның кеме — «районкада» эшли торганы. Шуңа күрә ул газета кешеләренең вәгъдәле булуларына ышана иде. Ләкин барыбер көтәргә кирәк. Аны балаларча түземсезлек биләп алды, һәм ул шәһәрнең элек алар эскадрильясы торган иске районына барырга булды. Ни өчен? Аэродромның яшел кырын, андагы самолетларны тагын бер кат күрер өченме? Ул бу теләгенең балаларча беркатлы икәнен дә, чирек гасыр гомер үткән булуын да, шуңа күрә каләмдәш дусларын сабыр гына көтүдән башка чара калмаганлыгын да аңлый иде. Әмма бу минутта аның бөтен барлыгын биләп алган ниндидер күтәренкелек тойгысы гакылның бу тавышына колак салмады, һәм Сәрия үз группасыннан аерылып, аэродромга китте.

Ләкин хәзер ул урында аэродромның эзе дә калмаган. Кайчандыр янәшә тезелешеп утырган тәбәнәк йортларны сүткәннәр, алар урынына күп катлы биналар салганнар, очыш вакытында зарарланган самолетлар төшә торган яшел кырны ипподром иткәннәр. Гади эш көне бул-

ганга, анда бүген ат чабышлары юк иде. Шуңа да карамастан, тирә-юнь гөр килеп тора. Бала-чага шаярыша, ни турындадыр кызып бәхәсләшә-бәхәсләшә, яшүсмерләр уза. Сүзләрен аермачык аңламаса да, Сәрия бәхәснең ат турында икәнен чамалый иде.

Менә бит ул ничек килеп чыга. Ул — Польша өчен бөтенләй чит кеше, шунда яшәүче кешеләр бәхете өчен сугышып йөрде, орденга лаек булды, ә менә алар, шул кешеләр, Сәриянең кем икәнен дә белмичә, моны башларына да китермичә, алар янында үтеп йөриләр, көлешәләр, сөйләшәләр, бәхәсләшәләр. Сәриягә кинәт ничектер рәхәт булып китте.

Ул менә хәзер кемнең дә булса шул самолетлар турында, күптәнге аэродром турында бер генә сүз белән искә төшерүен теләде. Аннары бу теләгеннән үзе үк көлде: әй, җүләр, күпме вакыт үткән ләбаса, еллар бармак арасыннан ага торган ком кебек үтеп киткән, ә син шуларны кире кайтармакчы!

Ул ипподромга үтте, буш эскәмияләр янында озак кына басып торды. Үзләренең кайчандыр менә шул кыр өстеннән заданиегә очып китүләрен, арып-талып кире кайтуларын күз алдына китерде.

Алар Польша гаскәре Генеральный штабының элемтә машинасы ролен үтәргә яшел төстәге елгыр кукурузникта очалар иде. Очканнан соң Сәриянең күңеле болгана иде. Шуңа күрә, җиргә төшкәч, ул үзенең штурман кабинасында бер кавым хәл алып утыра, ә Юзеф ул арада кабинадан чыгарга өлгергән була һәм машинаны канатыннан тотып селкетә-селкетә: «Прошу, пани Сирена! Без исән!» — дип кычкыра, һәм аның игътибарлы күзләре Сәриягә назлап карыйлар иде.

Сәрия һәрвакыт кабинадан үзе чыгарга һәм самолет канаты буйлап үзе төшәргә тырыша, ә зур гәүдәле, көчле Юзеф аны кулына күтәреп алырга хәзер булып, аста басып тора. Мондый игътибар Сәриягә ошый, күзне йомасы да сузылган көчле кулларга авасы килә аның, ләкин ул үзендә бу теләкне җиңәрлек, җитди булып, кырыс булып күренерлек көч таба: «Юк, мин үзем. Үзем!» — ди. Ул самолет канатыннан җитез генә җиргә сикерә, аякларын язар өчен бер-ике тапкыр чүгеп ала, ә Юзеф елмаюдан туктамыйча аңа карап тора. Ә нигә елмаймаска? Шөкер, менә тагын исән-сау кайттылар. Тиздән сугыш та бетәр.

Гомумән, бу яктан алар бәхетле булдылар. Юка дюраль белән генә тышланган, кабинада үзләре белән йөртә торган автоматларны исәпкә алмаганда, бернинди дә коралы булмаган кукурузник җирдән атып төшерергә дә, һавада юк итәргә дә бик уңай мишень бит ул. Ә менә аларныкына ул-бу булмады. Бер генә очракны искә алмаганда. Бер вакыт аларниндидер партизан отряды белән элемтә урнаштырырга бардылар. Ялгышып, немецларны үзебезнекеләр дип белеп, һич ни искәрмичә, алар янына төшә башладылар. Немецлар атмады, шатланып кул гына болгады. Тик берсе соңгы минутта түзмәде, автоматтан атып җибәрде. Пуля самолетка тиде, машина кинәт түбәнәя башлады.

Сәрия үз кабинасыннан Юзефның самолетны күтәрергә никадәр маташса да булдыра алмавын, машинаның һаман түбәнәя баруын күрде. Немецлар, аның төшүен көтеп булса кирәк, бүтән атмадылар, машина артыннан йөгерделәр. Сәрия шлемын яхшылап киде, ян ишектәге чехолдан автоматын алды, магазинын тикшереп карады һәм машинаның утырганда мәтәлеп китмәвен тели башлады. Самолет туктау белән ул кабинасыннан чыгып немецларны каршы алачак, шулай итеп, Юзефка да чыгарга мөмкинлек бирәчәк. Аннары алар урман эченә кереп китәчәкләр.

Юзеф самолетны туп-туры урман кырыена таба тотты һәм әйбәт кенә җиргә утыртты. Ләкин тәгәрәп бара торгач ул соңгы минутта гына

чокырга туры килде дә бер якка янтайды. Сәрия кабинадан, элек уйлаганча, беренче булып чыкты. Ә Юзеф, башын прибор тактасына куйган хәлдә, хәрәкәтсез утыра бирде, битеннән кан ага иде. Сәрия калпакны ачып, Юзефны кабинадан тартып чыгармакчы булды, ләкин әчтә аны нидер тотып тора иде. Бәлки Сәрия бөтен көченә тартса чыгара да алган булыр иде, ләкин ул Юзефның бер әр җирен авырттырудан куркып моны эшләмәде. Ул автоматын бөтенләй онытып, Юзефны җиңеннән тотып тартуын белде, ә тегесе аны куллары белән этәрә, үзе чыгарга азаплана иде. Сәрия Юзефның кычкырып җибәрергә, автоматынны тоткан хәлдә тик торасың, җүләр, дип аны тиргәргә теләгәнен сизде. Әмма Юзеф тиргисе урынга ягымлы ялвару белән аңа:

— Пани Сирена, атыгыз, ат,— дип пышылдады.— Урманга таба йөгерегез. Тизрәк...

Немецлар инде бөтенләй якынлашкан иде. Сакал-мыеклары кырылмаган, бите-башы юылмаган шыксыз солдатлар, мондый котелмәгән уңышка шатланып булса кирәк, нидер кычкыралар иде. Ә Сәрия аларга атасы урынга елый-елый Юзефны тарта. Кирәк бит сугыш бетте дигәндә генә шундый ахмак үлем!

Сугыш буена тере немецка атарга туры килмәде аңа. Башта ул төнге бомбардировщиклар эскадрильясында хезмәт итте. Самолетларын бәреп төшергәч, парашют белән сикереп, поляк партизаннары отрядына эләкте дә шуннан менә шушы ике канатлы кукурузникка күчеп утырды. Ул рухи хәлате буенча дошманны үтерергә әзер булса да, менә хәзер, бу үтерү мөмкин генә түгел, хәтта мөһим дә булган бер минутта, ничектер каушап калды, солдат, сугышчы башы белән нәни бер кызый төсле елый ук башлады.

Ләкин алар өчен бәхет капусының ачылган көне иде бу. Алар эзләп килгән партизаннар да шушы ук урманда булып чыктылар. Алар да җиргә төшкән самолет янына ашыкканнар икән, бик тә вакытлы килеп җиттеләр. Эш уңышлы тәгәлләнде. Тик Юзефның гына каш өстендә җөй сузылып калды...

...Өч көннән туристлар ил буйлап сәяхәткә чыгып киттеләр. Алар Польшаның индустрия үзәге Силезиядә, туристларның мәккәсе Татры тауларында, беренче бөтен дөнья сугышы алдыннан Ленин яшәгән Поронинода булдылар... Сәриягә сәяхәт ошады. Ул бар булган пленкасын төшереп бетерде, хәтта күбрәк алмавы өчен үзен-үзе битәрләп тә куйды: менә син, ачык авыз, журналист була торып, шуны да уйламаган. Редактор: «Буш блокнот белән кайтасы булма, ярты ай буе номер саен биреп барырлык материал булсын»,— дигән иде бит. Материал күп булачак — анысы сөендерде. Шулай да аның тизрәк Варшавага кайтасы килде. Юзеф ничек икән анда? Бәлки исәндер, табылгандыр? Кара син, күпме вакыт үткән, тормыш дигәнең артта калып бара, шулай да берни онытылмаган... Бу көннәрдә ул бүгенге тормышының бер өлеше булып әверелгән ерак хатирәләр белән яшәде. Ул хатирәләрдән күңел җилкенеп тә, ямансулап та куя иде. Их, Юзеф, Юзеф!.. Бирегә, Польшага килүнең төп сәбәпчесе дә син булдың бит.

Варшавага алар шимбә көн кайтып төштеләр. Туган илгә кайтып китәргә бер тәүлектән аз гына артык калган иде инде. Сәрия Юзефның табылачагына өметен өзә башлады. Ләкин шулчак аның номерына редакциядән йомышчы килеп, аңа телефон номеры язылган бер кәгазь кисәге тоттырды. Ә сүз белән:

— Сезнең пилотыгыз табылды. Кичен гостиницага үзе киләчәк,— диде дә китеп барды.

Сәрия кечне көч-хәл белән житкереп, вестибюльгә төште. Көн карангыланган, урамда, куышлы уйнагандай, реклама утлары сикерешә. Сәрия вестибюльдә ишекле-төрле йөренде, Юзефны танымый калмагаем дип керүче һәр кешегә текәлеп карап торды. Халык күп иде, пыяла ишек бер туктаусыз ачылып-ябылып торды, ләкин Юзефка охшаган кеше һаман күренмәде.

Сәрия түзмәде, тагын үз номерына менде, телефон номеры язылган кәгазьне тапты да шалтыратты. Трубканы тавышына караганда әле бик яшь бер хатын-кыз алды. Ул Юзефның кызы булып чыкты. Бу хәл Сәриянең телефон шалтыратуы төсле үк гади бер нәрсә булса да, ул ни өчендер каушап калды. Юзефны семья башлыгы, бала атасы итеп күз алдына китерә алмый торды, ниһаять, үзен кулга алды, рус сүзләрен инде онытылып бетә язган поляк сүзләре белән бутый-бутый, үзенең кем икәнлеген әйтте, Россиядән, Агыйдел буйларыннан килгән булуын, ә моннан егерме биш ел элек аның әтисе белән бер самолетта очканлыкларын аңлатты. Кыз да башта каушады булса кирәк, аннары шатланып-көлеп җибәрде, шулай ук рус сүзләрен катнаштырып, әтисе белән әнисенең өйдә юклыгын, әтисенең «сугышчан дустын» эзләп китүләрен әйтте.

Сәрия тагын вестибюльгә төште. Каршысына йөгереп килүче киң җилкәле, озын буйлы, кыска пальто кигән кешенең Юзеф булуын танудан бигрәк күңеле белән сизеп белде.

— Пани Сирена!..

— Юзеф!..

Вестибюльдә кеше күп иде, ә Сәрия тик Юзефны һәм... аңардан калмаска тырышып, кызу-кызу атлаучы тәбәнәк буйлы хатынны гына күрде. Сәрия аңына килгәндәй булды, әкренрәк, тынычрак атлый башлады. Юзеф та аңардагы бу үзгәрешне сизде булса кирәк, каршысына килеп туктады да, эшләпәсен салып, нәзакәтле генә итеп Сәриянең кулын үпте. Аннары артына борылды да читтәрәк торган ханымга күзләре белән ымлап, русчалатып:

— Пани Велина. Моя женка,— диде.

Сәрия бу ханым белән үзен ничегрәк тотарга икәнен белмичә, тәкәллефле генә итеп, вәкарь белән исәнләште.

Пани Велина яшь булып күренергә тырышучы мөлаем гына хатын иде. Борчак-борчак кара тамган аксыл озын пальтосы, курчактай матур туфлиларын каплап торган киң кара чалбары, түбәсенә чук тагылган мех береткасы аңа килешеп тора кебек. Яшәрергә тырышуы да килешә иде аңа. Ул ягымлы гына елмайды, үзен бик иркен тотып, Сәриягә кызыксынып карап торды.

Алар өчәүләп Сәриянең номерына менделәр. Сәрия кунакларын чишендерде, Казанда вакытта махсус сатып алган «Кош сөте» конфеты тәкъдим итте. Һәм каушап калды: тагын нишләргә соң? Әңгәмә өзелде. Һәр сүзне үзенне көчләп диярлек бертеклап чыгарып утыруы уңайсыз иде. Ниһаять, Юзеф бу хәлдән чыгу юлын тапты, шәһәрне карап керергә тәкъдим итте.

Вакыт шактый соң иде. Вак яңгыр сибәли, ул тротуар өстенә йомшак кына шыбырдап төшә. Алар төнге йокыга тала башлаган шәһәр буйлап озак йөрделәр, туңып беттеләр. Аннары кечкенә генә бер ресторанга юлыгып, шунда керделәр, кельнердан буш өстәл табып бирүен үтенделәр. Пани Велина бик кызыксынучан кеше булып чыкты. Ул, Сәриянең Юзеф белән бер самолетта оча алган булуына ышанмагандай, аның күзенә туры карап утырды. Сәрияне дә кызыксыну биләп алды, бөтенләй таныш булмаган бу ханымнан, Юзеф белән ничегрәк таныштыгыз сез дип, тату торасызмы, бер-берегездән канәгатьме, дип сорыйсы килде, ләкин мондый төпченүне килештермәүләре бар дип

тыелып калды һәм, уңайсызлануын яшерер өчен, яртылаш кына шәраб тутырылган рюмкаларны игътибар белән карарга тотынды.

Юзеф моны үзенчә аңлады:

— Әйдәгез эчик. Очрашуыбыз хөрмәтенә,— диде ул.

— Әйдәгез.

Рюмкаларын чәкештерделәр дә эчеп җибәрделәр. Сәрия шәрабның эчесен тоймады да. Юзеф аның фужерына минераль су койды, бераз авыз итүен көтеп торды, аннары кельнерны чакырып, бушап калган рюмкаларга ымлады.

Юзеф элек тә русча ярыйсы гына ермачлый иде, ә хәзер бөтенләй яхшы сөйләшә. Сугыштан соң граждански авиациягә күчкән, халыкара трассаларда очкан. Ләкин яшь дигәне үзенекен иткән, кулларда элекке ныклык калмаган, инспектор булып китәргә туры килгән. Пани Велина белән тату гына яшиләр икән, һәрхәлдә, савыт-сабаны шалтыратмаска тырышалар, тик менә шунысы начар — хатыны русча өйрәнә алмаган. Шуңа күрә пани Сиренаның монда артык исе китмәсен...

Пани Велина сүзнең үзе турында баруын аңлады булса кирәк, иренең сүзен җөпләргә теләгәндәй, оялчан гына, ягымлы гына елмаеп куйды.

Юк, Сәриянең монда исе китмәде, ул үз тормышы турында сөйләп китте. Ире турында әйтеп тормаска булды, күбрәк улы турында сөйләде, аның Мәскәүдәге инженерлык-физика институты кебек җитди уку йортына керә алырлык акыллы егет булып үсеп җитүенә шатланып бетә алмавын әйтте. Ул бераз исерә дә төште, бу кичнең гадәти булмавы да күңеленә вәсвәсә салган иде булса кирәк, эченә кереп урнашкан бер шайтан аны Юзефтан соңгы тапкыр бергә үткәргән кичебезне хәтерлисеңме, дип сорарга котырта башлады.

Әйтергә генә ансат: егерме биш ел үткән бит! Алар ул кичне менә бүгенге кебек кара-каршы утырдылар, ләкин ресторанда түгел, штабның офицерлар ашханәсендә. Икесе дә моның соңгы утыру икәнен беләләр, аңлыйлар иде. Юзеф кара көйгәнче кыздырылган котлетны чәнечкесе белән казый-казый, аска текәлгән килеш утыра, ә Сәрия аны күзәтә, ә үзенең шукланасы, шаярасы килә.

Нигә шаярмаска! Сугыш беткән, ә иртәгә ул өенә, җырларда җырлана торган Агыйдел буйларына кайтып китәчәк. Хәтта ышанасы да килми: шундый рәхимсез каты сугышта аның тырналган җире дә булмады бит. Тик шунысы кызганыч: Юзеф монда кала. Аның йөрәген нидер чеметеп алгандай булды, ләкин ул көтмәгәндә күңелен биләгән сагышлы уйларын куып җибәрергә тырышты, тагын чая телләнде, тагын шаярды. Нәрсә булган Юзефка? Очраштылар, бергәләшеп сугыштылар, күп тапкырлар бәлагә очрадылар, харап була яздылар, берни булмады ич әле, моннан соң да берни булмас. Сәриянең үз иле бар, Юзефның үзенеке. Әгәр кешеләр уйлап тапкан дәүләт чиге дигән нәрсә булмаса, һәркем кая теләсә, шунда бара, кайда теләсә, шунда тора торган булса, бөтен кеше бер гаиләдәй яшәсә, бик тә әйбәт булыр иде кана. Ләкин бу әле хыял гына, чынбарлыкта мондый хәл, ай-һай, кайчан булыр?

Кичке ашны сүзсез генә ашап бетерделәр. Аннары озаклап аэродромда йөрделәр. Висла буена чыктылар, снарядлар шартлап казылып беткән яр буеннан киттеләр. Шактый суыткан иде, елга ягыннан дымсу салкын һава бөркелә, аларның баш өстендә, иске крепость хәрабәләрендә нидер кыштырдый, ә түбәндә, вак дулкыннарын ярга сугып, Висла сулыш ала иде.

— Монда элек һәйкәл тора иде. Сирена һәйкәле,— дип куйды Юзеф.— Син — Сирена...

— Сирена түгел — Сәрия...
— Сирена...
— Сәрия...
Хәер, барыбер түгелмени: Сәрия ни дә Сирена ни. Сәрия инде Юзефның аны шулай атавына күнегеп тә беткән, бүген аны беренче тапкыр төзәтүе, ләкин бүген ул шундый инде, кешегә гел кире сүз әйтәсе, гел бәхәсләшәсе килеп тора.

Юзеф кинәт житдиләнде һәм Сәриягә күптәнге бер риваятьне сөйләп бирде. Имеш, кайчандыр бу тирәләрдә эшкә гажәеп уңган, төскә чибәр бер балыкчы егет яшәгән. Көн саен ул елгага үзенең җәтмәсен сала торган булган һәм көн саен мул итеп балык тотып алган. Ә көннәрдән бер көнне аның җәтмәсенә искитмәле бер табыш — Сирена исемле бик тә гүзәл кыз эләгеп чыккан. Шул көннән башлап балыкчы егет тынычлыгын җуйган, Сиренаны үзенә хатын итмәкче булган, ә кыз исә аңардан үзен суга кире җибәрүен үтенгән, ялварган. Балыкчы егет кайгыга төшкән, синнән башка миңа тормыш юк дип, башны суга ташларга гына кала дип караган, тик кыз Варшаваны дошманнардан саклармын дип ант иткәч кенә аны кире җибәрергә риза булган. Сугыш башланыр алдыннан гына менә шушы урында граниттан чокып Сиренаның кулына калкан һәм кылыч тоткан сынын куйганнар. Ләкин шәһәрне саклап калу сылу кызның гына кулыннан килерлек булмаган. Немецлар Варшаваны алганнар, биш ел буена анда хуҗа булып торганнар, аны җимереп бетергәннәр. Ә менә Сәрия очып килгән дә шәһәрне азат иткән...

Сәрия Юзефның аны «пани Сирена» дип атап йөртүен поляк кешесенә татар исемен әйтү кыен булганга дип уйлый иде. Бактың исә әнә нинди риваять уйлап тапкан егет...

Юзеф кулын Сәриянең җилкәсенә салды, шул килеш бер мәл уйга чумып торды да:

— Мин сезне җибәрмим, пани Сирена,— диде.— Сугыш бетте, ул бүтән беркайчан да булмас, ләкин сез биредә калыгыз. Калыгыз...

Сәрия башта Юзеф бүтән вакыттагыча шаяра торгандыр дип уйлаган иде, ләкин егетнең йөзе үтә җитди, хәтта кырыс булуын күреп, бу сүзләрнең тикмәгә әйтелмәгән, нык уйланылган булуын, үзенең дә көчле дә, назлы да бу егетне якын итүен аңлады. Ул чакта Сәриягә егерме генә яшь, кызның әле чын-чынлап беркемне дә яратканы юк иде. Нигә яшереп торырга: Юзеф белән бер самолетта ел ярым бүе бергә очу дәверендә аның үзен бу егет белән Агыйдел буенда итеп еш кына күз алдына китергәне булды. Менә алар киң болын өстендә икәннәр, печән өсте икән, иң алдан, чалгысы белән селтәнә-селтәнә, өстенә ак күлмәк, яшел хәрби конфедератка кигән Юзеф атлый икән. Сәрия дә шунда, хатын-кызлар белән печән җыеп йөри, үзе чүмәлә өя, ә үзе бәхеттән мөлдерәмә күзләрен Юзефтан ала алмый икән... Юзефы чалгысын кайрарга дип тукталдымы, Сәрия җиргә күмеп куелган салкын әйрән савытын казып ала да аның янына йөгереп килә икән... Шулай ашыкмаса, аның янына гүя икенче берәү килеп җитәчәк... Юзеф чыжылдатып чалгысын кайрый, әледән-әле бармагы белән аның үткенлеген тикшереп карый, аннары кувшин авызыннан гына әйрән эчә, үзе кырын күзе белән генә Сәриягә карап ала, ә тегесе, бәхетен яшерә алмыйча, аның янында басып тора икән...

Ләкин сугыш гөрелтесе эчендә болар барысы да бик-бик ерак нәрсә булып, тормышка ашмастай хыял булып күренәләр иде. Менә сугыш бетте, тормыш җайга салына башлады, һәм ерактагы хыял булып тоелган нәрсәләр якын ук килеп каршыга бастылар. Аларның чынга әйләнүен теләргә генә калды. Менә шушы нәрсә аны кинәт каушап, өркетеп җибәрде. Һәм ул йөрәк түрендә күпме вакытлар яшәп килгән хискә ирек бирмәскә, аны авызлыкларга булды.

Сәрия үзен дә, Юзефны да кызганып куйды, үзен Юзеф алдында гаепле итеп, аңарга ниндидер бер начарлык эшләгән кеше итеп сизде. Кычкырып елап җибәрергә җитешкән, күкрәгендә йөрәгенең дөп-дөп типкәнен ишеткән хәлдә, үзен-үзе белештермичә, аяк очына басты, Юзефны башта маңгаеннан, аннары яңакларыннан үпте.

Көтелмәгән бу хәлдән Сәриянең коты алынды, һәм ул, аңына килеп, борылып китеп барды. Ул янып күмергә әйләнгән йортлар яныннан ашыга-ашыга атлады, Юзефның «пани Сирена! Пани...» дип пышылдавын ишетте, туктап көтәсе килде, ә үзе курыкты.

Ә иртәгесен алар аерылыштылар. Польша җирендә сугышкан, аның халкына бәхет яулашкан совет кешеләре бер эшелон җыелды. Сәрия үзен бик тә уңайсыз хис итте, күңелендәге уй-теләкләрнең очына чыга алмавы өчен үзен-үзе битәрләде. Ул әле кичәге кичнең бөтен кеше күз алдында тагын кабатлануын теләде, әле Юзеф белән очрашудан, аның күзенә караудан курыкты.

Юзеф аның бу шикләнүләрен ничек белде-сизенде икән? Иртән ул ашханәгә дә килмәде, станциягә озата килүчеләр арасында да күренмәде. Башта Сәрия алай хәтта җинелрәк тә булыр әле дип уйлаган иде, ләкин көтелгән җиңеллек урынына күңелен ямансулык, сагыш биләп алды. Поезд кузгалып тизлеген арттыра барды. Сәрия проводник хатынның башы өстеннән сузылып карый-карый, Юзефны күрергә, аңа соңгы тапкыр кул болгарга теләде, ләкин егет күренмәде. Менә шәһәр үзе дә күздән югалды, тик ике аксыл металл тасма булып сузылган рельслар гына артка таба йөгерештеләр. Күк йөзенең иң читенә барып җиткәч, бу тасмалар бер сызык булып бергә кушылалар да офык артына кереп югалалар иде.

...Сәрия Юзефка караган килеш әнә шуларны исенә төшереп утырды, шактый ук калыная төшкән озын буйлы бу кешедә ул чактагы оялчан егетнең билгеләрен күрергә тырышты. Юзефның да үзенә карапкарап алуын сизде. Ресторан эче шау-шулы иде. Залда кечкенә генә оркестр уйный иде, яшьләр бии башлады. Боларның да беренче очрашканда булган тартынулары югалды, кичә генә аерылышкан танышлар төсле иркен һәм җиңел генә сөйләшеп утыра башладылар. Үзләрен бер-берсенә якын иткән иң мөһим нәрсә турында сөйләшәселәре килде аларның, моның өчен үзенә бер төрле көчле һәм матур сүзләр табасылары килде, ләкин үч иткәндәй, телгә җыен вак-төяк кенә килеп торды. Юзеф ул чактагы ахмаклыклары, самолет дошман уты эченә килеп кереп, машинаны йомычка урынына селкетә башлаганда үзенең трубкасына:

— Курыкма, пани-штурман! Төшсәк тә җиргә төшәрбез! — дип шаяртып кычкырулары турында сөйләп китте.

Сәрия исә беренче тапкыр парашюттан сикерүен исенә төшерде. Бу хәл сугыш башланган гына вакытта, ул штурманнар мәктәбендә укыганда булды. Ул чакны хатын-кызларга ирләр киеме бирәләр иде әле. Занятиеләрнең берсендә парашют инструкторы Сәриягә сикерергә кушып: «Пошел!» дип кычкырды, ә Сәрия чишелеп киткән аяк чолгавын рәтлим дип тоткарланды да сикерүдән бигрәк мәтәлеп төшеп китте. Ул үзенә таба якынлашучы җиргә таштай очып төшә, күз аллары әлжемөлҗе килә, ә үзе тизрәк бәҗраны тартасы урынга һаман шул каһәр төшкән чолгау белән маташа иде. «Эләгә инде миңа старшинадан»,— дип куркып уйланды Сәрия. Җиргә төшүгә аның янына ачуыннан яшелләнеп, йөнтәс зур йодрыгын бутый-бутый, инструктор йөгереп килде: «Курсант Байбулатова! Син, нәрсә, парашютсыз сикерү ярышлары оештырасыңмы?» Сәриянең кулындагы аяк чолгавын күргәч кенә эшнең нәрсәдә икәнен аңлады булса кирәк, йомшарды, көлеп җибәрде:

— Үзеңдә калдыр, борын яулыгыңа булыр!

Алар янына берничә мәртәбә кельнер килеп, кайнар әйбер кирәкмиме дип сорап китте. Пани Велина иренә үз телендә нидер әйтмәкче булды, ә Сәрия полякча белүен күрсәтергә, мактанып алырга теләп, елмая-елмая: «Дзенкую. Рәхмәт!» дигән булды.

Сәрия чыннан да бу кич өчен язмышына рәхмәт әйтеп, шатлыгыннан ни эшләргә белми утыра. Инде ярым онытылган, вакыт дигәнең бер могжиза аркасында гына сүндерми калдырган тормыш хатирәләренә кинәт кенә яңадан әйләнеп кайтып булуга ышанасы килми иде. Ә чынлап карасаң, нәкъ менә шул хатирәләр аның тормышына җылылык өстәп торган, аның тормышында да шатлыклар, юанычлар булуны искә төшереп, күңелгә рәхәтлек биреп торган икән.

Ул вак-вак йотымнар белән кофе эчә, ә үзе Юзефтан, дөресрәге, аның уң кашы өстендә илтифатсыз гына төшерелгән бер сызык сыман сакланып калган җөйгә карап утыра иде. Юк, чыннан да бәхет дигәнең бер дә ташламады шул аларны: күпме очыш ясадылар, күпме үлем, күпме кан күрделәр, ә үзләре икесенә бер җәрәхәт белән чикләнделәр. Анысы да пуля-мазар тиеп түгел, болай, очраклы рәвештә генә... Бу җөйне Сәрия бик тә ярата иде, ул Юзефның битен һич кенә дә ямьсезләтми, киресенчә, аны ягымлырак, ихтыярлырак итә дип саный иде.

Менә хәзер дә Сәриянең әнә шул ягымлы җөйгә кулы белән кагыласы... юк, үбеп аласы килде. Мондый сәер теләге өчен ул эченнән үзен шелтәләп тә куйды. Моннан тыш Сәриянең Юзефтан: син Висла буендагы теге кичне, сине үбүләремне хәтерлисеңме дип, иртәгесен нигә мине озатырга килмәдең? — дип сорыйсы килде. Ләкин моны эшләргә ярамый. Алар янында кыска буйлы мөлаем хатын, кешеләр арасындагы гадәт буенча Юзефны баштанаяк үзенеке итеп санарга хакы булган пани Велина утыра. Аның бу нәрсәне өнәп бетермәве бар. Чөнки бүтәннәр мондый хокуктан мәхрүм. Алар әнә шул инде онытыла язган ерак хатирәләр белән генә яши алалар. Сәрия биредәге, Польшадагы гадәтләрне белеп бетерми бетерүен, шулай да бу хатирәләр турында ишетүнең дә әлеге мөлаем хатынга авыр булуы бар. Шуңа күрә Сәрия гафу үтенде, инде шактый соң дигән булды, юлдан соң арылган, ә иртәгә тагын юлга чыгасы бар, диде. Мәскәү поезды төштән соң китәргә тиеш иде. Алар иртәгә очрашырга сүз куештылар да аерылыштылар.

Алар карамагында бер көн, чирек гасырның бер көне бар иде әле. Иртән Юзеф Сәрия янына гостиницага керде. Алар Юзефның «Москвич»ына утырып, хәрабәләр эченнән калкып чыккан Варшава буйлап йөреп кайтырга булдылар. Варшава өчен сугышларда һәлак булганнар күмелгән туганнар каберлегендә шактый озак йөрделәр һәм ин ахырдан элекке хәленә кайтарылган Сирена кыз һәйкәле янында туктадылар. Сүзсез генә басып тордылар. Ахырда Юзеф:

— Алар үле булсалар да бергә...— дип куйды.

Сәрия, «алар»ның туганнар каберенә күмелгән кешеләр икәнен аңлап:

— Без исән булсак та аерым...— дип өстәде.

Болытлы шыксыз көн иде. Җил сары яфракларны яр буе урамы буйлап тавышсыз гына куып йөртә дә, тәбәнәк кенә таш койма өстеннән күтәреп, саклык белән су өстенә китереп төшерә. Яфраклар тыныч су өстендә җебеми-нитми ял итеп яталар.

Кичәге сөйләшүләрдән соң сүз табылмады. Кичә ресторанда башына килгән нәрсәләр бүген Сәриягә ничектер бик вак булып тоелдылар. Алар, баштан үткәннәрне ничәмә-ничә елдан соң күңелләреннән кабат кичереп, сугышта һәлак булган, югалып калган иптәшләре өчен җаваплы булуларын йөрәкләре белән сизенеп, аларның исәлегән кирәген-

чә үк саклый алмаулары өчен үз-үзләрен эчтән битәрләп, сүзсез атладылар.

Вокзалда да тын иде. Алар перрон буйлап йөрделәр. Бер-берсенә соңгы йомышларын әйттеләр. Еллар буе бер-берсен очрашу шатлыгыннан мәхрүм итүләре өчен үкенеп, үз-үзләрен битәрләделәр. Юзеф, пани Велина һәм кызы белән бергәләп, Россиягә, жырларда жырлана торган Агыйдел буйларына килеп чыгар өчен вакыт табарга, ә Сәрия Варшавага улын алып килергә тиеш, дип сүз куештылар.

Менә поездның кузгалу сигналы булды. Сәрия үзен ничек тотарга белмичә аптырап калды. Юзеф та сагышлы иде, эшләпәсен салып, ихтирам белән тәкәллефле генә башын иде, сагаеп кына Сәриянең кул бармакларын үпте. Сәрия кинәт Юзефка күтәрелеп карады һәм аның күзләре белән очрашты. Бу күзләр вакыт үтү белән ничектер аксыллана төшкән кебек, ләкин моннан чирек гасыр элек булгандагы кебек үк ягымлы, шундый ук көләч-оялчан иде. Кичәге төсле үк Сәриянең каш өстендәге теге җөйгә бармагы белән кагыласы килде. Ләкин бүген бу теләк шул ук вакытта бөтенләй башка да иде: ул аналарныкы төсле саф һәм назлы иде. Шулай булса да ул үзенең кыюсызлыгын җиңә алмады һәм, кулында Юзефның кытыршы иреннәрен тойган хәлдә, бер үк сүзне кабатлады:

— Довидзенья, Юзеф. Рәхмәт!

Поезд кузгалып китте. Сәрия вагон баскычына сикереп менде. Ул шунда баскан килеш, шпалларга беркетелгән ике аксыл корыч тасмага, мәңге янәшә булып та, бергә кушылу мөмкинлегеннән мәхрүм ителгән рельсларга, эшләпәсен болгап калган Юзефка карап барды, аңа кул болгады, үзләре кавыша алмасалар да, кешеләрне кавыштыручы рельсларга күңеленнән рәхмәт әйтәсе килде...

≈≈≈≈≈

## Рифгать Закиров

### Ышаныч

Карурманда ялгыз калган чакта, —
Юлдан язган чакта,
Мин ашыгам һәр чак сөенә-сөенә
Тавыш килгән якка.

Мондый чакта булмый күңелемдә
Шикнең бөртеге дә,
Күнеккәнмен чөнки кешеләрне
Күптән үз күрергә.

Бүтәннәр дә шулай булырлар, дип,
Ышанганга микән,
Кешеләрдән мин явызлык түгел,
Гел яхшылык көтәм.

### Йөрәк

Йөрәк... аңа бөтенесе сыйган,
Чыгалмассың моны санап та!
Кайгы-сагыш,
Чиксез шатлыкларым
Этә аны эчтән як-якка.

Шуңа күрә
Аның ярылмыйча
Чыдавына таңга калырлык;
Тыштан аны,
Күкрәк кенә түгел,
Кысып тора, ахры,сабырлык...

### Сугыш узган җирдә

Сугыш узган җирләр... Бу якларда
Азмы аккан дисең солдат каны?!
Моңсу йөзле хатыннарны күрсәң
Уйлыйсың: бу да бер солдаткамы?..

Ярый әле: бу җир күптән инде
Ала-кола түгел, — яшелләнгән...

Әмма сугыш монда җир астына
Нинди генә төсләр яшермәгән?!.

Үсәләр дә монда ал чәчәкләр,
Каралары мәңге шытып чыкмас!
...Бу якларда инде икенче кат
Бер кайчан да кеше мылтык тотмас!!.
Ышанасы килә шуңа.

## Җырлады кыз...

Сагынуларның чиге юктыр ла ул,
Сагынмаган кеше булмыйдыр...
Сагындыра мине
инде күптән
Бер ишетеп калган моңлы җыр.

Урман ышыгында җырлады кыз,—
Белалмадым аның кемлеген...
Еллар үткәч,
Аны күрмәмме дип,
Килдем кабат шунда мин бүген.

Тын аланда моңлы җыр сузучы
Син булдыңмы,
әллә бүтәнме?..
Бу сорауга җавап табар идем,
Тик кайтарып булмый үткәнне?!.

## Яңгырлы перроннарда...

Яңгыр явып торган перроннарда
Бәрелә-сугыла узган-барганнарга,
Көндәгечә менә бүген дә,
Кырык эшен ташлап кырык якка,
Мине әле, Рәйсә, синнән башка
Озатмады шулай бер кем дә.

Озатмады кем дә мине, Рәйсә,
Иңнәремә болай сарылып;
Карамады бер кем күзләремә
Һәм бакмады бер кем йөзләремә
Китмәс борын шулай сагынып...

Шуңа ерак юлда җирсимен дә
Сине генә якын, үз күреп,
Кайтып төшү белән, тын алганчы,
Кочагыма алам бөтереп!
Карамыйча узган-барганнарга,
Яңгыр коепдырган вокзалларда...

# Алга!..

Күпме юллар үтелмәгән,
Әмма
Барасы җир әле әй ерак!..
Бу ничәнче чакрымдыр — белмим;
Бәлки... белмәү үзе яхшырак.

Поезд ыргый алга бертуктаусыз...
Бу төбәк соң — юлның кай төше:
Башы гына мәллә,
Я булмаса
Үтелгәнме инде яртысы?!

Ахырымы?
Әйдә була бирсен,
Тик борылып кире кайту юк! —
Туар таңнар каршысына очам
Таң йолдызы сыман атылып!!.

## Булат Сөләйманов

### Ак каурыйлар

Ак канатлы аккошларым кайта
Мин белмәгән ерак иллардән.
Күлләр күзе күптән томанланган,
Хәбәр алдым искән җиллардән.

Юллар илтер сезне Себеремә,
Сәламләрем алып китегез.
Ул исән-сау диеп, әнкәемә
Ак каурыйлар сибеп үтегез.

Ак канатлы аккошларым үтте
Йөрәктәге ярам кузгатып.
Бер чылбырга тезеп, туган якка,
Сагынуларым калдым озатып.

### Яман күзләр күрмәсен

Яман күзләр күрмәсен,— дип
Төнгә качтык, аулакка.
Йолдызларны бүләк иттем
Мин иркәмә калфакка.

Яман сүзләр йөрмәсен,— дип
Безнең хакта авылда,
Чәчәкләргә генә ачтык
Серебезнең барын да.

### Этюд

Төн.
Томан.
Җир —
Бәйгедән кайткан сыман.
. . . . . . . . .
Иртә.

Күтәрелә кояш,
Тарала томан.
Уйный нурлар.
Җир —
Яңа туган бала сыман.

### Ишкәк

Диңгез бит ул минем оям,
Тик диңгездә бәхет таям,
Мин ансыз яши алмыйм, дип,
Ишкәк ялына-өзелә:
«Җибәрче, җир, диңгеземә!..»

Белми мескен җиргә үзен
Чыгарып ташлавын диңгезнең...

*Шәрәф Мөдәррис*
*(1919—1963)*

# ҖЫРЛАНМЫЙ КАЛГАН ҖЫР

Полк байрагы — полк намусы. Полк байрагы — солдатның Ватанга бирелгәнлеге, ирекне, кешелекне сөюе, дошманнарга нәфрәте билгесе. Полк байрагы сугышчыларны җиңүгә рухландыра, баскан җиренең ныклыгын тоярга булыша. Авыр бәрелештә полкның зур югалтуларга дучар булуы бар. Әмма сугышчылар байракны дошманга бирмиләр, үлсәләр үләләр — полк намусын күз карасыдай саклап калалар.

Бу турыда мин беренче тапкыр Шәрәфтән ишеткән идем. Ул аны фронтта язып кайткан «Полк намусы» трагедиясен күрсәткәндә сөйләгән иде. Шагыйрь Казанга кайтканда трагедиянең беренче варианты тәгәлләнгән булган һәм аны Татар академия театрында укып та чыкканнар. Шәрәфнең әйтүенчә, коллектив аны нигездә яхшы дип тапкан, сәхнә законнарын искә алып, кай җирләрен төзәтергә киңәш иткәннәр. Мин белгәндә бу әсәр тагын да ныграк уйлану, яхшырак әзерләнү өчен вакыт булсын дип, бер читкәрәк алып куелган хәлдә иде. Шуннан соң күп кенә шигырьләр, поэмалар, публицистик мәкаләләр язылды. Ләкин Шәрәфне әлеге трагедия һаман, һаман борчып торды. Вакыйгаларны баталь күренешләр аша, сугышчыларның фронттагы батырлыкларына нигезләп ачу гына инде аны канәгатьләндерми иде. Бу әсәргә ул ике лагерьның идея көрәшен нигез итеп алырга теләде. Фашизм — үз идеясенә фанатикларча бирелгән, сугыш белемен бик яхшы өйрәнгән, баштаняк коралланган дошман иде. Һәм шундый дошманга каршы сугышу безгә җиңел булмады. Бу сугышта без үз җиребезне дошман басып алучыларыннан әрчеп кенә калмадык, уннарча дәүләтләрне фашист коллыгыннан азат иттек. Бу сугышта без кешелеккә дошман булган фашистик идеяне тар-мар иттек. «Полк намусы»нда Шәрәф әнә шул көрәшне бирергә теләде. Аны әсир төшкән комиссар Булатов белән фашист Унтигельнең бәхәс картинасы нык дулкынландыра да, борчый да иде. Ул әсәрнең кульминацион ноктасын әнә шул җирдә күрде һәм аны югары накалда, чакма ташы бәрелешкәндә очкыннар чәчрәп торгандай, көчле пафос, үткен тел белән бирергә теләде. Тора-бара трагедиянең формасы да үзгәрде. Ул инде чәчмәдән шигъри юлларга күчте. Рухы белән дә Шекспир трагедияләрен хәтерләткән романтик стильдә, пафослы әсәр булырга тиеш иде.

Гомеренең соңгы елларында Шәрәф бу эшкә ныклап тотынды. Ул вакытта Татар академия театрының баш режиссеры булып эшләгән Ширияздан ага Сарымсаков белән еш кына очрашып, рухланып сөйләшеп утыра торган булдылар. Сәхнә белгече буларак, Ширияздан ага аңа күп кенә кызыклы фикерләр әйтә иде.

Кызганычка каршы, әсәр тәгәлләнеп өлгермәде. Соңгы вариантта аның тулы эшләнгән беренче пәрдәсе һәм икенче пәрдәнең ике күренеше генә язылып калды. Журналга тәкъдим ителгән бу кисәк икенче пәрдәнең беренче күренеше була.

ЛӘБИБӘ ИХСАНОВА.

# БЕЗ—СИНЕКЕ, ПАРТИЯ, БЕЗ—СИНЕҢ БЕЛӘН!

ПУБЛИЦИСТИКА

Партиянең тугрылыклы дусты, ярдәмчесе, ышанычлы таянычы! Безгә, язучыларга, Партиябез шундый югары бәяне бирә. Бу бәя безнең йөрәкләрдә үзебез өчен, үзебезнең тыйнак профессиябез өчен хаклы горурлык хисләре уята. Уята һәм «дус, ярдәмче, ышанычлы таяныч» дигән шушы бөек исемнәрне эштә аклау өчен безне иҗади батырлыкларга, фидакарь хезмәткә чакыра. Алай гына да түгел, бу сүзләр безгә халкыбыз алдындагы вөҗдан бурычыбызны лаеклы рәвештә үтәү өчен бетмәс-төкәнмәс дәрт бирә, үзебезнең көчебезгә ныклы ышаныч тудыра. Һәм без бүген, татар язучылары, үзебезнең бердәм сүзебезне әйтәбез:

— Без — синеке, Партия, без — синең белән!

Нәрсә ул яки кем ул Партия? Партия — мәгънәсен зирәк философлар да тиз генә эзләп таба алмаган әллә нинди абстракт төшенчә түгел. Шулай ук ул гади кешедән әллә кайда, ерак йөри торган идеал көч тә түгел. Партия ул — безнең янызбызда, безнең үзебездә. Без аны һәр даим тоеп торабыз, аңар карыйбыз, аның кулын кысабыз, аңардан киңәш сорыйбыз. Партия ул — без көн саен, сәгать саен күреп торган коммунист иптәшләр.

Минем буын кешеләре бик яшьли үк Партия рухын тоеп үстеләр.

Әтием 1917 елдан бирле партия члены иде һәм гомеренең соңгы көннәренә хәтле аңар тугрылыклы булып калды. Мин бала чакта ук авылыбызның Шакиров Абделхак кебек эшлекле, намуслы коммунистлары йогынтысына эләктем, алар җитәкчелеге белән колхозда бригада стена газеталары чыгара идем, басуда газеталар укып йөри идем. Казанга укырга килеп, рабфак ишеген ачып керү белән мине коммунист укытучылар каршы алдылар. Матбугат йортының беренче баскычына аяк басуым белән үк коммунист язучылар беренче булып миңа ярдәм кулы суздылар. Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк минем иң якын дусларым замполит Инюткин белән политрук Александрин булды. Ротаның шактый өлкән яшьтәге коммунистлары Купцов һәм Брегида, мин яралангач, беренче булып ярдәмгә килделәр, дошман пулялары астында, муеннан суга кереп, мине елга аръягына алып чыктылар. Миномет дивизионы комсоргы коммунист Рейманның, соныннан бөтен сугыш буена «ахирәт дустым» булып калган комиссар Ахрамковның якты образлары минем күңелемдә әле дә ачык саклана. Соңрак, фронт газетасы эшчесе буларак, мин Хәрәкәттәге Армия частьларында күп йөрдем һәм йөзләрчә коммунист сугышчының Ватан өчен көрәштә күрсәткән искиткеч батырлыкларына шаһит булдым. Кискен моментта батальонны, роталарны атакага күтәргән парторгларның пулялардан тишкәләнгән изге партия билетларын күрдем.

Коммунистлар, минем тормышта ышанычлы якын дусларым булган кебек, иҗатымда да иң яратып язган образларым. «Биш минут»та депо парторгы Иван Палыч, «Яшел тасма»да колхоз парторгы Әнвәр Тимергалин белән райком секретаре Мария Божан, «Кызыл Мәйдан»да аталы-уллы ике ветеран — Владимир һәм Виктор Поповлар, әле күптән түгел генә тәмам булган «Үлемсезлек» исемле поэтик симфониядә



ленинчы ветеран Захар Бакланов... Мин бу образларны әсәрләремә «мода өчен» түгел, хәтта әсәр өчен органик зарур булганга гына да түгел, бәлки бөтен җаным белән дулкынланып, үзем партия әгъзасы булмасам да, коммунист тибын идеал итүем өчен, тарихи дөреслек шаһите булуым өчен керттем. Бәлки алар әле тулы канлы образ булудан битәр якынча штрихлар гынадыр. Әмма мин үземнең киләчәк иҗатымда бөек Ленин партиясенең лаеклы улы образына чын мәгънәсендә гүзәл натуралы, корыч ихтыярлы булган коммунист образын тудыруны изге бурычым итеп саныйм.

Минем буын шагыйрьләре үзләренең беренче балалык шигырьләрен Ленин исеме белән башладылар. Ленин исеме белән үзләренең шактый озын иҗат сукмакларын үттеләр. Шик юк, алар киләчәктә дә үз иҗатларының иң кадерле, иң бәхетле җимешләрен Советлар Союзының данлыклы коммунистлар партиясенә бүләк итәрләр, халкыбыз белән тыгыз элемтәдә булып, аның идеалы өчен янарлар.

Партия безне бөек халкыбызга лаеклы әсәрләр тудыру өчен иҗади рыцарьлыкка чакыра. Аның чакыруына җыелышларда ялкынлы чыгышлар ясап, озын-озын резолюцияләр төзеп яки «ут сулый торган» мәкаләләр язып кына җавап биреп булмый. Бәрәкәтле, кыю иҗади эш — партиябезгә, халкыбызга безнең конкрет җавап әнә шул.

Мин үзем, мәсәлән, шактый еллардан бирле инде «Полк намусы» исемле трагедия өстендә эшлим һәм ул хәзер тәмамлану алдында тора. Бу әсәр Бөек Ватан сугышында коммунистлар партиясенең җитәкчелек ролен, совет халкының, аның героик Армиясенен — генералларның, офицерларның, рядовой солдатларның — Ватан намусы өчен, халык бәхете өчен көрәшләрдә күрсәткән легендар батырлыгын чагылдыра. Ватан сугышы — Бөек Октябрь социалистик революциясе нәтиҗәсендә туган Совет властен раслау акты булды. Менә шушы инде минем трагедиянең дә төп идеясе булып тора.

Партия чакыра. Аның чакыруына җавап итеп шундый әсәрләр бирик ки, без язган әсәрләрне укыгач, безнең хөрмәтле укучыбыз янадан да бер мәртәбә кабатласын:

— Без синеке, Партия, без — синең белән!

*Сентябрь, 1957*

# ПОЛК НАМУСЫ[1]

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Килеп житте фронт җиле Башкалага,
Килеп житте шәһәр чите-дачаларга.
Бар яктан да камап алды ныгытмалар,
Тимер чыбык киртәләре, траншеялар.

[1] Трагедиядән өзек.

Аэростатлар тирбәләләр тонык күктә,
Зенит туплар улый-күкри көнен-төнен.
Пышылдаша сугышчылар: «Артта Мәскәү!»
Йөрәк әрни, йөрәк дулый: «Артта Кремль!»
Житте, житте! Инде хәрби пружинабыз
Кысылуның соңгы чиген үтеп китте.
Анар хәзер зилзиләле куәт белән
Алга табан ычкынырга вакыт инде!
Кояш нуры балкый, диләр, бер тамчыда,
Жиңү рухы балкый бүген бер ноктада,—
Очсыз-чиксез озын фронт сызыгыннан
Тыйнак кына урын алган землянкада...
Монда бүген ике гадел тугры куәт,
Хыянәтсез ике сакчы сакта тора:
Тышта — көзнең үзәк өзгеч салкынлыгы,
Эчтә — жанның ургып янган шашкынлыгы...

## Дүртенче жыр

### БЕРЕНЧЕ КАР — ЯЗ ЧӘЧӘГЕ

Землянкада — Файер ялгыз.

Файер.

Табигатьтә дүрт стихия хөкем сөрә:
Шуның берсе — ут, янар ут, бөек бер көч!
Анардан саф, аннан чиста һич нәрсә юк,
Киң галәмдә иң изге һәм пакь стихия!
Жирдә, Суда — бактерияләр мириадасы,
Һава дисәң — микроб белән мыжлап тора.
Тик ут кына мәңге азат вируслардан,
Тик ут кына — идеал сафлык тантанасы!
Ут барын да ялап китә, әрчеп китә,
Бар да аның кодрәтенә буен сона,—
Аның өчен барсы да бер: саф чәчәк тә,
Шакшы чүп тә шул ук уттан көлгә дүнә.
Ләкин ут ул — терекләкнең чыганагы,
Ул бөек зат, мәңге-мәңге янып тора
Кояш булып табигатьнең тәхетендә...
Ут ул — яшәү, чиксез тумыш, чиксез үрчем!
Утта туган эсселектән, яктылыктан
Хасил була мәхәббәтнең бөек көче.
Әгәр миннән сорасалар: «Алла бармы?»
Мин әйтәм: «Бар, ул — титан Ут, нурлы Кояш!»
Шырпы сызам, әй гүзәл Ут, ян син тагын,
Ак чәчәк күк кабын әйдә минем кулда!
Син — яшәүнең мәңгелекле башлангычы,
Син — кояшның жиргә ингән хәбәрчесе!
Ялкынланып дөрли-дөрли ян син, жаным,
Кансулатып кыздыр минем тимер мичне.
*(Мичкә ут кабыза.)*
Өстим сиңа, әй нурлы Ут, өстим утын,
Житми икән, ал син өстәп йөрәк утын!

Акчурин белән Карачурин керә.

Акчурин. Куллар катты...
Карачурин. Әйе, шул-шул. Колак тунды.
Акчурин. Борын сызлый.
Карачурин. Әйе, шул-шул. Битне кисте.
Файер. Ут, бөек Ут! Сезгә дәва тик Ут кына!
Утырыгыз менә монда. Мич каршына.
Акчурин. Рувим туган!
Карачурин. Рувим иптәш!
Файер. Нәрсә дуслар?
Акчурин. Бөтен полк йөртә сине «философ» дип.
Карачурин. Әйе, шул-шул. Бөтен кеше шулай атый.
Акчурин. Менә нәрсә. Хөкем ит син бүген безне.
Карачурин. Әйе, шул-шул. Синең сүзең безгә закон!
Файер. Нәрсә өчен? Нинди хөкем? Нинди закон?
Акчурин. Ул да, мин дә менә дигән пулеметчы...
Карачурин. Ләкин бездә адым саен ризасызлык...
Акчурин. Холык-гадәт, фигылебез капма-каршы.
Карачурин. Хәтта менә фамилиябез капма-каршы!
Акчурин. Мин — Акчурин.
Карачурин. Мин — үч итеп: Карачурин.
Файер. Фамилиягез төрле булса, исмегез — бер,
Син дә Әхмәт, син дә Әхмәт, сез — адашлар!
Акчурин. Әй бер ходам, кайсы мине мыскыл итеп,
Шушы типка Әхмәт дигән исем кушкан?
Карачурин. Әйе, шул-шул. Кайсы минем бишегемнән
«Әхмәт» исемен шуңар урлап бирде микән?
Акчурин. Ул — бик озын.
Карачурин. Ул — бик кыска.
Акчурин. Ул — бик нечкә.
Карачурин. Ул — бик калын. Күрәсеңдер, түмгәк төсле.
Файер. Менә дигән! Гармониягә килеп тора!
Акчурин. Характеры дисәң инде — ярыл да үл!
Урынында тора алмый,— дулый, ярсый.
Кызган таба өстендәге борчак сыман!
Кичә генә нәрсә булды? Котың очар!
Каршыбызда немец дзоты. Бу торды да
«Әй анаң!» да «фәлән»! диеп, чинап куйды.
«Тик кенә ят, атып кына ят!» дисәм дә,
Минем сүзне тыңламады. Батыр, имеш!
Гимнастерка төймәләрен ычкындырып,
Гранаталар бәрә-бәрә алга чапты...
«Нигә шулай җенләнәсең?» дигән идем,
«Бичаралар һаман дзотта тончыгалар,
Азрак һава суласыннар!» дигән була.
Файер. Судан алган балык төсле!
Карачурин. Әйе, шул-шул.
Аның холкы, Рувим иптәш, ифрат начар:
Җирдә ятып кара каткан бер тораташ!
Каршысына ишелә-ишелә яу килсә дә,
Кесәсеннән янчык алып махра төрә.
— Ат, ат,— дим мин. Ул тын гына шырпы сыза.
«Башта мин,— ди,— пруссакның күзен күрәм,
Иягендәге төген санаым. Аннан инде
Тәмләп кенә атып егам»,— дигән була.
Кичә генә алдыбызга снаряд төште.
Сулы җирдә чыж-пыж килеп, кайнап тора.

Әйдә, дим, мин, Акчурин дус, тайыйк моннан!
Шартладымы — эшең бетте. Хәтәр инде!
Уйлап та бит бакмый шайтан! Махра урый.
Нәрсә ди бит? Имеш, моннан нигә качыйм?
Ул бит үзе килеп төште безнең янга!
Чакырмадым, нигә аңар урын бирим?

Файер. Ярый. Бик шәп. Язып алыйк.

Карачурин. Әйе, шул-шул.

Акчурин. Әгәр аның начар ягын белсәң икән!
Көнен-төнен шахмат белән жаны чыга.
Бөтен сүзе гел «шах» та «мат»! Гажәп инде!
Котелоктан зуррак кисәк ит алса да,
«Шах!» дип куя. Имеш, калма авыз ачып!
Йоклаганда «шах!» дип, мине кырт уята.
Хатынымнан үпкә катыш бер хат алдым.
Карачурин аның сиңа «шах»ы бу, ди.
Немецларга аткан чакта бигрәк жүләр.
Башта «шах!» ди, дөмектерсә, «мат!» дип куя.
Командирдан әллә ничек шелтә алдым,—
Бу ни ди бит: Кара, имеш, «мат»ка барма!
Аның «мат»ы гауптвахта бугай инде!
Сухиничта яраландым. Җирдә ятам...
Бу килде дә: «шах»мы, «мат»мы? дигән була.
Бер дә бер көн туры юлдан илтә, имеш,—
Әйдәп китте миналаган кыр буйлата.
«Мин — кара фил, син — ак фил, ди. Әйдә, йөр», ди,
Хәтәр җирдән алып чыкты кыеклата,—
Диагональләр теориясен яхшы бел, ди!

Файер. Ярый, ярый. Чү, бусын да язып алыйк.

Карачурин. Әгәр аның жүләрлеген белсәң икән!
Күңелендә, сүзләрендә — һаман сыра.
Бөтен дөнья сыра булып күренә аңар!
Юлда очкан соры тузан — сыра аңар,
Сазлыктагы тончу су да — сыра аңар!
Котелокта чәй булса да — «сыра» ди ул,
Аның өчен ак болыт та — сыра күбеге!
Мунча керсә, тәмам шаша. «Ах, сыра!» дип,
Тазындагы күбекләргә акылы китә!..
Сугышкача биш ел ярым сыра саткан.
Күптән түгел нәрсә булды? Бомба төшеп,
Ком да туфрак басып китә окоп өстен.
Казып алам. Нәрсә ди бит шунда явыз! —
Минем башка бер уй килде, дигән була,—
Әгәр шулай җиргә күмеп өч ел тотсаң,
Нишләр икән ул чак, имеш, бәрхет сыра?

Файер. Ярый. Булды. Әйдә, тагын ниләр языйм?

Акчурин. Сәгать саен, минут саен талашабыз...

Карачурин. Әйе, шул-шул. Ызгышмаган бер көн дә юк.

Файер. Ярый, дуслар. Инде сезне хөкем итим,—
Судья икән,— минем сүзем закон булыр.
Табигатьтә чиксезлеккә бер дә чик юк.
Беләсезме? Киңлек — чиксез, вакыт — чиксез.
Киңлек — чиксез. Ягъни аның чиге — чиксез,
Йолдыз арты йолдыз китә, тагын йолдыз...
Галактика арты тагын галактика...
Мәңге-мәңге бар син очып, ләкин галәм
Мәңге-мәңге чиксез булыр, төпсез булыр.

Лэкин мена шуңар һич тә башым житми:
Ничек инде чиксезлекнең чиге юк соң?

*Акчурин белән Карачурин, гаҗәпләнеп, бер-берсенә карашалар.)*

Вакыт — чиксез. Мәңге-мәңге галәм булган.
Терєклекнең башы да юк, ахыры да юк...
Безгә чаклы миллионнарча планеталар
Туып торган, яшәп торган, үлеп торган.
Бездән соң да булыр тагын чиксез дөнья,
Чиксез тумыш, чиксез яшәү, чиксез үлем.
Хәзер дә бар чиксез санда планеталар,
Чиксез тормыш, чиксез халык, чиксез кеше.
Галәм — чиксез, димәк, анда «мин» дә чиксез,
Карачурин, Акчуриннар — мәңге чиксез!
Лэкин мена шуңар һич тә башым житми:
Ничек инде чиксезлекнең чиге юк соң?

Акчурин. Чү, чү, Рувим, шулмы булды синең хөкем?
Карачурин. Әйе, шул-шул. Имеш, син дә, мин дә чиксез!
Файер. Ни булды соң? Нидән тора сезнең дәгъва?
Акчурин. Чү, чынлап та! Бәхәсебез нәрсә иде соң?
Оныткანмын. Белмисеңме, Карачурин?
Карачурин. Әйе, шул-шул. Мин дә, малай, хәтерләмим.
Акчурин. Әйдә, киттек. Бәлки, тагын искә төшәр.
Карачурин. Әйе, шул-шул.
Файер. Димәк, дуслар, әлегә нокта!

Тышта снаряд шартлый.

Акчурин. Нокта!

Тагын шартлау тавышы.

Карачурин. Нокта!

Ашыгып Конышко керә, чәчен учлап, сәкегә барып каплана.

Файер. Тукта, ни бар, Конышко дус?
Конышко, дим! Александр! Нәрсә булды?
Конышко. Сорап торма син дә, Файер! Беләсең бит!
Полкыбызны туздырдылар хәзер генә!..
Безнекеләр сезгә килеп кушылдылар.
Полк бетте... Йөз кырык ел гомер иткән
Данлы полк төште бүген исемлектән...
Чыгып кара! Безнекеләр елый анда!
Еламассың! Бу полк бит, Рувим туган,
Кутузовлар тарафыннан нигезләнгән!
Бородино кырларында кан койган ул,
Березина буйларында дан җыйган ул!
Наполеонны куып барып, поляк җирен
Немец җирен азат иткән полк бит ул!
Варшаваны үтеп чыгып, Берлин юлын,
Париж юлын үлчәп үткән полк бит ул!
Франциянең революцион көрәш рухын
Рус иленә алып кайткан полк бит ул!
Ярсу йөрәк — декабристлар үсеп чыккан,
Сенат алдын яңгыраткан полк бит ул!
Иске хезмәт! Кайда сиңа лаек хөрмәт?
Нинди полкны туздырдылар! Нинди полкны!
Комдивыбыз Санышевның йөзе чытык...

Аңар да бит бигрәк авыр, бигрәк авыр!
Басып тора исән калган өч йөз кеше...
Безгә приказ укыдылар... Шундый суык...
Шунда тора командарм Колоссовский,—
Безгә карап: «Булдырдыгыз! Әх сез!» диеп,
Кулын селтәп, акрын гына читкә китте...
Полк бетте... Командарм сүз дә әйтми,
Карап торып, ул да шуңар риза булды.
Нинди полкны туздырдылар! Нинди полкны!
Иске хезмәт! Кайда сиңа лаек хөрмәт?

Рация пипелдәве ишетелә. Файер икенче бүлмәгә чыга.

Акчурин. Байрагыгыз юк ич сезнең? Югалттыгыз?
Карачурин. Әйе, шул-шул. Әлек нәрсә карадыгыз?
Акчурин. Беләсеңме, Бородинода, канлы кырда,
Безнең армия бер әләм дә югалтмаган!
Карачурин. Әйе, шул-шул. Моның өчен указ бар ич,—
Полк әләмен югалттыңмы — полк түтү!
Акчурин. Миңа ышан! Бүгеннәргә байрак ышан!
Карачурин. Әйе, шул-шул. Полкларын туздырдылар.
Акчурин. Безнең полк боткасына кызыкканнар!
Карачурин. Әйе, шул-шул. Бездә паек шәбрәк, имеш!
Акчурин. Начар хуҗа йортын сата. Ахыр килеп...
Карачурин. Әйе, шул-шул. Таптый кеше бусагасын!
*(Конышко, сикереп торып, пычагына ябыша.)*
Конышко. Җитәр сезгә, кабахәтләр! Чинамагыз!
Юкса, менә! Каныгызга сусап тора!..
Акчурин. Монда герой! Анда нәрсә карадыгыз?
Менә байрак, мә, рәхим ит, немец агай!
Карачурин. Әйе, шул-шул. Хәзер мөмкин җенләнергә!
Бакса, менә байрак та юк, полк та... юк!
Конышко. Әх сез, этләр! Кара эчле хәшәрәтләр!

Граната алып кизәнә. Астахов килеп керә.

Астахов. Бу ни эш бу? Нинди гауга? Нинди тавыш?
Акчурин. Иптәш майор! Гранатадан дәрес бара.
Карачурин. Әйе, шул-шул. Ыргытуның техникасын...
Астахов. Ялган өчен трибуналга җибәрермен!
Артка борыл! Марш әйдә! Калай этәч!

Акчурин белән Карачурин чыгып китә. Астахов Конышкога ташлана.

Конышко. Иптәш майор...
Астахов. Нәрсә сиңа? Нәрсә? Нәрсә?
Конышко. Хәзер инде нәрсә эшлик, иптәш майор?
Нинди полкны, нинди полкны тараттылар!
Астахов. Син һаман да нигә монда? Мар-ш әйдә!
Юк, юк, китмә, Саша туган! Нәрәк әрни...
Әллә атылып үлим микән? Полк бетте...
Мин унбиш ел хезмәт иткән данлы полк!
Беләсеңме, комсомолга шунда кердем,
Шунда сөйдем, мәхәббәтем чәчәк атты.
Бөтен полк бергәләшеп, туем иттек,—
Шушы полкта туды минем улым, кызым...
Партиягә кердем шунда... Билет алдым.
Билет алдым... Шушы чакны, полк намусы —
Минем өчен яшәү ул, дип эчкән антым!..

Полк намусы! Әх, бармы соң дөньясында
Солдат өчен аннан бөек, изге нәрсә!..
Әллә атылып үлим микән?

**Конышко.** Иптәш майор!
Бездә генә түгел ич соң бөтен гаеп!
Без ул вакыт позициядә тора идек...

**Астахов.** Син һаман да мондамыни? Мар-рш әйдә!
Юк, юк, китмә, Александр! Аңламыйсың!
Бөтен гаеп бездә генә түгел, имеш!
Алай булса, гитлерчылар ничек үткән?
Полк штабы ничек калган чолганышка?
Син дә, мин дә күзле бүкән булган өчен!
Алга гына карау житми, артка да бак!
Уңга гына карау житми, сулга да бак!
Өскә кара, аска кара! Сугыш бит ул!
Штаб кайда? Нәрсә эшли? Онытканбыз.
«Штаб» диеп, аңар артык ышанганбыз...
Ул — безнең баш. Иң өтек бер бәҗәк тә бит
Гәүдәсеннән бигрәк башын, башын саклый!
Штаб, имеш! Утырганнар сапожниклар!
Ярый, бар да һәлак булып котылдылар...
Юкса барсын трибуналга! Юк, юк, атылам!

**Конышко.** Иптәш майор?

**Астахов.** Калдырыгыз хәзер мине!
Приказ бирәм сезгә, иптәш кызылармеец!

*Генерал-майор Санышев, ишектән кереп, карап тора.*

**Конышко.** Иптәш майор!

**Астахов.** Саша туган! Юк, юк, атылам!

**Санышев.** *(Алга узып)*
Нәрсә, майор, шизофрения башландымы?
Нигә болай мавыктыгыз пугач белән?

**Астахов.** Әйе, иптәш полковник... мин...

*Санышев ымлавы белән Конышко чыгып китә.*

**Санышев.** Шулай диген!
Кем сез, майор? Командирмы? Тәти кызмы?
Солдатларга ничек үрнәк күрсәтәсез?
Атылам, имеш! Әйдә, без дә карап торыйк!
Тондырыгыз берәр пуля тинтәк башка!
Хәер, булмас. Ташка ничек пуля үтсен!
Әх син җүләр! Вадим Ильич! Шундый чакта
Суга төшкән тавык төсле ләпшердәдең!
Капельмейстер Харитонов дисәң инде...
Аңар берни әйтә алмыйм... Башка нәрсә...

**Астахов.** Нәрсә булды? Әллә аның...

**Санышев.** Нәрсә булсын?
Подполковник Харитонов атылып үлгән!

**Астахов.** Кайчан? Ничек?

**Санышев.** Сезнең полк таратылгач...
Күзендә — яшь, барабанын кочаклаган...
Кан буялган башындагы ап-ак чалга...
Үлем — җиңел, сыңар пуля житә аңа!
Шулай да мин Степанычны гафу итәм,—
Чөнки аның моңар азрак хакы да бар.
Илле биш ел полк тынлы оркестрына
Дирижерлык иткән кеше. Илле биш ел!

Ул тәүге кат дирижерлык иткән чакта
Минем әткәй тавык оясын кармалаган.
Бер үк полкта илле биш ел, илле биш ел!
Ниләр күреп, ниләр генә кичермәгән!
Туган полкын бетерделәр, йорты тузды.
Һәлак итте Степанычны шушы кайгы...
Полк намусы — аның өчен бөтен гомер!

А с т а х о в. Ә соң менә минем өчен? Минем өчен?

С а н ы ш е в. Ә соң менә минем өчен? Әллә, майор,
Монын өчен миңа рәхмәт әйтерләрме?
«Ахх, Санышев, ничек моңар ирештегез?»
«Ахх, Санышев, сезгә, туган, орден лаек!»
Юкка гына женләнәсең, Вадим Ильич,
Әллә миңа жинел диеп беләсеңме?
Бүген минем дивизиямдә тирән кайгы...
Сугышчылар, командирлар борчылалар.
Безнең данлы дивизиянең бер полкы юк!
Өзелеп калды дивизиянең сыңар кулы.
Китерерләр башка полк. Ләкин ансы
Табигый кул түгел инде, протез гына.
Бу полк соң синең генә полкыңмыни?
Киндер ыштан, чабатадан, түбәтәйдән
Үндүртенче елны мин дә, Вадим Ильич,
Килеп бастым шушы полк флангысына.
Айкап чыктык Пруссиясен, Галициясен,
Кичеп чыктык Карпат тавы үткелләрен.

А с т а х о в. Әйе, иптәш полковник, сез...

С а н ы ш е в. Беләсезме?
Мин Казанда, революция көннәрендә,
Солдатларны үзебезнең якка өндәп
Йөри идем шушы таныш дивизиягә.
Аның бөтен полклары безгә күчте.
Беләсездер Сөембикә манарасын? —
Борма-борма тар баскычтан үрләп менеп,
Шушы полк каһарманы, татар егете,
Элеп куйган манарага кызыл байрак.
Шушы байрак, шушы нурлы кызыл бәрхет,
Тәбрикләде Октябрьның якты таңын!
Соңрак аны менеп алып манарадан,
Дивизиягә бүләк иттек. Шуны чигеп
Полк әләме ясадылар... Беләсезме?
Сезнең генә кайгыңмыни? Мин дә елыйм.
Мин өчләтә кайгы чигәм, иптәш майор!
Әмма дөнья бер дә алай начар түгел,
Өмет белән тулы һаман минем күңел!

А с т а х о в. Өмет белән?

*Ишектән генерал-лейтенант К о л о с с о в с к и й керә. Сәламләп, торып басалар.*

К о л о с с о в с к и й.
Исәнмесез тагын бер кат...
Сез — Астахов бугай, майор?

А с т а х о в. Әйе, Астахов.

С а н ы ш е в. Махсус укчы батальонның командиры.

К о л о с с о в с к и й.
Ярый. Яхшы.
*(Кесәсеннән газета чыгара.)*
Менә моны танайсызмы?
Бу тип сезнең якын иптәш булган икән.

Астахов. Чү! Бу — Вәсил. Бу... бу безнең Булатов бит!
Әйе. Комсорг. Нәкъ шул үзе! Ничек болай?

Колоссовский.
Менә шулай! Бүген генә кулга төште.
Немец фронт газетасы — «Нах Остен» бу.
Күрәсездер Булатовны? Нинди көләч!
Өстә текст: «Германиягә минем бүләк».
Монсы нәрсә? Күрәсезме, менә монсы!

Астахов. Байрак!

Санышев. Байрак?

Колоссовский.
Таныйсызмы? Сезнекеме?

Астахов. Танымыйча! Һич шөбһә юк!

Санышев. Нәкъ шул үзе!

Колоссовский.
Димәк, сезне сатучылар булган икән.

Астахов. *(Кесәсеннән рәсем чыгара)*
Иптәш генерал-лейтенант, чыдый алмыйм!
Хөкем итәм хәзер үк шул хаин җанны!
*(Рәсемне түшәмгә чөеп, атып җибәрә.)*

Колоссовский.
Чү, чү, майор!

Санышев. Тагын нинди хулиганлык?

Астахов. Иптәш генерал-лейтенант, гафу үтенәм!

Колоссовский.
Гафу иткән — гафу белән сату иткән,—
Дисциплина җитми сездә, иптәш майор!

Санышев. Сезгә инде ничә кабат кисәтелгән!

Астахов. Кичерегез! Чыдый алмыйм, йөрәк әрни!
Ничә еллар бергә ашап, бергә эчеп,
Югын-барын һаман бергә уртаклаштык!
Бер ай гына аерылышып торсак та бит,
Күрешкәндә кочаклашып үбешә идек!
Вәсил, Вәсил! Минем өйдә күпме булды,
Килгән саен сөйде минем балаларны,
Алар шуңа «абый» диеп сарылдылар...
Әй саф җанлы бер гөнаһсыз балакайлар!
Күпме эчте минем чәйне, эчемлекне,—
«Ханым» диеп, хатынымның кулын үпте!
Елан икән! Хәер, нигә аптырарга? —

Колоссовский.
Ләкин шуны онытмагыз: бу бит әлегә
Безнең өчен суга язган дәлил генә.
Берәр төрле провокация булып чыкса?
Гестапоның шантажларын белмисезме?
Димитровка булган судны хәтерләгез.
Тапшырырбыз разведкага. Эзләнербез.
Тикшерербез. Төпченербез. Ачыкланыр.
Кабат әйтәм, татарларны яхшы беләм:
Үләр, торыр, тагын үләр — илен сатмас!
Үзен суяр — хаин дигән исем такмас!
Менә нәрсә: монда, сезнең дивизиядә
Бер егет бар, үткен егет, башлы егет.
Полкта үзен «философ» дип йөретәләр.
Фамилиясе... җен кыргыры... онытканмын.

Астахов. Файер. Файер. Рувим Файер. Минем егет.
Менә дигән радистыбыз. Чакыраммы?
Монда, күрше землянкада.

Колоссовский.
Чакырыгыз.

Астахов. Файер! Рувим!

Бүлмәдән Файер чыга, аптырап, каушап кала.

Файер. Иптәш майор! Командарм! Колоссовский!
Иптәш, иптәш... генерал-лейтенант...

Колоссовский.
Фамилиягез?

Файер. Файер. Рувим Самсонович.

Колоссовский.
Немец телен беләсезме?

Файер. Үз телем күк.

Колоссовский.
Яхшы. Тагын нинди телне?

Файер. Һу, күп телне!
Алты яшьтә инглиз телен кимергәнмен,
Җиде яшьтә французча елаганмын.
Сигез яшьтә итальянча кикергәнмен,
Тугыз яшьтә финчә икмәк сораганмын.
Ун яшь чакта грекча радио тыңлаганмын,
Унбер яшьтә испан жырын жырлаганмын.
Калган чорны инде үзем ачык беләм:
Чөнки ничек өйрәнгәнем хәтеремдә.
Яхшы беләм латин телен, гарәп телен,
Аңлый алам төрек телен, фарсы телен.
Укый алам поляк, болгар телләрендә,
Чехча беләм, һәм шведча... венгр, румын,
Әрмән, грузин, татар, якут

Колоссовский.
Уй-уй! Җитте!
Сезнең кебек полиглотка эшең төшсә!..
Менә нәрсә, Файер иптәш. Бүген кичен
Сезне армия штабында көтәчәкмен,—
Миңа, туган, сезнең кебек кеше кирәк!

Тышта снаряд шартлап, землянка ишеген ачып җибәрә.

Санышев. Кар ява, кар!

Астахов. Кыштан хәбәр!

Файер. Беренче кар!

Колоссовский.
Кар ява, кар!

Землянка ишеге төбенә барып басалар.

Санышев. Шатлык белән!

Астахов. Күбәләк кар!

Файер. Атлый сугыш кырларына Кыш-генерал!
Яу әйдә, Кар, немецларга акыл өйрәт!
Фронтларны карап йөри генерал Кыш!
Озакламый безне яклап, һөҗүм итәр!

Колоссовский.
Шулаймыни? Сезне монда, Файер иптәш,
Әмма белеп «философ» дип атаганнар...
Беренче кар! Кышның тәүге хәбәрчесе!
Күбәләк кар! Язның рәхмәт чәчәкләре!

Бу кар бит ул, туганкайлар, яз дигән сүз!
Алмагачтан чәчәк коела, күрәсезме?
Җәй дә үтте, көз дә узды... Белоруссия,
Смоленщина кырларында җиргә аккан
Тирләребез, каннарыбыз, яшьләребез,
Җиңелүләр, хурлык белән чигенүләр
Барсы калды, барсы калды кар астында!
Кил, рәхим ит, яу син әйдә, беренче кар!
Алдыбызда хәзер, дуслар, чиста җәймә,
Ап-ак булып җәелеп яткан көмеш сәхнә.
Шул ак кырдан алга китәр якты, киң юл,
Чыгып бу юл Мәскәвебез итәгеннән,
Барып керер илбасарлар Берлинына!
Әх, көмеш кар! Шатлыклары, рәхәтләре!
Җиргә коела язның тәүге чәчәкләре!

*Дүртенче җыр тәмам.*

## Блокноттан

●

Әй, туган җир, синең чибәрлегең,
Иркенлегең, көчең, сафлыгың!
Сиңа булсын йөрәк тирәнлегем,
Шигърияте, кайгы-шатлыгым!
Әй, газиз җир, синең чәчәкләрең,
Чыклы иртәң, тыныч кичләрең...
Сиңа булсын җырым, мәхәббәтем,
Батырлыгым, көчем, хисләрем!

*Июнь, 1941*

●

Ни бар дисәң миндә, санап чыгам:
— Йөрәк көчем, кайнар каным бар;
Таңгы балку, кичке шәфәкъ сыман,
Шигъриятта янган җаным бар.
Тагын ни бар? — йөрәк җырларымда
Чиста ак нур — идеал яктым бар;
Бу зур сугыш-сынау кырларында
Җиңелмәскә дигән антым бар.

*Июнь, 1941*

●

Хисап ачтым... Төзәп мылтыгымны
Бер фашистны җиргә кападым.
Шулай итеп бүген җырчылыкны
Сугышчылык белән расладым.
Бәлки, бер дә сугыш мәйданында
«Шәп снайпер» данын җәймәм мин,
Тик шулай да эш бар мактанырга:
Хисап ачтым бүген — мәргән мин!

*Август, 1941*

●

Сак бул, иркәм, хисләр сыналганда
Мәхәббәтең һич тә сулмасын.
Мин юк чакта берәр сыңар карга
Синең талга килеп кунмасын!

Мин бит синең яшьлек сафлыгыңны
Кулга корал тотып саклаучы;
Сугышларда кайгы, шатлыгымны
Синең исмең белән баглаучы.

*Август, 1941*

●

Ян син, жырым, ләкин күмерләнмә,
Зөһрә йолдыз кебек нурлы бул.
Сугышларда мең-мең күңелләргә
Мәхәббәтең белән тугры бул.

Ак син, жырым, ләкин акрынланма,
Салкын чишмә төсле житез бул.
Калма артта, жаннар ашкынганда
Сафларыбыз белән тигез бул!

*Август, 1941*

●

Юк, мин һич тә истән чыгармамын,
Канлы шоссе, яшьле урманны;
Үлгән дуска карап, чыдам жаным
Газапланып, әрнеп узганны...

Гомер буена истән жибәрмәмен
Башкаемнан нинләр үткәнне;
Авылларның моңсу тирәкләрен
Чигенгәндә кочып үпкәнне...

*Октябрь, 1941*

●

Үстем синең юмарт кулларында,
Туган илкәй, минем хисем пакь,
Әткәм, бабам йоклый туфрагында,
Иң гадел хак жирдә синең хак!

Сугыш сулый иркен күкрәгендә,
Елый кырда кышкы буран, жил...
Ут бар жанда, яшь бар күзләремдә,
Әй, газиз жир, минем туган жир!

*Февраль, 1942*

●

Күп булса да йөрәк ялкыннарым,
Чит-ят җиргә чәчәр җылым юк.
Үтсәм дә мин кургаш яңгырларын
Сыкранырга туган җырым юк!

Килде-китте җилдә тибрәнергә,
Думбырамда артык кылым юк.
Көрәш дәрте ярсый хисләремдә,
Сызланырга туган җырым юк!

*Февраль, 1942*

●

Туган халык басты батыр сафка,
Калма, иптәш, син дә алдын бул.
Куркынычта исемең, даның сакла,
Һөҗүмнәрдә ут һәм ялкын бул!

Туган илдән сәләт, илһам алдың,
Кутәрелдең тауга тиң булып.
Эттән туган фашист-илбасарның
Көлен күккә күтәр җил булып!

*Февраль, 1942*

●

Омтыл, иптәш, һаман көнбатышка,
Батырлыгың белән алдын бул.
Китмә артка, чикмә бер карыш та
Халкыбызга синең антың шул!
Эх, бармы дан, бармы җиңелгәнгә
Туган өй һәм газиз туган җир?
Юк һич артта әрнеп чигенгәнгә
Рәхәтләнеп иркен сулар җир!

*Апрель, 1942*

●

Эх, зур минем, һич тә улчәнмәгән,
Илем өчен булган хәсрәтем,—
Зур шулай ук бүген үч һәм нәләт.
Дошманнарга каршы нәфрәтем.

Күп гаять тә йөрәк түрләремдә
Дус-ишемә рәхим-шәфкатем,—
Ялкын булып ярсый күкрәгемдә
Дошманнарга каршы нәфрәтем.

*Апрель, 1942*

●

Әх, куркак җан, сугыш тәтененнән
Котын чыгып артка качтың син,
Бүген нәрсә? — халык хөкеменнән
Иң дансыз бер үлем таптың син.

Синең урның һич тә дөнья түгел,
Син, чүп булып, читкә түгелдең.
Кара җиргә түгел, комга түгел,
Каргыш белән үчкә күмелдең.

*Август, 1942*

# ФРОНТ ЮЛЛАРЫНДА

**СУГЫШЧАН ХАТИРӘЛӘР**

Иртәнге сәгать алтыда посттан кереп, күз йомарга да өлгермәдем, армия гадәтенчә, килеп үкчәгә тибә башладылар.

— Тор, тор! Сугыш!

— Ә? Ә? Сугыш? Кем белән?

— Германия белән! Әйдә тизрәк митингка!

Сибелеп яңгыр явып тора. Аэродромга хезмәт итү батальонының комиссары политрук Александрин уң кулындагы фуражкасын болгый-болгый речь тота.

— Фашизм, күп еллар буе безнең каныбызга тоз салып, безнең күзебездә арпа булып торды. Гитлер Германиясе, безгә һөҗүм итеп, үзенә-үзе үлем карары чыгарды.

...Якындагы шоссе буйлап, араларында дистанция дә калдырмыйча, тоташ бер агым булып, көнбатышка таба ябык машиналар агыла. Безнең аэродром самолетлары, бомбалар төяп, дошман өстенә ашыгалар. Өстән, төркем-төркем булып, безнең истребительләр очып китә.

Политрук янына барам.

— Иптәш политрук, «Сугышчан листок» чыгарасы түгелме?

— Әйе, әйе. Ләкин бит син төн буе постта торган кеше. Башта берәр сәгать ял ит, ә без материаллар әзерли торырбыз.

Кая инде ул ял итү! Казармага керү белән бала чактан ук шигырьләр язып килгән калын дәфтәрләремне чыгардым да яза башладым. Ләкин башка һични керми, фикер — таркау. Язам, сызам, язам, бозам. Озак азаплана торгач, шулай да ике строфа шигырь килеп чыкты:

Эх, сөйлә, җыр, фронт хакыйкатен,
Көнебезнең чорга тиңлеген,—
Йөз юл белән — эпос вакыйгасын,
Үн сүз белән — роман киңлеген!

Минем илһам канлы тартышулар,
Бәрелешләр өчен саклаңды;
Ни бар бүген миндә — барысы шуңар,
Җырга да бит сынау башланды...

Иртәнге сәгать җидедә «Сугышчан листок» казарма алдындагы витринада эленеп тора иде инде. Сәгать сигездә исә безнең өстә һава сугышы булды. Иртәнге уннар тирәсендә, арыш кырын тирә-яктан чол-

гап алып, шпион тоттык. Шпион минем якташым чуваш егете Кортюковның корсагына атып өлгерде. Беренче яралы, беренче кан...

Аннан соң, дәһшәтле төн... Безнең аэродромны йөзләп немец самолеты бомбага тотты. Эссе кояш нуры астында тиргә бата-бата тузанлы юлдан ачу һәм ярсу белән артка чигенүләр. Витебск, Смоленск, Ельня, Вязьма... Яңадан алга ыргылу... Яңадан чигенү, чигенү...

> «Россия»,— дисең,— «чик юк бер дә монда,
> Ул гаҗәп зур, иркен, киң»,— дисең.
> «Өлкә түгел, хәтта бер район да
> Дания кебек илгә тиң»,— дисең.
> Тик бел, иптәш, карап көнбатышка,
> Күзләребез яшькә тулганын;
> Тулы бер ил түгел, бер карыш та
> Шул кадәр үк изге булганын!

Ярцево янында яраландым, контузия алдым. Мәскәү госпиталеннән Казанга кайттым. Кайтуыма ук шагыйрь Нур Баянны фронтка озату кичәсенә чакырдылар. Безнең каләмдәш дусларның күпчелеге фронтта иде инде.

Салкын декабрь узды, буранлы гыйнвар үтте, яз сулышын сулап, март житте. Апрель башында Язучылар союзына фронттан шагыйрь Шәйхи Маннурның озын хаты килеп төште. Шәйхи Маннур ул хатта шагыйрь Вәдүт Мифтаховның геройларча һәлак булуы турында язган иде. Бүтән иптәшләр ничек? Исәннәрме алар, кайда йөриләр? — Бу хакта мин бөтенләй белми идем. Бары тик җәен, яңадан фронтка китеп, татар телендә чыга торган «Ватан өчен» исемле фронт газетасында эшли башлагач кына миңа күпчелек иптәшләрнең язмышы билгеле булды. Безнең язучылар,— исемнәрен санасам бик озакка китә инде,— кайсылары алгы позициядә сугыша, кайсылары фронт газеталарында эшли икән. Кыскасы, безнең язучыларның иң зур күпчелеге, кулларына корал тотып, Ватан намусы өчен, илебезнең азатлыгы, бәйсезлеге өчен көрәш утына ташландылар. Ләкин безне Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Нәби Дәүлиләрнең, яшь шагыйрьләрдән Зәки Нуриның һәм Әнәс Галиевнең язмышы бик борчый иде. Алар хәбәрсез югалдылар. Аларның авыр язмышы сугыштан соң гына мәгълүм булды. Муса Җәлил һәм Абдулла Алиш Моабит төрмәсендә геройларча һәлак булдылар. Нәби Дәүли һәм Әнәс Галиев, үзләренең язучы икәнлекләрен яшереп, немец әсирлегенең иң авыр, иң каты газапларын кичергәннәр. Зәки Нури легендар Заслонов отрядында разведкачы-партизан булып сугышып йөргән.

Озакламый фронтларда батырларча һәлак булган дусларыбыз турында хәбәрләр килә башлады. Без Нур Баян, Рахман Ильяс, Фатих Кәрим, Гадел Кутуй, Хабра Рахман, Мөхәммәт Әблиез, Мөсәгыйть Мостафин, Габдулла Галиев, Мансур Гаязов, Мөхәммәт Әхмәтгалиев, Әгъзам Камал иптәшләрнең якты истәлекләре алдында башыбызны идек.

Гәрчә мин сугышка чаклы Фатих Кәримне күп укысам да, аның белән таныш түгел идем. Сугыш вакытында без аның белән бик еш кына хатлар языша башладык. Хатип Госман белән Гомәр Бәширов, мин хезмәт итә торган миномет дивизионына килеп, мине редакциягә алып киттеләр. Күп тә үтми безнең редакциягә, Валдай шәһәре янындагы нарат урманына, Мирсәй Әмир белән Афзал Шамов килде. Афзал Шамов белән без икенче тапкыр Калинин өлкәсенең Лоховка авылында очраштык. Шул ук көнне без Абдулла Әхмәт белән солдат боткасы ашадык. Кызык кына булды бу очрашу. Мин килгәндә ул йоклап ята иде.

— Каһәр төшкән чебеннәр! Тимәгез сез аңар. Ул йокласын. Ул арыган. Менә нинди тәмле йоклый,— дип кычкырган гына идем, язучы Абдулла Әхмәт күзен ачып җибәрде. Күрештек. Бик яхшы булды. Ва-

тан өчен саф канын түккән һәм хәзер дә фронтта булган язучы белән күрешү минем өчен бик яхшы булды.

— Шәйхи абый Маннур кайда? — дип сорадым.

— Ул алгы сызыкта. Сугышчылар белән әле күптән түгел генә китте. Абдулла Әхмәтнең өстәленә күзем төште. Яшел буяуга буялган ике уенчык танк тора. Кызык. Каян килгән алар?

— Балаларым җибәргән. «Әти, бу танк бик яхшы танк», дигәннәр. Саклап торам. Телимсез, хатларын укыйм.

Гади генә беркатлы тел белән язылган балалар хатын укудан да рәхәтрәк нәрсә бармы? Белмим, юктыр.

Сугышчы-язучы фронтта иҗат итә. Иҗат итә һәм артында үз балаларының җылы сулышын тоя.

— Мылтык та, каләм дә дошман өчен үлем китерергә тиеш,— ди язучы. Күп тә үтми, Афзал Шамов та кайтып керде... Бу язучы иптәшләр татар телендә чыга торган фронт газетасында эшлиләр. Алар һәрвакыт иң алгы сызыкта, сугышчылар белән бергә булалар. Аларның сүзләрен тыңлыйлар, җырларын ишетәләр. Шулай итеп, киләчәк әсәрләренең геройларын өйрәнәләр һәм бүген исә, алар белән сугышның авыр көннәрен бергә кичерәләр.

Фронтовик та алар белән бергә уйлый, аларның моң һәм шигърияте аңлый. Күп вакыт төнлә землянкада берәр сугышчы Шәйхи Маннурның шигырен укып җибәрә. Икенчесе исә шул ук вакыт көйгә салып җырлый:

> Мин кайтырмын инде төн үткәч,
> Каһәр төшкән дошман дөмеккәч...
> Бәлки тагын... таңнар атканда —
> Сине сагынып китеп ятканда.

Аннан соң Хатип Госман белән Казанга кайттык. Без кайтканда Хатипның күршесе Гадел Кутуй чемодан өстендә утыра, мине хәзер, мине хәзер фронтка чыгып китәргә генә тора иде. Кердек, кочаклаштык, үбештек. Кутуй әйтә:

— Эх, дуслар, сугыштан соң без иң якын дуслар, иң якын туганнар булып яшәячәкбез! Ярый, хушыгыз!

Аның бу «хушыгыз» сүзе мәңгелеккә булды.

Янадан фронтка кайттым. Кайту белән күршедәге запас полкта Гамир Насрыйның полк комсоргы булып хезмәт итүен белдем. Күңелле очрашу! Сталинград герое, яраланган, телгәләнеп беткән, ләкин элеккечә саф һәм омтылучан Гамир!

Сугыш инде бетеп килә. Киттем Берлинга, эзлим Ибраһим Газиларны, Гариф Галиевләрне... Таптым. Берлин янындагы кечкенә генә Эберсдорф дигән авылда татарча газета чыгарып яталар. Күрештек, сөйләштек.

## ТАГЫН БЕРЛИНДА

Күрдем шикелле мин ул нәләт төшкән Моабитны, күрдем бугай мин аны!

1945 елның маенда татар телендә чыга торган «Фронт хакыйкате» газетасы редакциясеннән командировка алып, Берлинга барырга җыендым. Без ул вакыт Штеттиннан ерак түгел генә Христиненберг дигән шәһәрчектә тора идек. Редактор Гани Гыйльманов минем китүемә бик үк риза булмады, әлбәттә.

— Берлин безнең Икенче Белоруссия фронты зонасына керми. Рядовой солдат булгач, сине анда җибәрмәсләр. Тоткарлар да бер запас полкка озатырлар. Аннан соң газета эше...

Газета эше! Эх, иптәш майор, Берлинга барып житү газета эше түгелмени? Без бит Берлинга житү өчен дүрт ел кан түктек. Белоруссия урманнарыннан, Пинск сазлыкларыннан чигендек, Вязьмага килеп житеп, атаклы Бородино аркылы уздык. Безнен өстән өзек-өзек гүелдәп дошман самолетлары үтә иде. «Мәскәүгә»... ди идек без һәм, тирән ачу белән тешне кысып, тынып кала идек. 1941 елнын көзендә мин Мәскәүдә госпитальдә яттым. Төннәрен безнең госпиталь янына фашист бомбалары төшә иде. 1941 елнын 14 октябрендә Мәскәү камалыш хәлендә дип игълан ителде. Шул көнне мин аксап-туксап Казан вокзалына киттем. Мәскәү елгасы күпереннән чыккач, Кызыл Мәйдан аркылы уздым. Хәзер менә минем Берлинга барасым килә, жиңүче армиянен рядовой солдаты булып Берлин урамнарыннан атлап үтәсем килә.

Аркага капчыкны тактым, блокнотны кесәгә тыктым, олы юл өстенә чыгып бастым. Бераз «тавыш биреп», ягъни кул күтәреп торганнан соң машина очрады.

— Сез кая? — дип сорадым мин шофердан.

— Берлинга. Ләкин без анда туры бармыйбыз. Шпандауга керәсе бар. Наунга да кагылабыз.

— Ярый, бик шәп! Минем өчен барыбер,— дидем мин һәм кузовка менеп утырдым.

Берлинга! Элек безнен бөтен армиянен сугышчан лозунгысы булган бу сүз хәзер гади солдатнын көндәлек сүзенә әверелде.

Шактый озак бардык. Безнең машина тәгәрмәче астында чакрым арты чакрым сузыла, артка таба Герман жире шуыша. Наунны үттек, озакламый Берлин.

Берлинга көнбатыш яктан барып кердек.

— Станция Берлин,— диде шофер,— машина сулга борыла, сина турыга китәргә!

Асфальт жәелгән киң урамда япа-ялгыз басып калдым. Менә шул икән ул Берлин дигәннәре! Тәрәзәләрдә, йорт түбәләрендә ак флаглар эленеп тора. Күрән төскә буялган бер йортның стенасына: «Hitler ist schuldig» дип язылган. Әлбәттә, бу ак флаглар, «Гитлер-бандит» дигән язмалар Германия һәм Берлинның язмышы сугыш кырларында хәл ителгәч кенә килеп чыккан нәрсәләр.

Урам буйлап барам, әллә ничек, йөрәккә шом сала торган өзлексез улау тавышы ишетәм. Югарыга күтәрелеп карыйм: озын жиз торба. Берәр завод морҗасы булса кирәк. Күрәсең, жилдән шулай улап тора. Озак тыңладым мин бу улау тавышын. Китәргә җыенган идем, янымда басып торган олы яшьләрдәге бер немецка күзем төште. Беләгенә ак ситца бәйләгән, башында иске шляпа, кулында — зонтик-таяк. Немец, мине күргәч, әллә ничек гаепле төстә елмаеп куйды һәм кулы белән моржага изәп:

— «Deutschland weinet».— диде.

Германия елый, янәсе. Нинди Германия турында әйтте икән соң ул Herr?

Хәер, мин әле көнбатыш зонада идем. Моны бераз баргач кына аңлап алдым. Урамда инглиз солдатлары күренә башлады, америкалылар утырган машиналар узып китkәләде.

Менә сул якта озын таш стена сузылып китә. Стена гаять биек булуга карамастан, өстенә козырек шикелле тышка чыгып торган чәнечкеле тимер челтәрләр куелган. Һәр ун метр саен диярлек биек башнялар. Урта гасырнын феодаль замоклары шикелле дәһшәтле, шомлы булып торган таш крепость. Монын элек төрмә булганлыгы әллә каян күренеп тора. Әчкәрәк, готика стилендә салынган таш манара гына күренә. Чиркәү түгел микән? Анда-санда стена жимерелгән. Стенанын бер жирендә фашистлар язып калдырган лозунг бар: «Berlin bleibt deutsch».

Әлбәттә, Берлин немецларныкы булып калды, ләкин фашистларныкы түгел!

Мин бу юлларны язганда гына түгел, Муса Җәлил белән Абдулла Алишның язмышы билгеле булганнан бирле һаман шушы төрмәне күз алдыма китерергә тырышам. Хәтерне эшкә җигеп, бу таш крепостьның аерым детальләрен искә төшереп азапланам. Ләкин еллар үткән, вакыт җиле хәтердән артык-портык нәрсәләрне себереп аткан. Аннан соң шунысы да бар: җиңү бәхете белән канатланып йөргән солдат ул чакта ниндидер бер төрмә белән булашып торыр идеме?

Әгәр дә ул Моабит булган булса? Юктыр, Берлинда бер генә төрмә булганмыни? Бөтен җире чәнечкеле тимер чыбык белән уратып алынган Германиядә, бигрәк тә Берлинда, квартал саен төрмә булганлыгын кем белми соң?

Бәлки шул үзедер дә. Чөнки аннан ерак түгел мескен генә торган ике-өч катлы йортлар фонында ул мәчеләр янында яткан гигант юлбарысны хәтерләтә.

Тарихта дәһшәтле исемнәре калган берничә атаклы төрмә бар. Лондонда «Үлем манарасы» дигән исем алган Тоуэр, Парижда 1789 елны баш күтәргән халык тарафыннан җир белән тигезләнгән Бастилия, патша Россиясендә безнең бик күп гүзәл акыл ияләре интеккән Петропавел крепосте, Испаниядә — терелэй яндырылган кешеләрнең көлләрен әле дә үзендә саклаган Альказар крепосте... Шушы дәһшәтле исемнәр янына хәзер Моабит төрмәсе өстәлде!

1957 елның июнь башында, декада вакытында Мәскәүдә мин немец язучысы Эдвард Цак белән очрашу һәм аның белән сөйләшү бәхетенә ирештем. Мин аңа үземнең Берлинда булуымны, анда Наун аркылы барып керүемне һәм гаять зур төрмә күрүемне әйттем һәм: «Моабит шул түгел идеме икән?» — дип сорадым. Эдвард Цак елмаеп куйды һәм немецларга хас дипломатик мөлаемлек белән җавап бирде:

— Мөмкин, мөмкин. Булуы мөмкин...

Хәер, хикмәт андамыни? Мин безнең дусларыбыз, каләмдәш иптәшләребез Муса Җәлил һәм Абдулла Алиш газап чиккән Берлинда булдым. Без Берлинга озак килдек, кан коя-коя, авыр газаплар, канлы сугышлар юлыннан килдек. Бу юлда безнең бик күп иптәшләребез егылып калды. Безнең Берлинга бару юлыбызда моңсу курганнар булып Фатих Кәрим, Гадел Кутуй, Нур Баян, Мөхәммәт Әблиев, Рахман Ильяс, Хабра Рахман, Александр Бенедиктов, Вәдүт Мифтах, Әгъзам Камалов, Мансур Гаяз, Мөхәммәт Әхмәтгалиев, Габдулла Гали, Касыйм Вахит, Әдһәм Әмин каберләре калды. Ләкин без, һәлак булган дусларыбыз өчен күзләрдә кайнар яшь һәм йөрәктә тирән хәсрәт саклаган язучылар, Совет Армиясе составында, һаман алга, Берлинга омтылдык. Без, язучылар һәм шагыйрьләр, Ак диңгездән алып Кара диңгезгә чаклы сузылган озын фронт сызыгын алга этә-этә көнбатышка бардык. Һәм без, 1945 елның маенда төрлебез төрле яктан, төрле вакытта Берлинга килеп кердек. Әгәр дә без бәхетле бер очраклылык белән 25—30 язучы Германия башкаласына бер үк көнне, бер үк сәгатьтә килеп кергән һәм бер-беребез белән очрашкан булсак, Рейхстаг хәрабәләре арасында яки Бранденбург капкасы төбендә татар язучыларының чираттагы гомуми җыелышын үткәрә ала идек. Тылда калган иптәшләр турында «гафу ителерлек сәбәпләр белән килә алмадылар» дияр идек һәм теләсә нинди мәсьәләне хәл итәргә дә безнең кворум җиткән булыр иде.

...Ике катлы автобуска утырып, озак кына барганнан соң Унтер ден Линденга килеп чыктык. Гаять киң һәм озын проспект. Каршыда — уң якта — Рейхстаг. Сул якта — элекке Рейхс-канцелярия, гитлер резиденциясе. Көн бик эссе. Тамак кипте, эчәсе килә. Элек без Берлинга барып «Шпрее суын эчәчәкбез әле» дисәк тә, аның сап-сары булып тор-

ган болганчык пычрак суын авызга алаесы килми. Каян һәм ничек су табарга?

Рейхстаг янына барып житкәч, мәсьәлә бик жиңел хәл ителде: бик күп немец хатын-кызлары Рейхстаг төбенә чиләк белән су алып килгәннәр һәм кергән бер кешегә кружка белән су тәкъдим итеп торалар. Без, Совет сугышчылары, Америка, Англия, Франция солдатлары туйганчы су эчәбез дә, хатыннарга, туташларга чын күңелдән рәхмәт әйтеп, Рейхстаг эченә кереп китәбез.

Стеналар, стеналар! Ходаем үзең сакла! Йөзләрчә бүлмәнең стеналары, түшәмнәре, ишек-тәрәзә яңаклары гына түгел, хәтта идәннәре дә безнең солдатларның истәлек язулары белән тулган. Кайсы карандаш белән, каләм белән, кайсы акбур, кайсы күмер белән язган. Кайсыберләре «минем язуым гына калсын» дигән шикелле таш стенага тирән итеп чокып язган. Түшәмнәр гаять биек. Ләкин анда да инә төртер жир юк. Истәлегемне кая языйм? Урын юк. Юк урын, вәссәләм! Урын эзли-эзли, Рейхстаг бүлмәләрен карый-карый, этаж арты этаж югарыга менәм. Менә, ниһаять, түбә. Алдымда — купол, купол өстендә — башня, башня өстендә — Жиңү байрагы. Рейхстаг түбәсеннән бөтен Берлин дип әйтерлек күренә. Хатирәмне язар өчен урын эзләп, яңадан Рейхстаг бүлмәләре буйлап йөрим. Шулай да таптым һәм язып калдырдым...

Берлинда өч көн буталып йөрдем. Аркада капчык кисәге, янда сумка, сумкада — блокнот. Егет солдат Швейк шикелле йөрим дә йөрим. Ике катлы автобуслар кая бара — сорап тормыйм, утырам да китәм. Транспортка түләргә маркаларын гына житсен. Шюнвейде бистәсендә йөрим. Зур бер йортның икенче катындагы квартир тәрәзәсеннән ирлехатынлы ике немец карап тора. Алар белән исәнләштем дә, Унтер ден Линдерга ничек барырга? — дип сорадым. Алар жавап урынына миңа озын җепкә тагылган әчкеч тоттырдылар һәм, ишекне ачарга кушып, үзләре янына керергә чакырдылар.

Кердем, әлбәттә. Ишек төбендә немец басып тора. Кул биреп күрештем. Ул мине квартирасына алып керде.

Болар әле кичә генә Кельннән кайтканнар икән. Юлда аларның бик күп кыйммәтле нәрсәләрен инглиз солдатлары талап алган.

— Хурландык,— ди, Негг әйтә,— сезнең белән без дүрт ел сугыштык, ләкин мине сездән качып эвакуациягә киткән чакта инглизләр талады. Шуңа күрә, борылдык та кичә Лиза белән кире Берлинга кайттык. Сезнең ичмаса безне җәберләргә хакыгыз да бар!

Ни сөйли бит. Бездә егылганны тәпәләмиләр. Җәберләргә тагын. Минем конфетларым бар иде. Фрау Анна Лиза тиз генә чәй кайнатты. Мин дә ачыккан идем. Рәхәтләнеп ашадык, эчтек тә Негг мине автобуска озатып куйды.

# ХАТЛАР

## *Гали Халитка*

**12 июнь, 1945 ел, Штеттин**

Иптәш Халит!

Минем иҗат турында 1934 елда ук яза башладылар. Бүгенгә кадәр булган тәнкыйтьләр күбесенчә мактаудан һәм, кайчандыр бер миңа Иманетдинов әйткәнчә, «ода» җырлаудан тора, һәм аларда аек фикер бик аз иде. Мин бервакытта да аларга бирелмәдем, ул мәкаләләрнең соңгы юлларында булган кайбер күрсәтүләр миңа барыннан да кадерлерәк булды.

Бүген инде минем тарафтан бик күптән хөрмәт ителгән, ә кайберләр йөз җыерып караган тәнкыйтьченең игътибарын үзенә тарта алганым өчен шатландым. Мәкаләдән соң мин бер иптәшкә шаярып болай яздым: «Минем шикелле дуамал һәм йөгәнсез кешене уңны-сулны карамый торган һәм дуамал рәвештә кисә торган кеше генә акылга утырта алыр». Бу, әлбәттә, Сезне кимсетү яки Сездән көлү түгел. Чынлап та, мин үзем шулай сизәм. Башладыгыз икән — рәхим итеп, дәвам итегез. Вакыт-вакыт шулай, уңлап-суллап чапкалап алсагыз, мин тик шат кына булыр идем.

Идея-политик яктан булган кимчелекләр бар икән — алар миннән чыккан нәрсәләр түгел. Аннан соң мин үземне бу яктан яхшы ук әзерлекле дип саныйм... «Татар солдаты»н язу табигый зарурлыктан килеп чыкты, һәм ул, баһадир татар солдаты, шулай, җизгә катып, һәйкәл булып калыр дип өметләнәм. «Тупчы Ваһап» турында язып тормыйм. Чөнки минем аның хакында Сез күтәргән фәлсәфәгә керергә башым җитми. Чынлап шулай. Мин, аны-моны уйламый, ни күрәм, ни беләм — шуны язган идем. Ләкин гарип булса да, анага үз баласы кадерле. Мин ул поэманы язганда котырып яздым; кайгылы-тантаналы бер көй чыгарып, хәзер дә шыңшып йөрим, кайчандыр бер аны укыган чакта күп кенә окоп кешеләре елаган кебек, ара-тирә минем дә күздән яшь чыга. Мин аны сугыш вакытындагы иҗатымның зениты итеп саныйм. Яхшы, хәерле булсын. Сез куйган дәлилләр белән килешәм. Ләкин бит, үзара гына әйткәндә, бу дәлилләр поэманы бөтенләй юкка чыгара алмый.

Уй, фикер һәм хисне бирү мәсьәләсендә Сез күтәргән нәрсәләр белән бик кызыксынам. Ләкин Сез анда һәм анда гына түгел — берничә җирдә, миңа карата «аңлапмы, аңламыйммы», «белепме, белмичәме» дип әйтеп китәсез. Сүзем аткан ук, каккан кадак булсын — аңлап, белеп эшлим. һәм үземнең киләчәк көнне, барачак юлны шунда күрәм. Бәлки, минем аңа көчем җитми торгандыр, әмма мин бу бөек һәм мәңгелек көннәрне, гайре табигый батырларны югары пафослы, героик тавышлы аваз белән бирергә омтылам. Сезнеңчә, мин поэманы 12 иҗекле система белән түгел, ә эчке мәҗлесләрендә җырлана торган көйгә, 7-7, яки 8-7 һәм соңгы чиктә 10-9 белән язарга тиеш идем. 12 ле система — башланып ташланган һәм хаксыз рәвештә онытылган иң гүзәл бер алым ул. Аның шөһрәтсез үткәне һәм зур гына киләчәге бар. Гомумән, бу хакта күп кенә сөйләшәсе, күп кенә фикерләр ишетәсе килә. Мин моны сезгә, үземне аклап кына түгел, бәлки бөтенләй икенче бер теләк белән дә язам: әгәр Сез гомумән безнең поэзия турында, аның үткәне һәм бүгене, яхшысы һәм авыры турында зур гына бер хезмәт язсагыз, минемчә, бик әйбәт булыр иде. Ә бит бездә андый хезмәт юк әле. Бүтәнне белмим, мин үзем аңар бик сусыйм, һәм моны үтәп чыгу өчен, мин фәкать Сездә генә илһам һәм куәт җитүенә ышанам. Әгәр Сез чын күңелегездән безнең туган поэзия өчен янасыз икән, Сезнең өчен бездә мәйдан бик тар булса да, үтенеп сорыйм, күбрәк әһәмият бирегез. Үзегез беләсез — кадрлар күп түгел. Сугыш аларның бик яхшыларын үз упкынына йотты. Муса Җәлил һәм Нәби Дәүли югалды, Фатих Кәрим һәм Вәдут Мифтах һәлак булды. Шәйхи Маннур сүнде, Сибгат Хәким тынды, Нур Баян әллә бар, әллә юк, Әхмәт Фәез ишетелми башлады.

Мин хәзер «Үлемсезлек» исемле поэма өстендә эшләп ятам. Ара-тирә вак-төяк шигырьләр дә язам. Шулай да, Казанга, туган илгә кайтасы килә, вакыт-вакыт шундый авыр, шундый кыен була ки, чәчнә учлап тотасың да, кулда чәч бөртекләре йолкынып чыга. Киңәшер һәм сөйләшер, талашыр һәм бәхәсләшер кеше юк, бер үзем һәм ике күзем... Ә бит болай бик ерак барып булмый. Мин шулай хыялланам: сугыш вакытында аяк өсте язган нәрсәләрдән торган иҗатның капкасын ябып, тыныч шартларда, кешечә тормышта һәм яхшы коллектив ярдәме белән иҗат итәсе иде. Бу өметнең чынлыкка чыгуына хәзер инде нигез бар.

Ярый, хуш иттек, кадерлем. Минем иҗатка игътибар итүегез өчен, Сезгә рәхмәт. Барлык киңәшегезне истә тотармын. Чөнки минем өчен, әсәрнең астына яки өстенә куелган имза «Шәрәф Мөдәррис» түгел, туган поэзия кыйммәтрәк.

Кичә генә үземнең икенче бүләк — Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнүем турында ишеттем. Вакытыгыз булганда, хат языгыз.

Сезгә сәлам һәм ихтирам белән — Шәрәф.

Гази абый!

Сиңа туганнарча кайнар сәлам. Исәнлек-саулык һәм илһам телим. Үзем шул ук урында исән-сау гына эшләп ятам.

Менә нәрсә, хөрмәтле Гази абый: минем Казанга кайтып килү мөмкинлегем юк. Булса да бик соң булыр. Хәзер шундый вакыт, фронттан бер адым да читкә китеп булмый. Турыдан-туры сугышчы бурычларын үтәргә кирәк. Шуның өчен дә синнән һәм сез дус-ишләрдән теләк бер генә: кулыгыздан килгән кадәр булышлык итсәгез икән. Мин сезгә яшерен почта белән җыентыкны җибәрәм. Анда Х. Госманның рецензиясе, Г. Гыйльмановның сүз башы һәм фоторәсем бар. Үзегез белгәнчә эшләгез. Үзегез редакцияләгез. Кыскача әйткәндә — теләсәгез ни эшләгез. Ләкин башка ук әйтәм: кем дә булса берәр җирен кыскартырга яки сүзләрен үзгәртергә тели икән, минем бу җыентыгым да 1940 елда чыкмый калган җыентыгым язмышы белән бер булачак. Автор буларак — моңа рөхсәтем юк. Китапның ничек бар — шул көенчә чыгуын телим.

Аннан соң мин әле тагын өстәмә рәвештә берничә әйбер җибәрәм. Мөмкинлек булса, өлгерсә, өсти барырсыз.

Минем уемча, җиңү көннәре якынлаша, күптән көткән шатлыклы көннәр бусага төбендә. Безнең фронт та ташкын булып кузгалып дошман өстенә китәр һәм сез безнең шөһрәтне дә ишетерсез.

Мин яңа әйберләр дә язам. Хәзер очучы-герой хакында героик поэма башлана башлады, фәрештәләрнең «амин» дип әйткән вакытына туры килгән булса — тиздән өлгерер.

Җыентыкның эшен бик тиз тотуыгызны сорыйм. Договор төзү мәсьәләсен дә үзегез хәл итегез. Кыскача әйткәндә, бөтен эш сезнең кулда.

Күп булган тәкъдирдә гонорар җибәрү өчен адрес:

Татарская АССР,
Дрожжановский район,
дер. Нижняя Каракитя,
Мударрисовой Бике[1].

Хәзер хуш, Гази абый. Бәхетле очрашу көннәрен көтеп: Шәрәф.

Полевая почта 18715-А,
Мударрисову Шарафу
14/VIII-43

Гази абый!

Сиңа дусларча кайнар сәлам. Эшеңдә уңышлык, иҗатыңда илһам, тормышыңда тынычлык телим. Ә мин мин инде ул. Кичә генә алгы сызыктан 15 көн йөреп кайттым. Хәзергә яңа әйберләр юк әле, ләкин булыр. Шәрәфкә бер яктан алла, икенче яктан шайтан булыша.

Менә җыентык өчен тагын 4 шигырь җибәрәм. Сез аларны «Севастополь» дигән шигырь артыннан өстәп җибәрсәгез икән.

Гази абый! Йөрәк ярсый, җан кисәгем! «Полк намусы» дигән мелодрама язам. Октябрь аенда син аның белән иркәле-иркәсез танышырсың.

«С. Э.» дә минем әйберләр басылганы бармы? Булса шул журналны миңа адресым белән җибәрә алмассыңмы?

Хуш, Гази абый.
Шәрәф.
Хат яз, ичмаса!
21/IX-43.

---

[1] Шагыйрьнең әнисе.

*Кадерле Гази абый!*

Хатыгыз әзрәк чәнечкеле булса да, язуың өчен гаять шатмын. Бу арада бер дә хат юк иде.

Гази абый! Мин үзгәртмәскә, сызмаска дип язганмын икән, аннан бит бер ни дә юк. Алай булган тәкъдирдә мин бит «басмагыз» дип үк куям. Бу гадәтем минем фронтта булуыма һич тә бәйләнмәгән, ул бик чуп сәбәп булыр иде. Бу минем яза башлаганымнан ук килгән авыруым. Бит үзең хәтерлисең, мин бер заман «Отряд байрагы» исемле пьеса язган идем. «Яхшы» дидегез, әмма кыскартырга, җимерергә куштыгыз. Ул пьеса миндә һаман ята. Мин аны үз көенчә калдыруны яхшырак күрдем. 1940 елда минем бер җыентык чыгарга тора иде. «Кораб Ватанга кайта», «Кылыч» һ. б. кебек лирик һәм, әйтергә кирәк, кыю шигырьләрне алып ташларга куштылар, мин риза булмадым, китапны һәлак иттем. Мондый фактлар редакцияләр белән аерым бер шигырьләр турында да булып торды. Эх, Гази абый, Гази абый! Шуларны онытасың, мине горурлыкта һәм «мин-үзем»лектә гаеплисең. Юк, дөрес түгел! Мин әле кайбер шагыйрьләрне хәтерлим. Алар шигырьләрен туксан тугызга телеп бастыра алсалар да риза булалар иде. Тик аларның исемнәре-имзалары гына чыксын.

Нигә вакланасың, Гази абый. Син бит олы кеше. Чәнечкеле сүзләр нигә? Мин баламыни? Ахры, мин үземнең еллар буенча килгән үзсүзлелегем һәм принципларым белән күп иптәшләрнең ачуын кабартып, аларның куралмауларын уятырмын. Мине аңламаучы кеше бар икән — минем өчен барыбер.

Инде җыентык хакында. Күрсәтүләренә килешәм. Рәхмәт. Мин шулай хатта язуны өмет иткән идем дә.

«Мин көзге ай — гүзәл айсың» түгел, бәлки —
«Син көзге ай — гүзәл айсың».

Монда машинкада язылганда хата киткән булса кирәк. «Ай» мәсьәләсе — бик кечкенә мәсьәлә ул. Әгәр кирәк икән — ул юлларны йөзгә бора алыр, йөз вариантта «айсыз» да яза алыр идем. Ышанмасаң язып күрсәтим:

«Үт син салкын чиллә кар-бураның,
Үт син шаулап чиллә кар-бураның,
Үт син уйнап чиллә кар-бураның,
Үт син бүген чиллә кар-бураның,
Үт син шаулы чиллә кар-бураның»,

һ. б., һ. б., һ. б. Әгәр чынлап та минем элекке вариант начар икән, мөнә шушы соңгысына каршы түгелмен. Шулай ук «минем якташ — ай бер баһадир»га да иҗекләр, сүзләр, вариантлар йөзләп табылыр иде. Ләкин мин шуңар туктальп калганмын, шигырьнең моңлы эчтәлегенә, кайгылы тонына «ай» диган ике хәрефле бер иҗекле нәрсә өстәгәнмен. Бу балласт түгел, ә кирәк.

«Гөл булып ла булып йөрер чагым»!

«Булып» сүзе кабатлана икән, аннан ни бар соң? Ул бит көчәйтә генә. Минемчә, Гази Кашшаф ага игътибар итмәскә, әгәр итсә, шигырь нясенең бер алымы икәнлеген аңларга тиеш иде.

Җыентыкның исеме начар. Сүзең дөрес. Мин аны үзем дә сөймим, һәм ул формада исем куюу бик примитив булыр иде. Гомумән мин биредә дә, язган хәбәргә дә, очеркка да, шигырьгә дә исем таба алмау белән начар ат чыгардым. Чукынсын. Иң авыры шул. Мин «Ярсый йөрәк» дип куймакчы идем. Хатипның сездә «Йөрәк ялкыны» исемле әйбере басыла. Исемгә вариантлар язам, кайсын алсаң да ризамын. «Ярсый йөрәк», «Барды сугыш», «Фронт сулый», «Ярсый уйлар», «Туган җирем», «Землянкада».


Хатип алгы сызыкта. Мин кайттым. Эш күп. Хәзер «Полк намусы» исемле мелодрама язам. Яһүдин хикәяләр җыентыгын хәзерли. Минем Казанга кайтып килү өметем дә бар. Киләсе ел планына минем билгеле — җ ы е н т ы к. Балалар өчен күптән инде «Хәсән-Хәсәен» дигән бер баллада эшләп ятам.

Хат языгыз, ешрак языгыз. Эх, белсәң иде, сезнең хатлар кәчат, дәрт, дәрман бирә бит! Тагын язармын.

Сәлам.

Кабат сәлам белән Шәреф.

25/IX-43.



**Равил Вәлиев**

# КАУРЫЙЛАР ЧЫНЫККАНДА

## Кыенлыклар аша



Вазих башта мине кабул итәргә теләмәде. «Үзебезгә дә эш фронты җитми әле», дип сукранды.

Ул уртача буйлы, куе коңгырт чәчле, зәңгәр күзле егет. Сул битендә миңе бар. Борын очында, бит урталарында — соры сипкел.

Бригадага болай «арбаның бишенче тәгәрмәче» булып килеп керәсе булгач, минем дә кәеф төшеп китте. Участок начальнигы янына барырга һәм «Алырга!» дип бары бер сүз язылган кәгазь кисәге китерергә туры килде.

Әлмәт юлының уң ягында больницалар шәһәрчеген салабыз. Бу урын дәвалау учреждениесе өчен бик уңышлы сайланган. Янәшәдә генә — яшь наратлык. Ул бүлеп чыгарган терелткеч, езонлы һава без эшләгән хуҗалык корпусына кадәр килеп җитә.

Бүген кирпечтән бүлмә араларын өйдек. «Син нинди кош? Ничек сайрыйсың икән, яле, карап карыйк» дигән сыман, мине ишек яны стенасын әяргә куйдылар. Мастерокны кулга алмаганга да ничә ел бит инде! Аннан соң «Сынатмыйсы иде!» дип дулкынланганга күрәдер, ишек почмагын бераз эчкәрәк кертеп өйгәнмен. Ишек яңагына пробка тыгып калдырырга да истән чыккан. Өстәвенә, тагын эштән киткәндә, яңа спецовкамның курткасын тәрәзә төбендә онытып калдырганмын. Кире барып алырга туры килде.

Эш арасында ташчылар белән таныштым. Николай Курицин Чаллы төзелешенә Саратов шәһәрендәге бетен уңайлыклары булган ике бүлмәле квартирасын калдырып килгән. Дамир — Чиләбе шәһәреннән, Абдулбәк белән Рамил — Башкорстаннан. Алар әлегә 30 километр ераклыктагы авылда яшиләр икән. Бер дә зарланмыйлар. Автобус ярты сәгать эчендә җилдертеп алып кайта һәм китереп куя, диләр. Түгәрәк

йөзле, сумала төсле кара чәчле, кечкенә гәүдәсе белән туп шикелле тәгәрәп йөрүче Әлфинур Әхмәтова якташым — Арча районы кызы булып чыкты.

Кызып-кызып эшләп ятканда, яныма Вазих килеп китте.

— Исемең ничек әле?

— Равил.

— Комсомол членымы?

— Әйе. Тик учетка басарга өлгермәдем әле.

— Без комсомол-яшьләр бригадасы бит. Бригадабызга игътибар бик зур. Менә әле съездда да булып кайттым.

Бригада комсомоллары турында кайгыртуы яхшы. Тик менә аның соңгы сүзләре мине сагаерга мәҗбүр итте: масаеп, алай-болай борынын күтәрә башламаганмы ул? Әлегә әйтә алмыйм. Бәлки, аның эчендәге тышындадыр. Һәрхәлдә, танышып җитмәгән кешегә мин андый сүзләрне әйтә алмаган булыр идем.

Эштән соң Вазихның, Мәскәүдән комсомолның XVI съездыннан алып кайткан тәэсирләрен бүлешер өчен, бригада будкасына җыелдык.

— Я, Вазих, Старшиновның үзен күрә алдыңмы соң? Сәлам җибәрмәдеме ул безгә? — дип шаярту катыш башлап җибәрде сүзне Анатолий Турцев дигән егетебез.

— Күрмичә! Бер рәттә утырдык. Автографын да язып бирде,— диде Вазих, аның кызыксынуын канәгатьләндереп.

Аннары Мәскәүдән алып кайткан хисләре белән уртаклаша башлады. Билгеле, съезд материаллары белән егетләр яхшы таныш булырга тиеш. Ләкин газета-журналлардан уку бер нәрсә, ә анда катнашучының үз авызыннан ишетү бөтенләй башка! Вазих моны яхшы аңлый иде. Шуңа күрә сөйләде дә сөйләде ул.

Бераздан Вазих тынып калды... Үзе Мәскәүдә йөрсә дә, күңеле, йөрәге бригадада калган булган икән. Туган илнең төрле почмакларыннан җыелган делегатлар съезд трибунасыннан хезмәттәге уңышлары турында Ватанга рапорт биргәндә, «Егетләрнең хәлләре ничек, төзү материаллары җитә микән?» дип, Чаллыда калган бригадасы турында уйланган. Борчылулары тикмәгә булмаган икән. Күренеп тора: егетләрнең кәефе шәптән түгел.

— Инде сезнең чират,— диде бригадир, ниһаять.

«Сүз сиңа бирелә» дигәндәй, бригада членнары Николай Курицинга караштылар.

Яраталар шушы озын буйлы, кояшта янып каралган йөзле, соргылт чәчле егетне бригадада. Башкаларга караганда олырак, тормыш тәҗрибәсе зуррак булганы өчен генә түгел, яхшы күңеле өчен үз итәләр. Авыр сүз әйтеп, беркайчан да каты бәрелмәс. Ашыкмыйча әйткән сүзе, елмаюлы йөзе, «Нинди ярдәм кирәк?» дигән сыман, һәрчак үзенә дәшеп, чакырып торыр. Җитәкчеләр аны «бригадирның уң кулы», ә бригададагылар дядя Коля дип йөртәләр. Ул Кама автозаводына килгәнче, озак еллар Саратов шәһәрендә төзүче булып эшләгән. Хәзер биредә — дүртенче разрядлы ташчы. Коллективта «четерекле» моментлар килеп чыкканда, йөкнең авыры аның җилкәсенә төшә.

— Кем әйтмешли, тик тә тормыйбыз, эш тә кырмыйбыз,— дип башлады Николай сүзен, үгезне мөгезеннән эләктереп алып.— Кирпеч булса — изма юк, изма булса — кран юк. Нәкъ Аркадий Райкиндагыча инде. Дөрес, көнлек норманы үтәми калган юк югын. Тик хикмәт ничек үтәүдә бит. Материаллар булу белән, дәррәү кубып, эшкә башлыйбыз. Кирәк икән, эш сәгате чыкты дип тә тормыйбыз. Егетләр сынатмый, сыгылмый торганнар. Алар белән таулар күчерергә була. Тик менә материаллар җитмәү үзәкне өзә. Гел ярты көчкә генә эшләргә туры килә...

Иртәгесен Вазих 32 нче төзү идарәсенә китте. Мәсьәләне кабыргасы белән куеп, бригаданың зарын аңлатып бирде. Нәтиҗә озак көттермәде. Безне, салынып бетмәгән больница шәһәрчегеннән алып, дүртенче кварталдагы ашханә төзелешенә җибәрделәр. Ярдәмгә, янәсе.

Биредә Воронеж шәһәренең профессиональ-техник училищесыннан практика үтәргә килгән кызлар бригадасы эшли икән. «Гепетеушник» кызлар ачык йөзле булып чыктылар. Ике бригада членнары бергәләшеп, эш арасында таныша-таныша, булачак ашханә нигезенә бетон ташыдык. Шулай, үзара ярышып эшләп, көннең үткәне дә сизелми калды.

Әмма бу шатлыклар озакка булмаган икән. Икенче көнне кызлар бригадасын, әлеге объекттан алып, башка урынга җибәрделәр. Ләкин безнең күңелне төшергәне икенче нәрсә булды: эшләр өчен ни кран, ни измә, ни кирпеч юк. Материаллар сорап, 32 нче төзү идарәсенә киткән Вазихыбыз да бер нәтиҗәсез, кара янып кайтты. Ул әйтә: «Моннан соң һәр простой саен «Молния» чыгарып барырга һәм аны начальникларның борын төбенә элеп куярга кирәк»,— ди. Әйбәт фикер.

Шулай итеп, ярты эш көне бушка үтте. Малайларның кайсы «кузла»ларны турник итеп уйный, кайсылары төрле мәзәк уйлап чыгара башлады. Эшсезлектән тилмергән Ганс Нәбиев дигән егетебез аяк астындагы бер гөнаһсыз буш шешәне кулындагы чүкече белән чәкелдәтеп ватарга керешкән иде дә, һәрвакыт җитди Таня Лазарева, «уклы» сүзләрен кадап, аны шып туктатты:

— Эх син, детсад! Кеше йөри торган җирне шулай чүпләргә ярыймы соң инде?

«Турник» янында эшләр бик кызуга киткәч, Вазих болай дип әйтеп куйды:

— Сакланыбрак, егетләр! Мин Казанда бер шагыйрьне беләм: армиядә хезмәт иткәндә турниктан егылып төшкән, хәзер урын-җир өстендә ята. Ләкин бирешми, молодец егет! (Бу, билгеле, Фәнис Яруллин турында инде.)

Гомумән, Вазих егетләр белән шаярышып алырга да вакыт таба. Әмма аның бу хәлате озакка бармый. Ул тагын эш турында уйлап борчыла башлый.

Смена ахыры якынлашкач, ниһаять, кран килде, кранга ияреп, озын буйлы, элеп киптергән гәүдәле, 32 нче төзү идарәсе начальнигы Макаев үзе дә килде.

— Удар объект бу безнең. Ашханә тагын ике айдан, август урталарында, эшли башларга тиеш. Хәл аңлашыла торгандыр дип уйлыйм. Вакыт күп калмады. Сынатмассыз бит? — диде ул, безне дәртләндерергә омтылып.— Ә материаллар белән тоткарлык ясамаска тырышырбыз.

— Эш бездән тормас, Федор Алимович,— диештеләр бригада членнары.

Идарә начальнигы киткәч тә, бригаданы җыеп, Вазих кыска гына «летучка» уздырып алды.

— Материаллар гына булсын! Калып та эшләрбез, бу бит үзебез өчен дә файдалы,— диде.

Ташчылар аның сүзләрен хупладылар, гомумән, бригада членнары ярты сүздән аңлыйлар аны.

Әмма, аянычка каршы, тиз генә шатланырга насыйп булмаган икән безнең егетләргә. Төрле вак-төяк эшләр белән, юкны бушка аударып, тагын бер көн, аннан икенче көн узып китте. Өченче көнне, ниһаять, түзмәдек, сабыр канатларыбыз сынып, бөтен өеребез белән «Жилстрой-1» идарәсе начальнигы Марат Шакирович Бибишевнең үзе янына киттек.

Сүзне әлеге дә баягы шул кетү башлыгыбыз дядя Коля башлап җибәрде:

— Телеграмм баганасы чаклы шушы гәүдәм белән ике тулай торак арасында (без төзи торган ашханә 4/1 һәм 4/2 нче йортларның баш-башларына терәтеп салына) каккан казык кебек эшсез басып торуы оят. Семьябызны, яхшы эш хакларын калдырып монда килдек. Газеталардан укыйбыз: ташчылар җитми дә ташчылар җитми, имеш. Ә безне монда эшсез тоталар.

Себердәге бөтен төзелешләрдә диярлек катнашып, күп эшләгән, күпне күргән кеше булса да, утлы күмердәй очкын чәчеп торган күзләре, ташып торган энергиясе белән әле шактый яшь күренгән бу чал чәчле «начальник агай» — Марат Шакирович — безнең зарны сабыр гына тыңлап торды да 32 нче төзү идарәсе начальнигы урынбасары, комсомолның XVI съезды делегаты Роберт Вәлиевне чакыртып китерде.

— Без Мәүлихов бригадасы турында күп сөйлибез, газеталарга язабыз. Ә егетләр чынлыкта эш эзләп йөрергә мәҗбүр,— диде Марат Шакирович.— Аларның эшсез торган сәгатьләре өчен түләргә һәм иртәгәдән үк бригаданы эш белән тәэмин итәргә киңәш бирәм. Беркетелгән участогың юк, моның өчен туп-туры үзең җавап бирәсең.

Файдасы булды бу сөйләшүнең. Иртәгесен үк бригадага Роберт үзе килде. Аңа ияреп кран килде, кирпеч килде, измә килде. «Мәңарчы эшсез торуның үчен кайтарабыз» дигәндәй, дәррәү эшкә тотындык.

...һәм берничә көннән тагын элекке хәл кабатланды. Мастер Виктор Журавин, «Ашыгыч эш бар» дип, бирегә җибәрелгән автокранны каядыр икенче участокка алып китте. Ә без, эшсез тормас өчен, сантехузел урнашачак бүлмә астына ике көн буе

чокыр казырга мәҗбүр булдык. Эш бетәр алдыннан экскаваторны кире борып җибәрдек. Экскаваторчының әйтүе буенча, әлеге чокырны ул ике сәгать эчендә казып ыргыткан булыр иде. Ике сәгать һәм әрәмгә үткән ике көн! Әйе, борчылырлык урын бар иде монда.

Ләкин эш эш булып кала инде. «Хезмәт — иң шифалы дәва», дип белми әйтмиләрдер, күрәсең. Торган саен тирәнәя барган чокырны күреп, давыл басылгач тынган диңгез дулкыннары кебек, эшсезлектән интеккән күңелләребез дә үз «яр»ларына кайтты, кәефләр бераз күтәрелеп киткәндәй булды. Ә мондый чакта инде берәрсенең тел очыннан көлкеле, мәзәк сүз чыгуын көт тә тор. Бигрәк тә коллективта Йосыф Галләмов кебек «теленә тилчә төшкән» Арча малайлары да булса!

Арча малайлары дигәннән, алар бригадада өчәү: «тәптән юан» гәүдәле, йөзе белән бераз негрларны хәтерләтүче Йосыф үзе — бөек Тукайның авылдашы, Кушлавыч егете; киноартист Смоктуновскийга охшаш йөзле, соргылт йомшак чәчләре һәрчак сул як маңгаена төшеп, яңа гына судан чыккан каз бәбкәсенең мамыгы кебек сыланып торучы Ибраһим Бәйрәмсв — Мәтәскәдән; яңа гына өйләнеп, кәләшен еракта калдырып килгән, уң кулының урта бармагында алтын балдак, күңелендә һәрвакыт җыр-моң йөртүче Таһир Гайнетдиноз — Иске Кенәр авылыннач.

ВЛКСМның Арча район комитетына комсомол путевкалары алырга баргач очрашып танышкан бу өч колхозчы егет, Казанда алты айлык курсларда укып, башта ташчы һөнәренә өйрәнеп чыкканнар. Аннан Чаллыга — Кама автомобиль заводын төзешергә килгәннәр. 6/2 нче тулай торакның бер үк бүлмәсендә яшиләр. Ашау бергә. Йоклау бергә... Кем әйтмешли, нәкъ «агылый белән тагылый» кебек инде! Өчесендә өч характер тагын. Ибраһимга — дары мичкәсенә — кирәк чакта су сибәргә Йосыфның тел очында йөргән җор сүзләре бар. Җыр-моң кирәксә, Таһирда ул капчык белән! Бригадада аларны, шаяртып, «өчлек союзы» дип йөртәләр.

Кирәкләрне алмашка килүчеләргә бирдек тә бераз хәл-әхвәл алырга дип чокыр кырыена тезелешеп утырган гына идек, менә шул Йосыф дигән егетебез, тешен ялтыратып, көлке капчыгының авызын чишеп тә җибәрде:

— Берәүдән «кайда эшлисең?» дип сораганнар.

— Райисполкомда.

— Oho-ho-o! Кем булып?

— Каравылчы.

— Һи-и-и!

Йосыф үргән көлке җәтмәсенә эләгеп, барыбыз да шырык-шырык көлешәбез.

Ул да булмый, Йосыфтан «эстафета»ны Вазих үзе ала:

— Чаллыга килеп бер айлап вакыт үткәндерме-юкмы — бригадага Бибишев килде. «Я, ничек, Казан бригадасында эшләр барамы?» ди бу.

— Бик ал да гөл түгел әле, Марат Шакирович,— без әйтәбез.

— Ә нигә?

— Бер ай эшлибез инде менәтерә, тик үзебезнең СМУ начальнигын күру бәхетенә ирешә алган юк. Фамилиясен дә белмибез хәтта.

Бибишев шунда ук Лебедь фамилияле начальнигыбызны чакыртып китерде дә:

— Нигә начар очасың, Анатолий Васильевич? — ди.

Аңлады бит, каһәр, тегесе дә үз бакчасына таш ыргытылганны. Алар көлә, без көләбез...

— Кара әле, Вазих! Казан бригадасы да Казан бригадасы дип теңкәгә тияләр. Каян килеп тагылды соң бу исем безгә? Син үзең дә «бүрекле» Шәмәрдән ягыннан бугай. Сөләп җибәрең әле шул турыда бераз, малай! — дип, күптән түгел генә бригадага килгән Ринат Кисюшев сүзгә кушылды шунда.

Шулай, сүз иярә сүз чыгып, Вазихтан үзенең тормышы турында сөйләттек.

## Яра

— Әни исән минем, ләкин үзен хәтерләмим,— дип башлады сүзен Вазих, яшел спецовкасының җиңенә ябышкан кызыл балчык кисәкләрен каккалап. Аннары бераз тордашмичә торды да сүзен дәвам итте.— Әтине ташлап, хатын аерган бер кешегә тормышка чыккан. Мин тугач, үги әти дә аны аерып җибәргән. Әни дигән кеше мине — сигез айлык баласын — «үзеңә булсын!» дип, яңадан үз әтием буссагасына илтеп

ташлаган. Үскәнмен шулай, Тукай әйтмешли, үги әнинең күгәрченнәре арасында чәүкә булып.

Дүртенче класска тикле кругом отличнога укып бардым. Аннан, кул астына керә башлаганлыктандыр, бөтен йорт эшләре минем җилкәмә менеп утырды. Шуның аркасында, үги энеләрем белән чәкәләшеп алган чаклар да була иде. Хәтеремдә: бер тапкыр алар, «үзеңнең әниең янына кит!» дип, мине өйдән куа башладылар. Фәрит дигәне балта белән бармагыма да чапты. «Менә, бала чак истәлеге булып калды»,— дип, Вазих сул кулының имән бармагындагы аксыл җөйне дә күрсәтте. Ә мин: «Бармагыңа гына түгел, ә йөрәгеңә дә уелган яра, әниең була торып та, ана җылысын тоеп үсмәүдән туган яра да инде бу, алай булгач, Вазих дустым!» — дип аны жәлләп куйдым. Кылт итеп, сугыштан кайтмый калган әтием искә төште. Ул чыгып киткәндә, мин әле тумаган да булганмын. Бер уйлап карасаң, мин дә ятим! «Әти!» дигән иң кадерле сүзне минем дә берәүгә дә әйтеп караганым булмады! Ләкин ни гаҗәп: аның юклыгы безгә — әнкәләренең ялгыз, әмма җылы канатлары астына сыенган «каз бәбкәләре»нә — үзен бик сиздермәгән. Әтиләрен сугыш йолкып алган балалар авылда бер мин генә булмагангадыр да инде. Тик менә үсеп җитеп, хәзер үзем әти кешегә әйләнгәч, «үчтеки-үчтеки, үсмәгәнгә кечтеки» дип кечкенәмне югарыга чөйгәндә, әтием мине шулай сөя алмаган, миңа хәтта, бер мәртәбә булса да, «улым!» дип тә дәшәргә туры килмәгән аңа, дигән уй килеп, бу кадерле кешенең юклыгы үзен сиздереп, йөрәкне бераз телгәләп куя. Безнең йөрәкләргә үзе салган ярасын сугыш үзе үк бәйләгән дә!

Ә менә Вазихныкы... Вазихныкы бөтенләй башка!

— Шуннан, яралы бармагымны кысып, ишек алдын себереп йөргән әти янына йөгереп чыктым. Ул, кесәсеннән кулъяулыгын чыгарып, бармагымны бәйләде дә:

— Син. инде үз иркеңдә,— дип сүзен бетерде.

Аның нәрсә әйтергә теләвен аңлап алдым. Яман ачуым чыккан иде — энеләремә дә, үги әнигә дә, бөтен тормышына да... Өйдән куган энеләремнән ачуны алдым. Кисәү агачы белән. Шуннан үги әни мине көне буе идән астына ябып яткырды...

Аннан һөнәр училищесы... Аннан армия... Казандагы оргсинтез заводы. Өлкән аппаратчы булып эшләдем. Акча шәп төшә иде. Артканын Шәмәрдәнгә җибәреп тордым. «Үги булса да, малаеннан уңды Мәрьям», дисеннәр, янәсе...

Озак та үтмәде, Чаллыда «бөтен Европада тиңе булмаган автозавод салына икән» дигән хәбәр таралды. Кузгатты бит бу хәбәр күңелне. «Оргсинтез заводы удар төзелешләрдән хисаплана да, Казан Казан булып калды инде. Нигә әле әзергә хәзер генә булып ятарга? Татарстанны да ташлап китәсе юк. «Ишек алдында» гына шундый зур төзелеш! Әнә бит: «Иң кирәкле кешеләр — ташчылар»,— дип язалар.— Ә синең кесәңдә өченче разрядлы ташчы таныклыгы ята түгелме соң?» дигән уйләр башка кереп утырды да тынгылык бирми башлады.

Заводның ВЛКСМ комитетында:

— Синең белән хушлашасы килми дә бит инде. Ни хәл итик: КамАЗ дигәндә безнең дә аяк идәндә инде. Ләкин кара аны: оргсинтез маркасын югары йөрт. Безнең йөзгә кызыллык килерлек булмасын! — дип әйбәтләп кенә озатып калдылар.

Без Чаллы төзелешенә китүче Казан комсомолларының беренче партиясе булып чыктык. Менә шулай, бер үк шәһәрдә яшәсәк тә, ВЛКСМ өлкә комитетында комсомол путевкалары алганда гына танышкан унлап егет, декабрь башларында Чаллы каласына килеп төштек.

Башта безне СМУ-2 гә җибәрделәр. Бу идарә Түбән Кама ГЭСын төзи икән. Кадрлар бүлегендә безгә «диңгез һавасы... янгызда гына Кама агып торачак...» дип алтын таулар вәгъдә итә башлаганнар иде дә, «Теплоконтроль» заводында үк комсорг булып эшләгән Хәбир Нәбиуллин дигән комиссар егетебез:

— Киңәшегез өчен рәхмәт! Ләкин без биредә Кама комында кызынырга түгел (аңа өлгерербез әле!), ә КамАЗ төзергә дип килдек. Без — Идел егетләре! — дип, аларны салпы ягыбызга салам кыстырудан шып туктатты.

Шуннан киттек «Жилстрой» идарәсенә. «Яңа шәһәр төзисебез килә, ә безне ГЭС корырга җибәрмәкчеләр, фәлән дә төгән» дип, ничек кирәк алай хәлне Марат Шакировичка аңлатып бирдек.

— Кайсыгыз моңарчы ташчы булып эшләде? — диде бу, һәрберебезне җентекләп күздән кичереп чыкканнан соң.

Бик сикеренер җиребез юк икән тагын үзебезнең. Монда килгәнче төзелеш белән бары минем генә азмы-күпме танышлык бар булып чыкты. Марат Шакирович мине «прицель»гә алды:

— Липецк ысулы белән, тигез җөйле итеп кирпеч салганың булдымы?

— Туры килмәде. Ләкин өйрәнербез...

— Юк инде, күгәрченкәйләрем! «Ырбыз-ербез»ләр киләчәккә калып торсын. Бу номерлар бүгенге Чаллыда батмый алар. Батмый-й-й! Ишетәсезме шуны! Мин моны сезгә илнең зур төзелешләрендә чәчен агарткан кеше буларак әйтәм. Уйлап карагыз: нибарысы дүрт ел үткәч, «КамАЗ» маркалы беренче автомобиль эшләнеп чыгарга тиеш. Төзелеш тарихы мондый темпларны әле белми! — дип, ул башта безне «йомшак җәеп, катыга утырткандай» итте дә, аннары сәлперәя башлаган канатларыбызга тагын рух өрә башлады: — Дөрес, анадан беребез дә белеп тумыйбыз. Теләк кенә булсын! Ә ул, күреп торам, сездә җитәрлек. Әйдәгез болай эшлибез: чәчелми-түгелми генә сез иртәгә Василий Радаев бригадасына килеп кушыласыз. Ә син, Мәүлихов, элеккеге төзүче буларак, Казан звеносын үзең җитәкләрсең. Эшләр барса, тиздән кирпеч эшләренә күчербез. Менә дигән ташчылар булып, менә дигән йортлар сала башларсыз.

Аннары Марат Шакирович үзе җитәкләгән идарәнең бай традицияле, Чаллыдагы иң карт төзү оешмаларының берсе булуы, аның киләчәк перспективалары турында сөйләп үтте һәм:

— Ягез, Казан егетләре! Уңышлар телим сезгә! Авырлыклар килеп чыкса, туп-туры үз яныма килегез! — дип сүзен бетерде.

Бибишев яныннан барыбыз да очынып, канатланып чыктык. Вәт, дибез, җитәкченең әйтә белгән бер җылы сүзе дә күңелне күтәрә.

Бригадир Вася Радаев безне ачык йөз, җылы сүз белән каршылады. Ләкин бу җылы сүзләр артына начар ният яшеренгән булган икән.

Хәл-әхвәл сорашып, бераз эшләп алырга да өлгермәдек:

— Әйдәгез, егетләр! Чыгарыгыз берәрлекне! Сезнең яңа шәһәр төзергә килүне билгеләп үтәргә кирәктер бит инде. Нишлисең — традиция!..— димәсенме бригадирыбыз.

Традиция тек традиция. Аны бозарга алланың кашка тәкәләре түгел ич без, дип, кесәләребез белән сөйләшеп алырга туры килде. Ах, ул чакта ук күзләребез ачыграк булсачы!..

Икенче көнне башны төзәтер өчен тагын берәр сум!

Ниһаять, ай ахыры да килеп җитте. «Портянка»[1]ларны карагач, күзләребез шар булды. Декабрь ае өчен нәрәт нибары өч сум белән ябылган булып чыкты. Бригаданың эшләгән эше дә «ташка үлчим» генә.

Юк, болай ярамый.

Тагын кесә мәсьәләсе кузгатылгач, без, Казан егетләре, җыелыштык та киттек СУ-32 нең парторгы Р. Валиев янына. Түкми-чәчми генә (үз гөнаһларыбызны да яшермичә, билгеле) зарыбызны Роберт Гумеровичка сөйләп бирдек.

Күп тә үтмәде, бригада җыелышы булды. Берничә ел ташчы булып эшләгәнгә күрәме, мин фәкыйрегезне шунда бригадир итеп куйдылар. Бер атна ризалык бирмичә йөрдем. Аннан килешергә туры килде...

...Бер заманны чокырның тирәнлеген үлчәп карасак, исләребез-акылларыбыз китте: Вазихның «тормыш китабы»н актара-актара, артыгын тырышып җибәргәнбез бит. Балчыкны кабат ишеп төшереп, дыңгычлап төяргә, тыгызларга туры килде.

«Итәкне кисеп җиңне ямау» кебек нәрсә килеп чыкса да, аңа карап кәефләр кырылмады. Ә Ринат һаман тынычланасы килми:

— Инан беләч нәмә булып бетте соң? — диде Вазихка.

---

[1] Айлык хезмәт хакының күләмен күрсәтүче, телеграф тасмасы төсле тар гына расчет кәгазен төзүчеләр шулай дип йөртәләр.

— Һәй-й-й! — дип кулын гына селтәде Вазих.— Барнаулда диләр бугай аны. Бер очрашасы иде үзе белән. Күрәсе килә. Тик һаман шул вакыт-якут мәсьәләсе менә...

Һәм бераздан уйчан гына:

— Ә кирәк микән?..— дип естәп куйды.

# Йомычка

5/13 нче тулай торакның ике бүлмәле квартирасында без сигез кеше яшибез. Кысан дип беребез дә зарланмый. Бабайлар әле землянкаларда, баракларда торып, Магниткаңы, Днепрогэсны төзегәннәр. Ә безгә бөтен уңайлыклары да тудырылган менә дигән квартира!

Бүген бүлмәдәш егетебез Олег Селиванов белән хушлаштык. Ул бирегә Чиләбе шәһәреннән килгән булган. Күңелле, шаян телле малай иде, кызганыч. Зур төзелешләрдә була торган беренче кыенлыклар белән очрашып дүрт-биш ай үткәч үк күңеле төшүе кызганыч!

Аның белән «хушлашу» болайрак булды.

Без өчәү — Виктор Филимонов бригадасы монтажчысы Петро Башкиров, ташчы Женя Козлов (күзлектән йөргәнгә бүлмәдәгеләр аңа «очкарик» дигән кушамат тагып өлгергәннәр) һәм мин — төнге сменага эшкә барыр алдыннан бераз черем итеп ята идек. Менә бер заманны, шалтыр-шолтыр килеп, шактый ук «төшереп» алган Олег Селиванов кайтып керде. Чалбар кесәсеннән, корыган агач ботагы кебек тырпаеп, үзе әйтмешли, тагын бер «өч сум 62 тиен»нең муены күренеп тора.

— Пожарниклыкка укып ятмагыз! Торыгыз давай,— диде бу керешкә. Аннан туктаган сәгатенең пружинасын борды да дәресләп куйды.— Значится, минем самолет очарга ярты сәгать вакыт калган. Хушлашырга туры килә, егетләр. Әнә, Одесса янында станоклар төзү заводы сала башлаганнар, ди. Үзе генә дә ни тора: диңгез буе, экзотика... Чаллы комын сулап, тәмәкелек акчага эшләп ятарга башыма тай типмәгән. Бер сүз белән әйткәндә, монда «ловить нечего!»

Аның бу сүзләре миңа, яңа кешегә, аяз көнне яшен суккандай тәэсир итте. Петро да яткан җиреннән торып утырды:

— Нәрсә, Чаллы комы тамагыңа утыра башладымы әллә? Төзелештә тузан булмый калмый инде. Белеп торам: акчада да түгел хикмәт. Просто куркак син! — диде ул.

— Нигә кызыл сүзләр? Минем юл аягына бәрәрне тотып җибәрсәк яхшы булмасмы? — дип, Олег кесәсеннән теге «гөнаһ шомлыгы»н чыгарды.

«Эшкә барасы бар» дигән булып, Петро белән без аның тәкъдименнән баш тарттык. «Сезнең белән сөйләшеп торган мин юләр» дигәндәй, егетебез безгә кулын селтәде дә, гадәттәгечә, бер көй шыңшый-шыңшый, Женя яткан караватка таба борылды.

— Мә, булмаса, минем саулыкка син күтәреп җибәр, «очкарик»!

«Очкарик» булып «очкарик»ның да эчмәве, бары стакан кырыена иренен генә тиереп куюы тегенең җен ачуын чыгарды. Ул алдан тутырып куелган чемоданын тиз-тиз генә караватастыннан тартып чыгарды һәм:

— Эшкә барасылары бар, имеш! Патриотлар, имеш! Чиләнегез, КамАЗ төзибез дип җаныгыз чыксын! Туган ил сезне онытмас! — дия-дия, ишеккә таба юнәлде.

Ул ишекне шундый каты итеп япты, аның артыннан ишек йозагындагы ачкыч чыңлап идәнгә төшеп калды. Әйтерсең шулай чыңылдап, ишектәге йозак ачкычы түгел, ә әлеге «герой» егетнең йөрәгенә табылырга тиешле, әмма, күрәсең, табылып җитмәгән күңел ачкычы төшеп югалды.

Бу фикерне бүлмәдәшләрем белән дә уртаклаштым.

— «Китәм» дә «китәм» дип күптән кытаклап йөри башлаган иде инде. Эштәгесен белмим. Әмма ләкин без әйтмәдек түгел, күп әйттек. Ничек диләр әле? Ана сөте белән кермәгәнне, тана сөте белән керми, диләрме? Әйдә, китә бирсен. Андыйларның алларыннан артлары матур. Ятмасыннар монда саф һаваны болгатып! — диде дә Петро янә урынына барып ятты.

Күземнән йокы качкан иде инде. Тышкы яктан караңгылык пәрдәсе элене башлаган тәрәзә каршысына килеп бастым.

Тулай торагыбыз аэродром каршында гына. Ике арадан бәләкәй Мәләкәс инеше агып үтә. Инешнең бу ягында артык зур булмаган сазлык җәелеп ята. (Ул берничә елдан, ГЭС төзелеп беткәч, Кама диңгезе астында калачак.) Менә шушы сазлык аша, инешнең аргы ягына, аэропортка таба тар гына «кәҗә сукмагы» үтә.

Бер кулына кара чемодан тоткан әзмәвердәй егетнең — җиңел тормыш эзләп китеп баручы безнең кәннәр «доброволец Батыргали агай»ның алпан-тилпән атлап, кәҗә сукмагыннан шул баткак сазлык эченә кереп китүен шәйләп калдым.

Кеше китте. Эш урынын ташлап, дусларының ышанычын таптап, дезертир кебек китте!

Бәлам, ул бу сазлыкны үтәр. Ә менә тормыш сазлыклары белән нишләргә? Исәнимин генә үтеп чыга алырмы ул аларны? Әллә күке кебек оя саен йомырка салып йөреп, тормыш баткагында бөтенләй күмелеп калырмы?..

Олы диңгез ул — бүгенге Чаллы.

Диңгезнең дә бит дәһшәтле дулкыннары олы максат белән юлга чыгучы корабларны гына кабул итә, ә йомычкаларны... Йомычкаларны күбекләр белән бергә ярга бәреп чыгара.

Тормыш иләгеннән төшеп калып, дулкыннар ярга бәреп чыгарган Олег Селиванов кебек «арка сөяге йомшак» егетләрнең төзелештә сирәк булса да очрап куюы мине борчый. Нилектән килеп чыга соң бу? Кыенлыклар турында әйтмичә, романтика дип, квартира дип, үзең салачак шәһәр дип без кешеләргә артык күп «алтын тау»лар вәгъдә итмибез микән? Ә монда килеп шактый кырыс төзелеш белән очрашкач, «бер атналык романтиклар» кире үкчә ялтырату ягын карый башлыйлар. Зыянмы? Бердән, өлеге кикрикләре шиңгән «әтәчләр», элеккеге эшләреннән аерылып, производствога зарар китерә. Аларның бит күбесе кире борылып кайтачак. Икенчедән, элекке урыннарына кайткач, аларның төзелеш турында төрле гайбәт таратулары бар. Ә боларны ишеткәч, бирегә килергә җыенучыларның икеләнә башлаулары мөмкин. Нәтиҗәдә җәмгыятькә дә, кешенең үзенә дә зыян килеп чыга түгелме соң?

Халыкка дөресен әйтергә кирәк. Монда акча, квартира артыннан куучылар түгел, ә чын энтузиастлар килсен!

*Дәвамы бар.*

**Мирза Мәхмутов,**

ТАССР Мәгариф министры,
СССР педагогия фәннәре академиясенең
член-корреспонденты.

# ЕРАКТАГЫ ЯКЫН ЧИЛИ



Чили турында хәзер барлык илләрдә дә күп язалар, күп сөйлиләр. Безнең укытучы халкының да бу ил белән кызыксынуы бик табигый: Чилидә власть халык кулына күчте. Киң катлау хезмәт ияләренә аң-белем бирү өлкәсендә дә яңа шартлар туды.

Шушы кызыклы илгә күптән түгел СССР Мәгариф Министрлыгы делегациясе барып кайтты. Мин кыскача гына итеп әнә шул хакта сөйләп бирмәкче булам.

## Диңгезләр, таулар аръягында

Берәр чит илгә баруны язган чакта, гадәттә, самолет белән очу кебек детальләргә тукталып тормыйлар, чөнки хәзерге очкычлар бик тиз вакыт эчендә безне теләсә кайсы илгә илтеп җиткерә. Шулай да без Чилигә бик тиз барып җиттек димәс идем: унҗиде мең километр араны узар өчен хәзерге самолетларга да егерме сәгатьтән артык вакыт кирәк. Географлар әйтмешли, дөнья әйләнә сәяхәтнең яртысына якын юл бу. Без карлы Россия, Украина, Польша өстеннән очтык һәм Урта диңгезне үтеп, беренче тукталышны Алжирда ясадык. Шуннан соң, меңнәрчә чакрымнар дәвамында бер сары, бер көрән, бер соры төсләргә кереп, очсыз-кырыйсыз Сахара чүле сузылды. Бары тик Дакар каласына җитәрәк кенә җирдә вак-вак куаклыклар күренә башлады. Сенегал башкаласында бүтән самолетка күчеп утырдык.

Дакар — Африканың көнбатышындагы иң аргы ноктасы һәм Көньяк Америка континентына иң якын юл әнә шуннан. Күпчелек авиакомпанияләрнең самолетлары Бразилия, Аргентина, Уругвай, Чили кебек илләргә әлеге Дакардан очалар.

Атлантик океаны аша узганда юл гел бер төрле дип әйтерлек: өстә зәп-зәңгәр күк йөзе, аста да шундый ук зәңгәр океан суы.

Рио-де-Жанейро, Сан-Пауло, Буэнос-Айрес кебек сигез миллионлап халкы булган гигант шәһәрләр өстеннән очканда гына җир өстендәге күренешләр үзгәргәләп алды.

Ерак юл шактый арытса да, без Чили кешеләре белән очрашуыбызны түземсезләнеп көттек. Швейцария авиакомпаниясе самолеты (самолетны кораллы бандитлар алып китүеннән курыккан авиакомпаниянең хезмәткәрләре һәр ир пассажирны профессиональ осталык белән тентеп чыктылар) Кордильер таулары аркылы очып чыгуга, аста Сантьяго шәһәре күренде. Берничә минуттан соң инде аэропорт безне Чили җиренең декабрь аендагы кырык градуслы эссесе белән каршы алды.

XVI гасырның урталарында испан конкистадорлары Чилигә бик әкрен һәм озак барганнар, әмма юл михнәтләренең әҗерен уны белән кайтарганнар: табигатьнең иң матур урыннары, таулар, урманнар, үсәнлекләр һәм Тын океанның иксез-чиксез байлыклары илбасарлар кулына күчкән. XVI гасыр азагында граф Вальдивия Чилине Испания короле каршында тезләнергә мәҗбүр иткән. Европадан агыла башлаган кешеләр, башлыча — испаннар, океан белән Кордильер таулары арасындагы тар гына җирне әкренләп басып ала барганнар. Җирле халыкның килмешәкләр белән аяусыз көрәше, испаннарның индеецларга каршы рәхимсез сугышы дәвамында Чили дәүләте барлыкка килгән. 1552 елда Сантьяго шәһәренең беренче нигез ташы салына. Әмма араукан индеецларенең илбасарларга каршы көрәше әле йөз елдан артык дәвам итә.

Хәзер инде анда индеецлар калмаган диярлек. Калган кадәресе коньяктa яши, примитив хуҗалык белән көн күрә. Алар — хәзерге Чили халкының иң ярлы өлеше. Әмма бүгенге заман арауканының да әле йөрәгендә азатлык һәм патриотлык рухы яши. Яшь кенә бер индеец егете, гитара чиертеп, испаннар минем ватанымны басып алганнар, испан токымнары индеецлар җирендә рәхәт яшиләр, дип җырлаганда минем башта әнә шундый уй туды. 1820 елдан бирле Чили парламентлы, президентлы буржуаз республика булса да, бу илгә Испания корольләре инде күптән баш булмасалар да, индеецларга азатлыкларын да, байлыкларын һәм җирләрен дә кире кайтармаганнар.

## «Бөтенесе киресенчә»

Без хәзер Африка һәм Азиянең әллә кайдагы ерак почмакларында да илебезне белүләренә гадәти бер нәрсә итеп карыйбыз. Ә менә Америка пропагандасы һәм җирле буржуаз пропаганда дистәләрчә еллар буена дөньяда Советлар иле барлыгын Чили халкыннан яшереп килгән, безнең тормышны бозып, яманлап сөйләгән.

Чили кешеләренең илебез турында берни белмәүләренә кайвакыт хәтта гаҗәпкә дә каласың. Мәсәлән, бер мәктәптәге алтынчы класс балалары белән безнең менә мондый бер сөйләшү булды.

— Кайдан килдегез сез?

— Советлар Союзыннан. Беләсезме?

Укучы бала белмим дип башын чайкый.

— Берәрегезнең Мәскәү турында ишеткәне бармы?

— Юк, беребез дә белми.

Без гаҗәпкә калдык.

— Гагаринны беләсезме?

— Юк, белмибез.

— Айга төшкән очкыч, космос, Ай турында беләсезме?

— Беләбез, Армстронг, Америка астронавты,— диләр.

— ...?!!

Безнең ил турында бөтенләй ялгыш карашлы кешеләр дә бар. Мәсәлән, Вальдивия шәһәренең мэры белән сөйләшкәндә бер Чили кешесе болай дип сорады:

— Әйтегез әле, сездә ата-аналар үз балаларын күрә алалармы?

— Ничек инде ул, күрә алалармы? — дип кайтарып сорадым мин.

Шуннан соң мэрның урынбасары миңа болай дип аңлатып бирде:

— Сезнең илдә, әлбәттә, прогрессив строй, социализм төзелгән, ләкин сездә балаларны ата-аналарыннан аерып алып, интернатларда тәрбиялиләр икән. Шул сәбәпле без: «Ата-аналар үз балаларын күрә алалармы?» — дип сорыйбыз.

Аларга бездәге мәктәп-интернатларның нәрсә икәнлеген, ата-аналарның хокукын, мәктәпнең ролен һәм башкаларны аңлатып бирергә туры килде. Берничә көннән соң Вальдивия шәһәрендә булган пресс-конференциядә шул ук сораулар яңадан кабатланды. Кыскасы, пропаганда бөтенесен киресенчә аңлаткан.

Чили мәктәпләре белән танышканда, стеналарында тасма сыман озын географик карталар күргәч, беркадәр гаҗәбрәк тә тоелды безгә. Үзебездә бөтен стенаны тотырып торган карталар күреп гадәтләнгән бит без. Кара күзле чибәр генә бер укучы

малай, күрсәткеч таягын өстән аска шудырып, горурланган бер төс белән болай дип сөйли:

— Чили ул үзенә бер төрле ил,— ди.— Аның киңлеге — 200 километрдан алып 600 километрга чаклы, буе — 4200 километр. Көнчыгыш чиге карлы Кордильер таулары буйлап, көнбатыш ягы Тын океан буйлап сузыла. Төньягында, Перу һәм Боливия белән янәшә җирендә, эссе Атакама чүле җәелеп ята. Көньягында — Магеллан бугазы һәм мәңге эреми торган бозлары белән Утлы җир атавы бар. Төньяктан көньякка таба тасма шикелле сузылган төрле климатлы бу җирдә 9 миллионнан артык креол (испаннар токымы), метисләр (испаннар белән индеецләр токымы) һәм беркадәр араукан индеецләре яши. Төньягында итальяннар, ә көньяк провинцияләрдә немец поселоклары бар.

Безнең җирләрдә декабрь азагында карлы салкын кыш булса, Чилидә бу вакыт җәй уртасы булып санала, Сантьягода көннәр эссе, Атакама чүле ут кебек кыза, ә көньяк провинцияләрдә салкынча була.

Чилидән кайту белән миңа Татар Хуҗашы авылындагы сигезьеллык мәктәпкә барырга туры килде. Андагы өлкән класслар дәресенә кердем. География дәресе икән. Укучыларның алларындагы атласларында Көньяк Америка материгы төшерелгән бит ачып куелган.

География фәнен укучыларның күбесе ярата. Алар минем Чили турында сөйләвемне кызыксынып тыңлый башладылар. Чилидәге балаларның ничек яшәүләре турында бик күп сораулар бирделәр, ә мин бу вакытта аларның география дәресе икәнен исемнән чыгармадым.

— Декабрь аенда нигә бездә кыш була да, Чилидә бу вакытта 38 градуслы эссе җәй уртасы, анда җимешләр пешә?

— Нигә бездә көньякка таба барган саен җылырак, ә көньякта бик эссе, ни өчен Чилидә киресенчә — көньякка таба барган саен салкынрак, Магеллан бугазы янында Тын океан култыкларына әллә ничә метр калынлыктагы бозлыклар шуышып төшә?

Укучылар бу сорауларга тиз генә җавап бирмәделәр. Класста тынлык урнашты. Уйга калдылар. Шуннан соң бер малай кыяр-кыймас кына:

— Экватор,— дип әйтеп куйды.

Икенче берсе, шул фикерне куәтләп, без җир шарының иң эссе төше булган экватордан төньякта яшибез, ә Чили көньяктарак, шуңа күрә «бөтенесе киресенчә» дип аңлатырга кереште. Тасма шикелле озын карта янында басып торган Чили укучысы да шулай дигән иде. Әлбәттә, ул испанча җавап бирде, аннары үз иле белән безнең ил табигатен чагыштырганда ул да «бөтенесе киресенчә» дигән иде. Димәк, «киресенчә» дигәнебез кайдан торып әйтүгә карый икән.

## Икмәк һәм җир өчен

Чили йөз илле елдан артык инде буржуаз республика булып яшәп килә. Бу строй, әлбәттә, киң катлау халыкның дөньяга карашына билгеле бер йогынты ясаган, кешеләрне байлар өчен генә демократик булып саналган закон һәм принциплар рухында тәрбияләгән. Шул дәвер эчендә утыз тапкыр сайлаулар булган. Сайлау алды ярышлары кызган, әллә ничәләп партия үзара президент урыны өчен көрәшкәннәр. Властька нинди партия килсә дә, хезмәт халкы тормышның төп мәсьәләләрендә хокуксыз булып кала биргән: ул һаман да үз байлыгына үзе хуҗа була алмаган, һәм аның тормыш шартлары да, бер чилиле әйтмешли, «сизелмәслек дәрәҗәдә генә яхшырган».

Әмма дөньяда күп халыкларның язмышын үзгәртә торган көрәш дәвам итә. Мондый үзгәрешләр ерактагы Чилигә дә барып җитә. Латин Америкасы илләрендәге карагруһ полковниклар тарафыннан ясала торган бик күп контрреволюцион переворотларга җәмәгатьчелек инде күнегеп беткән. Ләкин 1970 елның сентябрь ае көтелмәгән шатлыклы бер хәбәр китерә: Чилидә, президент сайлап, халык властьны үз кулына ала.

Сайлау алды көрәше дәвамында бер хәл ачыклана: кулларында массовый информация чараларын тоткан күп акчалы буржуаз партияләр сайлауда компартия кандидаты Пабло Неруданың яки социалистлар кандидаты Сальвадор Альенденың җиңеп чыгуына юл куймаячаклар. Коммунистлар, беренче буларак, сул партияләрнең сайлауда үзара берләшү идеясен күтәреп чыгалар. Коммунистик һәм социалистик партияләр, радикаллар партиясе һәм сул христиан демократлар партиясе бергәләп уң партияләргә каршы чыгалар һәм халыкны социалистик партия лидеры Сальвадор Альендены яклап тавыш бирергә өндиләр. Әнә шул рәвешчә Чилидә халык бердәмлеге блогы туа.

...Тавышларны санап караганнан соң, Альенденың көндәшләреннән өстен чыгуы билгеле була. Ә парламентта күпчелек — уңнар — капиталистлар, вак һәм эре җир биләүчеләр, сәүдә буржуазиясе вәкилләре кулында. Уң карашлы газеталар, радио һәм телевидение исә алдан ук уңнар кандидаты Александре җиңәчәк дип әйтеп куйган була.

Радикаллар белән берлектә коммунистлар һәм социалистлар, Чили хезмәт ияләренең Бердәм профсоюз үзәге халыкка мөрәҗәгать итәләр. Илнең политик тормышындагы шушындый кыен бер вакытта йөз меңләгән гади кешеләр башкаланың һәм байтак провинция үзәкләренең урам һәм мәйданнарына чыгалар. Барлык лозунгларның да асылы бер таләпкә кайтып кала: власть халык бердәмлеге блогына бирелсен! Альенденың урыны — президент сарайнда!

Халыкка каршы барудан, революцион хәрәкәтнең күтәрелүеннән куркып, уңнар чигенергә мәҗбүр булалар. Сальвадор Альенде яңа хөкүмәт төзи. Ундүрт министрның бишесе — эшче, өчесе — коммунист, дүртесе — социалист. Марио Асторга — мәгариф эшләре буенча яңа министр — моңарчы Чили университетында гади бер укытучы булып эшләгән.

## Властьны саклап калу кыенрак...

Капитализм дөньясындагы кебек, Чилидә дә контрастлар тулып ята әле.

Чилинең шәһәрләрендә, бигрәк тә Сантьягода, эшсезләр күп. Алар, шәһәр читләрендәге җирләргә килеп, ящик такталары, фанер кисәкләреннән үзләренә алачыклар корып куялар. Ул алачыкларда адәм рәтле яшәү өчен кон яктысы да, су, канализация дә, бүтән шартлар да юк.

Шәһәрнең үзәгендә инде ярлыларны күрмәссез, анда Европа архитектурасы стилендә салынган матур-матур йортлар, искиткеч яхшы магазиннар өстендә — күз явын алырлык витриналар. Ярлылар анда берни эшли алмыйлар. Банкларда, яхшы магазин һәм рестораннарда аларга эш тә бирмиләр, анда берни дә сатып ала алмыйлар. Шәһәрнең үзәк урамнарында күбрәк яхшы киенгән таза хәлле кешеләр йөри, читтән карагнда — монда бөтен кеше дә яхшы яши икән дип уйларлык. Шәһәрнең үзәк кварталларыннан читкә чыккач кына балчык өйләр күрәсең һәм Чилидәге гади хезмәт ияләренең нинди йортларда яшәгәнен аңлыйсың.

Чили республикасының яңа хөкүмәте каршына берьюлы бик күп кыен мәсьәләләр килеп баса. Шулардан иң кыены — эшче һәм крестьяннарның тормыш шартларын яхшырту.

Чили эшчесе әле бик ярлы яши, кулында эше булган кеше генә, көч-хәл белән очын-очка ялгап, тормыш итә. Эшче ала торган иң аз хезмәт хакы — аена 300 эскудо (28 сум чамасы), ә Сантьягода итнең килосы — 35 эскудо. Эшче кеше аена 600—700 эскудо акча алса, бу инде яхшы хезмәт хакы булып санала.

Әгәр бездә эшче квартира өчен хезмәт хакының дүрт-сигез процентын бирсә, Чили эшчесе яртысын диярлек түли. Сантьягода бер бүлмә өчен генә дә 300 эскудо акча түләргә кирәк. Адәм рәтле костюм алу мең ярым эскудодан артыгракка төшә.

Хәтта хезмәт хакын «яхшы» алганда да гел ит ашап тормыйлар. Сантьягода ит айның беренче ун көнендә генә була, ә провинцияләрдә ит атнага ике-өч көн сатыла. (Кибет хуҗасы, йортның алдына кызыл әләм эләп куеп, кибетендә ит барлыгын хәбәр итә. Ак әләм эленсә — кибеткә ипи китерелгән була.)

Аз акча алучы эшче һәм хезмәткәрләрнең эш хакын 30—35 процентка арттыру турындагы карарны халык яңа хөкүмәтнең эшчәнлегендәге мөһим бер адымы итеп бәяли. Ләкин эш хакын алай арттыру өчен хезмәт җитештерүчәнлеген үстерергә, товарны күбрәк булдырырга кирәк. Предприятиеләрнең күбесе исә капиталистлар кулында.

Тагы икенче бер кыен мәсьәлә дә бар — шәһәрләрдә 300 меңнән артык эшсез кеше бар, нигездә алар — яшьләр. Аларны эшле итү өчен завод-фабрикалар салырга кирәк. Моннан тыш, илдә торак мәсьәләсе дә бик кыен, икмәк, ит җитешми, мәктәп, больницалар, укытучы, инженер, врачлар аз.

Эре җир биләүчеләр, завод, урман, юл хуҗалары байлыкларын халыкка бирергә теләмиләр, чит ил капиталистларының да Чилидән китәселәре килми. Уңнар инде янап-әркетеп кенә калмыйча, эшкә ук керешкәннәр — террорчы бандалар оештырып, бомба ташлаталар, акча һәм алтынны чит илгә алып китәләр, предприятиеләрне ябалар, заводларны туктаталар, төрлечә аяк чалалар....

Чили калаларында Мадрид, Париж, Марсель шәһәрләренә охшашлык бар. Чили университеты 1765 елда ук салынган булган. Читтән карaганда бу илдә халыкка әйбәт яшәү өчен бөтен шартлар да бар кебек. Чынында исә җир биләүчеләр һәм компрадор буржуазиясенең хакимлеге, экономиканы чит ил капиталы басып алуы нәтиҗәсендә Чили халкы үз хезмәтенең җимешләреннән үзе файдалана алмый. Бакыр рудникларын эксплуатацияләп кенә дә американлылар Чилидән утыз миллиард доллардан артык байлык алалар. Моннан йөз илле ел элек Конституция мәйданына салынган президент сараена безнең делегацияне кунакка чакыргач, Сальвадор Альенде илдәге әнә шундый кыенлыклар турында сөйләде. Әңгәмә шактый озак булды. «Марксист буларак мин халыкның тормышын җиңеләйтердәй мәсьәләләрне хәл итүне озакка суза алмыйм, шул сәбәпле без Америка монополистлары кулындагы бакыр рудникларын национализацияләү турында карар кабул иттек, җир реформасы ясап, крестьяннарыбызга җир өләшергә булдык. Эшсезләрне эшле итү, ач семьяларны икмәкле итү өчен безгә яңа предприятиеләр төзергә кирәк»,— диде Альенде.

Бер көннән соң, президент сараеның балконыннан торып, дистәләрчә Сантьяго халкы алдында чыгыш ясаганда, Альенде төп мәсьәләләрне хәл итүдәге кыенлыклар, уңнарның эшкә аяк чалырга тырышулары, бөтен халыкка берләшергә кирәклеге турында сөйләде. «Бердәмлек булмаганда без җиңеп чыга алмаячакбыз, властьны үз кулыбызда саклап кала алмаячакбыз»,— диде ул.

## Исәнме, маэстро!

Чили мәгарифе җитәкчеләре хезмәт ияләре балаларының барысын да укытырлык мәктәпләр булдыру өчен халык хөкүмәтенә әле байтак кына вакыт кирәк булачагын аңлыйлар. Чили укытучылары безгә мәгариф өлкәсендәге кыенлыклар турында күп сөйләделәр. Барлык балаларга да алтыеллык белем бирү турында 1923 елда ук гамәлгә кертелгән закон илле ел узганнан соң да әле үтәлмәгән, Чилидә уникеельлык урта мәктәпне эшче һәм крестьян балаларының бик азы гына тәмамлый ала икән. Беренче класска укырга кергән 406 мең баланың 103 меңе генә 1970 елда сигезенче классны тәмамлый, ягъни укучыларның 75 проценты мәктәпне ташлый. Беренче класстан ук дүрт баланың берсе төшеп кала. Моның сәбәбе — авыр тормыш шартлары: ата-аналар балаларын бик яшьли эшкә бирергә мәҗбүр булалар.

Көньяк провинцияләрдә халык башлыча терлекчелек, яшелчә үстерү, бодай игү белән шөгыльләнә. Күпчелек крестьяннар җирсез булып, җир биләүчеләрдә батраклыкка ялланып эшлиләр. Крестьян балалары сәтнең нәрсә икәнен дә белми үсә. Чилидә балалар күп үлә. Осорно провинциясендә бөтен дөнья күләмендә чагыштырганда иң күп бала үлә. Чилидә укый-яза белмәүчеләр уртача 20 процент булса да, бу провинциядә халыкның 80 проценты надан.

Илдә дәүләт мәктәпләре, хосусый мәктәпләр һәм чиркәү (католик) мәктәпләре бар. Чиркәү дәүләттән аерылган. Дәүләт мәктәпләрендә уку түләүсез. Хосусый мәктәпләрдә, гадәттә, бай кешеләрнең балалары гына укый, түләү хакы семьяның доходына карап куела. Мәктәптә уку срогы унике ел. Укулар испан телендә бара. Немецлар күп

яшн торган кайбер кеньяк провинцияларда немец телендә укыта торган башлангыч мәктәпләр дә бар. Уку елы 1 марттан башланып, 20 декабрьда тәмамлана.

Мәктәпкәчә тәрбия эше, башлангыч сигезьеллык һәм урта дүртьеллык белем бирә торган мәктәпләр белән Чилинең Мәгариф министрлыгы идарә итә.

Ике дәүләт университеты, мәктәпләр салучы акционерлар җәмгыяте һәм башкалар системалы рәвештә Министрлык белән бергә эшлиләр.

Чилидә төп уку формасы булып башлангыч сигезьеллык мәктәп санала. Аерым фәннәр укыту 5 нче класстан башлана. Бу мәктәпләр барлык балаларны да укуга тарту, контингентны сакларга тырышу кебек байтак кына кыенлыклар кичерә.

Сигезьеллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, яшьләрнең бер өлеше дүртьеллык урта мәктәпкә укырга керә. Шәһәрдәге урта мәктәпләрдә гадәттә 1—8 нче класслар юк. Бу мәктәпләр «гуманитар» һәм «профессиональ» мәктәпләргә бүленәләр. Гуманитар мәктәп дип, белгеч итеп хәзерләмичә, гомум белем генә бирә торган гадәттәге мәктәпләрне атыйлар. Бу мәктәпне тәмамлаган кеше университетның теләсә кайсы факультетына керә ала. 9—12 нче классларлагы 300 меңләп укучының 100 меңе гомум урта белем һәм белгечлек бирә торган профессиональ мәктәпләрдә укый.

Теориягә сәләтсезрәк балалар гадәттә профессиональ мәктәпләрне сайлыйлар. Эшче балаларының да күбесе, сигезенче класстан соң да укырга теләгәндә, шул ук мәктәпләргә укырга керә.

Профессиональ-техник урта мәктәп башлыча дүрт төрле белгечлеккә укыта: коммерция мәктәпләре, индустриаль мәктәпләр, техника белгечләре һәм халыкка хезмәт күрсәтү системасы, авыл хуҗалыгы мәктәпләре. Профессиональ мәктәптә укып чыккан кеше университетның гуманитар факультетына керә алмый, чөнки мәктәптә әдәбият, тел, тарих һәм географиядән кыскача курс кына узган була.

Чилинең Мәгариф министрлыгы планы буенча урта мәктәптә укучыларның саны ел саен 20 процентка арта барырга тиеш. Ләкин, хезмәт ияләренең балалары бик яшьли эшли башлаганлыктан, бу план хәзергә үтәлми әле.

Чилидә алты университет бар. Шуның дүртесе хосусый университет. Чили университеты белән техник университет — дәүләтнеке. Аларның төрле провинцияләрдә институт рәвешендәге факультетлары бар. Университетларның үз автономияләре бар, алар белән Ректорлар советы идарә итә, бу советка Мәгариф министры да керә. Бу ике университетның 80 меңләп студенты бар. Аларның күпчелеге демократик карашлы яшьләр. Болар арасында коммунистик яшьләр оешмасының байтак кына членнары да бар.

Укытучыларны университетларда һәм педагогия училищелары тибындагы «нормаль» мәктәпләрдә әзерлиләр. Чилидә йөз меңләп укытучы бар. Аз түгел бу. Ләкин авыл мәктәпләрендә укытучылар җитешми әле. Күпчелек укытучыларның югары белеме юк. Укытучыларның иң аз хезмәт хакы — аена 600 эскудо, уртача хезмәт хакы — 1500 чамасы. Өч ел эшләгәннән соң эш хакын беркадәр арттыралар, ә унбиш елдан соң бермә-бер арта. Укытучы хатынга, бала тапкач, өч айлык декрет ялы бирелә. Чили шартларында укытучы алган хезмәт хакы белән генә җитешле яшәп булмый, шуңа күрә укытучылар хезмәт хакының аз, мәктәпләрдәге материаль шартларның начар булуыннан, социаль тәэминатның начарлыгыннан һәм торак шартларының кыенлыгыннан ризасызлык белдерәләр.

Сантьягодан ун чакрымдагы матур калкулыклар өстенә укытучыларның белемен күтәрү һәм экспериментал тикшеренү үзәге урнашкан. Бу үзәкнең еллык бюджеты — 5 миллион доллар. Аның моннан өч ел элек дәүләт һәм укытучылар профсоюзы акчасына салынган заманча яхшы базасы бар (әйбәт биналары, кабинет, мастерскойлары, китапханәсе, укыту-техник җиһазлары һ. б.).

Укытучыларның белемен күтәрү планлы рәвештә алып барыла. Провинцияләрдә, университет факультетлары булган урыннарда бу эшне университет укытучылары ярдәме белән эшлиләр. Бу үзәкнең методистлары арасында гыйльми дәрәҗәле кешеләр дә бар. Аларның эш хакы университет укытучысының хезмәт хакына тигез. Тик хәзергә укытучыларның бик азы гына бу үзәккә килеп белем алып торырга тулай тәрак юк, ачысыннан да бигрәк — командировка вакытында хезмәт хакы сакланмый, шуңа күрә, үзәкнең директоры Марио Лейтон сүзләре белән әйткәндә, укытучыларның үз квалификацияләрен күтәрергә мөмкинлекләре юк икән.

Без әлеге үзәккә барганда анда байтак кына Латин Америкасы илләрендәге шундый ук үзәкләрнең җитәкче хезмәткәрләре семинары җыелган иде. Безгә алар алдында кыскача гына чыгыш ясарга да мөмкин булды.

Чилинең Мәгариф Министрлыгында, Чили укытучыларының берләшкән профсоюзында халык мәгарифен үзгәртеп кору турында күп сөйлиләр. Тик без бу үзгәрешнең нинди юллар белән тормышка ашырылачагын белә алмадык. Чили кешеләре әле үзләре дә бу мәсьәләнең асылын күз алдына китереп бетерә алмыйлар бугай. Халык мәгарифен үзгәртеп корудан максат — укучыларны тормышка әзерләү һәм аларның уйлау сәләтен үстерү булырга тиеш. Мәктәп программаларын һәм дәреслекләрнең эчтәлеген заман таләпләренә якынайтып үзгәртү күздә тотыла. Ләкин бу үзгәртүнең принциплары хәзергә ачыкланып бетмәгән әле. Әнә шул сәбәпле Чилидә мәгариф хезмәткәрләре СССРдагы мәктәп программаларының эчтәлеген үзгәртү мәсьәләләре белән кызыксындылар, бездәге мәктәпләрне үзгәртеп кору гринципларын җентекләбрәк аңлатып бирүебезне үтенделәр.

* * *

Без Чилидә әллә ни озак булмадык. Шулай да ачык йөзле, кунакчыл Чили укытучыларын без бик яраттык. Аларның бик күбесе халык властен яклый, укучыларга һәм ата-аналарга яңа властьның бурыч һәм максатларын күп аңлаталар. Чили укытучыларының берләшкән профсоюзы председателе Умберто Ульниста безгә, яңа Чилине барлыкка китерү өчен укытучылар бик тырышып эшлиләр, диде. Сигезенче класс укытучысын испанча «маэстро» дип, ә урта мәктәптәге өлкән класс һәм университет укытучыларын «профессор» дип атыйлар. Безнең белән саубуллашкан чакта Чили укытучыларыннан берсе:

— Без әле яхшылап танышып та өлгермәдек, сез инде китеп тә барасыз,— диде.

— Бу — безнең беренче делегация. Без әле тагы да очрашырбыз, шуңа күрә без дә сезнең белән бөтенләйгә хушлашмыйбыз, «буэнос диас, амигос» — хәерле иртә, дуслар, дибез. Исәнме, яңа Чили маэстросы! — дидем мин аңа.

Сантьяго Мәскәүдән бик ерак булса да, Чилинең кешеләре үзләренең рухлары, ирекле киләчәкләре өчен көрәшүләре белән бик якын безгә.

Ипполит Иванов

# РУХИ ТУГАННАР

*Татар һәм чуваш әдәбиятлары элемтәсе*

Чуваш халык шагыйре Педер Хузангай «Туган Татарстаныма» дигән шигырендә, безнең якын күршебез булган татар халкына карата барлык чувашларның уй-тойгыларын чагылдырып, менә болай дип язган иде:

**Сагынам сине һаман, Казан,**
**Хәтердә син, хәтердә син.**
**Яшьлегемә күзем салсам,**
**Сине күрәм хәзер дә мин.**
**Кайларда сез, кордашларым!**
**Хәтерлимсез яшьлек таңын!..**

**Синдә туды, нурлы Казан,**
**Минем иң беренче җырлар.**
**Кайда безнең уртак телдә**
**Шигырь укып йөргән еллар!—**
**Һади Такташ, Гадел Кутуй**
**Миңа киңәш биргән чорлар!!**

**Казан — минем кардәш калам,**
**Татарстан — матур, бай җир! —**
**Елдан-ел үс, балкы һаман,**
**Синең даның белсен бар җир!**
**Мин — бер улың, гүзәл калам!**
**Сиңа рәхмәт, сиңа сәлам!**

Безнең халыкларыбызның тарихи язмышлары шулкадәр охшаш ки, аларны бер-берсеннән аеру һич мөмкин түгел. Бу дуслыкның тамырлары бик ерак заманнарга барып тоташа. Безне бер-беребезгә территория, этнография һәм культура якынлыгы бәйли. Һәр ике халык тормышның, культура үсешенең барлык өлкәләренә үтеп кергән бу тыгыз бәйләнешнең шифалы тәэсирен тоеп, күп гасырлардан бирле кулга-кул тотынып гомер кичерә.

Урта Идел һәм Кама буйларында яшәгән җирле халыкларга күп төрле авырлыклар күрергә, әйтеп бетергесез газап-михнәтләр чигәргә туры килә. Ләкин, шуңа да карамастан, алар үз телләрен, үз культураларын саклап калу өчен барган көрәшне бер генә минутка да туктатмыйлар.

Чуваш халкы, башка милләт хезмәт ияләре — руслар, татарлар, марилар, башкорт һәм удмуртлар белән берлектә, сыйнфый дошманнарына каршы һәрвакыт аяусыз көрәш алып барды. Ул, нинди генә кыенлыкларга дучар булмасын, изүчеләргә баш иеп, буйсынып яшәргә теләмәде. Чуваш халык шагыйре Яков Ухсай «Кельбук бабай» поэмасында әнә шул хакта яза. «Кельбук бабайның Әхмәт агай белән әңгәмәсе» дип аталган бүлектә чуваш егетенең сөйгән кызы Зәйнәп турында, яшьләрнең фаҗигале язмышы турында сөйләнә. Аларның матур яшьлегенә, мәхәббәтенә балта чапкан дин кануннары һәркемнең йөрәгендә нәфрәт уятырлык итеп сурәтләнә.

Буйсындырып тоту җиңелрәк булсын өчен, патша Россиясендә чувашларны территориаль яктан берничә губернага таратталар. 1897 елда уздырылган халык санын алу нәтиҗәләреннән күренгәнчә, ул заманда 900 меңләп чуваш Казан, Сембер, Уфа, Самара, Оренбург губерналарында яши. Шуларның күпчелеге — 550 меңе Казан губернасына туры килә. Менә шуны искә алсак, чуваш халкының культурасын саклап калуда һәм үстерүдә Казанның нинди

әһәмияткә ия булуын күз алдына китерү кыен түгел. Иске Россиядәге фән һәм культура үзәкләренең берсе буларак, Казан чуваш халкының язма әдәбиятын тудыруда искиткеч зур роль уйный. Унтугызынчы йөзнең икенче яртысында Казандагы фән әһелләренең чуваш теленә, аның халык авыз иҗатына һәм этнографиясенә игътибары бермә-бер көчәя. Чуваш халкының теле һәм тарихы турында хезмәтләр языла, шактый бай этнографик әдәбият барлыкка килә. Ул хезмәтләрнең бөтенесе дә диярлек Казанда басыла.

Чуваш культурасының күп кенә эшлеклеләре Казан уку йортларында тәрбияләнәләр. Чуваш халкының күренекле мәгърифәтчесе И. Я. Яковлев (1848—1930) Казан университетында белем ала. Университетны ул 1875 елда тәмамлый һәм Казан уку округына керә торган чуваш мәктәпләренә инспектор итеп билгеләнә. Дөрес, аның карамагындагы мәктәпләрнең саны башта дистәдән артмый. Әмма яңа билгеләнгән инспектор чуваш балалары өчен яңа мәктәпләр ачу буенча зур эшчәнлек җәелдереп җибәрә. Аның турыдан-туры катнашы белән 1875 елдан башлап 1903 елга кадәр ачылган мәктәпләрнең саны 40 ка җитә. Сембердә чуваш мәктәпләре арта һәм ныгый. Казан уку йортлары кебек үк, ул мәктәпләр дә чуваш интеллигенциясе кадрларын хәзерләү үзәге булып әверелә.

Үзе оештырган мәктәпләрдә И. Я. Яковлев барлык халыклар арасында тигезлек һәм туганлык идеясен үткәрә. Җир йөзендә бик күп төрле кешеләр һәм халыклар яшәвен, ләкин тәннәренең төрле төстә булуына карап аларны бер-берләреннән аерырга ярамаганын һәрвакыт укучыларның исенә төшереп тора. Милләте белән рус булмаган халыклар, ди ул, Россия составына үги балалар булып түгел, ә аның тулы хокуклы уллары булып керергә тиешләр. «Руслар, татарлар, чувашлар — барысы да кешеләр»,— дип яза Яковлев үзенең «Чувашлар өчен әлифба»сында, һәм укучыларны ул беркайчан да милләтләренә карап аермый.

Чуваш культурасының, әдәбиятының алга таба үсеше өчен Яковлев күрсәткән хезмәтләрнең әһәмияте әйтеп бетергесез зур булды. Аның күп яклы эшчәнлеге чуваш халкының тормыш-көнкүрешен, культурасын, милли үзенчәлекләрен һәрьяклап өйрәнүгә этәргеч ясады. Казан галимнәре, Казан университеты укытучылары һәм студентлары чуваш халкының тарихын гыйльми өйрәнүгә аеруча күп көч куйдылар. Унтугызынчы йөзнең икенче яртысында чувашларның тормыш һәм көнкүрешен объектив күзлектән чыгып, нигезле итеп тикшерүчеләрнең берсе булган В. К. Магницкий (1839—1901) эшчәнлеге аерым игътибарга лаек.

Шушы якта туып үскәнлектән, ул чуваш халкының тормышын бик яхшы белә. Казан университетын тәмамлаганнан соң, Магницкий үзенең бөтен гомерен Идел буенда яшәүче рус булмаган милләтләр арасында эшләүгә багышлый. Башта суд тикшерүчесе, аннан халык училищелары инспекторы сыйфатында, бик күп урыннарда була һәм бай материал җыйный. Аны патша чиновникларының җирле халыкка карата булган тупаслыгы нәфрәтләндерә, изелгән халыкларның милли интеллигенциясе үсүен күреп, ул чиксез шатлана, чуваш мәгърифәтенең ул вакыттагы эшлеклеләреннән Н. И. Ашмарин, М. Ф. Федоров, И. Ю. Юркин кебекләрнең әдәби һәм иҗтимагый-культура эшчәнлекләренә һәрьяклап булышлык күрсәтә.

Гомеренең күп өлешен төрки телләрне өйрәнүгә багышлаган профессор Н. И. Ашмарин һәркемне сокландырырлык хезмәтләр калдыра. Студент чагында ук инде ул чуваш теле белән кызыксына. 1894 елда Казан уку йортларында укытучы булып эшли башлый һәм чуваш теле сүзлеген төзүне дәвам иттерә. Аның тарафыннан чуваш теленең йөз мең сүздән торган унҗиде томлык сүзлеге төзелә.

Чуваш интеллигенциясе арасыннан чыккан күренекле кешеләрнең һәркайсының диярлек язмышы Казан белән тыгыз бәйләнгән. Чуваш телендә язылган беренче оригиналь балладаның авторы М. Ф. Федоров, белемгә сусап, 1878 елның январенда Казан укытучылар институты каршындагы курсларга укырга килә. Укытучылар хәзерләү буенча ачылган бу курсларны уңышлы тәмамлап, бер елдан соң ул туган ягына кайта. Эшкә билгеләнүен көтеп, җәйне авылда уздыра һәм шунда хәзер инде һәрбер чуваш укучысы яттан белгән «Шүрәле» балладасын иҗат итә.

Татар һәм чуваш әдәбиятлары арасындагы элемтә беренче рус революциясе елларында аеруча ныгый. Бу бик табигый хәл. Эшчеләрнең революцион хәрәкәте крестьяннарның һәм изелгән халыкларның милли азатлык хәрәкәте белән кушыла. Казан шушы хәрәкәтнең бер үзәгенә әверелә. РСДРПның Казан оешмасы губернада яшәүче рус булмаган халыклар арасында агитация-пропаганда эшләре алып баруны көчәй-

тә, аларны патша хөкүмәтенә каршы бердәм көрәшкә туплый. Революцион хәрәкәтнең көчәюеннән курыккан патша ашыгыч рәвештә манифест чыгара. Шуннан файдаланып, чуваш интеллигенциясе вәкилләре үз телләрендә Казанда «Хыпар» («Хәбәрләр») дигән газета чыгарырга рөхсәт алалар. Үзе күтәреп чыккан күп кенә мәсьәләләр буенча газетаның позициясе большевиклар куйган таләпләргә бик якын тора. Милли мәсьәләгә килгәндә, газета барлык милләтләрнең дә тигез хокуклы булырга тиешлеген яклап чыга: «Хезмәт халкының интереслары — татармы ул, рус яки чувашмы — һәркайсыныкы бер үк төсле». Мондый чыгышлары өчен газета, әлбәттә, җәзасыз калмый. Озакламый аны чыгаруны бөтенләй тыялар. Ләкин кыска гына вакыт эчендә чыгып калуына да карамастан, «Хыпар» газетасы чуваш вакытлы матбугатын үстерү, халык массаларын революцион рухта тәрбияләү, милли интеллигенциягә дөрес юнәлеш бирү юлында шактый зур эш башкара. Чуваш әдәбиятының К. В. Иванов, Н. И. Полоруссов-Шелеби, Тайр Тимки, Н. В. Шубосинни кебек күренекле вәкилләре «Хыпар» газетасы идеяләрендә тәрбияләнәләр. «Интернационал»ны беренче тапкыр чуваш теленә тәрҗемә иткән талантлы шагыйрь Тайр Тимки Казандагы социал-демократик оешмалар белән тыгыз элемтәдә була, Казан большевиклары Х. Ямашев, Н. Накоряков һәм башкалар белән очраша. Үзенең шигырьләрендә ул халыкны изүчеләргә каршы бердәм көрәшкә күтәрелергә чакыра. Большевистик оешмалар белән бәйләнеш тотуда гаепләп, озакламый аны кулга алалар һәм сөргенгә җибәрәләр.

Ул елларда Н. И. Шелеби поэзиясе дә көчле публицистик характер ала. 1907 елда «Хыпар» газетасында басылган «Җылан» шигырендә ул иске җәмгыятькә каршы кыю рәвештә күтәрелә. Революцион-демократик чуваш әдәбияты, әлбәттә, башка әдәбиятлардан аерылган хәлдә, үзеннән-үзе генә үсми. Аның үсешенә рус, татар һәм башка халыклар әдәбиятларының бай традицияләре көчле йогынты ясый. Революциягә кадәр яшәгән чуваш шагыйрьләренең иҗатларына аеруча Габдулла Тукай иҗатының йогынтысы зур була. Чөнки күп гасырлык тәҗрибәгә, рус һәм көнчыгыш әдәбиятларының бай традицияләренә таянып үскән татар әдәбияты Тукай иҗатында иң югары ноктасына күтәрелде. Яңа туып килгән яшь әдәбиятларның күпчелек вәкилләре әнә шул биеклеккә омтылалар. Аларны Тукайның иске дөнья тәртипләрен аяусыз рәвештә кире кагуы, үз халкының көченә һәм сәләтенә чиксез ышануы, аны барлык изүчеләргә каршы көрәшкә өндәве, халыклар дуслыгы җырчысы булуы сокландыра. Халык бәхете һәм якты киләчәк өчен көрәш юлында шагыйрьне берниндн кыенлыклар да, берниндн янаулар да куркытмый.

Тарихи язмышларында татар халкы белән бик күп уртаклыклары булган чувашлар өчен Габдулла Тукай поэзиясе аеруча якын. Тукай әсәрләрендә аларның уй-хыяллары, теләк-омтылышлары чагыла. Менә шуңа күрә дә Тукай һәм революциягә кадәр яшәгән чуваш шагыйрьләренең иҗатларында уртак мотивлар күп булуы бер дә гаҗәп түгел. Мондый уртаклык Г. Тукай һәм чуваш әдәбияты классигы К. Иванов иҗатларын чагыштырып карагандa бигрәк тә ачык күренә.

Алдауга һәм талауга корылган дөньяның өшәкелеген Тукай бик күп шигырьләрендә фаш итә.

К. Ивановның «Шайтан колы» исемле трагедиясендә дә байлык һәм акчаның кешеләрне коточкыч җинаятькә этәрүе тасвирлана. Акчага табынып яшәүнең кеше рухын гарипләве шагыйрьнең «Нарспи» поэмасында тагын да тулырак чагыла. Акчага кызыгып, әтисе үзенең кызы Нарспины бер картка кияүгә чыгарга мәҗбүр итә һәм шуның белән ул Нарспиның бәхетен җимерә. Нинди генә юл белән булса да баеп калырга тырышкан аганың комсызлыгы ахыр чиктә Нарспиның үләменә сәбәп була.

Г. Тукай һәм К. Иванов тормышта кешенең шәхес буларак һәрьяклап үсүе өчен кирәкле шартлар тудырылуын таләп итәләр, кешедәге матур сыйфатларның кайчан да булса җиңеп чыгачагына, чәчәк атачагына ышаналар, аның акылына, иҗат көченә мәдхия җырлыйлар. Болар барысы да бер үк чорда яшәгән ике шагыйрьнең идея-эстетик карашлары һәм иҗат принциплары якын булуы турында сөйли. Бу принциплар исә татар һәм чуваш халыклары тормышындагы социаль-экономик һәм политик шартларга нигезләнә.

Һәрбер милли шагыйрь, барыннан да элек, үз халкының, үз милләтенең рухын аның иң көчле чагылышында күрсәтергә омтыла. Башка халыклар өчен ул шуның белән кызыклы да. Г. Тукай поэзиясе татар халкының табигатендә, рухында булган барлык матур якларын үзенә җыйган. Менә

шуңа күрә дә ул гомумхалык культурасының бер өлеше булып, әле бүген дә бик күп халыкларга армый-талмый хезмәт итә. Советлар Союзының күп милләтле башка республикаларындагы шикелле үк, Чувашстанда да Тукайны беләләр һәм үз итәләр. Чуваш теленә аның шактый күп әсәрләре тәрҗемә ителгән. Чувашлар Тукайның «Көзге җилләр», «Япон хикәясе», «Шагыйрь», «Эштән чыгарылган татар кызына», «Шүрәле», «Сабыйга», «Су анасы» кебек шигырь һәм поэмаларын үз ана телләрендә укыйлар. Чуваш телендә Тукайның аерым җыентыклары, аның тормышы һәм иҗаты турында язылган күп санлы фәнни хезмәтләр, мәкаләләр, очерклар басылып чыкты. Мондый олы мәхәббәтне Тукай башка халыкларга үз милләтенең җанын, рухи дәньясын тулы итеп, талантлы итеп ачып бирүе белән яулап алды.

Чын шагыйрь шуның белән дә бөек, һәр җирдә һәм һәркайда ул һәрвакыт үз халкы белән бергә, үзенә тапшырылган бөек миссияне үтәү юлында. Тукай да, Иванов та үзләренең идеалларына беркайчан да хыянәт итмәделәр, байлыкка, тыныч тормышка кызыгып, талантларын, кирәк икән хәтта җаннарын да сатарга әзер торучыларга алар нәфрәт белән карадылар. Бөек Октябрь социалистик революциясе, Россиянең башка халыклары белән бергә, чуваш халкын да барлык изүләрдән азат итте, халык талантларының чәчәк атуы өчен киң юл ачты, аның культурасын һәм мәгарифен, әдәбиятын һәм матбугатын үстерү өчен бөтен шартларны тудырды. Октябрьдан соң чуваш милли матбугатында зур үзгәрешләр булып узды. Контрреволюция органына әверелгән һәм революцион карашлы чуваш солдатлары һәм эшчеләре тарафыннан ябылган «Хыпар» газетасы урынына тулысынча Совет власте платформасында торган «Канаш» газетасы чыга башлады. Шул ук вакытта чуваш телендә башка бик күп вакытлы басмалар барлыкка килде. 1918 елда Казанда беренче чуваш профессиональ театрының төзелүе драматургиянең чагыштырмача тиз үсә башлавына этәргеч ясады. Беренче тапкыр чуваш телендә сәхнәгә куелган оригиналь әсәр авыл укытучысы Михаил Акимов-Аруйның «Вакытсыз үлем» пьесасы булды. Үзенең театрлары һәм күренекле артистлары белән элек-электән дан тоткан Казан чуваш театрының милли кадрларын тәрбияләүдә дә зур роль уйнады.

Революция елларында Казанда һәм башка шәһәрләрдә чыгып килгән газета-журналлар тирәсенә тупланган чуваш интеллигенциясе вәкилләреннән М. Сеспель, Г. Зайцев-Талмурза, И. Ундрицов-Ахах, И. Ефимов-Тхти, Н. Полоруссов-Шелеби, М. Акимов-Аруй, Ф. Павлов, С. Фомин, П. Осипов, И. Максимов-Кошкинский һәм башкалар соңыннан чуваш әдәбияты һәм сәнгатенең төрле жанрларын үстерүгә үзләренең бөтен сәләтләрен багышладылар.

Бөек Октябрь революциясеннән соң киң үсеш юлына аяк баскан чуваш әдәбиятына рус, татар һәм башка халыклар әдәбиятларының йогынтысы зур булды. Татар һәм чуваш әдипләре арасындагы иҗади дуслык совет чорында тагын да үсте, ныгыды.

Чувашстанда Г. Тукай һәм башка татар язучыларының иҗатын тикшерү һәм өйрәнү буенча шактый эш башкарылды. Бу уңайдан, барыннан да элек, Я. Ухсайның «Габдулла Тукай», Ф. Шапошников белән В. Долговның «Тукай әсәрләре чуваш телендә», Е. Владимировның «Габдулла Тукай һәм революциягә кадәр яшәгән чуваш шагыйрьләре иҗатлары арасындагы бәйләнеш», Н. Павловның «Г. Тукай һәм Константин Иванов» дигән мәкаләләрен күрсәтеп үтәргә кирәк. Ләкин бу өлкәдә әле эшләнәсе эшләр дә аз түгел. Бездә әле, мәсәлән, чуваш совет поэзиясенә нигез салучы Михаил Сеспельнең поэтик таланты формалашуга Тукай иҗатының йогынтысы турындагы хезмәтләр бөтенләй юк.

Хәлбуки, Сеспельгә дә Тукай иҗатының йогынтысы бәхәссез. Совет властеның беренче елларында Сеспель Казанда яши һәм Чувашстан автономияле республикасы төзелгәнгә кадәр шунда чыгып килгән «Канаш» газетасы белән хәбәрләшеп тора. Татарлар һәм аларның әдипләре белән якыннан аралашкан Сеспельнең, әлбәттә, Тукайның «Шагыйрь» исемле шигырен белмәве мөмкин түгел. «Диңгезгә» дигән шигырендә ул да шагыйрьнең иҗтимагый роле турында тирәнтен уйлана, халкының барлык шатлык-кайгыларын уртаклашып, үз язмышын халык язмышы белән аерылгысыз итеп бәйләгән шагыйрь образын тудыра. Терелүенә инде өмете киселеп, каты авырып яткан хәлдә дә ул үзе турында түгел, халкы турында кайгырта, аның интересларын үз интересларыннан өстенрәк күрә. Кырымда дәваланып ятканда, Сеспель Идел буенда яшәүче халыклар өстенә коточкыч бәла — 1921 елгы ачлык ябырылуы турында ишетә һәм, дәвалану курсын да тәмамлап бетермичә, украин авылларына юл тота. Анда ул еракта ачлыктан газап чигүче як-

ташларына ярдәм итеп җибәрү өчен азык-төлек җыйнауны оештыра.

Чуваш язучылары иҗатына Тукай поэзиясенең йогынтысы К. Иванов, М. Сеспель һәм Тайр Тимкидан алып безнең чорда иҗат иткән әдипләргә кадәр килә. Иҗатларының формалашуына татар язучыларының зур йогынты ясаганлыгын раслау өчен П. Хузангайның «Туган Татарстаныма», «Хәсән Туфанга», «Татар шагыйрьләренә», Я. Ухсайның «Муса Җәлил», «Мине татар, диләр» кебек шигырьләрен күрсәтеп үтү дә җитә. Чуваш халык шагыйре Якоа Ухсай «Мине татар, диләр» шигырендә үзенең Мәҗит Гафури белән дус булуы, Хәсән Туфан һәм Муса Җәлил белән очрашулары турында илһамланып яза, аларның иҗат осталыкларына соклануын белдерә.

1920 елның июнендә Чуваш автономияле өлкәсе төзелгәч, автономиянең җитәкче органнарында эшләү өчен хәзерлекле кадрлар, учреждениеләрне урнаштыру өчен биналар җитешми. Шуңа күрә башта ул учреждениеләр үзләренә йөкләтелгән вазифаларны Казанда урнашкан хәлдә үтиләр. Казан партия оешмасы һәм барлык хезмәт ияләре тәҗрибәле кадрлар, белгечләр һәм төрле кирәк-яраклар җибәреп, Чуваш автономияле өлкәсенә зур ярдәм күрсәтәләр. Казаннан килгән полиграфистлар көче белән Чабаксарда типография оеша һәм эшли башлый. Революциягә кадәр Чувашстанда бер генә профессиональ культура учреждениесе дә булмый. Культура төзелешен үстерү буенча да чуваш халкына Казан үзенең ярдәм кулын суза. Автономияле өлкә төзелгәч, чуваш телендә чыга торган «Канаш» газетасы редакциясе, чуваш театры һәм чуваш дәүләт нәшрияты акрынлап Казаннан Чабаксарга күчә, Казанда эшләгән чуваш язучылары, журналистлары һәм галимнәре дә шунда кайта.

...Чувашстан язучылар союзы оешу республикадагы барлык әдәби көчләрне бер коллективка тупларга мөмкинлек бирде. Бу эштә, рус язучылары белән беррәттән, башка тугандаш әдәбиятларның, шул җөмләдән татар әдәбияты вәкилләренең дә булышлыгы зур булды. Ул елларда татар һәм чуваш язучылары арасындагы үзара бәйләнешнең үсүен аларның бер-берсенә күршедәш республикаларда яшәүче халыкларның тормышы белән якыннан кызыксына башлаулары да бик ачык раслый. Татар әдәбиятының күренекле әдипләреннән К. Нәҗми, Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, Ф. Бурнаш, Т. Гыйззәт, З. Бәшири, Ш. Усманов, Г. Бәширов һәм башкалар үзләренең әсәрләрендә чуваш халкы вәкилләренең кызыклы һәм тормышчан образларын тудыралар.

З. Бәширинең «Чуваш кызы Әнисә» повестенда чуваш Аксаби белән татар карты Таҗи арасындагы эчкерсез дуслык, чуваш кызы Әнисәнең татар егете Зәрбигә булган романтик мәхәббәте тасвирлана. Әсәрнең төп герое Зәрби бабасы Таҗиның, татарлар һәм чувашлар арасындагы дуслыкны югалтмагыз, дигән васыятен күңел түрендә саклый. Аның әтисе Шереби дә чувашлар турында, алар намуслы һәм киң күңелле халык, дигән матур фикердә тора. Чуваш һәм татар язучылары З. Бәширинең бу повестен дуслык китабы дип атадылар. Әсәр менә ничә дистә еллар буе инде ике халык арасындагы дуслыкны ныгытуга хезмәт итә. Чуваш укучылары арасында Кави Нәҗминең «Язгы җилләр» романы да киң таралган. Чуваш егете Егор һәм татар крестьяны Нигъмәтҗан үзләрен изүчеләргә каршы берләшеп көрәшәләр, кыен чакта икесе дә татар эшчесе Мостафага таяналар.

Утызынчы елларда чуваш һәм татар әдәбиятларының дуслыгы тагын да ныгый. Н. Шелеби, Я. Ухсай һәм И. Тхтиның Татарстан турындагы тирән эчтәлекле шигырьләре, хикәя һәм очерклары барлыкка килә, татар язучыларының чуваш укучылары белән очрашулары уздырыла, татарчадан чувашчага һәм, киресенчә, чувашчадан татарчага бик күп әсәрләр тәрҗемә ителә.

«Утызынчы елларда, Мәскәүдә яшәгән чагында,— дип искә ала Я. Ухсай,— мин һәркөнне диярлек дустым Муса Җәлил белән очраша идем. Мәскәү урамнары буйлап йөргәндә ул Тукай шигырьләрен укырга ярата, безнең Ивановны татар теленә, ә Тукайны чувашчага тәрҗемә итәргә кирәклеге турында сөйли торган иде. Һәм Муса, чыннан да, үзенең сүзен онытмады: аның булышлыгы белән, шагыйрь Шәрәф Мөдәррис тарафыннан тәрҗемә ителеп, «Нарспи» поэмасы сугышка кадәр үк татар телендә басылып чыкты».

Фашист илбасарларына каршы көрәшкә күп милләтле Советлар Союзының барлык халыклары бердәм күтәрелде. Бөек Ватан сугышы чорында безнең язучыларыбызның әсәрләрендә халыклар дуслыгы темасы үзенең бөтен көченә яңгырады. Гитлерчыларның Советлар Союзы халыклары арасында дошманлык тудыруга токтан исәпләрен юкка чыгаруда совет әдәбиятының да хезмәте аз булмады. Совет кешеләрен ул чын гуманизм рухында, интернационализм рухын-

да тәрбияләде. Чуваш шагыйре Н. Шелеби, мәсәлән, азатлыкны яклаучы ил хуҗаларын — русларны, чуваш һәм татарларны фашист илбасарларны тизрәк җиңү өчен сугышка бергәләп күтәрелергә чакыра. Чуваш халык шагыйре С. Эльгер чуваш халкының данлыклы улы, Советлар Союзы Герое Иван Смирнов турында «Ул үлемсез» дигән поэма язды. Поэманы укыганда безнең күз алдыбызга халык әкиятләрендәге батырны хәтерләткән эпик образ килеп баса. Сугышка керер алдыннан взвод командиры Смирнов үзенең пулеметчикларына — төрле милләт вәкилләренә менә болай дип мөрәҗәгать итә: «Без, Идел буенда яшәүче төрле милләт уллары, төрле телдә сөйләшүче кешеләр — чувашлар, татарлар, удмурт һәм мордвалар бергә, рус туганнарыбыз белән иңгә-иң торып, Ленин шәһәрен һәм шуның белән бергә, үзебезнең Идел буен сакларга килдек».

А. Әсхилнең легендар Гастелло белән бергә сугышкан һәм Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган чуваш очучысы Ф. Н. Орлов турындагы «Бөркет» поэмасы да интернационализм идеясе белән сугарылган. Сугышта Орлов ялгызы түгел. Аның белән янәшә — рус Никоноров, татар Гобәйдуллин, чувашлардан Лаптев, Васильев, Ефимов. Очучы-герой, полковник Федот Орловның куркусыз образы драматургиядә дә сурәтләнә. Анда да ул үзе генә түгел, украин очучылары Бутенко һәм Милостивенко, рус Стрельцов, татар Мөхәммәтҗанов һәм башка коралдаш дуслары белән бергәләп хәрәкәт итә.

Сугыш елларында безнең әдәбиятыбыз чын мәгънәсендә зур сынау үтте. Бу чор әдәбият үзе яклап көрәшкән гуманистик принципларның һәм югары идеалларның тантана итү чоры булды. Ил язмышы хәл ителгән авыр көннәрдә төрле формалистик, абстракт-схоластик схемаларны бер як читкә этәреп, халыкның бөтен шатлык-кайгыларын үзендә чагылдырган чын поэзия мәйданга чыкты. М. Светлов, А. Твардовский, М. Алигер, О. Берггольц, К. Симонов, М. Җәлил, Я. Ухсай һәм төрле телләрдә язган башка бик күп шагыйрьләрнең ялкынлы шигырьләрендә сугыш лирикасы югары биеклеккә күтәрелде. Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре», күп милләтле әдәбиятыбыз тарихына совет кешесенең батырлыгын һәм үлемсезлеген чагылдыручы мәңгелек һәйкәл булып керде. Матбугатта басылып чыгу белән, ул бик күп телләргә, шул җөмләдән чуваш теленә дә, тәрҗемә ителде. Фашистлар тоткынлыгында язылган ул дәфтәрнең буеннан-буена Ватанга, халыкка, партиягә бирелгәнлек кызыл җеп булып сузыла. Андагы шигырьләрнең һәр юлы, һәр сүзе өчен шагыйрь йөрәк каны белән түләгән. Аның патриотизмын, көчен, горурлыгын, җиңүгә булган ышанычын берниндә кыеклыклар да, кеше түзә алмаслык җәзалар да какшата алмаган. Үлем балтасы күтәргән палачларына ул җирәнеп карый һәм алар алдында беркайчан да тез чүкмәячәген белдерә.

Герой шагыйрьнең онытылмас образы, батырлык белән тулы тормышы җирдә ирек сөеп яшәүче һәр кешене халыкка тугры хезмәт итәргә чакыра, иминлек хакына моңарчы күрелмәгән тиңдәшсез батырлыклар эшләргә рухландыра. Муса Җәлил тормышының һәм иҗатының безнең чуваш язучыларыннан Я. Ухсай, П. Хузангай, С. Шавлы әсәрләренә йогынтысы зур булды. Аның героик үрнәге бүгенге көндә үсеп килүче яшь әдипләребезгә дә мисал булып тора.

Совет кешеләренең илгә бирелгәнлеге, патриотизмы совет әдәбиятының Бөек Ватан сугышы чорында туган бик күп әсәрләрендә үзенең көчле чагылышын тапты. Мисал өчен язылу стильләре төрлечә булган әсәрләрдән Б. Горбатовның «Непокоренные» романын, О. Берггольцның Ленинград блокадасы турындагы шигырьләрен, М. Җәлилнең «Моабит дәфтәре»н, П. Хузангайның «Аптраманнар нәселе» исемле шигъри романын күрсәтергә мөмкин. Бу чорда шулай ук тематикасы һәм язылу стиле ягыннан бер-берсенә охшаган әсәрләр дә барлыкка килә. Шундыйлар рәтенә, мәсәлән, Бөек Ватан сугышының күренекле геройларына багышланып төрле телләрдә язылган әсәрләрне кертергә була. Татар әдибе Шәрәф Мөдәррис һәм чуваш шагыйре Яков Ухсай бер үк вакытта диярлек фронтовик-солдат исеменнән үз халыкларына хат язуны оештыралар. Татар шагыйрьләре Г. Хуҗи, Н. Арсланов, чуваш шагыйре П. Хузангай, рус шагыйрәсе М. Алигер Зоя Космодемьянскаяның батырлыгы турында шигырь һәм поэмалар иҗат итәләр. Татар һәм башка милләт әдипләре Матросов, Гастелло, яшь гвардиячеләр һәм Ватан сугышының башка геройлары турында әле бүген дә әһәмиятләрен югалтмаган әсәрләр язалар.

Сугыш чоры әдәбияты әсәрләре арасында безнең героик тылыбызның күркәм эшләрен чагылдырган әсәрләр дә зур урын алып тора. К. Турханның «Деревня в вет-

лех» романында сугыш елларындагы авыл тормышы тасвирлана. Романда чувашларның, татар һәм эвакуацияләнеп килгән украиннарның тату семья булып, бер үк теләк — дошманны тизрәк җиңү теләге белән янып яшәүләрен тоясың. Социалистик һәм коммунистик төзелеш чорында татарлар һәм чувашлар арасындагы дуслыкның тагын да ныгый баруы Я. Ухсай, А. Талвир, В. Юдин, А. Алга һ. б. чуваш язучыларының иҗатларында киң чагыла. Татар язучылары да чуваш әдәбияты алдында бурычлы булып калмыйлар. Аларның соңгы вакытта иҗат ителгән әсәрләрендә дә без чуваш халкы вәкилләрен бик еш очратабыз.

Шулай итеп, татар һәм чуваш әдәбиятларының арадашлыгы озак вакытлардан бирле яшәп килә. Бу ике милләт язучыларының һәр буыны, моңарчы яшәп килгән традицияләргә таянып, ике арадагы бу бәйләнешне үстерә бара, эстафета итеп аны киләчәккә илтә. Сугыштан соңгы елларда Чувашстан һәм Татарстан язучылары арасындагы элемтәне ныгыту буенча татар әдипләре һәм әдәбият белгечләреннән М. Әмир, И. Гази, А. Шамов, Г. Бәширов, М. Гайнуллин, Г. Кашшаф, Ш. Мөдәррис, Ә. Исхак, З. Нури, С. Сабиров, Ш. Рәкыйпов, К. Латыйпов һәм башкалар шактый күп эш башкардылар. П. Хузангай, Я. Ухсай, А. Алга, К. Турхан, А. Афанасьев, С. Шавлы, В. Юдин, К. Петров, Т. Петров кебек чуваш язучылары да үз укучыларын татар әдәбиятының күренекле әсәрләре белән таныштыру юлында көчләрен кызганмый эшләделәр һәм эшлиләр.

Милли культураларының бер-берләренә үзара тәэсире, нәтиҗәле йогынтысы турында соңгы вакытта шактый хезмәтләр язылды. Бу мәсьәлә буенча Татарстанда кызыклы гына күзәтүләр ясалды. Монда иң беренче чиратта К. Гыйззәтовның «Әдәбиятта һәм сәнгатьтә милли форманың үсеше турында», Б. Гыйззәтнең «Халыкның рухи үсешендә культура байлыклары алмашуның роле», М. Гайнуллинның «Идел буе, Урал һәм Казагыстан халыклары әдәбиятларының үзара бәйләнеше һәм баюы мәсьәләләре» дигән хезмәтләрен күрсәтеп үтәргә кирәк. Озак тикшеренүләр нәтиҗәсе буларак туган шундый ук хезмәтләр Чувашстанда да басылып чыкты.

Милли культуралар бик борынгы заманнардан бирле үзара бәйләнештә торалар. Татар һәм чуваш халыклары культуралары арасындагы бәйләнешнең дә тамыры бик тирәндә. Чувашстан республикасының 50 еллыгына багышланып уздырылган тантаналы җыелышта чыгыш ясаганда Татарстан АССР Министрлар Советы председателе иптәш Усманов менә болай диде: «Безнең эшчеләребез, колхозчыларыбыз, галимнәребез, әдәбият, культура һәм сәнгать работникларыбыз арасындагы чын дуслык көннән-көн үсте һәм ныгыды. Чуваш теленә татар язучыларының 200 дән артык әсәре, ә татар теленә чуваш язучылары һәм шагыйрьләре Эльгер, Уяр, Алга, Хузангай, Талвир, Терентьев, Ухсай һәм башкаларның менә дигән иҗат үрнәкләре тәрҗемә ителгән. Бездә чуваш композиторларыннан Лукин, Васильев, Ходящев, Лебедев, Токарев, Фандеев, Асламас музыкаларын яратып тыңлыйлар. Без сезнең чигү һәм агачтан кисеп эшләү осталарыгызның әсәрләрен югары бәялибез».

Бүгенге көндә милли әдәбиятларның үзара бәйләнеше аларның бер-берсенең тәҗрибәләреннән, чынбарлыкны чагылдыру өчен кирәк булган форма һәм методлардан уртак файдалану белән генә чикләнми. Хәзер бер милләт язучылары үз әсәрләренә төп герой итеп еш кына башка милләт вәкилләрен сайлап алалар. Мәсәлән, милләте белән чуваш булган космонавт Андриян Николаев турында татар язучылары, татарның милли герое Муса Җәлил турында чуваш язучылары тарафыннан әдәби әсәрләр язылды. Кайчагында бу уртаклык шундый тирән, икенче халыкның милли культурасына шулкадәр органик бәйләнгән, аны әсәрнең эчке тукымасына тулы анализ ясамыйча күрүе дә кыен.

Советлар Союзы халыкларының бердәм дуслыгы ярдәмендә алга киткән тугандаш милләтләрнең культуралары көннән-көн үсә һәм гомумхалык өчен уртак булган коммунистик культураның чәчәк атуына үзеннән зур өлеш кертә.

**Фәйзелхак Газизуллин,**

*экономика фәннәре кандидаты*

# Г. ФӘЕЗХАНОВНЫҢ СОЦИАЛЬ-ЭКОНОМИК КАРАШЛАРЫ

XIX йөзнең икенче яртысындагы социаль-экономик фикер тарихын фәнни өйрәнү татар халкының экономик һәм иҗтимагый-политик тормышындагы процессларны ачыклау өчен хәлиткеч әһәмияткә ия.

Экономик фикер тарихын өйрәнүнең практик яктан да зур әһәмияте бар. Илебез халыкларының фикер мирасын дөрес аңлатмый һәм аңа карата гыйльми мөнәсәбәт булдырмый торып, совет кешеләрен, бигрәк тә яшь буынны, коммунизм рухында тәрбияләү кыен булачак. Билгеле булганча, һәр милләтнең мәдәнияте үткәндәге мирасның иң яхшы казанышларына таянып үсә. Шуңа күрә иҗтимагый фикернең, шул җөмләдән экономик фикернең дә, бөтен агым һәм юнәлешләренә карата безнең ныклы үз позициябез булырга тиеш.

Бездә СССР халыкларының иҗтимагый фикер тарихын өйрәнү эшенә елданел зуррак игътибар бирелеп килә. Соңгы елларда совет халыкларының фәлсәфи фикер тарихы буенча күп томлы фәнни хезмәт басыла. Рус халкының экономик фикер тарихына караган күп томлы хезмәт, басылып чыгып, укучы хөкеменә тапшырылды, хәзер СССР халыкларының экономик фикер тарихына багышланган шундый ук хезмәт әзерләнә. Боларның һәммәсе бик кирәкле һәм күркәм эш. Чөнки аерым милләтләрнең иҗтимагый фикер тарихын тирәнтен белми торып, барлык халыкларның фикер тарихына караган төпле хезмәт язып булмаячак. Г. Фәезхановның[1] «Яшәү чаралары һәм муллык турында трактатлар» («Мәҗалисел-сәрвәт вә-нәгаш») исемле китабын тикшерергә алынганда без, хосусән, әнә шул принципиаль фикерләргә таянып эш иттек.

Хезмәт гарәп хәрефләре белән кулдан язылган, күләме — 209 бит. Ул кереш-

[1] Габделгаллэм Фәезханов (1850—1910) — Казан һәм Петербург университетларында мөгаллимлек иткән күренекле татар мәгърифәтчесе Хөсәен Фәезхановның туганы, күп кенә китаплар авторы, тәрҗемәче. Аның иҗат мирасы, тормыш юлы һәм иҗтимагый эшчәнлеге җитәрлек өйрәнелмәгән.

Г. Фәезхановның «Яшәү чаралары һәм муллык турында трактатлар» исемле китабы фәндә соңгы елларда гына мәгълүм булды. Аны беренче тапкыр «Башкорт халкының әдәби мирасы» исемле китабында Ә. Харисов телгә ала. Аннан М. Усмановның «Яңа табылган әдәби, тарихи истәлекләр» («Казан утлары» журналы. 1966 ел. 7 сан.) исемле мәкаләсендә искә алына, ул анда кузгатылган аерым мәсьәләләрне дә саный.

Мәкалә авторы, матбугатта чыгару өчен, «Г. Фәезхановның социаль-экономик карашлары» исемле хезмәт тәмамлап килә. Фәезханов монографиясенә тулы бәя һәм тәфсилле анализ шул хезмәттә биреләчәк.

тән, егерме бүлектән һәм соңгы сүздән тора. Галим аларны гыйльми рисаләләр, ягъни трактатлар дип атый. Кагыйдә буларак, һәр бүлек экономика фәненең теге яки бу конкрет мәсьәләсен тикшерүгә багышланган. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, хезмәттә экономика фәненә генә хас махсус терминнар күп очрый.

Автор бу монографиясен 1890 елда тәмамлый. Аны дөньяга чыгарырга рөхсәт исә 1892 елда гына алына. Ни сәбәптәндер, хезмәт кульязма хәлендә, басылмый кала.

Мәкалә күләменең чикләнгән булуын истә тотып, без бирелә хезмәтнең байлык җитештерү турындагы фәнгә билгеләмә бирү һәм аның җәмгыять тормышында тоткан урынын ачыклауга багышланган бүлегенә анализ ясау беләп чикләнергә булдык. Монографиянең әлеге бүлегендә шул кадәр мөһим экономик категорияләр тикшерелә ки, алар үзләре генә дә Фәезхановның экономик карашлары турында төпле фикер йөртү өчен тулы нигез бирәләр.

Г. Фәезхановның «Яшәү чаралары һәм муллык турында трактатлар» китабы — бездә экономика мәсьәләләре буенча язылган беренче капиталь хезмәт. Экономик фикер чыганагы булу беләп бергә, ул экономик тәгълимат һәм карашлар системасы чыганагы да. Ул татар социаль-экономик фикер үсешенең яңа баскычка күтәрелүе турында сөйли торган хезмәт.

Узган гасырның соңгы һәм егерменче йөзнең беренче елларында дөньяви фәннәргә омтылу торган саен киңрәк юл яра һәм алгы планга чыга бара. Татар җәмгыятенең хәлле даирәләреннән чыккан алдынгы караштагы кешеләре бу мәсьәләне уңай хәл итүне үзләренең граждалык бурычлары дип карыйлар. Г. Фәезхановның тормышы һәм иҗат эшчәнлеге, аның әлеге зур хезмәткә язган кереш сүзе һәм китапның гомуми эчтәлеге белән танышканнан соң әнә шундый нәтиҗә ясарга туры килә. Әлеге китапны язуны ул үзенең гражданлык бурычы дип карый, җәмгыять тормышында дөньяви фәннәрнең, шул исәптән экономия фәненең, роле үсә барганын тирәнтен аңлап эш итә. Г. Фәезханов монографиясе — татар халкының мәдәният һәм фикер мирасының мөһим чыганагы һәм аерылмас кисәге, шуңа күрә дә ул революциягә кадәрге татар әдәбиятында үзенә лаеклы урынны алырга тиеш.

Байлык җитештерү турындагы фәнгә төшенчә бирү һәм аның җәмгыять тормышындагы ролен билгеләүне Г. Фәезханов политик экономиянең үзәк мәсьәләсенә (кешеләрнең җитештерү эшчәнлегенә, аның максатларына һәм тормышта, җәмгыять үсешендә тоткан урынына) анализ ясаудан башлый. Хезмәтне, кешеләрнең җитештерү эшчәнлеген монография авторы түбәндәгечә билгели: «Инде һәр кылган эштән вә һәр иткән гамәлдән адәмнең дөньяда терәклегенә вә гомер сөрмәкенә зарур булган нәрсәләрне эстәмәк вә тапмак максуд улса, ул хәрәкәтләрне кәсеп дия тәсмия итәрләр» [1].

Күрәсез, өйрәнелә торган категория төшенчәсен автор, барыннан да элек, җитештерү һәм материаль байлыклар арттыру белән бәйләп карый. Кеше тарафыннан башкарыла торган актив хәрәкәтләрнең максаты һәм соңгы нәтиҗәсе — кешеләрне хезмәткә, җитештерү эшчәнлегенә тарта яки аннан биздерә торган төп критерий әнә шул. Без хезмәт, җитештерү эшчәнлеге белән эш итәбезме, әллә түгелме, дигән мәсьәләне хәл иткәндә, әлеге хәрәкәтләрнең формасы түгел, ә аларның юнәлеше һәм нәтиҗәсе хәлиткеч әһәмияткә ия. Фәезханов хезмәт эшчәнлеге төшенчәсен фәнни дөрес аңлата икән, бу аның кешенең яшәве һәм кеше организмының нормаль үсеше өчен кирәкле төп шартларны дөрес күзаллавы дигән сүз. Кеше организмы даими төстә һәм җитәрлек күләмдә азык алып торырга тиеш. Әгәр үзенең организмын ныгытып тормаса, ди автор, «ул кеше, һичшиксез, үлемгә хөкем ителәчәк», әгәр «эчәргә һәм ашарга тиешле күләмнән азрак бирелсә, бу чагында аның сәламәтлеге көннән-көн начарланачак, ул еш авырый башлаячак һәм аның тормышы акрынлап сүнүгә йөз тотачак». Организмның физиологик ихтыяҗлары — объектив фактор. Әгәр «теге дөньяга» китәргә теләмәсәң, алар белән санашмый булмый. Авторның фикер сөрешеннән ясалырга тиешле нәтиҗә әнә шундый. «Һәр терек адәм,— ди Фәезханов,— үзенең җисемене сакламага вә сәламәт тотмага мохтаҗ булыр...» [2].

[1] Г. Фәезханов. Яшәү чаралары һәм муллык турында трактатлар. 3 бит.

[2] Шунда ук.

Биредә укучының фикер һәм игътибары, барыннан да элек, кешенең теләк һәм ихтыярына бәйсез объектив законнарга юнәлтелгән. Шуның белән кешеләрнең үз-үзләрен тотышлары һәм кылган гамәлләре билгеле бер рамкаларга куела һәм теге дөнья кануннарына түгел, бәлки реаль дөнья, ягъни фәнни нигезләргә бәйле итеп карала. Г. Фәезханов кешенең яшәү средстволарына ихтыяҗы кебек бик мөһим экономик категорияне фәнни әйләнешкә кертеп җибәрә, аның күләме объектив характерда булуын дәлилләп бирә. Бу — аның социаль-экономик фикер формалашу һәм үсү тарихына кертkән җитди өлеше.

Ихтыяҗ төшенчәсенә ул нинди эчтәлек сала соң? Аның фикеренчә, кешенең яшәве өчен зарури материаль байлыклар ихтыяҗ яки кирәксенү була. Аның күләме һәм структурасы «кешенең нинди әйберләргә, предметларга гадәтләнгән булуына бәйле».

Г. Фәезханов дөрес аңлатканча, ихтыяҗларның күләме гел бер хәлдә калмый, җәмгыять үсешенә бәйле рәвештә үсә, үзгәрә тора. Менә ничә гасырлар инде, ди автор, кешеләрнең ихтыяҗы өзлексез тостә, көннән-көн үсә бара. Шуның бар, төрле географик шартларда яшәүче халыкларда аның күләме бертөсле түгел. Аерым кешенең, теге яки бу милләтнең ихтыяҗ үсешенә тәэсир ясый торган төп факторларга ул тормыш, белем һәм культура дәрәҗәсен, адәм балалары яши һәм эшли торган табигый шартларны, хезмәт төрен һәм аның авырлык дәрәҗәсен, кешенең яшен һәм гәүдә зурлыгын кертә. Хезмәттә әлеге факторларның һәркайсына тирән анализ ясала, авторның һәр фикере ышандыррылык дәлилләр белән ныгытыла.

Фәезханов кеше куллана торган материаль байлыкларның һәммәсен бер рәткә куймый, аларны, яшәү өчен никaдәр әһәмиятле булуларыннан чыгып, төркемнәргә бүлә. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, алгы планга ул яшәү өчен беренче чиратта кирәк булган нәрсәләрне куя. «Дәхи гомер итмәк өчен,— дип яза автор,— адәмнең вәҗүденә зарур улган нәрсәләр ризык илә җылылыкдыр; әүвәлгесе һәм икенчесе тәгам илә шәраптән хасыйл улыер, вә бонлар илә хаситә улган җылылыкны саклаучы вә ярдәм итүче өй вә утын, ягъни ягымлык шәйләр вә киемнәрдер. Мәгълүмдер ки, мәзкүр нәрсәләр адәм балаларының хаҗәте асныялары һәм иң тырышып эзләгән шәйләредер»[1].


Г. Фәезханов хезмәтенең кыйммәте шунда, ул кеше ихтыяҗларының күләм һәм структура ягын гадиләштереп, берьяклы итеп аңлатмый. Дөньяның төрле почмакларында, төрле табигый шартларда һәм төрле тарихи чорларда яшәгән халыклар тормышында ихтыяҗларның да төрлечә булу факторын танып да, моңа тиешеннән артык игътибар итми. Киресенчә, мәсьәләнең җитдилеген нык аңлаган хәлдә, ул теләсә кайсы дәвер һәм чор өчен ихтыяҗларның күләме даими булырга тиешлегенә, аларның кимиең дә булса шәхси теләгенә түгел, ә объектив законнарга нигезләнүенә басым ясый. «Һәр төрле адәмнәрнең мохтаҗ илияләре,— ди ул, — заманасына нисбәтән дәрәҗәдә төрле-төрле вәлә микъдар заят вә кем улса да, әмма аның чиге улгучыдыр, ул чикдән түбән итмәк адәмнең михнәтенә зарар вә эшенә кимчелек килмәенчә асла мөмкин улмас»[2]. Моннан күренгәнчә, кеше ихтыяҗларының күләм һәм структурасы аның нормаль яшәешен тәэмин итү зарурияте белән, ягъни организмның үз функцияләрен башкара алу һәм эшли алу сәләтен саклау белән билгеләнә. Әгәр сүз, мәсәлән, яллы хезмәтче турында бара икән, аның хезмәтенә эш хакы югалткан энергиясен кире кайтарырлык һәм хезмәткә сәләтен тергезерлек дәрәҗәдә түләнергә тиеш.

Кеше ихтыяҗларының объектив нигезен билгеләү һәм аларны даими төстә канәгатьләндереп тору зарурлыгын дәлилләү — бу инде үзе генә дә бездәге экономик фикер үсеше тарихында игътибарга лаек факт. Ул бигрәк тә эшче массаларына, алар хезмәтенә түләү күләмен һәм аларның тормыш дәрәҗәсен билгеләү өчен кулланылганда бик мөһим.

Монографиянең: «Мәзкүр нидаәттән ашып кителгән маллар начар, бозык гадәтләрнең тууына сәбәпче була», — дигән икенче бер положениесе дә җитди игътибарга лаек. Күрсәтелгән чик дигәндә, кешенең хезмәткә сәләтен тергезү һәм сәламәтлеген саклау өчен кирәк булган материаль байлыкларның гомуми күләме күздә тотыла. Фәезханов әлеге

[1] Шунда ук, 6 бит.

[2] Шунда ук, 6 бит.




*Г. Фәезханов китабының тышлык бите*

чикне кысуга кискен каршы чыга. Шуның белән бергә, әлеге тезистан күренгәнчә, ул әлеге чикне арттыруга карата да тискәре мөнәсәбәт белдерә. Аерым кешеләр кулында артык байлык туплану һәртөрле бозыклыкка, начар гадәтләргә илтә, ди. Кеше тормышындагы барлык ямьсез күренешләрне Г. Фәезханов артык байлык туплау белән бәйләп аңлата, ихтыяҗларның чикләнмәгән булуына кискен каршы чыга, андый кешеләрне ул «корсак коллары», «үз ихтыяҗларының корбаннары» дип атый. Шулай итеп, кешенең үз-үзен тотышын монография авторы аның экономик хәленнән, материаль интересларыннан чыгып бәяли. Шуның белән ул җәмгыять тормышын һәм аның үсеш законнарын фәнни дөрес аңлату юлында җитди адым ясый. Бу тезисның нигезле, урынлы булуы монографиянең күп кенә башка тезислары белән дә раслана. Автор, мәсәлән, кешелек җәмгыятенең нормаль яшәве өчен кирәкле шартлар турында сүз барганда, беренче урынга тормыш өчен кирәкле әйберләр җитештерү мәсьәләсен куя, материаль байлык җитештерүчеләр, аларның хезмәте турында җылы сүзләр әйтә.

Монографиянең байлык җитештерү турындагы фәнгә төшенчә бирүгә багышланган өлешләренә анализ ясауны төгәлләр алдыннан Фәезхановның фикер сөрешендәге аерым төгәлсезлекләргә дә тукталып үтәргә кирәк. Гомуми теоретик планда автор мәсьәләне дөрес чишә. Шуның белән бергә, «хезмәт эшчәнлеге» дигән төшенчәне аңлату өчен китерелгән мисалларда игенче, балта остасы кебек чыннан да материаль байлыклар җитештерүчеләрнең хезмәте сәүдәгәр хезмәте белән бер ясселыкка куела. Бу — методологик мәсьәлә һәм методологик хата. Җәмгыять үсешен аңлауда гомумән материалистик позициядә торганы хәлдә, ул бу мәсьәләдә ахырга кадәр эзлеклелек саклый алмаган һәм, заман агымына ияреп, аллага да өлеш чыгарган.

Җитештерү эшчәнлегенең асылын ачу һәм аның җәмгыять тормышында тоткан урынын билгеләү, ихтыяҗ дигән категориянең эчтәлеген ачыклау һәм аңа тәэсир ясый торган факторларны тикшерү — болар байлык җитештерү турындагы фәнне аңлау юнәлешендәге әһәмиятле адымнар. Байлык җитештерү турындагы фәнгә билгеләмә бирер алдыннан, Фәезханов теория, методология ягыннан

принципиаль әһәмияткә ия булган бер искәрмә ясый. Ул алга таба «хезмәт, җитештерү эшчәнлеге» дигән термин урынына шундый ук мәгънәдәге башка термин — «байлык җитештерү» дигән сүз кулланачагын әйтә. Алай гына да түгел, хезмәттә җитештерү эшчәнлеге һәм байлык җитештерү дигән төшенчәләр арасына тигезлек билгесе куела, алга таба Фәезханов аларны үзара тәңгәл категорияләр буларак куллана. Хезмәт байлыкның төп чыганагы итеп карала. Бу — XIX йөзнең икенче яртысында татар халкының экономик фикер үсешендә сыйфат үзгәреше барлыкка килү турында сөйли торган яңа күренеш һәм Фәезхановның аны фәнни элементлар белән баету, үстерү эшенә зур өлеш кертүе иде.

Байлык җитештерү турындагы фәнгә китап авторы нинди әчтәлек салган, аның иҗтимагый әһәмиятен нәрсәдә күргән? «Барча югарыда сөйләгәннәрне аңлаганнан соң, кешеләргә сәрүвәт эшләренең кирәклеген аңлаткан сәрүвәт фәненең бик кирәкле һәм зур гыйлем икәнен һәркем аңа бәһа биреп, аның файдалы икәнлеген аңлый белер. Димәк, сәрүвәт фәне кешеләргә файда бирә торган иң кирәкле эшләргә, барча халыклар һәрвакыт аның белән мәшгуль була торган гамәлләргә өйрәтә»[1].

Бу юлларда беренче бүлекнең төп эчтәлеге ачылган, байлык турындагы фәнгә төгәл билгеләмә бирелгән. Күргәнегезчә, политэкономия фәне иҗтимагый байлык җитештерүнең зарурлыгын нигезли, аны җитештерүнең төп юлларын ачып бирә икән. Болай практик эшчәнлекне югары бәяләсә дә, Г. Фәезханов байлык җитештерү турындагы фәннең чикләрен материаль байлык җитештерүнең конкрет алымнары һәм формалары белән генә чикләми. Бу бик мөһим нәрсә.

Иҗтимагый хезмәт бүленеше һаман тирәнәя барган бер чорда җитештерүнең специальлашуы кешеләрне бер-берсенә якынайта, алар хезмәтенә иҗтимагый характер сала. Фәезханов моны яхшы аңлый. Аннары, Г. Фәезханов карашы буенча, байлык җитештерү һәм аны бүлү барышында турыдан-туры җитештерүдә катнашмаган кешеләрнең дә экономик интереслары чагыла. Җитештерелгән иҗтимагый продукт артында төрле социаль группалар тора.

Шушы фикерләрне әйткәннән соң, автор байлык җитештерү турындагы фәннең предметын җитештерүнең конкрет алымнарын өйрәнү белән генә чикләү дөрес түгеллеген искәртә. Җәмгыять тә бер натураль хуҗалык кына яшәми ди автор, ул болай дип дәвам итә:

«Хәлбуки, хезмәтче кемсә эшне үзенә эшләмәс, бәлки хуҗасына эшләр. Дәһи шундый йирле вә сулы кешеләр бар ки, анлар үзләре йирләренә игеп икмәсләр, бәлки гайреләргә иҗарәгә бирерләр. Дәһи атганча, кешеләрнең бәгъзесе гайре бер кемсәгә карз акча бирер. Вә ул гайре аның акчасы илә игеп кәсебе не кылыр, я һөнәрханә ачар. Ошбу хәрәкәтләрнең файда тәхсыйль итеп, йирне иҗарәгә алган байга иҗарә пулене вә карзга акча алган байга каез, ягъни үсеш акчасыны түләп кон кичерер»[1]. Күрәсез, монография авторы фикеренчә, байлык җитештерү — күп яклы, катлаулы процесс, ул экономик күренешләрне дә һәм җәмгыять членнары арасындагы мөнәсәбәтләрне дә үз эченә ала. Аңа ул ялланып эшләүчеләрне, ягъни эшчеләрне һәм аларның хуҗаларын — промышленность һәм сәүдә капиталистларын, җир хуҗаларын, финанс капиталистларын, арендага алучы капиталистларны һәм шәхси милек хуҗаларын да кертә. Асылда монда буржуаз җәмгыятьнең барлык группалары һәм катлаулары телгә алына.

Байлык җитештерү турындагы фәннең төп бүлекләре, төп өлешләре итеп, Г. Фәезханов җитештерүнең үзен, бүлү һәм алмашуны саный. Куллану дигән нәрсә экономиканың башка мәсьәләләре кебек алга чыгарылмаса да, ул да кире кагылмый. Киресенчә, югарыда күренгәнчә, һәрвакыт искә алына. Фәезханов байлык җитештерү турындагы фәнне башка фәннәр арасында алгы урында куя һәм җәмгыять өчен кирәкле нәрсә дип саный. Ул бу фәннең һәм теоретик, һәм практик әһәмиятен, алар арасындагы тыгыз бәйләнешне, берсенең икенчесенә бәйле булуын таный. Әгәр хезмәтнең ишан һәм муллалар хакимлек иткән бер чорда, ягъни иске татар тормышы шартларында язылуын да искә алсак, монографиядәге әлеге моментларның ни-

[1] Шунда ук, 10 бит.

[1] Шунда ук, 17—18 битләр.

кадәр әһәмиятле булуы тагын да ныграк аңлашылыр.

Китапның беренче бүлегендә экономия фәнендәге үзәк мәсьәләне төрле яктан ачыклый торган күп кенә башка категорияләр, фәнни мәсьәләләр кузгатыла. Принципиаль әһәмияткә ия шундый бер генә мәсьәләгә тукталыйк. Бүлектә вакытка экономия ясау кебек универсаль законга дөрес һәм тәгәл аңлатма бирелә.

«Адәм баласы,— диелә анда,— һәммәдән мөкатдәм үзенә зарур улган һәм файданы күбрәк биргән нәрсәләрне әстәр вә аз гына мәшәкать илә тиз генә вә җиңел генә сәбәпләр иҗтигъмаль кылыш максудына ирешмәгә иҗдиһат әйләр»[1].

Хезмәттәге бу ачышның әһәмияте бәяләп бетергесез. Бу политэкономиянең мөһим мәсьәләсе, халык хуҗалыгы һәм иҗтимагый байлык җитештерү мәсьәләләрен дөрес хәл итәргә ярдәм итәрлек мөһим ачкыч. Авторның политэкономиянең бу әһәмиятле законы турындагы фикерләре дә заманча яңгырый. Мәсәлән, без анда менә нинди фикерләр очратабыз: «Бу хосуста ул табигать галәменең һәртөрле ярдәмнәрен вә хезмәтләре илә кулланып, вә аңа дәһи үзенең мәгърифәтен юлбашчы кылып әүвәлгедән артыграк илә вә яхшырак итеп эшләмәгә иҗдиһат әйләр»[2].

Монда җәмгыять һәм табигать көрәшләрен материалистик аңлату, теория белән практика арасына күпер сузу, җәмгыятьнең тормыш хәлен яхшырту өчен табигать көчләрен файдаланганда дөньяны белемнәрне бәяли белү кебек кыйммәтле фикерләр әйтелгән.

Г. Фәезханов китабында табигать кешегә каршы куелмый, киресенчә, материаль байлыклар җитештерүдә аның союзнигы һәм ярдәмчесе буларак яктыртыла. Автор кешенең табигать серләрен ача алачагына тирән ышаныч белдерә.

Табигать турындагы фикерләрен дәвам итеп, Фәезханов болай ди: «Табигать дөньясы үзе һәм аны әйләндереп алган сәбәпләр нинди юл белән адәмнәргә үз хаҗәтләрен җиңелрәк итеп табарга мөмкин(лек) әйрәтерләр.

Игенче крестьян җир сөрү кебек эшләр белән шуның өчен мәшәкатьләнәдер, чөнки бу кәсебе булмаса, җир аңа бушка гына иген бирми.

Әгәр адәм балаларының тирә-ягында тимер вә бакыр кебек мәгдәнкалар булса, алар анда шул мәгдән эшләре илә хәрәкәт итәрләр.

Вә әгәр мәгыйшәтләре диңгез буенда булса, алар анда диңгез сәүдәсе илә хәрәкәт итәрләр, әгәр якларында игенчелек җирләре булса, алар анда игенчелек илә шогыльләнерләр»[1]. Китерелгән өзектә ике фикер, беренчедән, кешене әйләндереп алган табигать аның укытучысы дигән һәм, икенчедән, материаль байлыкларның анасы табигать булса да, хезмәт — аның атасы дигән фикерләр аерым игътибарга лаек. Табигатькә тәэсир, йогынты ясый торган хезмәт кенә җәмгыятьне материаль байлыклар белән тәэмин итә, табигать әйберләренә «җан кертә», аларның кирәкле, файдалы якларын ача. «Әйдәгез, уйлап багыйк,— ди Фәезханов, — әгәр адәмнәр тимер вә агачтан әйберләр ясый белмәсәләр, аларга тимер вә агач файда китерер идеме? Юк». Бу фикер, алдагысы кебек үк, автор хезмәтенең байлык җитештерү юлындагы роле, җитештерү, алмашу, бүлү һәм файдалану кебек яңадан җитештерү процессларын өйрәнә торган фәннең ролен дөрес аңлау белән яктыртылган.

Фәезхановның иң мөһим мәсьәләләргә, экономика фәненең төп категорияләренә карашын гәүдәләндерә торган беренче бүлеккә анализ ясау Фәезхановның тирән белемле, киң карашлы галим булуы, иҗтимагый җитештерүгә бәйле иң мөһим законнарны дөрес аңлавы, күп кенә мәсьәләләрне хәл итүгә дөрес якын килә белүе турында сөйләргә мөмкинлек бирә.

---

[1] Шунда ук, 13 бит.
[2] Шунда ук, 13—14 битләр.

[1] Шунда ук, 14 бит.

# ЯҢА АВАЗ

Бу китапның редакторы булсам, мин Диләрә Зөбәерсвага аның исемен «Кичер, сөеклем» дип түгел, «Дустым авазы» дип куярга киңәш биргән булыр идем. «Дустым авазы»н өч кат укып чыктым. һәм укыган саен аны ярата бардым. Укыган саен укыйсыны китерә торган әсәрнең дөньяга килүе автор өчен генә түгел, әдәбиятыбыз өчен дә бәхетле казаныш.

Нәрсәсе белән охшады соң миңа «Дустым авазы»? Нәрсәсе белән күңелдә яхшы тойгылар уятты? Барыннан да элек Назирә образы белән. Ул шундый саф күңелле самими кыз. Кешеләргә яхшылык теләүдән, яраткан эшенә — укытучылык хезмәтенә мәхәббәттән башка аның өчен чын тормыш юк. Кешегә игътибарсыз, салкын йөрәкләргә, гаделсезлеккә каршы ул үзенең саф йөрәген, намуслы хезмәтен куя. Аның яшәү девизы — яраткан эшенә бөтен дәртенне, иҗади көчеңне биреп хезмәт итү. Чын кешегә хас булган шушы югары тойгыны язучы сәнгатьчә дөрес итеп, укучыны ышандырырлык итеп бирә алган.

Назирә, яшь кыз буларак, романтик хисләр белән яши, аңарда яшьләргә хас шуклык, шаянлык та бар. Иптәшләре, яшьтәшләре каршында беркадәр иркәләнергә омтылу да аңа ят түгел. Менә ул үзе күреп белмәгән бер егеттән — Камил исемле студенттан хат ала. Аның белән үзе арасында рухи якынлык тоеп, аңа хатлар яза. Шул хатларында аның үзе турындагы, мәктәбе, укучылары, шулай ук заман турындагы иң матур фикерләре, тойгылары. Хәзер инде ул үзе күреп белмәгән Камилне чын-чынлап ярата, аның белән күңеленнән киңәшләшеп яши. Менә беркавыт, Назирә торган өй хуҗасы Мәрьям апа кунакка киткән көннәрдә, аны эзләп Камил — булачак журналист үзе килеп төшә. Егет белән кыз икәүдән-икәү генә бер өйдә берничә көн уздыралар. Кызыксынучы күршеләренә Назирә Камилне абыем дип таныштыра. Ләкин дөньяны, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне һаман искечә генә аңлауда дәвам итүче кайберәүләр Назирәнең саф, керсез мәхәббәтен рәнҗетәләр, егет белән кунып, азып яткан дигән мәгънәдә гайбәт тарала. Назирәнең пакь күңеле моны күтәрә алмый. Кыен вакытта Камилдән дә хәбәр булмый тора. Кыз, бабасының киңәшен тотып, икенче кешегә кияүгә чыга. Ул кешегә карата аның күңелендә чын мәхәббәт юк. Ләкин ул аны хурламый, кеше буларак хөрмәт итә. Ниһаять, Назирәнең яшәү девизы — кешене кеше иткән нәрсә аның хезмәте дигән иманы — аны барыбер бәхеткә китерә. Монда аңа югалып калган яшьлек дусты Камилнең ерактан ишетелгән авазы ярдәм итә. Журналистның Назирәне искә төшереп язган мәкаләсен уку аңа тормышта үз юлын яңадан табарга булыша. Повесть мондый сүзләр белән тәмамлана:

«Ямансу да, рәхәт тә тоелган бу минутларда бөтен җаным, тәнем, рухым белән мин шуңа төшендем: кавышулардан азат, очрашулардан пакь, сагышлардан өстен мәхәббәт тә бар бит әле дөньяда!»

Повестьның бөтен эчтәлеге шушы фикерне гәүдәләндерә. һәм бу әсәрнең яңалыгы да шунда. Кавышулардан азат, очрашулардан пакь, сагышлардан өстен мәхәббәт! Сәер яңгырый кебек. Шулай да мин моңа ышанам. Мин монда нәкъ менә кешегә, фәкать кешегә генә хас тойгы күрәм. Югыйсә, бездә мәхәббәтне бары ин-

очрәшулар, җенси мөнәсәбәтләр белән бәйләнештә генә күрсәтүгә нигезләнгән әсәрләр дә языла бит. Күбесенчә, аның һәр хайванга хас булган физиологик ягы, төрле сүз чәчәкләренә төреп, идеаллаштырыла. Кызганычка каршы, кайбер яшь прозаикларыбызда да бу шулай. Әгәр дә Зөбәерова, мәхәббәт бары менә шушындый гына, ягъни Назирә әйткәнчә генә була дип раслаУрга теләсә, без, әлбәттә, аның белән килешмәс идек. Ә менә шундый мәхәббәт тә бар бит әле дөньяда диюе белән ул бик күпләрнең үзләре өчен дә сер булган хакыйкатьне ачып бирә. Чынлап та мәхәббәтме ул, әллә югары дәрәҗәгә күтәрелгән дуслыкмы? Теләсәң ничек уйла! Ләкин тормышта күпләрнең йөрәген җылыта торган, аларны яшәүгә рухландыра, югалткан юлларын табарга ярдәм итә торган шундый тойгы бар һәм кеше өчен аның булуы табигый. Диләрә шушыны ышандырырлык итеп, шуңа күрә мавыгып укырлык та итеп язып бирә алган. Мондый әсәрне язу өчен тормышны белү, аны кичерү, тоюы өстенә белгән тойгыларыңны җанлы әдәби тел ярдәме белән гәүдәләндерә белү, психологик төгәл детальләр таба алу осталыгы кирәк. Назирәнең самимилек белән чикләшкән саф күңеллеген без аның сөйләү стиленнән үк тоя барабыз. Ул Камилгә язган хатларында берәр акыллырак фикер әйтсә, шунда ук аны кемнән ишеткәнлеген дә белдерергә ашыга. (Ягъни кеше фикере белән акыллы яки оригиналь булып күренәсе килми.) Яки Мәрьям әбине характерлый торган бер деталь: «Әбекәй көтү чыкканчы ук торды. Идәнгә тамызмый гына комганга казаннан җылы су салды». Түгә-түгә салса аны һәркем күрер иде. Ә менә аның суны идәнгә тамызмый гына салуын күрү яки шуңа игътибар итү өчен чын язучы күзе, хәтта, мин әйтер идем, хатын-кыз язучы күзе кирәк.

Тагын бер деталь. Поездда барганда Назирә очраклы рәвештә үзенең күптән югалткан дустының — яшерен рәвештә һаман күңелендә йөрткән мәхәббәтенең исемен ишетә һәм Камил янында эшләүче кешегә, аманәт итеп, тубылгы[1] чәчәге биреп җибәрә. «Теләсә кайда, теләсә кайчан, теләсә нинди шартларда да чәчәк ата торган Себер умырзаясы. Аңа нур белән су гына кирәк!» Мәгънәле яңгырый. Ләкин бусы әле күп язучыда табылуы мөмкин булган традицион символика. «Поезд кузгалды,— дип дәвам итә Назирә,— мин аңа балдаксыз кулымны болгап калдым». Игътибар итегез, уң кулын да түгел, сулын да түгел, балдаксыз кулын болгап кала. Шул бер сүз җөмләнең мәгънәсен никадәр тирәнәйтеп җибәрә. Назирәнең йөрәгендә Камилгә булган мәхәббәтә һаман яшәп килүен дә, аның бервакытта да бетмәячәген дә, икенче — балдаклы кулның иргә бәйле булуын һәм монда аңа бернинди хыянәт юклыгын да, ягъни тормышның, кеше йөрәгенең ничек катлаулы, никадәр бай, никадәр матур, мәгънәле булуын да тоябыз. Бу — язучы тарафыннан уңышлы табылган образлы деталь.

Диләрә Зөбәерова каләменең үзенчәлеген һәм аның уңышын күрсәткән детальләр аз түгел. Аларның барысына да тукталуның кирәге юк.

Повестьның кайбер кимчелекле яки бәхәсле яклары да бар. Бәлки, алар әйтерлек зур да түгелдер. Ләкин нигездә әйбәт булган әсәрдә кечкенә кимчелекләр дә күзгә ныграк бәрелүчән була. Затлы киемгә тигән кечкенә тап та шулай бит. Гүзәл әсәрне ямьсезли торган кимчелекләр башлыча авторның телендәге кайбер төгәлсезлекләргә, аның әдәби телебезне җитәрлек дәрәҗәдә белеп җиткермәвенә яки белеп тә аның белән саксызрак эш итүенә кайтып кала. Бәлки, бу әдәбиятыбызны ярыйсы белгән, аның әйбәт традицияләрен үзләштергән язучының әдәби телебезне баетырга омтылуыдыр? Һәрхәлдә, «Башым сафланып, күз алмаларым җиңеләеп киткәндәй булды» дигән җөмләне кабул итеп булмый. Күз алмалары җиңеләю ничек буладыр, белмим. Әллә хәреф хатасы микән дип, күз аллары рәвешендә дә укып карадым, барыбер мәгънәле җөмлә чыкмый.

Татар телендә гадәттә икесе бергә йөри торган парлы сүзләр бар: кара-кучкыл, аксак-туксак, чуп-чар һ. б. Диләрә шундый сүзләрнең, беренче яртысыннан аерып, икенче яртысын гына куллана: «Кучкыл карт бакча эчендә». Мәрьям әби ире турында: «Туксак ул», ди. Гомумән, Мәрьямнең телен стильләштергәндә, артык авылча булам дип, ясалмалыкка кереп киткән урыннар бар. «Мин килеп төшкән елларны да, ходавәндә, олы иде әле безнең сала». Бирелә ходавәндә бөтенләй урынсыз.

Русча сүзләрне һич кирәксез урында калькалап татарчалаштырырга омтылу күренешләре очрый. «Сорау өстенә сорау биреп, минем хәлләр белән дә мәгълүмат-

[1] Китап вариантында богуля дип үзгәртелгән, тубылгы дөресрәк иде. М. Ә.

ланды әбкәй», «Мәгъсум балаларны почмакка җыйган да нидер сөйли. **Тыңланам».** (Русча «прислушиваюсь»тан калька. **Колак салам** дияргә була бит.) Кирәкмәгән урында сүзләр күплек санда алына: «Чәчләре зәңгәрләнеп торган каралар», «Кунакның... чәйләр әчми китү исәбе юк». Кырык биш енче биттә яхшы мәктәпнең эшлекле укытучылары турында сүз бара: «Мин аларның берәдә үз йортларына кайткандай, бернинди **церемониясез** керешүләрен, үз шкафларын ачып, үз кабинетларында **киләп сарып** йөрүләрен кызыгып күзәттем». **Киләп сарып** йөрү татар телендә эшсез йөрү, кирәксезгә бер урында таптану мәгънәсендә кулланыла. **Церемониясез** урынына бездә бит әдәби телебезгә күптән кергән **тәкәллефсез** дигән бик матур һәм аңлаешлы сүз бар. Повестьның азагына җитеп килгәндә тагы мондый бер җөмлә колакны тырнап куя: «Әйе шул,— диде ул миңа, карашларын чарлап,— менә нинди кызык...» Кызык килеп чыга шул. **Карашны чарлау** әдәби телгә дә, гади сөйләм теленә дә ятышмый бит. Һәрхәлдә, әдәбият киштәбезгә шундый матур әсәр бүләк итәргә таланты җиткән авторның телгә ныграк игътибар итәргә дә көче җитәр дип ышаныйк.

Инде икенче повесть турында берничә сүз. Идея эчтәлегенә исеме дә бик тапкыр килгән «Дустым авазы» повесте белән башланган китапка «Кичер, сөеклем» дигән исем куелудан бик үк риза түгеллегемне башта ук әйтеп киткән идем. Ләкин бу «Кичер, сөеклем» повесте уңышсыз әсәр икән дигән сүз түгел әле. Юк, бу әсәр дә шул ук талантлы каләм белән, кызыксынып, хәтта мавыгып укырлык итеп язылган. Идея эчтәлеге дә әйбәт. Шул ук яраткан эшеңә һәм сөйгән ярыңа турылыклы булу мәсьәләсе. Замандашларыбызның шактый җанлы образлары. Ләкин бу әсәрдә, минемчә, «Дустым авазы»ндагы сәнгать тирәнлеге җитми. Диләрә Зөбәерованың кем булуы турында китапның беренче битендәге аннотациядә кыска һәм ачык әйтелгән. Ул журналист буларак укучыларга таныш. Без аны газета-журнал битләрендә байтактан бирле басылып килгән язмалары, актуаль темаларга багышланган, образлы тел белән язылган мәкаләләре, очерклары, замандашларыбызны сурәтләгән әдәби портретлары аша беләбез. Әйе, Диләрә яхшы журналист. Һәм журналистлык практикасы аңа язучы булырга нык ярдәм итә. Ул аңа чиксез зур һәм катлаулы тормышыбызның төрле тармакларына үтеп керергә, төрле характердагы замандашларыбыз белән очрашырга, алар белән танышырга, кыскасы, күпне күрергә, күпне белергә юл ача. Журналистлык һөнәренең яхшы йогынтысын без «Дустым авазы»нда бик ачык күрәбез. Шул чагыштырмача кечкенә күләмле әсәр эчендә без зур илебезнең төрле почмакларында гизәбез, төрле дәрәҗәдәге, төрле характердагы замандашларыбыз белән очрашабыз. Бәхеткә каршы, болар һәммәсе дә повестьның эстетик идеясенә буйсындырылган, ягъни анда **язучы** каләме өстенлек алган, нәтиҗәдә чын әдәби әсәр дөньяга килгән. Ә менә «Кичер, сөеклем» повестенда язучыга журналистлыгы комачаулык иткән. Бу әсәрдә **журналист** каләме өстенлек ала. Ялгыш аңланмасын, журналист иҗатын кимсетеп әйтүем түгел. Журналист иҗатының да үз урынында әһәмияте язучы иҗатыннан ким түгелдер. Минемчә, журналистның үз дөреслеге бар, язучының үз дөреслеге. Журналист дөреслеге — ул барыннан да элек көннең әһәмиятле фактларына, конкрет вакыйгаларга, конкрет шәхесләргә нигезләнгән документаль дөреслек. Язучы дөреслеге исә — зуррак чорны, киңрәк географияне, күбрәк кешеләрне гомумиләштергән сәнгать дөреслеге. Бу ике дөреслекне мин бер-берсенә каршы куймыйм. Әдәбият дөньясында аларның бергә кушылган чаклары да күп. Андый бәхетле очракта чын мәгънәсендә әдәби дә, тарихи да булган әсәрләр дөньяга килә. Күп вакытта исә, бер-берсенә туган булган шушы ике дөреслекне аерып җитмәү нәтиҗәсендә, чын мәгънәсендә әдәби әсәр булып җитмәгән, ягъни алган темасын сәнгатьчә гомумиләштерү дәрәҗәсенә күтәрелә алмаган, шул ук вакытта үзенең документальлек көчен дә югалткан әсәрләр языла. Матур әдәбиятка журналистлык аша килүче кайбер иптәшләргә бу моментка ныграк игътибар итәргә кирәк дияр идем. «Кичер, сөеклем» повесте да шундыйрак хәлгә очраган. Авторның бу әсәренә исем сайлаганда кыен хәлгә төшүе дә очраклы хәл түгелдер. «Кичер, сөеклем» дә, «Куш өянке шаһит»та («Казан утлары» журналында шул исем белән басылды) уңышлы табылган исемнәр димәс идем. Һәм әсәргә аның эстетик идея эчтәлеген дөрес кенә чагылдыра торган исем табу да читендер. Чөнки бу әсәр безнең бүгенге тормышыбызга, үсешебезгә иллюстрация характерында язылган. Чын мәгънәсендә матур әдәбият әсәре өчен бу җиңел алым. Без анда әсәрдә катнашкан геройларның бала вакытла-

рын яки мәктәп яшендәге чакларын күрәбез дә аннары, күп еллар аша сикереп, аларның хәзерге портретларын күрәбез. Ә аларның шулай әйбәт кешеләр булып җитлегү юлларын, ягъни кешенең чын йөзен билгели торган хезмәт юлларын күрмибез.

Әсәрнең төп герое Гомәр туган авылына кайтып бара. Мәктәпне бергә тәмамлаган классташлары белән очрашуга чакырганнар. Юлда ул үзенең мәктәп яшендәге елларын, бергә укыган яшьтәш иптәшләрен хәтереннән кичерә. Аның кичерешләре аша без алда очратачак кешеләребезнең бала чакларын күрәбез. Бала чагыннан ук әбисе сүзеннән чыга алмаган, зурайгач та тар карашлы, үз-үзеннән канәгать, мещан йөрәкле кеше булып калган Гомәр тарафыннан бирелгән характеристика аша без аның иптәшләренең дә хәзерге көндә кем булып чыгасыларын чамалый алабыз. Шулай булып чыга да. «Өендә аз гына тырышса, класста бераз гына телен тыйса, отличник буласы малайның... тиешле урында балык кебек телсез, акбай кебек хыянәтсез» булган Әнвәрнең алдынгы укымышлы булып китүе; үзеннән «бәләкәйләрнең тәңкәсенә тия, телен чыгара, яный, үрти, өркетә» торган, «өлкәннәр янында коеп куйган менә дигән тәртипле, укуы да ташка үлчим генә» булган Миңнәхмәтнең тормыш төбеннән чыга алмавы; чая, горур кыз Ленизаның шәп инженер булып чыгуы һәм башкалар, һәм башкалар безне, укучыны, гаҗәпләндерми. «Кемнәр булып беткәннәр соң бу Таңкөле малайлары?» дип, аларга Гомәр генә гаҗәпләнә кебек. Чөнки алар, тормыш логикасына буйсынудан бигрәк, авторның алдан сызып куйган теләкләренә тапкыр китереп язылганнар.

Әгәр бу әсәр документаль повесть булып, конкрет шәхесләр турында сүз барса, без аны бөтенләй икенче төрле кабул итәр идек. Ә болай? Геройларның күбесе әдәби образ дәрәҗәсенә күтәрелә алмаган дияргә туры килә. Шулай да, Гомәр образының шактый тулы канлы булуы бу әсәрне уңышсызлар җөмләсенә кертүдән коткара. Әдәби образ буларак, Гомәрнең көче укучыны уйландыра алуында. Әйе, ул укучыны яхшы мәгънәсендә уйландыра, һәм бу әйбәт. Ә менә жанр бөтенлеге, жанрга турылык мәсьәләсе буенча бу әсәр уңае белән авторга да, кайбер башка язучыларыбызга да уйланырга урын бар.

Җыентыкка кергән кыска хикәяләр дә игътибарны җәлеп итәләр. Алар арасында да «Гөлназ», «Истәлек», «Энҗе чәчәкләре» шикелле лирик хикәяләр, «Уңган кыз», «Зәйләләр» шикелле әйбәт очерклар булган кебек, «Заман егете» шикелле очерклыктан чыккан, ләкин хикәя булып җитә алмаган язмалар да бар.

Әнә шундый, беркадәр тәнкыйтькә мохтаҗ урыннары булуга карамастан, Диләрә Зөбәерованың бу җыентыгы безне чын мәгънәсендә куандыра. Күп кырлы бүгенге әдәбиятыбыз доньясында ул яңа аваз булып яңгырый.

МИРСӘЙ ӘМИР

# УҢЫШЛЫ ЭЗЛӘНҮ

Тәнкыйтьче Рафаэль Мостафинның яңа китабы дөньяга чыкты[1]. Монысы да татар халкының батыр улы Муса Җәлил турында.

Башта ук шуны әйтергә кирәк, Р. Мостафин кызыклы һәм мавыгып укырлык хезмәт язган. Бер кулыңа алдыңмы, укып чыкмыйча аерылырмын димә. Китапта сурәтләнгән вакыйгалар үз артларыннан сине дә ияртеп алып китәләр, син әле Полесье сазлыкларына килеп чыгып, Волхов фронтындагы драматик хәлләрнең шаһите буласың, әле, автор белән берлектә, Германия төрмәләренең камералары буйлап йөрисең, ул да түгел, италияле Р. Ланфредининең совет кешеләренә карата ихтирам һәм соклану хисләре белән тулы хатларын укыйсың...

Муса Җәлилнең героик көрәш юлын яктыртуга багышланган бу китапта күп төрле хәлләр сурәтләнә, анда без төрле характердагы кешеләр белән очрашабыз. Шуңа да карамастан, әсәр бөтен һәм җыйнак чыккан. Ул, барыннан да бигрәк, материалының яңа һәм кызыклы булуы белән игътибарны җәлеп итә. Әлбәттә, материал җыю, фактларны корь санап чыгу гына фән була алмый әле. Р. Мостафин үзе җыйнаган әнә шул фактларны билгеле бер тәртипкә салган, аларга фән кануннары кушканча җентекле анализ ясый алган. Китап безнең татар филологиясендә сирәк очрый торган әдәби эзләнү жанрында язылган. Бу жанр, мәгълүм булганча, автордан күп хезмәт, энергия һәм зур эрудиция сорый. Автор әнә шул кыенлыкларны кыю рәвештә җиңеп чыккан.

Р. Мостафин Җәлил иҗатын өйрәнү өлкәсендә күптәннән эшләп килә. Аның моңарчы басылган мәкалә-очеркларын да укучылар җылы каршылаган иде. Яңа китабында исә, алда бер тапкыр әйтелгәнчә, герой шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлына караган күп кенә яңа мәгълүматлар китерелә. Шуларга таянып, автор Мусаның нинди шартларда һәм кайчан әсир төшүен ачыклый, Моабит шигырьләренең язылу тарихын аңлата. Р. Мостафин тарафыннан ачылган фактлар белән танышкач, Моабит дәфтәре — Җәлилнең соңгы айларындагы тормыш импульслары — йөрәк тибеше икәнлеген аңлыйсың. Автор укучыны шагыйрь белән йөзгә-йөз очраштыра, аның авыр сәгатьләрендә йөрәгеннән ыргылган поэзиясе аркылы укучыны шагыйрь иҗатындагы гуманистик, патриотик мәгънәне аңлауга алып килә. Муса Җәлилнең тормыш һәм иҗат юлын җентекләп өйрәнү нәтиҗәсендә автор шагыйрьнең әлегә табылмаган шигырьләре булу ихтималын әйтә һәм аларны эзләү юлларын күрсәтә. Шулай итеп, үзе ачкан фактлары ярдәмендә ул Җәлил иҗатын өйрәнү өлкәсендә эшләүчеләрне яңа чыганакларга юнәлтә.

Шагыйрьнең дошман ягына әләгүе һәм андагы героик көрәше һич тә Җәлилнең шәхси биографиясендәге гади бер факт кына түгел. Бу — дошман ягына әләгү бәхетсезлегенә дучар булган барлык кешеләрнең фаҗигасе, аларның, фашизм белән йөзгә-йөз килеп, авыр тормыш сынавы алдында калуларына бәйле вакыйга. Китапта Җәлил һәм җәлилчеләрнең коточкыч шартларда да патриотик хисләр белән яшәве турында сөйләнә. Автор бу хезмәтендә бер Җәлил эшчәнлеген сурәтләү белән генә чикләнми. Ул Җәлил группасындагы А. Алиш, Г. Курмаш, Ә. Симаев, Р. Саттаров кебек егетләрнең дә эшчәнлеген яктыртуга зур әһәмият бирә. Дәрес, Җәлилнең көрәштәшләре турында тикшеренүчеләр тарафыннан моңарчы да шактый гына мәгълүмат тупланган иде. Р. Мостафинның яңа хезмәтендә исә бу батырларның дош-

---

[1] Рафаэль Мостафин. По следам поэта-героя. Рус телендә. «Детская литература» нәшрияты. М. 1971 ел.

ман тылындагы патриотик эшчәнлеге, фашистлар белән яшерен көрәшләре тагы да тулыланә төшә, аларның эчке дөньялары, психологик портретлары, рухи халәтләре тагы да ачыклана. Шагыйрьнең шәхесе бу китапта заман рухына, коммунистик идеологиягә мөнәсәбәтле рәвештә ачыла. Китапта китерелгән күп санлы документлар, хатлар, истәлекләр, өңгәмәләр барысы да әнә шул искиткеч авыр сыналуга дучар булган Ватан улларын берләштергән хис — патриотизм хисен тасвирлауга хезмәт итәләр.

Муса Җәлилнең дошман тылында алып барган көрәше һәм аның поэзиясе — органик бәйләнгән бөтен бер күренеш. Данлы, мактаулы шагыйрьләр күп, ләкин Җәлил язмышына бик сирәк шагыйрь очрарга мөмкин: Джон Байрон, Шандор Петефи, Адам Мицкевич... Шагыйрь һәм геройлык... Боларны ничек бергә бәйләп алып барырга? Ничек күрсәтергә? Бу — шактый катлаулы бурыч. Р. Мостафин бу китабында әнә шул ике теманы бер максатка берләштерә алган. Шуңа күрә авторның хикәяләвенә Җәлилнең шигырьләре дә үрелгән, һәм, әйтергә кирәк, тәнкыйтьченең осталыгы аркасында мастерларча үрелгән. Китапта еш кына күтәренке лирик-патетик тондагы автор сөйләме Җәлил шигырьләре белән үрелеп китә:

«Никадәр чарланган шигъри юллар, образлар, әйтелеп бетмәгән фикерләр, алдагы көннәр өчен планнар аның башында! — ди автор Җәлилнең Моабиттагы иҗаты турында.— Һәкъ менә хәзер — тормышының атналары, ихтимал, көннәре санаулыга калгач, шагыйрьнең моңарчы күрелмәгәнчә иҗат күтәренкелегә кичерүен ничек аңларга?

Була кайчак гаҗәп күңел каты,
Бернәрсәгә юньләп ис китми.
Үлем җиле исә күңел гөлеңә,
Яфрагын да ләкин селкетми...» (112 бит).

Һичшиксез, әнә шулай табигый рәвештә шигырьгә күчеп китү Җәлилнең рухи халәтен ныграк, тирәнрәк аңларга булыша.

Р. Мостафин — фактлардан объектив нәтиҗә чыгара белә торган тикшеренүче. Ул кул астындагы материалларга битараф карамый. Үзенең геройлары белән бергә кайгыра, шатлана, аларның кешегә ышанычын бүлешә, лирик дулкынлану белән Мусаның бөек поэзиясе турында сөйли. Китапның эмоциональ хисләр белән баетылган булуы хакыйкатьне тасвирлауга комачау итми генә түгел, киресенчә, аны конкрет, җанлы, ягъни, тормышта ул ничек булырга тиеш, шулай күз алдына китерергә ярдәм итә. Һәм китаптагы лиризм никадәр нечкәрә барса, хикәяләү шул кадәр ота гына.

...Хыянәтче дошманы сатты. Моабит. Тикшерүләр, сорау алулар инде тәмам. Синә менә-менә җәзалап үтерергә тиешләр... «Шул вакытта,— дип яза Р. Мостафин,— Мусаның бөтен уйлары, хисләре һәм омтылышы бер генә максатка тупланә: ару-талуны белмичә язарга, язарга һәм язарга. Үз халәтенә ул үзе дә гаҗәпләнә. Кайчандыр, яшьлек елларында, «Авыру комсомолец» дигән поэмасын язганда Муса үлем көтеп яткан кешенең эчке дөньясын күз алдына китерергә һәм укучыларга сурәтләп бирергә теләгән иде. Нинди хис бу? Кот очумы? Өметсезлеккә бирелүме? Әллә үлемгә карата горур нәфрәтме? Поэма бераз гына риторик характерда булып чыга. Ләкин, Мусаның үзе кебек үк, романтик хисләр эчендә кайнаган егетләр һәм кызлар әсәрне хуплап каршы алалар. Еракта калган самими яшьлек... Ни өчен соң яшьлек чәчәк атып килгәндә үлем турында уйлана икән?

Чынбарлык исә мәрхәмәтсез дә, гади дә булып каршыга килеп басты.

Әйе, үлемнән курку да, багырьне телгәләгән сагыну — иркне, туганнарны сагыну да һәм яшәү өчен ялкынлы теләк тә бар иде. Ләкин суд тикшерүе тәмамлануга аның иң беренче тойгысы — рухи җиңеллек була. Әмма бу тойгы җәфалы сорау алулар һәм газаплаулар туктаганлыктан гына түгел. Бу җиңеллек бөтенләй башка нәрсәгә бәйләнгән...» (109—110 битләр).

Китапның бу битләре безне геройның хисләр дөньясына алып керә, Мусаның хисләрен аңларга, аның эчке дөньясына якынаерга ярдәм итә. Һәм моңа Р. Мостафин еш кына, укучы да сизмәслек нечкәлек белән, автор сөйләменнән геройның эчке сөйләменә күчү ярдәмендә ирешә. Р. Мостафин һәр яңа фактка — шагыйрьнең замандашлары истәлегеме ул, хатләрмы, кульъязмаларымы, яки безнең көнгә кадәр телдә сакланып килеп җиткән шигырьме — барысына да тәнкыйть күзе белән карый. Шуңа күрә китапта аз өйрәнелгән чыганакларга нигезләнеп ясалган ашыгыч нәтиҗәләр очратмыйсың. Теге яки бу чыганакның дөреслегә аз гына шик уяттымы, Мостафин тыйнак кына фәраз кылу (гипотеза) белән чиклана (бу уңайдан бигрәк тә аның Җәлилнеке дип йөртелгән, ләкин тәгаен расланмаган ши-

гырьләргә мөнәсәбәтен күрсәтергә мөмкин).

Автор хезмәтендә вакыт-заман рамкаларын еш кына күчерә, үткәндәге тарих белән бүгенгене сәнгатьчә бәйләп алып бара. Муса Җәлилнең геройлыгы — заманнар, вакытлар көченә бирелми торган сыйфат — гражданлык сыйфатыбыз ул. Немец халкының бөек шагыйре Г. Гейне болай дип әйткән: «Бүгенге көн — кичәге көннең нәтиҗәсе. Һәм бүгенге көнебезнең нәрсә теләгәнен белергә уйласак, без кичәге көннең ихтыярына төшенергә тиешбез». Муса Җәлилнең тормышы — безгә бүгенге көнебезне аңлар өчен хезмәт итүче кичәге көнебез ул. Р. Мостафинның эзләнүләре, нәкъ шул фикер белән сугарылып, бүгенге көнгә адресланган кыйммәтле фәнни хезмәт.

Китапта тормыш призмасы аша уздырылган интернационализм хисләре конкрет хәрәкәттә күрсәтелгән. Дошман тылындагы яшерен көрәшчеләр ялган патриотизм белән чын патриотизм арасындагы аерманы бик ачык аңлыйлар. Легионерларның Ватанга тугрылыклы булырга чакырып бастырылган листовкаларына «Патриот» дип имза куюлары гына да гаять тирән символик мәгънәгә ия. Сыйнфый аңның фашистлар тудырырга тырышкан милләтчелек агуыннан өстен чыгуы легионның белорус партизаннары ягына күчүендә конкрет чагылыш таба.

Китапта немец язучысы Л. Небенцальнең бер фикере китерелә. «Без, Германия Демократик Республикасы гражданнары,— дип яза Небенцаль,— Муса Җәлилне фашизмга каршы көрәшче дип кенә түгел, ә интернационалист буларак та тәкъдир итәбез. Үлемгә хөкем ителгән тоткыннар камерасында утырганда да ул үзе нәфрәтләнеп караган, тормышының соңгы сулышына кадәр аларга каршы көрәшкән Германиянең реакцион һәм милитаристик көчләре белән үзе хөрмәт иткән, бәяләгән һәм яраткан Маркс һәм Тельманны, Гете һәм Гейнены, Бах һәм Бетховенны биргән немец халкы арасында аерманы ачык күргән» (186 бит).

Китапның күпчелек урыннары искиткеч зур кызыксыну белән укыла. Билгеле, укучыларның кызыксынуы, башлыча, китапта язылган вакыйгаларның гадәттән тыш драматик булуына нигезләнгән. Әмма нәкъ шушы урында Р. Мостафинның мавыктыргыч итеп яза белү осталыгын да әйтергә кирәк. Автор тапталган алымнарны, җансыз, коры җөмләләрне яратмый, ул һәрвакытта яңа фикер әйтергә омтыла. Авторның фикерләре, гәрчә алар кайчак бәхәсле булсалар да, синең уйларыңны кузгаталар, син бу фикерләргә битараф кала алмыйсың, чөнки алар һәр очракта диярлек яңалык белән сугарылганнар.

Әлбәттә, авторның кайбер кимчелекләрен дә күрсәтергә мөмкин булыр иде. Мәсәлән, тасвирланган типларның бер төрлерәк, эскиз характерындарак булып, Җәлилнең шагыйрь буларак тиешенчә күрсәтелмәвен, кайбер урыннардагы стилистик чуарлыкны әйтергә мөмкин булыр иде. Ләкин бу кимчелекләрне жанр үзенчәлеге һәм сөйләнә торган хәлләрнең катлаулыгы хисабына гафу итәргә дә мөмкин.

Р. Мостафин бу китабын яшьләргә адреслап язган. Монда тирән бер мәгънә бар: яшьләр Ватаныбыз тарихындагы иң зур трагедияләр, иң якты батырлыклар сәхифәсен аеручә сизгер күңел белән кабул итәләр. Әмма бу китап, һәр яхшы әсәр кебек үк, күп адреслы әсәр: аны таләпчән әдәбиятчы да, фактларга игътибар итүчән тарихчы да һәм әдәбият сөюче гади кеше дә яратып укыр...

**Җәмил САФИУЛЛИН,**
**филология фәннәре кандидаты.**

# ЯҢА КИТАПЛАР

**Ә. ГЫЙЗЗӘТОВ. Эшчән куллар. Шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел.**

«Эшчән куллар» Әфган Гыйззәтовның үзе үлгәннән соң дөнья күргән икенче китабы. Исеменнән үк күренгәнчә, җыентыкта төп урынны хезмәт темасына багышланган әсәрләр алып тора. Әйтергә кирәк, бу җаваплы һәм актуаль теманы автор гади, үтемле итеп, поэтик осталык белән ачып бирә алган. Шагыйрьнең «Кулларның төсе» дигән шигырен генә алып карыйк. Беренче карашка шактый катлаулы тоелган төшенчәләр шигырьдә үзләренең конкрет гәүдәләнешен, образлы чагылышларын тапканнар. Шахтерның кулы күмердәй кара булса да, аның эшләгән эше нур чәчеп януы да, тимергә охшаган тимерче кулының сандалга суксаң, гөлт итеп кояш балкытуы да, кояшта янып, җиткән игенгә охшап калган игенче кулларының хезмәте дә — барысы да нәни укучы күз алдына җанлы картина булып килеп баса. Әмма автор мондый кызыклы күзәтүләр, параллельләр китерү белән генә чикләнеп калмый. Педагог буларак, тәрбияви нәтиҗә чыгарып куярга да онытмый.

**Кулларга йога**
**Хезмәтнең төсе.**
**Аксөяк була**
**Эш сөймәс кеше.**
**Ак булган өчен**
**Әйтелми бу сүз.**
**Йокмый бер төс тә,**
**Кул булса эшсез.**

Авторның шундый ук осталык белән язылган «Минем абый кранчы», «Мәкләрем», «Тегүче җил», «Кара», «Янәсе, шәп оя бу», «Чүкеч» кебек шигырьләре дә балаларда хезмәткә мәхәббәт тәрбияләргә булыша.

Әфган Гыйззәтов — нечкә тойгылы лирик шагыйрь. Табигать күренешләре аша кеше күңелен ачарга омтылу, якты моңхис, сизгер күзәтүчәнлек хас аңа. Бу сыйфатны балаларда да тәрбияләргә, үстерергә тырыша шагыйрь. Әфган Гыйззәтовның пионер оешмасының туган көненә багышлап язган «Таң атканда» дигән шигыре менә яхшы мисал була ала. Табигать күренешләрен сурәтләү ярдәмендә менә нинди зур гомумиләштерүләргә килә шагыйрь:

**Таң ата... мин карап тордым**
**Ал таңга исем китеп.**
**Гүя ипем таңны бүген**
**Таккан галстук итеп.**

Яки «Ай нигә ак?» дигән шигырьне алып карагыз. Монда да Әфган Гыйззәтовның табышы куандырырлык. Бала айның ни өчен ак булуы турында уйланып баш вата. Һәм озак эзләнә торгач үзенчә җавап та таба:

**Гаҗәпләнмимен хәзер мин**
**Иртән Ай ак булганга.**
**Төн буена су кера ул**
**Мин коенган елгада.**

«Бәбкәләр» исемле икенче бер шигырьдә шундый юллар бар:

**Каз оясыннан бипелдәп**
**Чыктылар да бәбкәләр,**
**Сибелделәр ихатага**
**Гүя сары чәчкәләр.**
**Берсен кулга алган идем,**
**Кинәт җиргә сикерде.**
**Тавыш бирде: «Бип-бип» дип,**
**Җир юлдашы шикелле.**

Кыскасы, җыентыкта һәр шигырь менә шулай кызыклы, үзенчә мавыктыргыч. Алар нәни укучыларыбызда матур, күркәм тойгылар — Туган илгә, хезмәткә мәхәббәт хисләре тәрбиялиләр, намуслы, батыр булырга, тырышып укырга һәм чын кеше булып үсәргә өндиләр. Балаларыгызга укыганда сез моны үзегез дә ачык тоярсыз һәм ул шигырьләрдән зур ләззәт-куаныч алмый калмассыз дип уйлыйм. Чөнки «Эшчән куллар» чын шагыйрь илһамы белән тудырылган китап.

Муса **СИРАҖИ.**

**Л. ХӘМИДУЛЛИН. Дала иртәсе. Повесть. Татарстан китап нәшрияты. 1971 ел.**

Бу — аның икенче китабы. Беренчесе, ягъни «Юлда» дип аталганы, 1968 елда чыккан иде. Ул китап, күләме ягыннан тәнкыйть күзенә чалынырлык дәрәҗәдә булмаса да, үзенең теле, тематикасы ягыннан безнең арада үзенчәлекле бер яшь каләм барлыгын хәбәр итте. Һәм мин, аның редакторы буларак, Лирон Хәмидуллинга нык бер өмет баглаган идем. Ниһаять, менә бу повестен укып чыкканнан соң өметемнең хак булуына ышандым. Беренчедән, Л. Хәмидуллин үзенең зуррак күләмле әсәр яза алуын исбат итте. Икенчедән, ул әдәбиятка, кайбер яшьләребез кебек, институт я университетның филология факультетыннан гына килми, ул тормышның эченнән үз дөньясы белән килә: аның җилкәсендә кимендә унбиш еллык эш тәҗрибәсе бар, һәм бу тәҗрибә, өй-

тергә кирәк, арадан беребезнекенә дә охшамаган. Бу да язучы өчен бик кирәкле сыйфаттыр. Өченчедән, аның әдәби теле дә үзенчәлекле — ул эшче кулы кебек нык, хәтта сөяллерәк тә. Хәер, шулай булуы әйбәт тә аның. Киләчәктә дә аның теле шулай үзенчә калсын иде.

Әсәрнең эчтәлеге болай. Тимер юл төзелешендә әле өч-дүрт ел гына эшләгән яшь белгеч Бәһрам Бикташевны, һич көтмәгәндә, икенче бер өр-яңа төзелешкә баш инженер итеп күчерәләр. Ягъни зур урынга куялар. Яңа урын, яңа коллектив. Өстәвенә, андагы төзү поезды башлыгы Михаил Яковлевич Горлов та фәкать үз сүзен генә сүз итәргә яратучы бер кеше булып чыга. Килешеп эшли алырлармы алар? Үзе дә яңа вазифасын күтәрә алырмы? Яшь коммунист Бәһрам Бикташевны борчыган уйлар әнә шул. Повесть нәкъ әнә шул уйлар-борчулар белән башланып китә.

Укый-укый беләбез: Бәһрам Бикташев тормышта җайлы гына, рәхәт кенә урын эзләми, ул һәр эшен намусы кушканча эшли. Ахырда үзенең принципиаль юлын яруга ирешә: консерватизм кирталәре җимерелә; дөрес, әлегә барысы да түгел, алар әле алдагы көндә дә күп булачак. Ләкин шунысы мәгълүм: Бикташев кебек янар йөрәкле яшь коммунистлар, комсомоллар булганда бернинди киртәгә дә озаклап тамыр җәяргә мөмкин булмаячак. Повестьның колакка киртеп куйган идеясе шул. Ләкин бу идея декларатив планда түгел, ә бәлки кешеләр аша, аларның эшгамәлләре аша, ниһаять, конфликтлар аша бирелгән.

Әсәрдә беренче планга хезмәт романтикасы калкып чыга. Л. Хәмидуллин күбебезгә таныш булмаган, үзе генә белгән хезмәт коралларын язмый, хезмәтнең кыен матурлыгын яза, шуның белән мавыктыра. Әлбәттә, романтика бар җирдә яшьләр, яшьләр бар җирдә романтика була. Бу әсәрдә дә яшьләр байтак: Алчәчәкләр, Серафимнар, Тонялар, Славалар. Болары — коммунизм эләмен эстафета итеп алга алып китүчеләр. Шулай да әле араларында «Зойка» Зайцев, Әхмәт Хәкимов ишеләр дә юк түгел. Ләкин болары — саф сунык яр читенә чыгарып ташлыйсы чүпләре, күбәләкләре генә.

Яшьләр бар җирдә мәхәббәте дә булмый калмый, диләр. Мине шунысы сөендерде: Л. Хәмидуллинда бер бозык «мәхәббәт» тә юк. Хәер, мәхәббәт бозык була да алмый, хәтта мәхәббәт дигән сүзнең үзенә дә «чын, саф, тирән» кебек сүзләр кушуның кирәге юк. Мәхәббәт — мәхәббәт инде ул! Әлеге повестьтагы Бәһрам белән Дилә, Серафим белән Алчәчәк, Нургали белән Кәримә — бу өч мәхәббәтнең өчесе дә сылу итеп тасвирланган. Мин авторның позициясен аңлыйм: һәр нәрсәдә гыйбрәттән әүвәл үрнәк булырга тиеш; начардан гыйбрәт алуга караганда, яхшыдан үрнәк алу яхшы түгелмени!

Әдәби телен үзенчәлекле, дидем. Л. Хәмидуллин күзәтә белә, шул күзәтүен детальләр аша уйлый белә, шуларга үз сүзен таба белә. Әйтик, аның кичә генә аерылышкан, сөйгән кызы да «...Дилә булмагандыр? Әнә ул тау битләрендәге сагышлы каеннар гына Дилә булып хыялыннан узадыр» кебек. «Анда йокымсырап яткан, әлегә ялгыз ялманнар гына чабып йөргән далада аны ни көтәдер — әлегә билгесез» дигән җөмлә дә Бәһрамның халәте-рухиясенә туры килә. Автор Алчәчәкләр барып төшкән вокзалның «тузан баскан ике тәрәзәле тар залын, тапталып такта идән икәнлеге дә беленмәс хәлгә килгән идән»не генә түгел, башкасын да күрә: «Барлыгы ике эскәмия һәм ишек катында чылбырлы алюмин су багы бар иде», ди. Моны вокзалдан чыгып киткәндә дә онытмый: «Залда булганнар һәммәсе дә дәррәү аякка басты. Колхозчы хатын да, ике капчыгын ике яклап җилкәсенә асып, кабаланып чыгып китте. Сулы кружка аның артыннан, чылбырын сөйрәп, идәнгә атылып төште». Деталь тәгәлләнгән. Миңа, мәсәлән, кружка да идәнгә атылып төшмәсә, вокзалның ыгы-зыгысы ул кадәр үк күз алдына килеп басмас иде кебек.

Уңышлы дип тапкан тагын берничә деталь. Серафимның чәче «каралып килүче язгы салам төсле, ял булып җилкәгә төшеп торә иде.» Багана башында җилгә чайкалып торучы электр лампасы «күзне ачкан-йомган саен яктырак яна шикелле». Һидиятнең бүреге, мәсәлән, «атлаган саен әйләнеп төшәр төсле булып, баш түбәсендә генә утыра». Яки әнә Алчәчәк ягар өчен даладан дүңгәләк җыя: «Ул аларны куып тотып берсен кочагына алса, икенчесен җил урлап кача. Тик шулай куышалар... Кабат дала буйлап кызыл төлкедәй кызыл пальтолы кыз йөгерә».

Повестьта бик урынлы китереп куелган, күпләп тапалмаган-изелмәгән тапкыр сүзләр, мәкальләр дә байтак. Менә берничәсе: «Тол ирдән хатын, җәяүледән ат сайлатма», «Керсез ай, моңсыз ходай», «Лозунг саен крендель бәйләмә элеп куелмый», «Яшьлеккә юл күп», «Карга батып карамаган ат кардан курыкмый», «Аем туры баккнда йолдызларга йодрык», «Ат утлаган болында күбәләккә дә урын бар» һ. б.

Күзәтүнең ахырында тагын шуны әйтәсе килә: әсәрне укып чыккач, «бетеп җитмәгән бит бу» дигәнрәк фикер калды. Шул сәбәпле, бигрәк тә төп герой Бәһрамның бөтен ягы да ялтырап ачылып җитмәгән, кайбер җирдә аерым-аерым штрихлар аша гына төсмерләнә. Шуңа күрә повесть, тулаем әйткәндә, бик матур кибән салынып та, очын очлап бетермәгән кебегрәк. Моны мин авторның материалы җитмәүдән түгел,— аның материалы түбәдән ашкан,— ә тәҗрибәсе җитмәүдән күрәм. Хуп, тәҗрибә әкренләп туплана. Димәк, Л. Хәмидуллинның киләсе әсәрләре болай гына булмас, моннан да яхшы булыр дигән өметтәмен.

**Хәсән САРЬЯН**

# ЛЕНИН ГВАРДИЯСЕ СОЛДАТЫ

Татар халкының батыр улы, революция солдаты генерал-лейтенант Якуб Җиһангир улы Чанышевка шушы елның 27 февралендә сиксән яшь тулды. Ул 1917 елның 15 мартыннан башлап коммунистлар партиясе члены, Казанда Октябрь революциясе җитәкчеләренең берсе, Гражданнар сугышына актив катнашкан хәрби начальник.

Якуб Чанышев батрак семьясында туа. Әтисе үлгәндә аңа сигез яшь була. Кечкенә малай чагыннан ук Якуб туганнары белән бергә, алпавытларга ялланып тамак туйдыра, кышларын авыл мәктәбендә мич ягучы булып эшли һәм шул ук вакытта белем алырга да тырыша. Шундый шартларда да ул мәктәпне бик яхшы билгеләренә бетереп чыга. Чыгарылыш имтиханнары вакытында мәгариф инспекторы, Якубның укуга сәләтен күреп, аңа Казанга татар-башкорт укытучылар мәктәбенә укырга керергә тәкъдим ясый.

1912 елда Якуб бу мәктәпне уңышлы тәмамлый һәм гомерен укыту, халыкны агарту эшенә багышларга хыяллана. Әмма Якубка балалар белән күп эшләргә туры килми, 1913 елда аны солдатка алалар. Бер елдан соң инде ул — беренче империалистик сугыш фронтында. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен Якуб Чанышев 1916 елда фейерверкер (кече артиллерия командиры) дәрәҗәсенә күтәрелә һәм Георгий медале белән бүләкләнә.

Сугышта патша армиясе зур югалтуларга дучар була. Кадровый офицерлар аз кала. Шунлыктан верховный командование элеккеге разночинец-студентларны, эшче-крестьян сословиесеннән чыккан унтер-офицерларны кыска сроклы прапорщиклар курсларына җибәрә. 1917 елның январенда элеккеге батрак һәм солдат Якуб Чанышев та Казандагы хәрби училищега элэгә һәм ул, Казан университеты студентлары белән бергә, беренче рота курсанты итеп билгеләнә.

Шулай итеп, Якубны патша армиясе офицеры итеп әзерләмәкче булалар. Әмма инде ул — империалистик сугыш мәктәбен үткән тәҗрибәле солдат — хезмәт халкы интересларыннан буржуазия интересларын яхшы аера белә.

...1916 елда Якуб хезмәт иткән батареяны Путилов һәм Мотовилих заводларында забастовкада катнашкан өчен штрафной роталарга җибәрелгән эшчеләр белән тулыландыралар. Алар арасындагы большевиклар батареядагы солдатларга тылдагы хәлләрне, хезмәт кешеләренең, солдат семьяларының авыр тормышы турында сөйлиләр, патша властьларының чын йөзен фаш итәләр, Ленин һәм большевиклар партиясенең югары сыйныф интересларын саклау өчен алып барыла торган империалистик сугышны бетерү, аны гражданнар сугышына әверелдерү һәм социалистик революция ясау өчен көрәшүен аңлаталар. Окопларда, траншеяларда большевистик брошюралар күренә башлый, солдатлар аларны битләре тузып беткәнче укыйлар. Шулай итеп, Якуб Казанга большевикларның ни өчен көрәшүләрен яхшы белеп килә. һәм февраль революциясе көннәрендә үзе дә, бер дә икеләнмичә, Ленин партиясенә член булып керә.



240 нчы укчы полк солдатлары Чанышевны батальон командиры, полк комитеты председателе урынбасары, эшче һәм солдат депутатларының Казан шәһәр Советы члены итеп сайлыйлар. Шул ук вакытта ул большевиклар партиясенең Казан комитеты каршындагы хәрби оешмага да сайлана. Якуб Чанышев Казан гарнизоны солдатлары арасында большевистик идеяләрне таратуда актив катнаша.

1917 елның 26 октябрендә Казанда власть тулысынча большевиклар кулына күчә. Большевик Якуб Чанышев Ревком члены, Казан хәрби округының Комиссарлар Советы члены итеп сайлана.

Комиссарлар Советы Бөек Октябрь социалистик революциясенең беренче көненнән үк Кызыл Гвардиягә, Кызыл Армиягә отрядлар, полклар, бригадалар оештырырга керешә һәм алар гражданнар сугышы фронтларына җибәрелә. Казанда оештырылган отрядлар Оренбург ягында атаман Дутов гаскәрләрен тар-мар итүгә, ак чехларга һәм ак гвардия бандаларына каршы сугышларга катнаша, Якуб Чанышев бу сугышның күбесендә үзе дә була. Шафран станциясендә, чехословак гаскәрләре отрядын коралсызландырган вакытта, аклар аны кулга алалар һәм Уфа төрмәсенә ябалар. Якуб 1918 елның 30 декабрендә Бишенче Армия гаскәрләре шәһәрне азат иткәннән соң гына ирекка чыга.

1919 елның 19 январе — Чанышев өчен онытылмаслык истәлекле көн. Ул Уфадан Мәскәү аша Казанга кайта һәм башкалада тукталып революция юлбашчысы В. И. Ленинны күрә. Бу көнне В. И. Ленин Мәскәү Советы бинасы балконыннан Роза Люксембург һәм Карл Либкнехтның ерткычларча үтерелүләре турында хезмәт ияләре алдында чыгыш ясый. Юлбашчының бу речь Якубта тирән тәэсир калдыра һәм аны ул хәзер дә ачык хәтерли.

1919 елның язында, Колчак армиясе Иделгә якынлашканда, В. И. Ленин һәм партия халыкка: «Барысы да Колчак белән көрәшкә!» лозунгысы белән мөрәҗәгать итәләр. Казан большевиклары, бу мөрәҗәгатькә җавап итеп, Беренче Аерым Идел буе татар бригадасын оештыруга керешәләр. 1 июньдә бригада Көнчыгыш фронтның Көньяк группасы командующие М. В. Фрунзе карамагына җибәрелә. Бригада сугышчылары Оренбург янында ак казаклар бандасын тар-мар иткәндә зур батырлыклар күрсәтә. Бу сугышларда Якуб Чанышев артиллерия дивизионы командир-комиссары була.

Төркстан фронты гаскәрләре белән кушылганнан соң, бригада Фирганәгә күчерелә һәм аңа басмачылар бандаларын тар-мар итү бурычы йөкләнә.

Төркстан фронтына күчкәч, фронт Революцион-хәрби Советы карары буенча, Чанышев Татар бригадасының комиссары итеп билгеләнә һәм ул дүрт ел дәвамында сугыш хәрәкәтләре, җирле халык арасында политик агарту эшләре белән җитәкчелек итә. Басмачыларга каршы сугышларда күрсәткән шәхси батырлыгы, җирле халык арасында ленинчыл милли политиканы эшлекле алып барганы өчен Чанышев Кызыл Байрак ордены һәм Үзбәкстан республикасы Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә. Беренче Татар бригадасының сугышларда күрсәткән батырлыгы күп мәртәбәләр фронт Революцион-хәрби Советының рәхмәтенә һәм котлавына лаек була.

1923—1924 елларда Якуб Чанышев Югары академия курсларында укый һәм 1924 елдан башлап 1932 елга кадәр беренче Казан дивизиясе белән командалык итә. 1932—1934 елларда М. В. Фрунзе исемендәге Хәрби академиядә белем ала. Академияне уңышлы тәмамлаганнан соң, 1934—1940 елларда, Төркстан хәрби округында (Термез шәһәре) 3 нче Тау-укчы дивизиясе командиры була.

Кызыл Армиянең зур берләшмәләре белән командалык иткән Якуб Чанышев, партия һәм җәмәгать эшләренә дә вакыт таба. Төркстанда җирле халык арасында ул бик зур ихтирам казана. Партия өлкә комитеты һәм өлкә башкарма комитеты карары нигезендә Чанышевка «Андижан шәһәренең Мактаулы гражданины» исеме бирелә, Төркстан республикасының партия оешмалары аны ВКП(б)ның X съезды делегаты итеп сайлыйлар. Анда Якуб Чанышев берничә тапкыр В. И. Ленинны күреп сөйләшә.

Казанда эшләгәндә Чанышев партиянең Татарстан өлкә комитеты бюросы члены, Татарстан Үзәк башкарма комитеты члены булып сайлана. Татарстанда да ул үзен тәҗрибәле пропагандист, оста оратор итеп таныта.

Бөек Ватан сугышы чорында генерал Чанышев дивизия, корпус белән командалык итә, 68 нче армия командующие урынбасары була. Аның кул астындагы берләшмәләр Брест крепостен, Варшаваны азат итү сугышларында, Модлин, Торунь, Гдынь, Соппот, Көнбатыш Буг, Нарев, Висла, Одер елгаларын кичә. Берлин операцияләрендә катнаша. Генерал-лейтенант Якуп Җиһангир улы Чанышев сугышчан батырлыклары өчен егерме биш хөкүмәт бүләгенә лаек була. Алар арасында ике Ленин ордены, дүрт Кызыл Байрак ордены, Беренче дәрәҗә Кутузов ордены, Икенче дәрәҗә Суворов ордены һәм шулай ук Польша, Америка Кушма Штатлары орденнары, медальләре бар. Генерал-лейтенант Я. Чанышев гаскәрләре унике тапкыр Верховный Баш Командующий приказында билгеләнеп үтелә, алар хөрмәтенә Ватаныбыз башкаласы тантаналы салютлар бирә. Аның командалыгындагы дивизияләргә, корпусларга Брест исеме бирелә, хөкүмәт бүләкләре тапшырыла.

Бөек Ватан сугышыннан соң генерал Я. Чанышев К. Е. Ворошилов исемендәге СССР Кораллы көчләре Генераль штабы Югары Хәрби академиясенең өлкән укытучысы һәм курс начальнигы итеп билгеләнә. Ун ел дәвамында ул Совет Армиясе өчен югары квалификацияле командирлар тәрбияли.

Ул 1958 елдан бирле отставкада. Олы яшьтә булуына карамастан, Якуб Чанышев ВЛКСМ Үзәк Комитеты, партиянең Мәскәү комитеты, сугыш ветераннарының Совет Комитеты члены буларак һәм «Белем» җәмгыяте буенча күп төрле иҗтимагый-политик эш алып бара. Ул әле һаман да яшьләргә хас дәрт һәм омтылыш белән партиябезгә, бөек Ленин эшенә хезмәт итә.

М. ӘПСӘЛӘМОВ, хәрби фәннәр докторы, генерал-майор, 1919 елдан КПСС члены.
Н. СӘЙФИ, Союз күләмендәге персональ пенсионер, 1919 елдан КПСС члены.

# ӘДӘБИЯТ һӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ЯШЬ ТӘНКЫЙТЬЧЕЛӘР СЕМИНАРЫ

22 ноябрьда Татарстан язучылар союзы идарәсе яшь тәнкыйтьчеләр семинары үткәрде.

Язучылар союзы идарәсе председателе Зәки Нуриның кереш сүзе белән ачылган ул семинарда филология фәннәре кандидатлары Хәсән Хәйри «Бүгенге проза һәм әдәби тәнкыйть», Зәет Мәҗитов «Бүгенге поэзия һәм әдәби тәнкыйть», Илтани Илялова «Театр һәм әдәби тәнкыйть» дигән темаларга докладлар ясадылар. Докладлардан соң өлкән әдипләребездән Нәкый Исәнбәт, Сибгат Хәким һәм Фатих Хөсни семинарга чакырылган иптәшләргә үзләренең тәнкыйть өлкәсендәге тәҗрибәләре турында сөйләделәр, яшь тәнкыйтьчеләр алдында торган бурычларга тукталдылар. Аннары семинар эше секцияләргә бүленеп дәвам иттерелде. Филология фәннәре кандидаты Илбарис Надиров Фатих Урманчиев иҗатына; Шәйхи Маннур, Гази Кашшаф һәм Зәет Мәҗитов Әдхәт Синегулов иҗатына; Илтани Илялова, Туфан Миннуллин Рим Кәримов иҗатына; Хәсән Хәйри, Нил Юзиев Нурмөхәммәт Хисамов иҗатына; Фәрваз Миннуллин, Ренат Харисов Равил Лотфуллин иҗатына җентекле анализ ясадылар. Яшь тәнкыйтьчеләргә иҗатларындагы уңышлы һәм кимчелекле якларны күрсәттеләр.

Ахырдан секция җитәкчеләренең әлеге семинарда катнашкан яшь тәнкыйтьчеләр иҗатына карата йомгак сүзләре тыңланды.

## КЕЧКЕНӘЛӘР ӨЧЕН ЗУР ӘДӘБИЯТ ТУРЫНДА КАЙГЫРТЫП

Дагстанның башкаласы Махачкалада СССР һәм РСФСР язучылар союзы, шулай ук Дагстан язучылары оешмасының берләштерелгән пленумы булып үтте. Анда хәзерге балалар әдәбиятының идея-художество дәрәҗәсен тагын да үстеру турындагы мәсьәлә тикшерелде. Пленумга Мәскәүдән һәм Ленинградтан, союздаш һәм автономияле республикалардан, үзәк нәшриятлар («Молодая гвардия», «Детская литература», «Малыш») һәм үзәк журналлардан («Пионер», «Мурзилка», «Детская литература») вәкилләр җыелды. Пленум эшендә Татарстаннан СССР язучылар союзы идарәсе секретаре шагыйрь Зәки Нури һәм Татарстан язучылар союзының балалар әдәбияты секциясе җитәкчесе шагыйрь Рөстәм Мингалимов катнаштылар. Пленум утырышларының берсендә Зәки Нури хезмәт һәм интернациональ дуслык темасына язылган яңа китаплар турында сөйләде. Шагыйрьнең Махачкала радиосыннан чыгышы да, Махачкала педагогия институты аудиториясендә, Махачкалада республика балалар китапханәсен ачканда һәм Буйнак шәһәре культура сараенда укучылар белән очрашканда сөйләгәннәре дә балалар әдәбиятының заман таләпләренә тулы җавап бирерлек югары сыйфаты турында, дуслык мөнәсәбәтләрен барлык чаралар белән көчәйтү турында булды. Шагыйрь Рөстәм Мингалимов та Махачкалада пыяла тукыма заводы эшчеләре белән, Буйнакта яшьләр һәм мәктәп балалары белән очрашуда катнашты.

## ДРАМАТУРГЛАР СЕМИНАРЫ

Ноябрь аенда Уфада РСФСР драматурглары семинары булды. Идел буе автономияле республикаларының һәм өлкәләренең драматурглары катнашында уздырылган семинарда Татарстан драматургларыннан Хәй Вахит, Туфан Миннуллин һәм Диас Вәлиевләрнең пьесалары да тикшерелде. Республикабыз әдипләренең әсәрләренә нигездә уңай бәя бирелде.

## КУЛЬТУРА РАБОТНИКЛАРЫ ПРОФСОЮЗЫ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Казанның Актерлар йортында культура работниклары профсоюзы өлкә комитетының IX өлкә конференциясе булды. Конференциядә культура работниклары профсоюзы өлкә комитеты председателе Я. С. Шәмсетдиновның һәм ревизия комиссиясенең отчет докладлары тыңланды. Докладлар буенча фикер алышуларда культура работниклары профсоюзының Бөгелмә шәһәр комитеты председателе М. Х. Ибраһимов, В. Качалов исемендәге Зур драма театры җирле комитеты председателе Ю. А. Коршок, Чистай типографиясенең коммунистик хезмәт ударнигы А. Е. Садыйкова, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге председателе

Р. А. Жиһаншина, Татарстан язучылар союзы правлениесе җаваплы секретаре Р. М. Харисов, Алабуга культура-агарту училищесы җирле комитеты председателе А. В. Кузнецов һәм башкалар катнашты.

Конференциядә культура работниклары профсоюзы Үзәк Комитеты председателе М. В. Пашков һәм ТАССР культура министры Б. М. Гыйззәтуллин иптәшләр чыгыш ясадылар. Конференция эшендә КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев катнашты.

Конференция культура работниклары профсоюзы өлкә комитетының һәм ревизия комиссиясенең яңа составын, профсоюзларның XII Татарстан өлкә союзара конференциясенә һәм культура работниклары профсоюзының VIII съездына делегатлар сайлады.

## ЯҢА ЖУРНАЛ

Совет тел һәм әдәбият фәнендә төрки телләрен һәм әдәбиятларын өйрәнү шактый зур урын тота. Ул илебезнең бик күп фәнни институтларында һәм югары уку йортларында укытыла һәм фәнни яктан тикшерелә. Шуны искә алып, СССР Фәннәр академиясе Президиумы «Советская тюркология» исемле яңа журнал чыгара башлады. СССР Фәннәр академиясе һәм Әзербайҗан Фәннәр академиясе органы буларак 1970 елда чыгарыла башлаган бу фәнни-теоретик журнал түбәндәге бүлекләрне эченә ала: телне өйрәнү методлары һәм теориясе мәсьәләләре; хәзерге телләрнең төзелеше (фонетика, фонология, грамматика, лексикология һәм лексикография); телләрне чагыштырма-тарихи өйрәнү һәм диалектология; әдәби тел тарихы; төрки әдәбиятларда социалистик реализмның үсеше; төрки әдәбиятларның һәм фольклорларының тарихы; төрки халыкларның үзара бәйләнешы һәм аларның башка әдәбиятлар белән мөнәсәбәтләре; милли мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында төрки телләрне һәм әдәбиятларын укыту методикасының теоретик мәсьәләләре; тәрҗемә теориясе; рецензияләр һәм библиографик күзәтүләр; фәнни тормыш.

Тел фәненә караган бүлектә, төрки телләрнең фонетикасыннан, грамматикасыннан, лексикасыннан һәм аларның тарихи үсешенә бәйләнешле мәсьәләләрдән тыш, математик лингвистиканың яңа методларын яктырткан хезмәтләргә дә киң урын бирелә. Әдәби телләрне нормальләштерү (алфавитларны һәм орфографияләрне камилләштерү, терминология принципларын эшкәртү) мәсьәләләрен күтәргән материалларга да журнал бик нык игътибар итә.

Бу журнал әдәбиятта милли үзенчәлек һәм илебездәге төрки халыклар әдәбиятларының социалистик эчтәлеге, ул әдәбиятларда социалистик реализмның үзенчәлекләре, художество үзенчәлекләре һәм фольклор чыганаклары проблемаларын мөмкин кадәр тулырак яктыртуны үзенең төп бурычы итеп куя.

«Советская тюркология» Татарстан тел галимнәренең хезмәтләренә дә киң урын бирә. Мәсәлән, журналның 1970 елгы алтынчы санында гына да Казан галимнәреннән Ш. Абиловның «Болгар-татар әдәбиятында «Кутадгу билик», Л. Мәхмүтованың «Татар тел белеменең хәзерге хәле һәм үсеш перспективалары», Ф. Фасеевның «Диалектологик сүзлекнең яңа төре», М. Мөхәммәдиевның « Тюркология мәсьәләләре», Ф. Ганиевнең «Хәзерге татар әдәби телендә фигыль төрләре» һәм Алабуга галиме Л. Арслановның «Хәзерге татар әдәби теле» исемле кызыклы мәкаләләре басылып чыкты.

«Советская тюркология» журналы ике айга бер мәртәбә чыгарыла. Ул фәнни хезмәткәрләргә, укытучыларга, аспирантларга, студентларга гына түгел, гомумән төрки халыкларының теле һәм тарихи мәсьәләләре белән кызыксынучыларның барысына да бик файдалы чыганак булып хезмәт итә.

«Советская тюркология» Баку шәһәрендә басыла. Редакциянең адресы: Баку — 73, проспект Нариманова, 31.

Язылу бәясе бер елга 6 сум.

## ЭЛЕМТӘЛӘР НЫГЫЙ БАРА

Татар әдәбиятының тугандаш халыклар һәм чит ил халыклары әдәбиятлары белән элемтәсе елдан-ел ныгый бара. Әле соңгы атналарда гына Татарстан китап нәшрияты венгр язучыларының шигырьләре һәм утызга якын хикәясен туплаган китапны татар телендә бастырып чыгарды. «Венгр әдәбияты җәүһәрләре» исемле бу китапка, чыннан да, венгр әдипләренең төрле елларда язылган һәм венгр әдәбиятының алтын фондына кергән иң яхшы әсәрләре тупланган. Җыентыкта венгр әдәбият галиме Шандор Коцкашның шактый зур күләмле кереш сүзе урнаштырылган.

## ДУСЛАР БҮЛӘГЕ

Татарстан китап нәшрияты узган ел башкорт язучыларының хикәяләрен туплап «Башкорт хикәяләре» исеме астында татар телендә аерым китап бастырып чыгарганын хәбәр иткән идек инде. Әле шушы көннәрдә генә Башкортстан китап нәшрияты татар язучыларының хикәяләрен башкорт телендә аерым китап итеп бастырып чыгарды. «Дуслар бүләге» исеме белән чыгарылган ул китапка төрле буын татар язучыларының утызлап хикәясе кертелгән. Китапка һәр хикәя авторының рәсеме һәм аның турында биографик белешмә дә урнаштырылган.

## ҖЫР БЕЛӘН ИЛ БУЙЛАП

Үткән елның октябрь, ноябрь айларында Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе артистлары, берничә төркемгә бүленеп, илебезнең Идел буе өлкәләрен-

дә, Себер һәм Урта Азия якларында гастрольдә булып, йөз илледән артык концерт биреп кайттылар. ТАССРның халык артисты Илһам Шакиров житәкчелегендәге «Идел» вокаль-инструменталь ансамбле Свердловск, Омск, Томск, Кемерово өлкәләрендә һәм Красноярск краенда; ТАССРның атказанган артисты Габдулла Рәхимкулов катнашындагы артистлар группасы Казагыстан, Кыргызстан һәм Үзбәкстан ССРларда; эстрада артистларының Бөтенсоюз конкурсы дипломанты Зиннур Нурмөхәммәтов катнашындагы артистлар Куйбышев, Саратов, Оренбург, Волгоград, Астрахань өлкәләре тамашачылары алдында чыгышлар ясадылар.

* * *

Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры коллективыннан РСФСРның халык артисткасы Зөләйха Хисмәтуллина, ТАССРның халык артистлары Идиал Ишбүләков, Рәйсә Билялова һәм ТАССРның атказанган артисты Сөләйман Йосыпов Пермьдә һәм Пермь өлкәсе районнарында булып, концертлар биреп кайттылар.

## ТӘНКЫЙТЬ СЕКЦИЯСЕНДӘ

29 октябрьда Татарстан язучылар союзы каршындагы тәнкыйть секциясенең чираттагы утырышы булып узды. Анда филология фәннәре кандидаты Хәй Хисмәтуллинның язучы Фатих Кәрими иҗатына багышланган монографиясе тикшерелде. Фикер алышуда филология фәннәре докторлары Гали Халит, Ибраһим Нуруллин, филология фәннәре кандидатлары Мөхәммәт Мәһдиев, Рафаэль Мостафин, тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин катнашты. Алар монографияне тагын да камилләштерү юнәлешендә киңәш әйттеләр.

Шул ук секциянең ноябрь аенда уздырылган утырышы филология фәннәре докторы Гали Халитның «Шагыйрь, герой, чор» исемле китабын тикшерүгә багышланды. Шул китап буенча фикер алышуда тәнкыйтьчеләрдән Гази Кашшаф, Хәсән Хәйри, Рафаэль Мостафин, язучылардан Нәкый Исәнбәт, Хәсән Туфан һ. б. иптәшләр катнашты.

## ЯШЬ ШАГЫЙРЬЛӘР ФЕСТИВАЛЕ

Әрмәнстанның башкаласы Ереван шәһәрендә яшь шагыйрьләрнең 5 нче Бөтенсоюз фестивале үткәрелде. Узган елның октябренда СССРның 50 еллык юбилеена багышлап уздырылган бу фестивальне ВЛКСМның Үзәк Комитеты һәм СССР язучылар союзы оештырган иде. Фестивальдә безнең республикабыздан яшь шагыйрь Роберт Миңнуллин да катнашты һәм аның шигырьләре дә тикшерүгә куелды. Семинар җитәкчеләре Михаил Львов һәм Валентин Сорокин Роберт әсәрләренә уңай бәя бирделәр.

## ТАМАШАЧЫЛАРГА ОШАДЫ

Мәскәүнең Лихачев исемендәге автозавод культура сарае каршындагы театр коллективы өлкән драматургыбыз Риза Ишморатның «Давылга табан» исемле пьесасын сәхнәгә куйды. Театрның баш режиссеры С. Л. Шейн җитәкчелегендә әзерләнгән ул спектакль, завод эшчеләре соравы буенча, культура сарае сәхнәсендә берничә көн рәттән күрсәтелде.

## ЛАЕКЛЫ БҮЛӘК

Республикабызның музыка сәнгате өлкәсендә актив һәм нәтиҗәле эше өчен һәм тууына 60 яшь тулу уңае белән, ТАССР Министрлар Советының телевидение һәм радиотапшырулар комитеты концертмейстеры Екатерина Александровна Соколова КПСС өлкә комитетының һәм Татарстан АССР Министрлар Советының **Почет грамотасы** белән бүләкләнде.

## ҮЗЕШЧӘН КОМПОЗИТОРЛАР СЕМИНАРЫ

Ноябрь ае ахырында Казанның Галимҗан йортында һәвәскәр композиторлар семинары үткәрелде. Республикабызның хор җәмгыяте һәм Халык иҗаты йорты тарафыннан оештырылган ул семинарда яшь композиторлардан Хәмит Булатов, Зөфәр Сәгыйтов, Габидулла Мәҗитов, Сөембикә Вәлиева, Сания Әхмәтова, Рәйсә Латифуллина, Алик Макаров әсәрләре тикшерелде. Республикабызның күренекле композиторлары Аллаһияр Вәлиуллин, Мирсәет Яруллин, Бату Мулюков һәм шагыйрь Мөхәммәт Садри ул иптәшләрнең әсәрләренә һәрьяклап анализ ясадылар.

## КҮРГӘЗМӘ УҢЫШЛЫ ҮТТЕ

Узган елда РСФСР художниклар союзы һәм Совет Армиясенең Үзәк йорты тарафыннан РСФСР художникларының Совет Армиясе тормышын чагылдыруга багышланган әсәрләреннән төзелгән күчмә күргәзмә оештырылган иде. Саратов һәм Ульяновск шәһәрләрендә булганнан соң октябрь аенда ул күргәзмә Казанга китерелде һәм Офицерлар йортына тамашага куелды. Нигездә Бөек Ватан сугышында катнашкан художниклар әсәрләреннән гыйбарәт булып, барлыгы иллегә якын экспонатны эченә алган ул күргәзмәдә Совет Армиясе узган данлы юл һәм аның бүгенге тормышы бик ачык чагылдырылган иде. Н. Никоновның «Сталинград. Кул сугышы», Н. Народицкийның «Безнекеләр Можайскига юнәлде», А. Костюченконың «Рейхстаг. Җиңү», В. Щербаковның «Күкне саклыйлар» исемле картиналары тамашачыларның игътибар үзәгендә булды.

## ЭСТРАДА АНСАМБЛЕ

Журналыбызның узган елгы саннарының берсендә Түбән Кама шәһәрендәге нефтехимкомбинатның ВЛКСМ комитеты һәм яшь белгечләр советы каршында татар яшьләреннән «Нур» эстрада ансамбле оештырылганлыгы һәм аның концертлар бирә башлавы хәбәр ителгән иде. Яшь инженер Сәгыйт Закиров җитәкчелегендәге бу ансамбльне хәзер Түбән Камада гына түгел, тирә-як авылларда һәм Чаллыда да яхшы беләләр. Ансамбль коллективы Кама автозаводын төзүчеләр һәм Түбән Кама районының совхоз һәм колхоз хезмәт ияләре алдында әледән-әле чыгыш ясап тора. «Нур» эстрада ансамбле тамашачылар тарафыннан ихтирам казанды.

## СҮЗ ОСТАЛАРЫ КОНКУРСЫ

Әлмәт драма театрының художество советы нәфис сүз осталары өчен конкурс игълан иткән иде. Артистларның нәфис сүз осталыгын үстерүне күздә тотып оештырылган ул конкурста шактый күп кеше катнашты. Конкурска әзерләнгән материаллар тематик яктан да, жанрлары буенча да бай һәм төрле иде. Сәхнәдә, рус классиклары әсәрләре белән беррәттән, татар әдипләренең әсәрләре дә яңгырады. Конкурста катнашучы сүз осталары репертуарларында Әлмәттә яшәүче шагыйрьләрдән Равил Фәйзуллин, Саҗидә Сөләйманова, Гамил Афзал һәм Әдип Маликов әсәрләре дә шактый зур чагылыш тапты.

Конкурста ТАССРның атказанган артисты Т. Кичүбаев җиңеп чыкты. Икенче урынны Т. Алишев, өченче урынны Ә. Садыйкова яулап алдылар.



КИЛӘЧӘККӘ ХАТЛАР



ЯКТЫ КИЛӘЧӘККӘ
ӨМЕТ БЕЛӘН ▲

ДОШМАН ТЫЛЫНДА ▼



Бу рәсемнәрне художник Мансур Рәхимов ясады.

Күп еллар инде Мансурны татар совет язучыларының тормышына караган тема кызыксындыра.

Аның Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Һади Такташ һ. б. язучыларга багышланган рәсемнәре өлкә газеталарында да басылдылар.



◀ ХӘРБИ КОМИССАРИАТКА

▼ ҮЛЕМ ТУРЫНДА УЙЛАМА



▼ ВАТАН ӨЧЕН (ГАЗИНУР)



Художник фронтовик язучыларның портретларын ясатып һәм бирелеп эшли. Үзе дә Бөек Ватан сугышында катнашкан кеше буларак, ул фронт тормышын яхшы тоя, язучыларны ут сызыгында, хәрәкәттә бирергә тырыша. Үзенең рәсемнәрендә Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Гадел Кутуйларны зур мәхәббәт белән сурәтли.

Художник Э. СИТДИКОВ.

«ЭНҖЕ ЭЗЛӘҮЧЕЛӘР»

Журналыбызның дүртенче санында басылачак бу хикәяне Миргазиян Юныс язды.

Диңгез сәүдә корабында хезмәт иткән чагында Миргазиянга күп илләрдә булырга, күп халыкларның тормышын, аларның гореф-гадәтләрен күзәтеп, өйрәнеп йөрергә туры килә.

«Энҗе эзләүчеләр» хикәясе Кызыл диңгез яр буйларында яшәгән ярлы гарәпләрнең — тирән диңгез төбенә чумып энҗе эзләүчеләрнең тормышын, аларның авыр һәм куркыныч көсепләрен сурәтли.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210